# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рәниф ШӘРИПОВ. Тормыштан да олы бернәрсә юк... *Шигырьләр.* ....3
Фирдүс ГЫЙМАЛТДИНОВ. Буа. *Роман.* ....8
Ренат ХАРИС. Татар кычытканы. *Поэма.* ....76
Рөстәм ГАЛИУЛЛИН. Хикәяләр. ....86
Ибраһим БИЕКТАУЛЫ. Кан сагышы. *Шигырьләр.* ....106
Ләйсән ФӘТХИ. Ут капканда чыгып йөрәгеңнән... *Шигырьләр.* ....122

«МӘЙДАН – БАТЫРЛАР ӨЧЕН!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ. Беренче Сабантуй. *Хикәя.* ....109

*Юбилейга барышлый:* фотоархив. ....126

*«Казан утлары»ның 100 еллыгын каршылап:* Алмаз ХӘМЗИН. Синдә тудым... ....128

*«Казан утлары» – минем язмышымда:* Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Сүз сәнгате маягы. ....130

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Яшьлеккә гашыйк әдип *(Рәфкать Кәрамигә – 65 яшь).* ....133
Равил РАХМАНИ. Замана шагыйре. *(Рафис Корбанга – 65 яшь).* ....140
Алсу ШӘМСУТОВА. Йөрәге – тоташ сөюдән, күңеле җырдан тора. *(Галимҗан Гыйльманга – 65 яшь).* ....149

ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН

Зөфәр МӨХӘММӘТШИН. Рәссамның шигъри иҗаты. ....157
Бакый УРМАНЧЕ шигырьләре. ....159

*Кардәш халыклар әдәбияты:* Баһаветдин АДЖИЕВ. Йөрәк таныла тибеше белән… *Дүртьюллыклар. Кумык теленнән Рафис КОРБАН тәрҗемәләре.* ....171

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ – ТӘРҖЕМӘДӘ

Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА. Мажара тәрҗемәсе яки тәрҗемә мажаралары. ....174

*Китап күзәтү:* Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА. Фәнни сүзем – саф тылсымым... ....178

*Укучыларыбыз иҗаты:* Марсель ШӘРӘПОВ. *Шигырьләр.* ....181

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕ КАБУЛ ИТЕЛҮГӘ 1100 ЕЛ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. 922 елда Багдад хәлифе әл-Мөктәдирдән килгән илчелек. ....182

*Газиз тавышлар:* Милләт гаме аны шагыйрь иткән. *(Әхмәт Гаделнең тууына – 80 ел).* ....188
Без яратмый, җирдә кем яратсын?! (*Кадыйр Сибгатуллинның туауына – 80 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....189

«Казан утлары» архивыннан. ....127
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 2 (1192) 2022*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан, Рамил Ханнанов.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.


---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.01.2022, график буенча 31.01.2022, басылып чыгу вакыты 03.02.2022.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-0294. Тираж 8573.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2022 ел



Рәниф
Шәрипов

# ТОРМЫШТАН ДА ОЛЫ БЕРНӘРСӘ ЮК...

## Кыя

Сынды тотка. Ауды терәк.
Дүрт кыйбламы дүрт ягым?
Арлы-бирле, бәрелеп-сугылып,
Зиһнем чуалган чагым.
Батам-калкам... Як-ягымда
Шаулы, болганчык агым.
Шул агымда сүз әйталмый,
Исемем югалган чагым.
Җисемем кыя. Зиһенем җыям.
Калды соңгы бер адым –
Шул кыяга исемем уеп,
Җисемем уалган чагым...

## Шундый дөнья

Яшь киленгә әйтте бер карт әби:
«Мин һәрвакыт мондый булмадым...»
Әйтте килен гамьле сүзе белән:
«Мин дә мәңге матур булмамын...»
Аянычы байтак бу дөньяның,
Кемдер йөри аннан тик көлеп.
Әйтерсең, ул бар дөньяга хуҗа,
Яшьлек матурлыгы мәңгелек.
Бер мизгелдә җимерелә кайчак
Гамьсез, имин хыял дөньясы.
Агып китә тик ишелеп килми,
Бөртекләп бит аны җыясы.

---

Рәниф ШӘРИПОВ (1950) – *шагыйрь; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, С.Сөләйманова, Һ.Такташ һәм Г.Исхакый исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Мәңгелек сер», «Азатлык көне», «Җомга» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Җыелыр ул, тагын җыелыр ул,
Вакыт бит ул көн дә агыла.
Өстән генә күлеп карамасаң,
Батып аккан җаннар ягына.
Мин дә җыйдым. Имин тормыш кордым.
Ник исемә төшә соң һаман:
«Мин һәрвакыт ямьсез түгел идем...»
«Мин дә картаермын берзаман...»

***

Көннең була шундый мизгелләре –
Томан кебек серле яктылык
Төшкә керә. Тормыш катып кала,
Бөгелә дә төшә яссылык.
Галәмнәрне айкый минем зиһен.
Раббым куйган чикләр эченең
Башы-ахыры юк. Ә калганы
Төшенә дә керми кешенең.
Хыялдагы камил дөнья анда,
Эреп аккан Вакыт диңгезе,
Тормыштан да олы бернәрсә юк,
Ә Мәхәббәт – аның нигезе.

***

Син көньяк дип йөргән тараф
Кемнеңдер бит төньягы.
Ике яклы, җиде катлы –
Ач күзеңне – дөнья бу.
Кем туздыра безнең газиз,
Туган үскән ояны?
Ачык авызыңны яп та,
Ач күзеңне, дөнья бу.
Иман белән бозык нәфес
Җан түренә сыямы?
Чабаталы түрәләр юк,
Ач күзеңне, дөнья бу.
Тешләп-тешләп телгәләнгән
Телеңне кем тыямы?

Без җайлаган, без майлаган,
Без сайлаган дөнья бу!
Сайланганнар су эчкәндә,
Сайлаганнар боз ялый.
Кемдер сайладым дип уйлый,
Шундый кызык дөнья бу.
Күпме фәрештә канатын
Таптый шайтан тоягы.
Дүрт ягың дүрт кыйбла түгел,
Кыйбласыз, чүп дөнья бу.
Илаһи моң, хыялый җан,
Чүп җиһанга сыямы?
Кулда каләм, алда Галәм,
Ач күзеңне, син ясаган
Серле, гүзәл дөнья бу!

## Сак булыгыз!

Сыгылам да, йомылам да карап,
Эткәләнгән көннәр ягына.
Кузгалабыз. Кемдер утырмады…
Сак булыгыз! Ишек ябыла!

Үпкәләшә, төрткәләшә белмим.
Керә белмим кеше хакына.
Чыгасылар, чыгып беттегезме?
Сак булыгыз! Ишек ябыла!

Кайтып булмас дуслык-кардәшлекнең
Яшьлектәге ихлас чагына.
Киртә ватып булыр иде, ләкин
Сак булыгыз! Ишек ябыла!

Ә шулай да, өзгәләнгән йөрәк,
Кайтыр көнен инде сагына.
Керәселәр, кереп беттегезме?
Сак булыгыз! Ишек ябыла!

Борылам да карыйм, елап яткан,
Язылмаган сүзләр ягына.
Фәкыйрь, мескен кавем… Бетә хәлем…
Сау булыгыз... Ишек ябыла…

Генераллар килә каты куллы,
Имин тормыш, тәртип сагына.
Иңбашына йолдыз кунган саен,
Кем өчендер ишек ябыла...

***

Типкәләнгән торып басар беркөн,
Сыйпалганга берни кирәкми.
Бөркет түгел, затсыз үләт кошы
Кайчак чукып китә йөрәкне.
Минем тормыш тулган савыт кебек.
Утырмадым. Әләк язмадым.
Мин чайкалам һаман уртасында
Сыгылмалы такта басманың.
Ялган белән чынны күрә белеп,
Тапталмаган юлга авышып,
Мәдхияләр җырлый белмәгәннең
Ишетелми кала тавышы.
Ишет, Раббым, безнең доганы да,
Бу дөньяны кирәк җайларга,
Түрәләргә иман, вөҗдан кайтар,
Хак, туры юл күрсәт байларга!

## Татар язмышы

*Яшьтәш туганым гомере буена*
*Чиләбе өлкәсендә шахтада эшләде.*
*Шалтыраткан саен сагынам дип елый*

Туган якка кебек күпме болыт
Зәңгәр күкне иңләп агыла.
Юк бәхетен эзләп,
Баш күтәрми эшләп,
Туган ягын татар сагына.
Язмышларны уйган,
Җанны кыйган,
Төзәтмәслек артта хаталар.

Дөнья айкап йөргән
Кайбер исәр башлар
Туган җиргә кайтып яталар.
Кайтып яту – соңгы, сирәк бәхет.
Узды татар авыр юлларны.
Чит җирләрнең еллар чоңгылына,
Елый-елый кереп югалды…
Йомыла да куя вакыт күзе,

Гомер түгел, Галәм өзелә.
Кара чоңгыл йота, дөнья бетә,
Үзе дә юк була, эзе дә.

Җан иясе дөнья буйлап килә,
Киек Казлар сызган Юл аша.
Җан кыела – юкка чыга галәм,
Дөнья елый, кемдер еласа.

## Шушы мизгел

Шушы мизгел, шушы көннәр яктысына
Күзләремнең сүлпән нуры бакты сыман.
Уза көннәр, гомер инде узып бара.
Бер борылып кара – артта күпме ара.
Кабаланмый, хафаланмый, тыныч кына,
Бертуктаусыз, көн артыннан көн ычкына.
Күпме соң ул тамчы-тамчы бер уч гомер?
Моны уйла, тегендә бар, шунда йөгер...
Туктадым да карап торам әле менә,
Кемнең дә үз мәшәкате-гаме генә.
Аз күрмәдем бу тынгысыз дөнья гамен,
Хәзер күреп калсам иде бераз ямен.
Купшылана машиналар, үсә йортлар,
Ерагая тик аралар. Күңелләр тар.
Күптән килгән дуслыкның да бетә яме,
Хәтта ипи-суларның да бетә тәме.
Яшь гомерләр бер кадерсез уза икән.
Йөрәк күпкә түзә, ләкин туза икән.
Сизми дә калырсың, барысы да үтә,
Барысы да бетә... Барысы да бетә...
Шушы мизгел, шушы көннәр яктысына,
Уйларымның салмак моңы ятты сыман.

## Әйтелмичә калган сүз

Кайчакларда шулай була икән –
Әкрен генә поезд кузгала,
Ерагая ара, бер-береңә
Әйтеп өлгермәгән сүз кала.
Мин сизендем, ләкин аңламадым,
«Түз, сикермә, – дидем, – йөрәк, түз!»
Бәргәләнде вокзал почмагында
Син әйтәсе миңа кирәк сүз.
Син аңладың – поезд кире килмәс…
Йөрәгемне уйды карашың.
Нигә шулай авыр икән үтү
Күңел белән күңел арасын?
Инде тормыш поезд кебек чаба,
Ә бит ничек әкрен кузгалды.
Бик үкенеч: гомер почмагында
Әйтелергә тиеш сүз калды.
Мин вокзалда. Борылам да карыйм,
Пышылдаган аваз колакта.
Өзгәләнгән, телгәләнгән бер сүз
Елап карый миңа ерактан.

***

Шигъри күңел шундый була инде,
Хыяллана юкны бар итеп.
Кемдер кул болгый дип, мин сөенәм,
Ул тәрәзә юа бары тик.

Якты көндә, җылы язлар җиткәч,
Кемдер тәрәзәсен юганда,
Мин кемгәдер кирәк, ахры, диеп,
Туктап калам кайчак урамда.

Пыялада тап юк. Ә сылу кыз
Карый миңа, көлә аптырап.
Тәрәзәңне юсаң, җанга рәхәт,
Яшәү ямьле, дөнья яктырак.

Лепелдәмә йөрәк, без ялгыштык,
Ул тәрәзә юа, бары тик.
Нишләтәсең, тормыш бит ул үзе
Хыяллану юкны бар итеп...

## Без ишектә торабыз

Без төрлебез төрле заманнан бит,
Ерагая һаман арабыз.
Барысын да күрдек, барысын да үттек,
Без ишектән чыгып барабыз.
Күпне белгән кебек өстән генә көлеп,
Аңламыйча карап торасыз.
Шырпы гына сызып, янып-пешеп, кызып,
Учак дөрләп китми чырасыз.
Барысын да тышка чыгармыйбыз,
Күзгә күренмидер ярабыз.
Әле хушлашмыйча, бер дә зарланмыйча,
Без ишектән чыгып барабыз.
Теләмәдек түгел, ләкин сөйләмәдек,
Без ишектә басып торабыз.
Дөнья бозык бүген, сезгә кызык түгел,
Беләсегез килсә сорагыз.
Ишек ачык инде, бер җылыда,
Бер салкында басып торабыз.
Шырпысы да сына, очкыны да сүнә,
Тик кабынмый бүген чырабыз.
Беләсегез килсә, күңел күзе белән
Китапларны ачып карагыз.
Барысын да белеп, өстән генә көлеп,
Без ишектән чыгып барабыз.

Фирдүс
Гыймалтдинов

# БУА

РОМАН

Нәсимә, чәйгә эретергә кар алып керергә дип, бишмәтен элеп, урамга чыкты. Авыр ишек гыйнвар суыкларыннан бәсләнеп каткан, аны ачып җибәрер өчен шактый азапланырга туры килде. Ул өйләре янәшәсендәге көрттән чистарак урын чамалап алды да шуннан чиләген тутырды. Аннан өйгә юнәлде. Ул кергәндә, Зөбәйдә дә уянган, мичтә ут элдереп маташа иде.

– Бүген кичәгедән дә суыграк, кызым, – диде ул, шәлен сәкегә салып. – Бияләйләрне ике кат киясе булыр.

– Тагын тегермәнгәме, әни?

– Кышка тегермәнгә, диделәр.

Нәсимә мич алдындагы самоварга кар тутырып, чыра белән тергезеп тә җибәрде.

Алар хәзер авыл читендә яшиләр. Каралты-куралар белән әйләндереп алынган алты почмаклы зур өй бүтән аларныкы түгел. Моннан ике ел элек күченгән амбарларына тәмам нур керде дияргә була. Уртада мич, ике сәке, сандык, өстәл, ике эскәмия, стенада агач рамда бер чите чатнаган көзге – өйнең хәзерге җиһазлары шуннан гыйбарәт иде. Баштарак Таһир бик дуласа да, аннан соң тынычланды, кечкенә генә каралты да төзеп куярга ризалык бирде, биш тавык белән бер кәҗәне Нәсимәләргә калдырды. Хәер, Зөбәйдә моның нигезендә мәкер ятуын аңлый. Шулай вак-төяк белән юмалап, кызны үзенеке итмәкче була Таһир. Очрашкан вакытта сүзе һаман шул хакта. Тик Зөбәйдә бирешми, Вакыйф белән сирәк кенә очрашып, аңа тугрылыгын саклый, Таһирның үзенә бәйләнүдән туктавын көтә.

Нәсимәләрне куып чыгарсалар да, мәсхәрәләмәделәр, авылдашлар күченергә ярдәм итте, типкәләүче булмады диярлек. Әйберләрен ат арбасына төяп, урам буйлап үткәндә, аларны күргән кешеләр оялып, карашларын читкә юнәлтәләр иде. Оятлары бер генә нәрсәдән – үзләре өчен шактый игелек эшләгән муллаларын саклап кала алмадылар бит. Нәсимә бик нык рәнҗеде моның өчен. Халык Хәмидулланы котырган этләргә бирергә тиеш түгел иде! Вакыт узу белән генә тынычланды ул. Саклап калырлык булмаган шул Хәмидулланы... Күрше авыллардан дин әһелләрен гаиләләре белән сөрә башладылар, хәллерәк байларның

*Дәвамы. Башы узган санда.*

сөргенлеккә дә барып җитмәс борын, Зөядәге төрмәдә үк атып үтерелүе турындагы хәбәрләр килеп иреште. Ахыр чиктә язмышына буйсынып, Нәсимә Хәмидулланың исән булуына шатланып, гомер итә бирде.

Сафа байның тегермәне хәзер колхозга хезмәт итә иде – Нәсимә белән Зөйбәйдә бирегә хезмәтче булып килеп төште. Берничә потлы капчыкларны ташыйлар, ни кушсалар, шуны эшлиләр. Авыр эш үзен сиздерми калмады – кайчандыр төз гәүдәле Нәсимә чак кына бөкрәеп йөри башлады. Ләкин биле бөгелсә дә, күңеле сынмады.

Аларның өен нишләтергә белми аптырап беттеләр коммунистлар. Берәүләр клуб итәргә кирәк дип кычкырды, икенчеләре авыл советы һәм колхоз конторасына бирүне яклап чыкты. Контора дип кычкыручыларны Таһир котырткан иде. Рәис буларак, бигрәк тә тырышты инде шул йортка кереп утырырга. Ләкин, ахыр чиктә, контора өчен артык зур булыр дип, мулла йортын клуб итәргә карар кылдылар. Бүрәнәсен бүрәнәгә сүтеп авыл уртасындагы мәйданга алып килеп җыйдылар, түбәсенә кызыл флаг кададылар. Хәзер анда төрле җыелышлар уза, концерт-мазар да булгалый, диләр, бер почмагында «изба-читальня» дигән нәрсә оештырганнар.

Мулланың нигезен тулысынча туздырдылар. Каралты-куралар да сүтелеп, колхозга тапшырылды. Бөтен маллар көтүе белән яңа хакимнәр кулына күчте.

Әгәр тегермәндә эш булмаса, аларны нәрәт белән башка төрле эшләргә дә җибәрә башладылар. Яңа оешкан колхозның малы күп бит – терлеген дә кара, басуын да эшкәрт, кышын кар ерып, печәнен дә кайтарт. Әле клубны, авыл советын, колхозның башка биналарын җылытып тору өчен утынын да табасы бар.

Таһир кулы тимәгән бер генә бина калды авылда – ул да булса мәчет. Әлегә аның ишегендә зур йозак эленеп тора иде...

Нәсимә белән Зөбәйдә урамга чыгып, таныш сукмак буйлап, тегермәнгә таба атладылар. Тегермәндә аларны авылдашлары Харис абзый, Фатыйма, Хәйбулла каршылады. Төшкә кадәр баш күтәрми эшләделәр – уннан артык капчык бодай тартасы бар иде. Төш вакытына тегермән янына җигүле ат килеп туктады. Чанада малахай бүрек, җылы сарык туны кигән Гыйльметдин күренде.

– Әй, кемнәр бар монда, әйдәгез тизрәк! – дип кычкырды ул, күрәсең, каты чабулаудан ярсыган атын чанадан төшми генә тынычландырырга маташып. Гыйльметдиннең тавышы калтыранулы, үзенә-үзе охшамаган иде бүген.

– Гыйльми, ни булды тагын? Нәрсә тавыш чыгарасың? – дип, чанага таба атлады Хәйбулла.

– Булмады, әмма булачак. Утырыгыз барыгыз да чанага, хәзер үк җыелышка килергә куштылар.

– Ниткән җыелыш тагын?!

– Утырыгыз, дим, колхозчылардан берсе дә калмаска тиеш! Юлда сөйләрмен.

Аптыраган кыяфәт белән Хәйбулла тегермәндәгеләрне тиз генә оештырып чыкты, барысы бергә чанага чумдылар һәм Гыйльметдин атын авылга таба борды. Тегермән тау башындарак урнашканга, биредән үк авыл үзәгенә шактый халык җыелганлыгы абайлана иде.

– Ни булды соң, Гыйльми?

– Мәчет манарасын кисәбез, диләр...

Нәсимәнең йөрәгенә пычак кадалгандай булды. Тыелырга кирәклеген белсә дә, түзә алмый елап җибәрде. Чанадагылар тынсыз калдылар. Хәйбулла гына бераз сүзсез баргач:

– Алай икән... – дип, әллә нинди бер мәгънә белән әйтеп куйды.

Алар авылга җиткәндә, үзәктәге мәйдан халык шаулавыннан гөж килә иде инде. Клуб ишекләре шар ачык. Ишек төбендә, клубтан ерак түгел урнашкан мәчет тирәсендә таныш булмаган кешеләр абайлана. Өсләрендә күн куртка, билләрендә пистолет кобуралары шәйләнә. Клуб артындарак унлап атлы коралллы кеше дә күренә. Бүгенге тамашага ныклап әзерләнүләре бер караштан аңлашыла.

Нәсимә, Зөбәйдәне култыгыннан алып, менә-менә егылам дигәндәй, аякларына сак кына баса-баса, халык арасына узды. Аларны күреп, кешеләр, ихтыярсыздан, ниндидер үзгә бер көч килүен сизгән төсле, юл бирәләр иде. Нәсимәгә бу мизгелдә күз салу куркыныч иде. Әйтерсең, ул шашар хәлгә җиткән. Әйтерсең, хәзер шушы коралллы кешеләр өстенә ташланыр да, барысын да тар-мар итеп атар. Әйтерсең, ул авыл мәчетен коткарып калыр... Ләкин Нәсимәнең таштай катып калган йөзе үзгәрмәде. Яннарына Вакыйф йөгереп килгәнен дә күрмәде, исәнләшкәнен дә ишетмәде, җавап та бирмәде. Халык ташкынының иң беренче рәтендә, ул, кайчандыр үз йортлары булган клуб ишегенә текәлеп, дәшми-тынмый басып тора бирде.

– Зөбәйдә, әниең авырмыйдыр бит? – дип пышылдады Вакыйф.

– Борчылма, Вакыйф. Йөрәгенә авыр, үтәр. – Зөбәйдә мышкылдап куйды. Вакыйф исә, кеше-кара күрмәслек итеп, кулын бишмәт аша тыгып, Зөбәйдәнең кулын кысып тотты.

Ниһаять, клуб ишегеннән Таһир күренде. Көннең чатнама суык булуына да карамастан, ул өстенә юка күн куртка гына кигән, яланбаш. Хәер, инде кып-кызыл борыны, ялтырап торган күзләренә карагач, клуб эчендә «җылынып» алырга өлгергәнлеге сизелә. Таһир белән бергә урамга озын күн плащтан тагын өч кеше, ике милиционер чыкты.

Клуб халык җыелган мәйданнан өстәрәк торганга, Таһирлар басып торган урын үзенә күрә трибунага әйләнде. Колхоз рәисе җыелган халыкны күз карашы белән айкап чыкты, Зөбәйдә янында торган Вакыйфны күргәч, бер мәл аңа текәлеп карап торды. Аннан кулындагы кәгазьне чак кына йомарлап, өскә күтәреп, сүз башлады:

– Иптәшләр! Колхозчылар! Кыска вакыт эчендә данлыклы юлбашчыбыз иптәш Сталин совет халкының тормышын яхшырту өчен зур эш башкарды. Быелгы язгы чәчүгә безнең басуларга өр-яңа трактор чыгачак. Моңарчы сез кул белән иза чигеп эшләгән эшне иптәш Сталинның тимер атлары башкарачак. Җәйгә безгә комбайн да кайтыр дип торабыз – анысын сез әле ишетеп кенә беләсез, күргәч, үзегез дә шаккатарсыз. Тормышыбызның ничек үзгәргәнлеген, җайланганлыгын сез үзегез тоясыз, иптәшләр! Ләкин кешеләрне бутап, бөек Ленин-Сталин юлыннан адаштырырга теләүчеләр байтак әле. Әле дә булса сезне законнар белән түгел, Алла белән, мулла белән куркытучылар бар. Ләкин бөек Сталин Конституциясеннән дә югарырак, дөрерсәк, гаделрәк китап бүген дөньяда юк. Без инде, элеккеге мулланың

чынлыкта җинаятьче булганлыгын, совет властена каршы җәнҗал куптарырга маташканлыгын яхшы беләбез. Совет иленең, данлыклы Сталинның гадел законнары ярдәмендә ул хәзер бездән еракта, безгә аның зыяны тимәячәк. – Таһир усал күзләре белән Зөбәйдәне бораулап алды. – Мәчеткә мин йозак салдым һәм дөрес эшләдем дип уйлыйм. Ул – хәерчеләрдән таланган мал хисабына, кешене алдап төзелгән бина. Һәм аның чынлап торып совет халкына хезмәт итәр вакыты җитте. Шушы көннәрдә миңа бер төркем иптәшләр мөрәҗәгать итте. Алар фикеренчә, мәчет бинасын халыкка кайтарырга кирәк. Шушы максаттан мин сезне авыл советы җыелышына җыйдым. Бүген без мәчетнең манарасын кисәчәкбез. – Халык өстеннән, диңгездәге дулкын сыман, «Аһ!» иткән тавыш таралды. Ләкин Таһир дәвам итте: – Әлеге иптәшләрнең тәкъдиме бөтен халык фикере белән килешеп башкарылырга тиеш. Димәк, иптәшләр, повесткада – мәчет манарасын кисү мәсьәләсе. Мин ачык тавыш бирүгә куям. Кем сәвит власте яклы?!

Мәйданда тынлык урнашты. Ерактарак торган атлы милиционерлар, мылтыкларын күтәрә төшеп, халык диңгезе ягына кузгалды, клуб ишеге төбендәгеләр кобурадан наганнарын чыгарды. Авыл мәйданындагы кешеләр акрынлап аңга килеп, җан кергәндәй, сүлпән генә кулларын күтәрә башлады. Кемнәрнеңдер сулкылдавы ишетелде. Мәчет манарасына пыяладай күзләре белән текәлгән Нәсимә, әллә нинди акрынлык, салмаклык белән башкаларга кушылып, кулын күтәрде, аңа Зөбәйдә дә иярде. Барыннан да бигрәк бу мизгелдә Зөбәйдә әнисенең акылдан шашуыннан курка иде.

Таһир каршындагы халыкны күзәтеп чыкты. Үзенә текәлгән күзләрдә ул нәфрәттән ары башка хис күрмәде. Ләкин аңа елмаерга, җиңүче кыяфәте чыгарырга кирәк! Аяк буыннары калтырана, тамак төбе кибә, елмаюы менә-менә каядыр качмакчы була, ләкин түзәргә кирәк! Менә – бөтен авыл, бөтен халык аны дошман күрә, хәлләреннән килсә, бәреп үтереп, таптап китәрләр иде дә бит, Таһир – хакимият кешесе. Аңа тия алмаячаклар. Чөнки аны власть саклый, кораллы кешеләр яклый. Калтыранган кулы белән ул билендәге наганын рәтләп куйды. Янәшәсендәге күн плащлы кешеләр, бармакларын төртә-төртә, сарык көтүен барлаган төсле, кешеләрнең кулларын санап чыктылар да, булды дип, Таһирга ымладылар.

– Төшерегез кулларыгызны! Икенче сорау – кем сәвит властена каршы?!

Мәйдан дәшмәде.

– Шулай итеп, мәчет манарасын кисү турындагы карар бер тавыштан кабул ителә. Повестка тәмам!

Атлы милиционерлар мәчеткә таба чигенде. Таһир районнан килгән кешеләр белән бергә шулай ук мәчеткә юнәлде. Аларны наганнарын кобурага да тыгырга өлгермәгән ике җәяүле милиционер озата китте.

Мәчет янына авыл халкына таныш булмаган берничә ир-ат йөгереп килде. Ирләр, килә-килешкә мәчет нигезе янында яткан, күрәсең, алдан әзерләнгән баскычларны түбәгә терәделәр һәм җәһәт кенә өскә үрмәләделәр. Түбәгә менеп кунаклагач, икесе билбаудан балталарын тартып алып, манараның агач тышлыгын әрчи башлады. Калган икесе өстән нык баулар белән урадылар. Балталы бәндәләр шарт-шорт китереп, манараны тураклый бирделәр. Тышкы як такталар инде ватылып бетте, хәзер үзәктән

үтүче калын баганаы чүкиләр. Багана озак түзә алмады. Ниндидер олы җанвар ыңгырашкан тавыш чыгарып, манара бер якка чалшаеп куйды.

– Җитәр! – дип кычкырды Таһир.

Балталы залимнар җәһәт кенә җиргә сикерделәр. Ир-атлар манарага бәйләнгән бауларга ябышты һәм үзләренә таба тартырга кереште. Тагын ыңгырашкан тавыш ишетелде, ул бөтен авылны сискәндереп куйган төсле булды. Баулар нык, залимнәрнең беләкләре көчле, мондый һөҗүмгә түзә алмыйча, гасырга якын торган манара, мәчет түбәсенең такталарын каерып, яман тавыш чыгарып, карга гөрселдәде. Манараның очына урнаштырылган ярымай, беркетелгән киштәдән аерылып, кар көртенә кереп чумды.

Әлеге тавышлардан курыкканга пошкырып, милиционерларның атлары ике аякка басты, берсе иярдән карга очып төште. Халык арасында шау-шу купты. Тыела алмыйча, кешеләр елый, кычкырыша башладылар, мәчет манарасын кисүчеләргә ләгънәтләр очты. Милиционерлар мылтыкларын әзер тотып, атларын халыкка таба атлатты. Берсе һавага атып җибәргәч, кешеләр янә тынды кебек.

– Булды, таралышыгыз, нәрәт үтәргә! – дип, явыз тавыш белән кычкырды Таһир. Ләкин халык кузгалмады. Кемдер тәкбир әйтергә кереште. Аның кыяр-кыймас кына яңгыраган тавышына акрынлап, башкалар да кушылды. Һәм бу тәкбир, әйтерсең, каргыш сүзләре булып, мәчетне ботарлаган залимнәр өстенә ява иде...

«Аллаһы әкбәр, Аллаһы әкбәр, лә Иләһү иллә-Аллаһ!!!»

Милиционерларның берсе калганнарына нидер әйтте. Ике атлы милиционер, мылтыкларын халыкка төбәп, читтәрәк калды, башкалары исә, мылтык урынына нагайкалар алып, мәйданга ыргылды. Чыр-чу, елаш, кычкырыш – авыл мәйданы мәхшәргә әйләнде. Берничә минут дигәндә, милиционерлар халыкны авылның төрле почмакларына куып таратты. Нәсимә белән Зөбәйдә, алда ук торган булсалар да, әлеге җәнҗалдан яраланмый гына котыла алды. Ләкин тән җәрәхәтенә караганда, җан яралары авыррак иде шул.

Халыкны куып тараткач, манара кисүчеләр бауларны сүттеләр. Бу кешеләрне күрше районнан махсус яллап китергәннәр иде. Аларга юлга мул итеп көмешкә, кабымлык куйдылар. Клуб эчендә исә Аллаһ йортына кул күтәргән бәндәләрне юмарт итеп корылган табын көтә иде.

Таһир калтыранган куллары белән шешәдән стаканнарга көмешкә салырга кереште. Табынның түрендә утырган адәм – район башкарма комитеты әгъзасы Савельев аңа озак кына карап торды да тынычландырырга булды:

– Каушама инде син алай, иптәш Фәтхуллин! Була торган хәл, халык сарык инде. Куып тараттык бит әнә. – Һәм ул елмаеп, милиционерларга күз кысты. Аннан, барысына да салынганлыгын күреп, стаканын тотып торып басты. Аңа башкалар да иярде. – Әйдәгез, иптәшләр, бүгенге зур эш өчен. Беренче коймак төерле була, диләр, анысы да хак. Хәзер без бу эшне ничек дөрес оештырырга кирәклеген беләбез. Халыкны төркемнәргә бүлергә кирәк. Милиционерлар да күбрәк таләп итәлә. Ә менә халыктан тавыш бирдереп тору кирәкме-юкмы икәнлеген әле киңәшләшеп хәл итәсе булыр. Тагын күпме алар – мәчетләре дә, чиркәүләре дә... Өйрәнербез,

шомарырбыз. Ә сиңа, иптәш Фәтхуллин, безгә шундый тәҗрибә үткәрергә мөмкинлек биргән өчен зур рәхмәт! Әйдәгез, иптәшләр, иптәш Сталинның исәнлеге өчен!

Беренче стаканны эчкәч тә, Таһир аз-маз тынычланды кебек. Ләкин курку хисе барыбер югалмады. Тәрәзә аша кичке эңгер-меңгердә манарасыз мәчет караеп тора. Ул бер яктан җиңелгән, җимерелгән, суга баткан кораб төсле. Икенче яктан, элек манарасы калкыган урын куркыныч бер ерткыч сыман Таһирны эләктереп алып йотар кебек тоела.

Эчә-эчә Таһир да, кунаклар да тәмам йомшады.

– Мулла турында әйткән сүзләрең ошады, Таһир, – диде Савельев, чираттагы стаканны бугазына коеп. – Жулик диденме әле?

– Террорчы дидем кебек...

– Ә юк, җинаятьче дидең. Без аның җинаятьче икәнлеген ачыкладык бит, исеңдәме?

– Исемдә, исемдә булмый ни, иптәш Савельев.

– Ә шулай да, Таһир, әйт әле. Ник син ул чакта мулланың гаиләсен дә этап белән җибәртмәдең? Алар да контрреволюцион элементлар бит!

– Алар минем күзәтүдә, иптәш Савельев. Бурычлары бар аларның миңа.

– Нинди бурыч?

Таһир эчүдән кызарып чыккан күзләрен район вәкиленә төбәде.

– Кызы. Минем аның кызына өйләнәсем бар.

– Коммунист башың белән контра кызына өйләнергә йөрисеңме?!

Бүлмәдә тынлык урнашты, аннан Савельев пырхылдап көлеп җибәрде һәм янә стаканнарны тутырды.

– Туйларда йөриселәр бар икән әле, иптәшләр! Яшьләр өчен!

...Эчә-эчә алҗып, районнан килгәннәрнең кайтырга вакыт икәнлеген аңлап, урамга чыкканда, тирә-якны инде караңгылык баскан иде.

– Иптәш Фәтхуллин, мәчетнең аен мин үзем белән алып китәм. Аның язмышын райком хәл итәргә тиеш, – диде Савельев, күн плащы өстеннән киелгән толыбын төймәләп.

Алар барысы да манара янына атладылар.

– Манара мәтәлгәч тә, аның башындагы ай сынып төште, – диде милиционерларның өлкәне.

Манара очы янына килделәр, ярымай күренмәде. Фонарьлар яктыртып кар көртләрен капшап чыктылар, берни табылмады. Ярты сәгать чамасы бер урында таптанганнан соң исерек төркем өчен барысы да аңлашылды – алар мактаныша-мактаныша салып утырган арада кемдер айны алып китергә өлгергән. Савельев, Таһирга барысын да кичекмәстән ачыкларга кушып, инструкцияләр артыннан районга ашыкты. Милиционерлар аны озата киттеләр. Таһир икесен булса да янында калдыруны сораса да, Савельев тыңламады.

Елашып, чәй эчеп кенә табыннан торганнар иде, Нәсимәләрнең тәрәзәләрен кактылар. Йөрәге дерт итеп, Нәсимә урамга карады, аннан ишекне ачты:

– Кем йөрер бу вакытта?

– Мин бу, Нәсимә апа. – Бусагада Вакыйф пәйда булды.

Вакыйфны күргәч, Нәсимә янә еларга кереште, аны кочаклап ук алды.

Бераз тынычлангач, өйгә уздылар, Зөбәйдә тиз генә чәй яңартырга кереште. Сүзләрендә бары тик бүгенге көннең тетрәндергеч вакыйгалары иде.

– Халыкны милиционерлар куып тараткач, мин кире мәчет янына килдем, – диде Вакыйф, кинәт пышылдауга күчеп. – Клуб тәрәзәсеннән карыйм – барысы да табында салып утыралар. Милиционерлар да шунда, түрәләре дә. Урамда ник бер кеше булсын. Мин алар күрмәгән арада мәчет манарасы ауган урынга барып, кар астыннан ярымайны казып чыгардым.

Нәсимә белән Зөбәйдә, телсез калып, ни булыр дип, Вакыйфка текәлделәр.

– Ерак китеп булмады, тегеләр чыктылар, мин мәчет артына качып өлгердем. Алар озак кына айны эзләп тә тапмагач, яман ачулары купты, мөгаен, авылда тентүләр көтеләдер. Районнан килгән кеше урысча Таһирга шулайрак әйтте шикелле. Мин качып китеп, мәчет аен куш имән эченә яхшылап яшереп калдырдым.

Нәсимә шунда ук, учларын күтәреп, дога укырга кереште. Яшьләр дә аңа кушылдылар. Ләкин багышлап бетерергә өлгермәделәр – урамда башта айгыр кешнәве ишетелде, аннан кемдер дөмбердәтеп, ишеккә китереп типте.

– Таһир! – дип бер тавыштан кычкырып җибәрделәр ана белән кыз. – Вакыйф, кач, зинһар, көндез үк исерек иде, йортыбызда канкоешка китерә күрмә, – дип, Нәсимә Вакыйфны тиз генә мич артына кертеп җибәрде. Бусагада, чыннан да, исерек Таһир күренде.

– Ә, чәй эчәсезмени? – диде ул, итекләрен салмый-нитми түргә узып. Бүреген һәм бияләйләрен сандык өстенә ташлады. Кичке якта аеруча салкын булганга, күн куртка киеп кыланып йөреп булмый, Таһир өстендә инде сарык тиресеннән тегелгән тун. Ул аның төймәләрен генә ычкындырды да агач урындыкка барып утырды. – Чәй, димәк?!

– Таһир, ни кирәк сиңа бездән? – дип сорады йөзе агарынган Нәсимә.

– Ниең бар соң, контра хатыны? Ә, бар икән! – Һәм Таһир бармагы белән Зөбәйдәгә төртеп күрсәтте. – Кызыңны бирәсеңме?

Нәсимә дәшмәде.

– Безнең Зөбәйдә бүген клуб каршында, халык алдында оялмый-нитми Вакыйф белән кочаклашып тора иде. Вакыйфка мәхәббәтең төштемени, иптәш Зөбәйдә?! – Һәм Таһир усал итеп шаркылдап көлеп җибәрде, аннан кинәт җитдиләнде. – Ярар, яхшы. Сез менә нәрсәне истә калдырыгыз. Мин булмасам, син дә – Нәсимә апа, син дә – Вакыйф себеркесе, монда утырмаган булыр идегез. Контра әтиегез белән Себердә череп ятар идегез. Мин коткардым сезне, беләсезме сез, юкмы?

– Без бу хакта синнән сорамадык, – диде Нәсимә тыныч тавыш белән. Бу тавыш Таһирны тәмам чыгырыннан чыгарды.

– Яп авызыңны, контра! Ирең Себердә чери, чират синдә, белдеңме? Кызыңны да ияртеп җибәртәм! Вакыйф белән песиләнеп йөрүең хәерлегә түгел, Зөбәйдә. Син аны үз кулларың белән юк иттең дип саный аласың. Бүген авыл җыенында нәкъ менә Вакыйф тәкбир әйтеп, халыкны сәвит властена каршы котыртты. Нәкъ менә ул берничә кеше белән сөйләшеп, безнең авылга килгән милиционерларны, мине, район вәкилләрен үтерүне, сәвит властена каршы җәнҗал, баш күтәрүне әзерләгәнен беләсеңме соң син?! Һәм иң мөһиме – нәкъ менә ул мәчет манарасының аен урлап китте.

– Ни сөйлисең син, Таһир? – дип елап җибәрде Зөбәйдә. Нәсимә исә мәет шикелле тыныч иде.

– Ни беләм, шуны сөйлим. Синең Вакыйфың Себергә бару бәхетен күрмәячәк, стенага терәп атачакбыз контраны! – Һәм ул, сүзләренең буш булмавын исбатларга теләпме, лачт итеп идәнгә төкерде, бүрек-бияләйләрен алды, ниндидер җыр мырлый-мырлый, ишеккә атлады.

Нәсимә, ишек ябылгач та, Зөбәйдәне кулыннан алып, сәкегә утыртты, аннан шәл бөркәнеп, урамга чыкты. Таһир монда түгел иде инде, аның аты тау астына төшеп барганлыгын тәмәке утыннан шәйләде. Авылда аннан башка урам буйлап тәмәке көйрәтеп йөрүче башка беркем дә юк. Аннан өйгә керде.

– Вакыйф, чык, Таһир китте, – диде ул. – Әй, балалар, ниләр генә күреп бетерерсез икән инде?! Вакыйф, сиңа кичекмәстән авылдан чыгып китәргә, качарга кирәк. Юк итәчәк сине Таһир!

Зөбәйдә, елап җибәреп, Вакыйфына елышты. Аннан тынычлангач, ниндидер карарга килде.

– Әни дөрес әйтә, Вакыйф. Мондый гаепләүләр белән сине сорап тормый-нитми бастырып атачаклар гына. – Ул Вакыйфның кулын кысып тотты да, әнисенә борылды. – Әни, мин Вакыйфны өзелеп яратам. Миңа аннан башка тормыш юк. Әни, син ачуланма инде. Зинһар, безгә никах укы. Минем Таһир кочагына кереп, харап буласым килми. Вакыйфымныкы буласым килә. Зинһар, әни, никах укы безгә.

Нәсимә ни әйтергә дә белми, каушап калды. Аннан, туктагыз әле, тәртибен белмим бит дигән булып, бераз вакыт сузды да, ахыр чиктә, күнде.

Вакыйф белән Зөбәйдәгә әнә шулай кара төндә киленнең әнисе никах укыды. Гөнаһлы никах булдымы ул, әллә инде Ходай кабул иттеме – анысын бу кичтә белергә мөмкин түгел иде. Никахтан соң янә утырып, чәй эчтеләр дә, Нәсимә, төенчеген җыеп, Вакыйфның әнисе Бибисарага төн кунарга китеп барды. Яшьләр икәүдән-икәү генә калдылар.

Беравык дәшми утырдылар. Икесе дә ни эшләргә дә белми сыман иде. Вакыйф бу мизгелне күпме көтте, күпме хыялланды, ә хәзер менә ничектер каушап калды.

– Утны сүндерик, – дип әйтергә көч тапты ул, ниһаять.

– Әйе шул, – диде Зөбәйдә, тагын ныграк кызарып чыгып.

Ут сүнгәч тә, ул үзенең билендә Вакыйфның көчле кулларын тоемлады. Назлы сүзләр пышылдый-пышылдый, егет аңа якынайды. Кайнар сулышы кызның бит очларына бәрелде. Иреннәр кушылды, көчле куллар инде Зөбәйдәнең изүенә үк менде. Вакыйф кагылган саен ул урында, әйтерсең, ут янып кала. Егетнең мәхәббәтен, чиксез теләген Зөбәйдә сүзсез дә бик яхшы тоемлады. Дөньясын, кайгы-газапларын онытып, ул таныш булмаган рәхәтлек диңгезенә чумды. Бу мизгелләрдә Вакыйфтан башка бүтән дөнья юк иде. Аларның тәннәре бергә кушылды, икесе бер җанга әйләнде. Мәхәббәт ташкыны ургылып чыкты, Зөбәйдә дә никахлы иренең назларына бирешеп, аңа иреннәре, куллары, бөтен барлыгы белән җавап бирде.

Назлы төн озак бармады – Вакыйфка китәргә кирәк иде.

– Мин хәзер синеке генә, – диде Зөбәйдә хушлашкан мизгелдә. – Җаным белән дә, тәнем белән дә. Мин сине мәңге көтәчәкмен. Шуны белеп яшә.

Әгәр кабат күрешергә насыйп булмаса, фани дөньяда түгел, ахирәттә очрашырбыз. Мин сиңа үлгәнче тугры калырга вәгъдә бирәм..

– Мин һичшиксез кайтачакмын. Син көт, яме, Зөбәйдә! Әгәр, алай-болай кайта алмасам, риза-бәхил бул. Мин сине бик нык яратам! Соңгы сулышыма кадәр сиңа хыянәт итмәскә вәгъдә бирәм. Миңа синнән башка беркем дә кирәк түгел, бары тик көт кенә!

– Хуш, җаным, Хозыр Ильяс сакласын сине!

Вакыйф урамга чыгып, караңгылыкта югалды. Тышта җылыта төшкән төсле, кар ява, җәяүле буран да чыгарга тора. Моның бер начар ягы булса, яхшы ягы да бар – аяк эзләрен кар себереп каплаячак.

Бакча башлатып, Вакыйф өйләренә кайтып житте. Өй тирәләре әле тыныч иде. Тавыш чыгармаска тырышып, эчкә керде. Әнисе йокламый, алар Нәсимә белән күз дә йоммаганнар. Бала белән ана күз яшьләрен агызып бәхилләште. Әнисе инде туксанның аръягына чыккан иде. Ул улына бары тик нык булырга, бирешмәскә дигән үгет-нәсихәтләр бирде. Баласына юлга дигән букча әзер иде инде. Саубуллашуны озакка сузмый, Вакыйф кышкы буранга кереп китеп юк булды...

...Авылда тентүләр, эзләүләр икенче көнне иртән генә башланды. Районнан килгән милиционерлар йорт саен йөреп, өйләрнең, каралты-кураларның һәрбер почмагын энә күзе аша үткәрделәр. Кичкә кадәр маташсалар да, мәчетнең ярымаен эзләү бернинди нәтиҗә дә бирмәде. Шуның өстенә, кичәге фетнәнең башында торучы саналган Вакыйфның авылда юклыгы ачыкланды. Аның әнисе Бибисарадан урысчалатып та, татарчалатып та сорап карадылар – файдасы тимәде. Районнан килгән милиционер, урысчалатып, Таһирдан Бибисара карчыкны кулга алыйкмы дип сорады. Таһир яше туксаннан узган карчыкка борылды. Әнисе белән ахирәтләр бит алар.

– Яшәсен әйдә, күпме калгандыр, – дип, Таһир чарасызлыктан кулын селтәп чыгып китте.

Кичке якта берничә кешегә, шул исәптән Нәсимәгә дә, икенче көнне район үзәгенә тикшерүчегә килергә повестка биреп, милиционерлар авылдан китеп барды.

Мең төрле газап кичсә дә, Вакыйф исән-имин килеш, милиция постларына эләкми, Сембергә килеп җитә алды. Көннәр салкын тора, шуңа да карамастан, Вакыйф Сембердә калырга ярамаганлыгын яхшы белә. Биредә милиция сагы үтә дә нык, Вакыйф турындагы хәбәрләр тирә-юньгә таралырга өлгергәндер. Сембер, хәзер инде халык теленә Ульян дигән исеме дә кереп бара, аларның авылына иң якын зур шәһәр, шуңа күрә биредә сәвит власте өчен аеруча «куркыныч фетнәчене» ныклап эзләячәкләр.

Шәһәрнең үзенә керми, егет якын-тирәдәге бистәләрнең берсенә таба юл алды. Кышкы карлы юлдан барганда, аны атлы чанага утырган бер абзый куып тотты. Русчаны рәтләп белмәсә дә, абзыйның арбага утырырга чакыруын аңлады Вакыйф. Ак сакаллы бу урыс кешесе читтән карап торганда, аңа куркыныч тоелмады. Әз-мәз белгәннәре белән юлда барганда, Вакыйф урысчалатып аңлашырга да маташты. Абзыйның исеме Иван Никитич булып чыкты. Ул Ишеевкада тора икән, ялгызы гына. Вакыйф исә туганнары янына Саратовка барам дип алдалады. Иван Никитич

Саратовның кайдалыгын әллә белмәде, әллә белеп тә игътибар итмәде, ләкин әллә ни исе киткән кыяфәт чыгармады.

Ишеевкага кайтып җиткәч тә, Иван Никитич үзенә кунакка чакырды. Күңелсез, нindидер кара Ишеевка бистәсенең читендәрәк кечкенә генә бүрәнә йортта Иван Никитич үзе генә яши булып чыкты. Ни уйларга да белми, Вакыйф бусагадан үтте. Иван Никитич чәй куеп җибәрде, мич тергезеп, чуен белән бәрәңге пешерергә куйды, табынга, күрәсең, кунак килә калса дип җыелган тәм-томнарын чыгарды. Иван Никитич Вакыйф белән күптән белеш, хәтта туган тиешле кеше төсле сөйләшә иде. Бер яктан олы яшьтәге бу абзыйның мондый җылы мөнәсәбәте күңелдә шик һәм курку уятса да, икенче яктан, өч көн буе җилсез почмак күрми кар ерып интеккән Вакыйф, ниһаять, җылыга, табынга эләгүенә чиксез шат иде. Иван Никитич туктаусыз нидер сөйли, ләкин аның сүзләренең яртысын да аңламый Вакыйф. Мондый җылы мөнәсәбәтнең, үз итеп сөйләшүнең серенә Вакыйф бераз вакыттан гына, Иван Никитичны инде тәмам аңлый башлагач кына төшенде.

Иван Никитичның хатыны Татьяна Алексеевна уллары тугач та вафат була. Алар баланы озак көтәләр, ләкин инде бәхетебез тулды дигәндә генә, Татьяна соңарып бала табуны күтәрә алмый, кендек әбисе кулында ук үлеп китә. Уллары Сергейны Иван ялгызы үстергән. Ләкин Сергей да озын гомерле булмый – унҗиде яше тулыр-тулмас үпкә авыруыннан бакыйлыкка күчә. Хатынын югалтудан болай да интеккән Иван Никитич моны, әлбәттә, зур авырлык белән кичерә. Ә Вакыйфны исә ул нигәдер үзенең улына охшатып алган була. Юк, картлач акылдан шашмаган, ләкин ялгыз юлаучы егеттә мәрхүм улының төсен күреп алган.

Вакыйф Иван Никитичта биш айга якын вакыт яшәде. Картка өй эшләре, хуҗалык буенча ярдәм итте. Ялгызлыктан интеккән бабай һәр кич саен аңа яшьлек маҗараларын, Татьянасы белән бергә ничек яшәгәнлекләрен бәйнә-бәйнә сөйләде. Биш ай эчендә Вакыйф шактый гына урысча сукаларга да өйрәнде.

Кеше күзенә күренмәскә тырышса да, Ишеевка шактый зур бистә булса да, Иван Никитичта ят егет яшәп ятуы турында имеш-мимешләр тарала башлады. Вакыйфның бүтән биредә кала алмаячагы икесенә дә аңлашыла иде. Иван Никитич Вакыйфның үткәне турында сораштырмады, әмма егетнең нindидер хәтәр эшкә катнашы булуын сизде, әлбәттә. Шуңа да ул, йөрәгеннән кан саркыса да, Вакыйфны мәрхүм улы төсле күрсә дә, аны юлга әзерли башлады.

Кечкенә генә төенчеккә бераз азык-төлек, юл кирәк-яраклары салынды. Ә иң мөһиме – Вакыйфка Иван Никитич мәрхүм улының туу турындагы таныклыгын бирде.

– Царицынга баргач та, анда менә шушы адрес буенча минем бертуган энекәш Василийны эзләп табарсың, – диде Иван Никитич. – Мин аңа менә бу хатны яздым, ул барысын да аңлаячак, аңа миңа ышанган төсле ышана аласың. Ул сиңа эшкә урнашырга ярдәм итәр. Минем улым урынына яшәрсең аңарда, анда кадәр барып кемнең кемлеген тикшереп йөрмәсләр...

Икенче көнне, май аеның салкынча таңында алар ат җигеп, Ульянга таба кузгалдылар. Беренче иртәнге пароход белән Вакыйф, дөресрәге,

Сергей Иванович Трифонов Сталинградка таба юл тотты. Пристаньда аны, җыерчыклы йөзе буенча йөгергән күз яшьләрен сөртеп, Иван Никитич озатып калды. Якты күңелле, яралы җанлы бу карт белән Вакыйфка бүтән очрашырга насыйп булмады...

***

Нәсимә кызындагы үзгәрешләрне әле кышын ук сизә башлаган иде. Ашавы, үз-үзен тотышы нык үзгәрде Зөбәйдәнең.

Алар язгы чәчүдән арып-талып кайтканда, урамда инде караңгы төшкән иде. Нәсимә, гадәттәгечә, кичке аш әзерләргә кереште, ә кызы исә, чамадан тыш арып булса кирәк, сәкегә барып ятты. Табынга утыргач та, әни кеше күптән башланырга тиешле сүзгә кереште:

– Кызым, ничектер бик сәер тотасың үзеңне...

– Арыганлыктан ул, әни, чәчүдә җиңел түгел.

– Артык тиз арый да башладың. Йөзләрең үзгәрде. Матураеп киттең димме шунда, түгәрәкләнеп хәтта.

Зөбәйдә комач төсле кызарды.

– Ярый, үзең әйтмәсәң, мин башлыйм. Син көмәнле бит, әйеме?

Зөбәйдә кинәт үксеп елап, әнисенең кочагына ташланды. Нәсимә исә берни дәшмәде, әледән-әле кызын чәченнән сыйпап, белгән догаларын пышылдый-пышылдый укый иде.

– Йә, ярый, язмаган булмас. Хәзер сабый турында уйларга кирәк. Сиңа чәчүгә йөрергә ярамый. Мин Таһир янына барырмын.

– Барма, әни, ул мине дә, сине дә үтерәчәк. Көн дә бәйләнә бит, үзең күреп торасың, әллә кай җирләрдә сагалап тора.

– Балакаем, совет власте хатын-кызларны яклый, диләр бит, менә безне дә якласын. Җитмәсә, безнең кияү була алмый калган Таһирыбыз партия әгъзасы, бик артык бәйләнсә, районга барып, тавышын чыгарырмын. Ләкин, кызым, бала мәсьәләсен без икәү генә хәл итә алмыйбыз. Киен әйдә тизрәк.

– Кая барабыз?

– Бибисара әбиең янына. Аның да бу балада үз хакы бар. Әйдә, барыйк, сөйләшик.

Вакыйфларның өйләрендә утлар сүнгән, Бибисара аптый, күрәсең, инде йокларга яткан. Тик йокысы бик сизгер булып чыкты. Ишек каккач та, ул мич башыннан гына кемнәр килүен сорады, аннан кабалана-кабалана идәнгә төшеп, соңарган кунакларны кертте.

– Ни йомыш белән, Нәсимә балам? – диде ул, дога кылып алгач. Соңгы вакыттагы хәлләрдән, улын югалту кайгысыннан картаеп калса да, Бибисара аптыйның сүзләре төгәл, акылы аек иде. Район үзәгеннән мәчет аен эзләп килгән тикшерүчеләргә дә ул «белмим»нән артыгын әйтмәде, урысчалатып-татарчалатып, үзенә кычкыручыларга ачу белән генә карап торды, күзеннән бер тамчы яшь тә төшмәде.

– Вакыйфтан хат-хәбәр юкмы, Бибисара аптый? – дип сорады Нәсимә.

– Төш күрдем, Вакыйфым мул табын артында сыйланып утыра иде, – диде Бибисара әби нык тавыш белән. – Әни, сиңа да күчтәнәчләр алып кайтырмын, диде. Димәк, исән балам. Ризыгы да өзелмәгән. Мин үлгәнче кайта алырмы-юкмы, анысын әйтә алмыйм. Ләкин кайчан да булса кайтачак ул.

– Менә без Зөбәйдә белән хәлләреңне белик дип кергән идек...

– Зөбәйдәне улым бик нык яратты. Миңа да сөйли торган иде. Каһәр суккан Таһирлар бутап йөрмәсә, икәү бергә булыр идегез, балакайларым. Насыйп булмаган, вакыты җитмәгән, Алланың амин дигән чагына туры килмәгән сүзләрегез.

– Бибисара аптый, монда тагын бер нәрсә бар бит әле. – Нәсимә, сүзен нидән башларга белмичә, төртелеп калды.

– Әйтмәсәң дә күрәм, Нәсимә кызым. Шөкер, кергәләп тора, хәлемне белешә, соңгы вакытта аеруча да матураеп китте кызыбыз. – Кинәт ул уң кулын, эчтән генә укый-укый, Зөбәйдәнең корсагына китереп, бераз иелеп нидер тыңлап торды. Аннан, башын күтәреп, кеткелдәп көлеп җибәрде. – Һай, малай булачак!

– Нишлибез соң, Бибисара аптый?!

– Вәт юләр, шул да булдымы сорау? Үстерәбез, Аллаһы боерса, бергәләп үстерәбез.

– Документы да юк, кияүгә дә чыкмаган кыз...

– Син укыган никахны Ходай үзе кабул иткән, димәк, шул арада җимешләрен дә биреп куйган. Баласы кемнән икәнлеген яшермик – бер дә оялырлык түгел. Вакыйф баласы диярбез. Документларын да ясарлар, контораның эше шул. Зөбәйдә миңа яшәргә күчсен, – дип, кырт кисте Бибисара аптый. Аннан урыныннан торып, сөйләшү тәмам булуына ишарәләде. – Иртәгә килерсең, кызым, урын әзерләп куярмын. Киемсалымнан ары берни кирәкми, Вакыйфның мендәрләренә кадәр калды. Ә син, кодагый, бер дә борчылма, кызыңны кыерсытмам да, башкалардан да кыерсыттырмам.

Икенче көнне иртән иртүк торып, Нәсимә колхоз конторасына юнәлде. Таһир биредә иде.

– Ни кирәк? – дип, усал гына сорады ул, Нәсимәне бусагада күреп алгач та.

– Сөйләшергә килдем, Таһир.

– Сөйләп кара, тыңлыйм.

Нәсимә Таһирның өстәле янына ук килеп басты.

– Беренчедән, Таһир энем, – диде ул, «энем» сүзенә басым ясап, – минем кызыма якын да киләсе булма, яме?

– Һе, мин нәрсә, аны күргәч, урамның икенче ягына чыгарга тиешмени?

– Син минем ни турында әйткәнемне беләсең. Кызымның колагы тешләнгән, никахы укылган!

– Никахы?!

– Әйе, никахы. Ул Вакыйф белән никахлашкан кыз, шуны колагыңа киртләп куй!

– Тукта, тукта... – Таһир өстәл артыннан торып, бүлмә буйлап атлап китте. – Нинди никах тагын? Ниткән искелек калдыгы турында сөйлисең син? Минем аша бернинди никах кәгазьләре дә үтмәде.

– Ходай каршындагы никахны әйтәм мин, Алласыз бәндә.

Таһир авызын кыйшайтып көлеп үк җибәрде.

– Гафу ит инде, абыстай булсаң да, әйтим – бетте ул сезнең никахлар заманы.

– Безгә анысын әйтүче булмады, шуңа күрә безнең өчен гомер-гомергә законлы никах Ходай каршында башкарылган һәм башкарылачак.

Таһир тәрәзәдән манарасыз мәчет бинасына күз ташлады. Аның түбәсен аннан-моннан япкалап, кибет корып куйганнар иде.

– Халык дошманы Вакыйф белән синең кызың арасындагы әфсен-төфсен никахын сәвит власте танымый! – диде ул һәм йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты.

– Халык дошманы?! Бусы ни дигән сүз тагын?

– Шундый сүз. Вакыйф – халык дошманы, синең ирең халык дошманы, сез халык дошманнарының хатыннары, кызлары!

– Әстәгъфирулла! – Нәсимә агарынып китте. – Хәмидулла абыең кемгә дошман булды соң?!

– Халыкка дим бит! Сәвит властена!

– И мокыт. Син аны үзең дошманга чыгардың бит. Имештер, ул фетнә әзерләп йөргән, имештер, корал туплаган, Троцкийга хатлар язган. Кайда соң ул кораллар, кайда ул хатлар?!

– Табылыр, ашыкма, табылыр. Мәчетнең ае да табылыр, кораллар да табылыр.

Нәсимә, калтыранып, Таһир каршына килеп басты, ике кулы белән тегенең күн бишмәт якаларыннан эләктереп алды. Күзендә мөлдерәмә яшьләр иде.

– Син безне теләсә ничек мыскыллый, теләсә ничек кыерсыта аласың, бәдбәхет, – диде ул тәмам пышылдауга күчеп. – Тик бер нәрсәне исеңдә калдыр – минем кызыма бармак белән генә кагылсаң да, мин үзем синең бугазыңны чәйнәячәкмен. Мине тол калдырдың, кызымны тол калдырдың, ирләребез исән килеш аларны күрми яшибез. Кая барып җитәргә икәнлеген белермен, үзеңнең башыңны Себергә җибәрермен, гөнаһларың җитәрлек. Сезнең совет власте хатын-кызларны якларга тиеш бит. Ә син, партия әгъзасы, ни кыланасың? – Аннан, якаларын җибәреп, артка атлады. – Мин үз сүземне әйттем. Һәм, белеп тор, Зөбәйдә көмәнле. Аны чәчүдән алып җиңелрәк эшкә күчерергә кирәк.

Таһир чак кына мәтәлеп китмәде.

– Көмәнле? Кемнән?!

– Никахлы ире Вакыйфтан.

– Зинадан корсакка уздымыни?!

– Зиначылар күрше урыс авылларына барып, марҗа кызлары белән маташалар дип сөйлиләр, – диде ул, Таһир турындагы төрле имеш-мимешләргә ишарәләп.

Таһир, тынычлана төшеп, урынына барып утырды һәм Нәсимәгә урындыкка күрсәтте. Нәсимә, аякларының хәле китүен тоеп, күрсәтелгән урынга барып утырды.

– Бу хакта кемнәр белә инде, Нәсимә апа? – диде Таһир, бик йомшак итеп.

– Күп кеше белә, ә нәрсә?

– Юктыр, күп кеше түгелдер, авылда сүз чыкса, миңа килеп сөйләгән булырлар иде. Әйдә болай итәбез. Зөбәйдә теге шакшы эттән корсакка узган баласын төшерә һәм законлы итеп, миңа кияүгә чыга. Балда-майда яшәячәксез, тел-теш тидермәм, йорт җиткерәм үзеңә.

– Рәхмәт инде, Таһир энем, халык дошманнарының туганнарын шулай кайгыртуың өчен. Тик мин дә, Зөбәйдә дә, Бибисара аптый да моңа килешмәячәк. Бел дә тор, бөтен районга тавышын чыгарам.

– Әһә, димәк, Бибисара карчык та белә. Яхшы. Алайса болай. Баланы үземнеке кебек итеп үстерәм. Ләкин сере өчебез арасында калачак.

– Мин үз сүземне әйттем, Таһир, – дип, урыныннан торды Нәсимә, тик Таһир аңа чыгып китәргә ирек бирмәде.

– Әле мин әйтеп бетермәдем. Кызыңны барыбер үземнеке итәм. Нинди юллар белән – минем эш. Сезнең барыгызга да файдалы булган юлны мин күрсәттем.

– Мин баланы рәхәт тормышка алмаштырмыйм.

– Яхшы. Алайса, мин түгел, син Себергә китәчәксең, аңладыңмы?! Бибисара карчык белән култыклашып китәчәксез.

– Без тагын нәрсә өчен?!.

– Бүген син совет власте вәкиленә янадың, совет властен тиргәдең, фетнә оештыру белән янадың. Шуның өстенә сез Бибисара карчык белән икәүләп, фетнә оештырган җинаятьчене советлар судыннан яшереп ятасыз.

– Тукта әле, ә син үзең?..

– Ә мин? Мин – власть, аңладыңмы?! Кара әле, нинди батыр кешеләр, исең китәрлек. Берсенең ире төрмәдә утыра, икенчесенең улы качкынлыкта, фетнәдә гаепләнә. Ә син, абыстай, миңа монда килеп янап йөрергә җөрьәт итәсеңмени?! – Янә йодрык шап итеп өстәлгә китереп сукты. – Кыскасы, догалар ятлап чүпләнгән башың белән бер нәрсәне аңларга тырышып кара – йә кызың миңа кияүгә чыга, йә бөтен гаиләгез белән төрмәдә черисез. Бибисара карчыкны да, сине дә кызганмам. Һәм тагын бер нәрсә – әгәр бу бала, безнең сөйләшү турында берәр кешегә сүзе чыкса, авыл советы исеменнән, колхозыбыз исеменнән иреңне атып үтерү турында гариза язачакбыз. Лагерьда торган килеш тә авыл халкын фетнәгә котыртып ята бит, кара әле син, ә?! Аңладыңмы?! Аңласаң, бар.

Нәсимә, аякларын көчкә атлап, сулкылдап елап, ишеккә юнәлде.

– Бүген икегез дә нәрәттән азат ителәсез. Минем вакыт күп, иртәгә кадәр көтәрмен. Нәрсә хәл иткәнен Зөбәйдә үзе килеп әйтсен, иртәгә шушы вакытта.

Урамга чыккач та, Нәсимә берара идарә диварына сөялеп басып торды, тыны кысылганлыгын, Таһир бүлмәсендә һава җитмәгәнлеген шушында гына аңлады.

Тау башыннан җигүле атта менеп килүче Нәгыйм картны күргәч тә, кинәт кенә барысын да хәл итеп, Нәсимә аңа таба йөгерде.

– Районга барасыңмы, Нәгыйм абый? – дип сорады ул.

– Әйе, абыстай, районга сөт илтәм менә.

– Мине дә ал әле, зинһар өчен.

– Утыр әйдә, сөтле бидоннан авыррак булмассың.

...Райком секретарен ул төшке ашка кадәр диярлек ишек төбендә сагалады. Аны куырга да маташтылар, бүлмәгә кертү турында сүз дә юк. Төрле кешеләр түрә бүлмәсенә керә-чыга, Нәсимәгә шашкан кешегә караган төсле карап үтәләр. Хәер, моңа күнеккән инде ул, иренең язмышы

турында хәбәр табарга маташканда күп утырды биредә. Ниһаять, ишектән секретарь үзе дә күренде.

– Сез миңамы? – дип сорады ул Нәсимәдән.

– Әйе, мин...

– Ә, сез бит Хәмидулла мулла хатыны, әйеме? Гафу, тикшерү күптән тәмам.

– Юк, мин ирем мәсьәләсе белән түгел, башка мәсьәлә белән идем, биш кенә минут вакытыгыз булмасмы?

Түрә, баштарак икеләнеп торса да, Нәсимәне бүлмәсенә чакырды. Нәсимәнең сөйләгәннәрен ул бүлдерми генә тыңлады.

– Миннән нәрсә сорамакчы буласыз инде сез? – диде ул, Нәсимәнең бәяны тәмам булгач.

– Фәтхуллиннан саклавыгызны сорыйм. Ул бит минем кызга бәйләнә, көчләп кияүгә алмакчы.

– Мин сакчы түгел. Таһир Фәтхуллин белән сөйләшермен. Кызыгыз зур җинаятьтә гаепләнүче кеше белән якын мөнәсәбәткә кергәнен аңлыйсызмы?

– Нахак ул, Таһир нахагы!

– Нахакмы-юкмы, анысын җинаятьчене кулга алгач белербез. Әлегә ул законнан качып йөри һәм шуның белән үз гаебен таный, җәзасын арттыра. Әгәр сез аның кайдалыгын белеп тә, әйтми торасыз икән, сезне дә җавапка тартачакбыз.

– Белмим мин, валлаһи дип әйтәм, белмим, кызым да аның кайдалыгын белми!

– Ярый, энә түгел, табылыр. – Түрә телефонга сузылып кемнедер җыйды һәм, кичекмәстән, Таһир Фәтхуллинны үз янына чакыртырга кушты. – Шуның белән шул, мин Фәтхуллин белән сөйләшәм, ул сезгә бәйләнмәс. Әгәр тагын бер мәртәбә тәртип бозуларда, фетнәләрдә катнашуыгыз ачыкланса, миннән ярдәм көтмәгез. Власть белән уйнашка керү ярамый, моны сез аңларга тиеш.

Районнан җәяүләп кайтып килгәндә, Нәсимәгә юлда кара айгырга атланган Таһир очрады. Нәсимәгә җитәрәк, атын туктатып, аның тирәли берара әйләнеп йөрде, ләкин берни дәшмәде. Күзләре ачу һәм нәфрәт тулы иде Таһирның. Нәсимә дә аңа берни әйтмәде. Алар бер-берсен бер караштан аңладылар. Бу юлы җиңү абыстай кулында иде. Ләкин алда әле күпме бәрелешләр булыр?!

Зөбәйдәне колхозда иң авыр эшләргә җибәрә башладылар. Ул кичләрен тәмам хәлдән таеп, Бибисара карчык янына кайтып егыла, иртәле-таңлы янәдән торып чыгып китә. Нәсимә бөтенләй дә кара кайгыга батты. Кызы да табигате белән аңа охшаган булса, бала исән-сау килеш дөньяга туа алмас бит. Әле ул күпме сакланып та, берничә сабыен карынында килеш югалтты, ә биредә кызыннан авыр әйберләр күтәртәләр, тын алырга да ирек бирмиләр.

Авырлыкларга да карамастан, яшьлек көче үзенекен итте. Урак тәмамланган көннәрнең берендә салам эскерте төбендә Зөбәйдә белән Вакыйфның уллары дөньяга тәүге авазын салды. Сабыйга Җиһангир дип исем куштылар. Бибисара карчык, үзенең бердәнбер исән улына бер тамчы судай охшаган балага сөенеп туя алмады. Көзге кичләрнең берсендә

кунакка килгән кодагыена исә ул күптән түгел төш күрүен, Җиһангирнең озын гомерле булачагына юравын бик тәфсилләп сөйләде. Моннан тыш ул илгә зур афәт ябырыласын дә әйтте. «Анысы минем гомергә тимәс, әмма сезнең башыгыздан үтәчәк», – диде ул, кодагые белән тәмләп чәй эчкәндә.

***

Беломорканал 1933 елның язына таба тәмам оешып бетә язды. Аның йөзләрчә чакрымга сузылган трассасын таш, бетон белән ныгыту тәмамланып килә иде. Биргән бит Ходай адәм баласына көч һәм куәт! Бу якларда аяк астыннан балчык эзләп табу да зур уңыш бит. Кая көрәк төртмә – ташка юлыгасың. Әле ташы да нинди диген – сыер зурлыгындагылары да еш очрый. Андыйларын тимер казыкка кувалда белән бәреп, башта ваграк кисәкләргә ваталар, аннан берәм-берәм төяп канал төбеннән ярга менгезәләр. Кайбер бригадаларда сирәк-мирәк атлар бар, ташларның авырларын алар ташый. Ләкин газапның күп өлеше кешеләр җилкәсенә төште. Ташлар арасында күпме мәет күмелеп калганын, Сталин исемен йөртәсе бу бөек корылманы кемнәрнең өрәкләре саклаячагын да белә бу кешеләр...

Хәмидуллалар инде берничә атна рәттән авыр ташлар ташудан азат ителделәр. Аларның бригадасы шлюз төбен рәткә китерергә күчерелде. Бусы да бригадирлары Николайның тырышлыгы нәтиҗәсе.

Шлюз үзе ниндидер алып мәете өчен казылган каберне хәтерләтә. Аның ике як стенасы, әйтерсең, күккә кадәр ашкан, ә ачылмалы ике капкадан турыдан-туры тәмугка кереп була сыман. Кешеләр биредә кырмыска төсле генә.

Төшке аш килгәч тә, бригада өскә менде. Шлюз янәшәсендә икенче бригада тоткыннары маташа иде. Алар тактадан сәхнәгә охшаш нәрсә коралар.

– Тагын мунчага барып, матур киенеп киләсе була, тагын концерт әзерлиләр безгә, – дип, тирә-юньгә ишетелерлек итеп кычкырды Петро һәм чын күңелдән көлеп җибәрде.

– Монда эш бетә, димәк, – дип көрсенде Николай. – Җайлана гына башлаган кебек иде, начальниклар белән дә танышып беттем. Хәзер безне яңадан таратырлар, яңадан берәр төрле икенче бөек төзелешкә җибәрерләр, каһәр.

– Бетмәде микәнни әле ул бөек төзелешләр?!

– Илебез зур бит. Төзисе дә төзисе. Бер бөек әйбер төзеп кенә куясың – икенчесе ишелеп төшә, – дип, бу юлы пышылдап пырхылдады Петро, ашаудан аерылмый гына.

– Баш сау булсын, Николай, түзәрбез, – дип көрсенде Хәмидулла.

Салкын кояш астында салкын ташларга утырып, салкын баланда чөмергән арада сөйләнгән сүзләр шуның белән вәссәлам булды. Бригада янәдән шлюз төбенә, аны чүп-чардан чистартырга, тишек-тошыкларны ямарга төшеп китте.

Кичен лагерь пунктына кайткач та, Хәмидулланы чакыртып алдылар. Барактагылар аны усал күзләр белән озатып калды. Мондый карашның ни икәнен белә Хәмидулла. Начальство янына бары тик сатлыкҗаннарны, сүз

йөртүчеләрне генә чакыралар. Ул үзе дә андыйларны нәкъ шундый караш белән озата иде. Ә бүген, менә сиңа мә, аның үзен чакырттылар. Берни аңламадым дип, җилкәсен сикертеп, ул Николайга күз салды. Николай исә, бар, аннан сөйләшербез дигән кыяфәттә барак ишегенә ымлады.

Лагерь пункты начальнигы урнашкан бина матур бүрәнәләрдән мүкләп эшләнгән. Эчкә керү белән борынга бал, чәй, мүк җиләге кайнатмасы, итле аш, тагын әллә нәрсәләрнең тәмле исе китереп бәрә. Аннан иләсләнгән төсле буласың. Ап-ак итеп акшарланган мичтә нарат агачлары шатыр-шотыр килеп яна, көйгән чәер бүлмәне үзенә күрә бер табигый хуш искә күмелә. Шушы илаһи гүзәллек, матурлык арасында тәбәнәк буйлы, чак кына симез гәүдәле, чатан бәндә утыра – лагерь пункты начальнигы. Дөресрәге, начальник эшли, ә Хәмидулла кебекләр утыралар. Утыручы күбрәк эшлиме, эшләүче күбрәк утырамы – монысын шайтан да аңлап бетерерлек түгел.

– Утыр, Тимерханов, утыр, – дип тәкъдим итте ничектер шикле итеп начальник. – Чәй эчәсеңме?

– Юк, рәхмәт, гражданин начальник, кичке ашта бик тәмле итеп ашаттылар.

– Тимерханов, син безнең «Перековка» газетасын бик яратып укыйсың, диделәр, шул сүз дөресме? – Начальник, әйткән сүзләренә ишарә итеп, төзелештә эшләүчеләр өчен махсус чыгарыла торган газетаны Хәмидуллага таба этәребрәк куйды.

– Укыйм дип... Карап чыгам инде. Әйбер төрергә дә ярап куя.

Начальник Хәмидулланың көлемсерәп әйтүенә игътибар итми, тагын да йомшый төшеп дәвам итте:

– Син беләсең бит, каналармияче Тимерханов, безнең төзелеш эшләре тәмамланып килә. Шул уңайдан шлюз төбендә тантаналы митинг үтәчәк...

– Тагын яңа фуфайкалар таратасызмы?

– Юк, запаслар бетте, – дип, дөресен әйтүенә уңайсызланып, кинәт кызарып куйды начальник. – Анысы мөһим түгел. Митинг булачак. Башка лагерь пунктлары килә, оркестр, музыка, чыгышлар... Без уйлаштык та, син дә, Тимерханов, ул митингта чыгыш ясарга тиеш дигән фикергә килдек.

– Мин? – Хәмидулла чын күңелдән гаҗәпләнгән иде, шуңа хәтта урыныннан да торып басты. – Нишләп нәкъ менә мин?! – диде аннан, тынычлана төшеп. Аннан йә көләләр, йә нинди дер кырын эшкә тарталар – бусы көн кебек ачык.

Начальник урыныннан торып, кулларын артка куеп, чатанлый-чатанлый, кечкенә адымнар белән уңлы-суллы йөреп, тар бүлмәне үлчәргә кереште.

– Мин синең шәхси эшеңне өйрәндем, Тимерханов. Һәм, беләсең килсә, син безнең өчен иң кулай кеше. Оратор.

– Ни турында ораторлыйсы инде миңа?!

– Сине бу төзелеш ничек итеп үзгәрткәне турында!

– Соң, ничек дип... Шыр сөяккә калуым, билем чатнап авыртуы һәм бүксәм чыгу беркемгә дә кызык булмас бит, гражданин начальник.

Мондый сүзләрне начальник көтмәгән иде. Ул йөренгән урыныннан туктап калды, аннан чатан икәнлеген дә онытып булса кирәк, йөгереп барып, өстәл артына утырды. Карашы үзгәргән, күзләре усал.

– Син миңа монда контра сүзләрен сөйләмә, яме?! Әгәр аңламыйсың

икән – барысын да аңлатам. Син элеккеге мулла бит?! Менә, чыгасың да, бирегә килгәч, Алланың юклыгына инандым, элек кешеләр мондый зур каналны төзи ала дип уйламаган да идем, дисең. Аңладыңмы?!

– Бер генә төзәтмәм бар, гражданин начальник. Мин Алланың барлыгына тагын да ныграк инандым. Алла сакламаса, бу кадәр кеше күптән монда кырылып беткән иде инде...

Начальникның күзләре акаеп чыкты. Ул акрын гына өстәл артыннан торып басты. Хәмидулла да торды.

– Сержант Петров! – дип кычкырды начальник, Хәмидулладан күзен дә алмыйча.

– Сержант Петров сезнең әмер буенча килде, иптәш начальник!

– Зек Тимерхановны ике тәүлеккә карцерга!

Хәмидулланы, эчке киемнән генә калдырып, яланаяк килеш таш идәнле караңгы карцерга кертеп яптылар. Биредә ятып түгел, утырып торырга да урын юк иде. Язга чыгу бәласе, идән урамнан кергән судан юпь-юеш, җитмәсә, боздай салкын. Утны кабызу-фәлән дигән нәрсә юк, биредә дөм караңгыда гына тоталар. Ике тәүлектән соң сакчылар аны сөйрәп баракка кертеп ташлаганда, Хәмидулла әллә үле, әллә тере иде.

Аны шунда ук барактагы иптәшләре күтәреп алды. Хәмидулланың карцерга җибәрелүен белгәннәр, кайткан төшенә болай да барлы-юклы паеклардан өлеш әзерләп торганнар. Агач ятакка барып сылану белән кемдер аңа кружка белән мич өстендә җылытылган баланда бирде. Кемдер кечкенә генә ипи кисәген сузды. Кызарынган ярымсукыр күзләре белән Хәмидулла моның Эрнест икәнлеген абайлады һәм елмаеп куйды. Сабаклары бушка китмәгән, егет тә ипи кадерен белә башлаган, димәк.

Икенче көнне иртән ничек кенә авыр булмасын, барыбер торырга туры килде. Бөтен тәне авырта, кыйнамасалар да, карцердан соң үзеңне изелгән төсле хис итәсең.

Тезеп бастыргач та, бүген аларга үзләре белән эш кораллары алып бармаска кушылды. Димәк, ниндидер башка вакыйга көтә. Бәлки, теге каһәр суккан митингтыр?!

Чынлап та, шлюз ягына, алардан кала, төрле яклардан, башка лагерь пунктларыннан тоткыннар төркемнәре агыла иде. Ниндидер машиналар йөргәне күренә, музыка тавышы ишетелә. Шлюзга якынрак килгәч, зеклардан торган тынлы оркестр уйнаганлыгы аңлашылды.

Шлюз яны халык, дөресрәге, тоткыннар белән шыгрым тулы. Кызыл чүпрәкләргә язылган транспарантлар, Сталин рәсемнәре, кая карама – «даешь!» та «ура!».

Сәхнә ясаучылар бу юлы да барысын да җиренә җиткереп эшләгән – аннан-моннан җыештырылган такталардан трибуна гына түгел, дүрт якка дүрт каланча да әмәлләп куйганнар, алардан мылтык көпшәләре акаеп карап тора.

Бу юлы митингта сүзләр күп булды. Әле берсе чыгып мактанды, әле икенчесе. Үз хәле хәл, Хәмидулла аларның кемлегенә дә, ни сөйләүләренә дә төшенергә маташмады. Ниһаять, чираттагы чыгыш ясаучының исемен атагач, ул уянып киткәндәй булды. Сәхнәгә, гадәттә зарланудан башы чыкмаган Сашка менеп басты. Аларның бригадасыннан һәрвакыт сырхау, ач, бөтен нәрсәдән дә канәгать булмаган Сашка иде бу!

– Каналармиячеләр! Минем гомер буе башым караклыктан чыкмады, – диде ул, барысы да ишетерлек итеп кычкырып һәм әледән-әле, дөрес әйтәмме дигәндәй, түрәләр утырган якка караштыргалап. – Беломор – Балтыйк су юлын төзергә җибәрәбез дигәч тә, мин биредән һичшиксез качып китәчәкмен дип карар кылдым. Ләкин төзелешкә килгәч, фикерем үзгәрде. Иптәшләр таптым, без бергәләп, шушындый зур, бөек төзелешне башкарып чыгарга сүз куештык. Хәзер инде мин бөтенләй икенче кешемен! Мин алга таба да бөек Сталиныбыз, бөек илебез өчен зур казанышларга ирешергә әзермен!

Сашка сөйләгән вакытта Хәмидулла янәшәсендәге «уголовный» җинаятьчеләргә күз салды. Алар бер отрядтан, Сашканы да бик әйбәт беләләр. Җинаятьчеләрнең үз төркеме, башлыклары Лёха Косой. Сашканың һәрбер әйткән сүзеннән соң Косойның йөзе карала бара сыман. Ниһаять, ул түзмәде, үзенекеләрен бер түгәрәккә җыйды да пышылдап, тиз генә нидер аңлатты...

Митинг тәмамланды. Тынлы оркестр марш уйнарга кереште. Кинәт шлюзның аргы ягында бер-бер артлы дүрт көчле шартлау тавышы ишетелде. Каналның Хәмидуллалар төзегән өлешен күлдәге судан аерып торган дамбаны шартлаттылар, күрәсең. Чөнки икенче мизгелдә үк яман тавышлар чыгарып, суда зур дулкын күтәрелде, ул юлындагы ташларны, төзелеш чүп-чарын як-якка чөереп, шлюзга таба ыргылды һәм ыңгырашып, плотинага килеп бәрелде. Түрәләр дәррәү кул чапты. Сталин исемендәге Беломор-Балтыйк диңгезе каналы шушы мизгелдән кулланылышка тапшырылган, димәк.

Кайтыр юлда Хәмидулла Сашканы күзәтте. Ул алдарак бара. Йөзе яктырган, авызында моңарчы мәңге күренмәгән елмаю. Егет аңа кызганыч булып китте.

Сашканы уголовниклар ничек урап алганын һәм ничек итеп як-якка таралышканын Хәмидулла абайламый калды. Сашканың кычкырган тавышы да ишетелмәде кебек. Хәмидуллаларның бригадасы узып беткәч кенә, арттан килүче конвой пычрак арасында аунап яткан «ялкынлы ораторны» шәйләп алды. Кемдер аның аркасына пычак кадаган иде. Үтерүчене тапмадылар, Сашка исә Беломорканал төзелешендә вафат булган дистәләрчә мең кеше исемлегенә чираттагы пункт итеп теркәлде...

***

...Ап-ак төскә яңа гына буялган пароходның киерелгән бортына «Анохин» дип язылган. Ул, озын морҗасыннан кара төтен чыгарып, Повенец янына килеп җитте. Пароходның иң биек урынында, кулына төрепкәсен тотып, Иосиф Сталин, аның янәшәсендә хәрби һәм диңгез эшләре наркомы Климент Ворошилов, партиянең Ленинград обкомы һәм горкомының беренче секретаре Сергей Киров, ОГПУ башлыгы Генрих Ягода басып торалар.

– Бу – беренче шлюз, – диде Ягода, алга таба күрсәтеп. – Без биредән Беломор-Балтыйк каналына кереп китәчәкбез.

– Ә кая чыгачакбыз, иптәш Ягода?

– Су юлы турыдан-туры Ак диңгез белән тоташа...

Сталин елмаеп куйды һәм янәшәдәгеләрен табынга чакырды. Бокалларга шәраб салынгач, Сталин, канәгать булуын яшермичә, тост күтәрде:

– Кара диңгез нәрсә ул? Кечкенә бер тагарак кына. Балтыйк диңгезе

нәрсә? Шешә, ләкин бөкесе бездә түгел. Менә, биредә, диңгез дисәң дә була, киң, бөтен дөньяга юл ача торган капка төсле. Биредә безгә зур флот булдырырга кирәк. Бу капка аша чыгып, без теләсә кемне, кирәк булса, Англияне дә, Американы да бугазлый алачакбыз! Иптәш Сталин исемендәге канал өчен!

Алар юл буе табыннан аерылмый гына каналны күзәтә килделәр. Бер мәлне Сталин Ягоданы чакырып алды.

– Генрих, чыннан да зур эш башкаргансыз, булдыргансыз, – диде ул, төрепкәсендәге төтен белән чебен-черки өерен өркетеп. – Миңа алдынгы төзүчеләрнең исемлеген китерерсең, аларны бүләкләргә кирәк.

– Яхшы, иптәш Сталин.

– Үзеңне дә онытма, яме, – дип елмайды Сталин.

– Рәхмәт сезгә, иптәш Сталин!

– Аннан тагын, беләсеңме нәрсә? Бу төзелештә төрле кешеләр эшләде бит. Алары арасында ялгышкан, заманында тайгак юлга басканнар да булгандыр. Ләкин шуңа да карамастан, эшләгәннәр, төзегәннәр, тырышканнар. Минемчә, аларны да бүләкләргә кирәктер. Кайберләренә хәтта өйләренә кайтырга рөхсәт итәргә. Ә нәрсә?! Кайтсыннар, сөйләсеннәр күргәннәрен.

– Без моны да уйлап бетерербез, иптәш Сталин.

«Анохин» теплоходы Беломорканалны башыннан алып азагына кадәр урап чыккач, Ак диңгезгә махсус китерелгән хәрби флот вәкилләре белән очрашкач, Сталин Мәскәүгә кайтып китте. Лагерьдагыларга исә Илбашчы күзенә күренмәгән эшләрне тәмамлыйсы, тишек-тошыкларны ямыйсы, каналны төзеп бетерәсе бар иде...

...Авыр эш көненнән соң лагерьга кайткач, Хәмидулланы Николай бер читкәрәк чакыртып алды.

– Мин бүген гражданин начальник янында булдым, – диде ул, лагерь җитәкчелеге утырган йорт ягына ымлап. – Каналны төзегән өчен безнең отрядтан ике кешене иреккә чыгарачаклар. – Һәм Николай нәрсә әйтерсең дигән кыяфәт белән Хәмидуллага текәлде.

– Аларны кем билгели? – дип сорады Хәмидулла, кинәт кабынган өмет утыннан тәне кызыша башлавын тоемлап.

– Миннән тәкъдим, алардан карар чыгару.

– Һәм син?.. Кемнәрне тәкъдим иттең?

– Әлегә беркемне дә түгел. Иртән керергә кушылды. Мин кучтәнәчләр әзерләдем инде әзерләвен...

– Үзеңне тәкъдим итәсеңме?

Хәмидулла Николайга текәлеп карады. Гадәттә кырыс, күзләре төпкә баткан бригадирның йөзе үзгәргән. Яктырган дияргәме шунда. Димәк, аның да җанын өмет уты җылыткан. Николай, уңайсызланып, карашын читкә төбәде, аннан дәвам итте:

– Икенче кеше – син булачаксың.

– Нигә нәкъ менә мин?

Түземлеген югалтып, Николай тәмәке төпчеген читкә ташлады һәм бу юлы Хәмидулла аның күзләрендә өмет белән катыш югалып калу, курку, хәтта нәфрәт тә тойды. Бригадирның иреннәре калтырана, кулларын әйткән дә юк.

– Чөнки мин шулай хәл иттем, аңладыңмы?! Әллә син кеше язмышын хәл итү җиңел дип уйлыйсыңмы?! Мин моны сиңа әйтмичә дә начальникларга җиткерә ала идем. Ләкин белмим, никтер синең белән сөйләшергә булдым. – Николайның күзендә яшь тамчысы күренде, ул аны тиз генә сөртеп ташлады да үзен-үзе кулга алды кебек, тынычланды, кырысланды. – Мин шулай хәл иттем, бел шуны, шуннан артыгын сорама. Синең гомереңне булса да саклап калырмын. Яхшы кешеләр күптер безнең бригадада, ләкин күңел никтер сиңа күрсәтте. Син рәхмәт диген дә, бетте-китте...

– Рәхмәт, Николай, – диде Хәмидулла, үзенең дә күзләре юешләнгәнен тоемлап. – Рәхмәт, ләкин...

– Нәрсә ләкин тагын? – Николай, әйтерсең, хәзер Хәмидуллага ташланып, аны өзгәләп ташлаячак. – Нәрсә җитми сиңа?!

– Кызма әле, Николай. – Хәмидулла йөрәк түрендә берничә минут элек кенә кабынган өмет утының сүнүен, инде төтене дә калмавын анык итеп тойды. – Мине барыбер чыгармаячаклар. Сиңа рәхмәт, ләкин минем әлегә иреккә юлым ябык.

– Нигә тагын?! Көтәр кешеләрең калмадымыни?

– Бар, шөкер, һәм алар көтәрләр. Ләкин начальниклар мине барыбер иреккә җибәрмәс, син сорасаң да җибәрмәс. Үзең уйлап кара – мин сәяси маддә буенча утырам. Алай гына да түгел, күптән түгел карцерда булдым, анда әләгүемнең сәбәпләре акка кара белән язылган. Чыгармаячаклар мине...

Николай янә тәмәке көйрәтеп җибәрде. Хәмидулла әйткәнне ул болай да белә, әлбәттә. Ләкин ничәмә еллар буе иңгә-иң эшләп, бу татар агаен эштә дә, тормышта да күреп, бригадир аңа чын күңелдән ихтирам һәм хөрмәт хисләрен тоя иде. Бүгенге сөйләшү булмый торып, иртәгә бөтен лагерь алдында Хәмидулланы түгел, башкаларны, шул исәптән Николайны иреккә чыгарсалар, шушы татар мулласының күзенә ул – гади крестьян егете Коля ничек карый алыр?! Хәзер иңеннән зур йөк, зур гөнаһ, зур гаеп хисе төште.

Алар берара дәшми утырдылар.

– Николай, ә икенче кеше итеп кемне әйтерсең соң?

– Синнән ишетәсем килә ул исемне.

– Миннән? Яхшы алайса. Эрнест.

– Ул да сәяси бит, – диде Николай, ишетелгән исемгә бер дә гаҗәпләнмичә.

– Аныкы җиңелрәк. Яшь бит әле ул. Менә ул исән кала алса, безнең икебезнең дә намусыбыз чиста булыр. Ә мин кайтырмын әле, өлгерермен.

Август аенда лагерь пункты тоткыннарын җыеп, биек мөнбәрдән боерык игълан ителде. Иреккә чыгарылучыларның исемлеге кыска булса да, анда Николай да, Эрнест та эләккән иде. Эрнест үзен атаганнарын ишеткәч, чак кына егылып китмәде. Аннан борылып, Хәмидуллага чын күңелдән елмайды. Хәмидулла да елмаюын яшермәде. Аның да шатлыгы эчкерсез иде. Бәлки, азат ителүчеләрнең кыска исемлегенә эләкмәгәннәр аны аңламас та, ә менә Хәмидулла белән Николай бер-берсен бик яхшы аңлый.

Николай белән дә, Эрнест белән дә саубуллашырга мөмкинлек бирмәделәр, аларны шунда ук гомуми рәттән чыгарып алып киттеләр, Хәмидулла бүтән аларны лагерьда күрмәде.

Октябрь аенда исә лагерь пунктын тараттылар. Башта җәяүләп, аннан поездда бик озак барырга туры килде. Килеп җиткәч кенә, Хәмидулла

үзенең туган ягына шактый якынаюын, мари урманнарына җибәрелүен белде. Чәнечкеле тимерчыбык артында булса да, ниндидер ике йөз чакрым ераклыкта гына туган ягың көткәнлеген уйлап йокыга талу Хәмидулланың күңеленә үзгә бер рәхәтлек бирә иде...

***

Шимбә көннәре сыраханә өчен бер яктан иң керемле булса, икенче яктан иң авыры иде. Адольф Гитлер хакимияткә килгәч, андый урыннарга йөрүчеләр саны бермә-бер артты. Моның үзенә күрә тирән мәгънәсе дә бар – нацистлар партиясе үзе үк сыраханәләрдә оешкан бит, Мюнхенда 1929 елда булган канлы вакыйгаларны да нацистлар үзләре үк «сыра путчы» дип атап йөртәләр. Шуңа күрәме, сыраханәгә кич саен, ә шимбәләрен бигрәк тә, көрән күлмәкле әтрәк-әләм кереп тула башлады. Кайдан килә диген, акчалары да кесә тутырып, туйганчы ашап-эчәләр, яңа, нацист җырларын кычкырып җырлыйлар. Ләкин бу шимбә иртәсе Берлинда башкаларына охшамаган иде.

Сәгыйдулла, гадәттәгечә, иртән торып чәйләп алды да юлга кузгалды. Тыкрыктан чыгу белән, ул урам тулы көрән күлмәкле егетләрне күреп алды. Берсе Сәгыйдулла янына йөгереп килеп:

– Яһүдме? – дип сорады.

– Юк, – диде Сәгыйдулла, һәм, инде күнегелгән гадәт буенча, калтыранган куллары белән кесәсеннән документын чыгарып күрсәтте. Көрән күлмәкле яшь егет аны озаклап өйрәнде дә Сәгыйдуллага кире сузды.

Атлаган саен бу күренешкә тап буласың. Урамда кемне күрсәләр, штурмчылар кешеләрнең документларын тикшерә. Ләкин аларга кирәкләре юк, күрәсең, кәефләре кырылып, документларны кире кайтарырга мәҗбүр булалар. Ниһаять, Сәгыйдулла үзләренең урамнарындагы ипи кибетенә килеп җитте. Аның каршында, бөерләренә таянып, ике штурмчы басып тора иде. Зур тәрәзәгә буяу белән алты почмаклы йолдыз ясалган, аның янәшәсенә зур итеп немесчә «яһүд» дип язып куелган. Әйе, бу кибетнең хуҗасы яһүд, исеме Мойша, үзе хуҗа, үзе сата. Сәгыйдуллага ул кайвакыт ипине бурычка биреп тора иде.

– Сиңа ни кирәк? – дип, кырыс итеп сорады бер штурмчы, Сәгыйдулланың кибет каршында туктап калуын күреп. – Яһүдме?!

– Юк, менә... – дип Сәгыйдулла каушап калуыннан кабалана-кабалана, янә документын күрсәтте. Бу штурмчы да аны бик озаклап өйрәнеп, кире кайтарды.

– Яһүдләрнең товарларын бөек Германиянең дошманнары гына сатып ала, шуны беләсеңме син?! – диде кырыс штурмчы.

– Әйе... Аңладым...

– Юлыңда бул!

Сәгыйдулла ашыга-ашыга, сыраханәгә таба атлады. Әледән-әле ул кергәләгән яисә беркайчан да бусагасын да узмаган кибетләр очрый. Аларның яһүдләрнеке икәнлеген моңарчы белми дә, уйлап та бирми иде Сәгыйдулла. Аннан соң, яһүдтән алдың ни дә, немес яисә татардан алдың ни?

Сыраханәнең ишекләре ачык иде инде, гәрчә әлегә ул клиентларны кабул итмәсә дә. Бүген иртәнге яктан ук Фридрих та килгән. Нигәдер аеруча усал күренә.

Барысы белән дә исәнләшеп, Сәгыйдулла өсләрен алмаштырды һәм эш урынына узды. Бераздан алар чәй эчәргә утырдылар.

– Урамнарда әллә нәрсә булып ята шунда, – диде Вильгельм, бүлмәдәге авыр мохитне бераз булса да таратырга маташып. Алар барысы да урамда ни икәнлеген болай да үз күзләре белән күрделәр, ә сүзне болай башлау хәлне тагын да катлауландырды төсле. Ганс кына, ниһаять, рәхәтләнеп елмаерга җай тапты.

– Яһүдләргә көн бетте, – диде ул, шатлыгын яшермичә.

– Яһүдләрдән сиңа ни зыян? – Вильгельм әллә чынлап, әллә уйнап гаҗәпләнде, Гансның нацистлар партиясенә шушы көннәрдә генә керүен бүлмәдәгеләр яхшы беләләр иде.

– Әй, аптыратма әле, Вильгельм, юк-бар сорауларың белән. – Ганс Вилли белән гадәти бәхәсләргә керү яклы түгел иде. – Ләкин безнең сыраханәгә бүген файда булачак, анысын мин бик яхшы беләм.

– Үлгәнче эшләячәкбез, – дип, канәгатьсезлек белдерде Вильгельм.

– Тагын бер атнадан эш тагын да артачак, – дип, кинәт сүзгә кушылды сыраханә хуҗасы.

– Ник алай, һерр Фридрих?

– Чөнки Ганс бездән китәргә карар кылды.

– Ганс? Кая?!

Гансның йөзе тагын да яктырды.

– Мин СС сафларына керү турында гариза бирдем, һәм мине һичшиксез алачаклар! – диде ул, кинәт урыныннан сикереп торды һәм уң кулын алга ташлап: – Хайль Гитлер! – дип кычкырды.

– Килешә, – диде Фридрих. – Нигә СС, нигә СА түгел? Әнә, адым саен тезелгәннәр, күрмәдеңмени?

– СА – искелек калдыгы ул, – диде Ганс бик белдекле кыяфәт белән. – Ә яһүдләр – безнең дошман, Адольф Гитлерның «Минем көрәш» китабын укып кара, Вилли.

– СС яһүдләр белән көрәшәме инде ул? – Вильгельм барыбер тынычланмады.

– СС Германиянең дошманнары белән көрәшә, Вилли.

– Дошманнар белән көрәшер өчен нинди булырга кирәк соң?

– Минем кебек – сары чәчле, зәңгәр күзле, озын буйлы. Ариец, кыскасы.

– Ә мин ариецмы?

– Тыштан ариец. Эчтән – белмим. Тикшереп карарга кирәк.

– Ничек, ярыпмы?

– Кирәк булса, ярырбыз да, Вилли, борчылма син. – Ганс Вильгельм белән дәвам иткән бәхәскә ачуланмады, киресенчә, күңеле генә күтәрелә бара иде.

– Ә Сагди ариецмы соң? – дип, төпченүдән туктамады Вильгельм. Бу сүзләрдә Фридрих инде түзмәде, ике яшь этәчне сүз белән чәкәләшүдән туктатты.

Вильгельмның соңгы соравы исә Сәгыйдуллага берничә көн буе тынгылык бирмәде. Чыннан да, нацистлар өчен Сәгыйдулла кем соң? Дусмы, әллә дошманмы? Моның өчен, күрәсең, Гитлерның «Минем көрәш» китабын укып чыгарга кирәктер, Ганс юкка гына шулай белеп сөйләшми, ул әлеге китапны яттан өйрәнгән диярлек. Ләкин Сәгыйдулла ул китапны

сатып алырга теләмәде. Көпә-көндез кибетләре мәсхәрә ителгән Мойша, башка яһүдләрнең күз яшьләренә чыланган төсле тоелды аңа бу китап. Гәрчә, берничә мәртәбә кибеткә кереп, озаклап, затлы басмаларга карап торса да, кулына да алырга кыймады.

Ганс киткәч, эш, чыннан да, тыгызланды. Фридрих аның урынына өстәмә кеше алып тормаска булды. Киңәш-табыш итәргә, милләттәшләрнең хәлен белергә дип, Вильмерсдорфтагы мәчеткә Сәгыйдулла җәй башында гына барып җитә алды. Җомга намазыннан соң алар, гадәттәгечә, Гыйльми белән бер чәшкә чәй эчәргә дип, каһвәханәгә керделәр.

– Дөньяда ниләр бар? – дип сорады Сәгыйдулла.

– Ниләр барлыгын үзең күрәсең, ишетәсеңдер, шәт.

– Яһүдләрне кысалар...

– Кысалар гынамы соң?! – Гыйльми, бармак бөгеп санарга кереште. – Кибетләреннән товар алырга ярамый, яһүдләргә дәүләт эшендә эшләргә ярамый, адвокат булырга ярамый, тегесе ярамый, бусы ярамый... Җитәкчеләр чыгышларында ачыктан-ачык яһүдләрне дошманга чыгаралар. Геббельсның 10 май көнне ясаган чыгышын ишеттеңме?

– Юк, ул көнне китаплар яндырганнар дип кенә беләм, миндә радио юк...

– Яһүд язучыларының китапларын, алар белән бергә коммунистларныкын да.

– Мин яһүд тә, коммунист та түгел, куркыр нәрсә юк сыман.

– Иртәгә сиңа да килеп җитәрләр дип ышандырып әйтә аласыңмы? Юк! Мин дә әйтә алмыйм. Без икебез дә Россиядән, иртәгә коммунист ярлыгы таксалар, нишлибез? Берлинда гына да коммунистлар өчен берничә аерым төрмә ясалган, гестапо коммунистлар белән азмы-күпме бәйле кешеләрне шунда илтеп олактыра...

– Минем коммунист дусларым да, белешләрем дә юк, Гыйльми.

Гыйльмулла Сәгыйдуллага ничектер сәер, балага караган төсле итеп карап куйды. Аннан, авыр сулап, пышылдауга ук күчте:

– Бер атнадан мин Франциягә. Әйдә минем белән.

– Анда хәерчелек ни дә, монда ни?

– Анда исән калып булачак.

– Нацистлар каршында гөнаһым юк, Гыйльми. Мин биредә калам. Сиңа исәнлек телим. Бераз акча юнәтә алсам, баеп китсәм, кунакка килермен. Йә син миңа.

Гыйльмулла ул көнне әле бик озак Сәгыйдулланы Берлиннан берәр кечерәк француз шәһәренә күченеп китәргә өндәде, аның кебекләр татарлар арасында шактый булуына ышандырырга маташты. Ләкин Сәгыйдулла күнмәде. Алар һичшиксез очрашырга сүз куешып аерылыштылар.

Әлеге очрашуга кадәр нәкъ сигез ел көтәсе иде...

***

Вильгельм хезмәт иткән танк төркеме 1941 елның җәе башында эшелоннарга төялеп, көнчыгышка Россия чигенә таба күчерелде. Дислокацияне үзгәртүнең сәбәпләре турында беркем дә кычкырып әйтмәсә дә, озакламый Германиянең СССРга һөҗүм итәчәге барысына да аңлашыла иде.

Вильгельм, ничек кенә карышмасын, армия хезмәтенә барудан читтә

кала алмады. Вермахтка эләккәч тә, ул, үзе уйлавы буенча, мөмкин булган һөнәрләрнең иң тынычын, кеше үтерү белән бәйле булмаганын – танк йөртүчесе һөнәрен сайлады. Сугыш дигән дөньяны ул үзенең тимер машинасының тар гына тәрәзәсе аша күзәтә. Тирә-якта ниләр булып ятканын исә командиры биргән әмерләр аша чамалый.

Июнь башыннан бирле аларның төркеме, күз буяу чаралары күреп, Буг елгасыннан ерак түгел урнашты. Һөҗүм турында әмер килгәнен шунда көтәләр. Ул арада танкларны яхшылап әзерләргә кушылды. Көн саен Вильгельм тимер машинаны төзәтә, төрле механизмнарны кат-кат көйләп куя. Танкның эчендә бер генә тузан әсәре дә калмады. Бары тик уң як бортының бераз гына яньчелгән өлеше танкка Польша кампаниясе вакытында снаряд тиеп үтүен хәтерләтеп тора. Снаряд танк өстендә шартламады, тимер сыртны чак кына сыдырып узып рикошетлады да кайдадыр артка төшеп ярылды. Ләкин ул вакытта да Вильгельмның җаны табанына төшеп китте, танкны шулкадәр селкетте ки, командирлары башнядан ук мәтәлеп төште.

Командирлары Юрген сүзләренә ышансаң, Россияне алар тиз арада басып алып, изеп чыгарга сәләтле. Әле сугышка кадәр үк Юрген Советлар Союзы белән Германия арасындагы тәҗрибә уртаклашу программасы буенча Россиядә булып кайткан. Шуңа күрә ул әлеге җирләр турында бик тәфсилләп, матур итеп сөйли иде. Кичләрен аны тыңларга башка экипаж вәкилләре дә җыела.

– Россия – егетләр, бик кыргый ил ул, – дип, инде йөзенче тапкыр сүзен башлый Юрген. – Анда юллар бөтенләй юк. Халык хәерче. Безне поезд белән Казан дигән шәһәргә алып бардылар. Ул шәһәр безнең Германиядәге авыл шикелле генә. Кая карама – бер-ике катлы агач йортлар. Урамда ат белән йөриләр. Юллар пычрак. Шәһәрләренең уртасында ак кирмән генә тора, бернинди завод-фабрика да күренми. Кая ул танклар җитештерү! Аларның училищесына баргач күрдек инде танкларын – консерва банкасы төсле нәзек металлдан эшләнгән, төртсәң, бармак белән тишәрлек!

– Россиядә урам буйлап аюлар йөри, урыслар алар белән утырып, шнапс эчә, диләр, шул сүз дөресме? – дип шаркылдап көлеп җибәрде бер нимес. Ләкин Юрген сүзне көлкегә бормады, бик җитди иде.

– Егетләр, беләсезме, урысларның көче аю биетүдә дә, танкларда да түгел. Алар үзләре танк шикелле. Нык гәүдәле, киребеткән кавем ул. Андый кешеләр белән сугышу бер дә җиңел булмаячак. Алар бака тәпие ашап биеп йөрүче француз яисә кемгә сатылырга аптырап беткән поляк түгел. Алар шул пычракка баткан җирләре өчен җаны-тәне белән көрәшергә әзер. Безнең Германиядә – нимесләр, Франциядә – французлар, Польшада поляклар яши. Ә Россиядә урыс дигәннәре бер урыс кына түгел, йөз төрле халык анда. Бер-берсен аңлап та бетермиләр кебек, ләкин бер илдә телсез генә аңлашып яшәп яталар.

1941 елның 21 июнендә Вильгельм хезмәт иткән төркем солдатларына мәйданга тезелергә кушылды. Күрәсең, нindider дәрәҗәле түрә килгән. Ялгышмадылар – алар каршына тәбәнәк буйлы, борыны астында агарып баручы тар гына мыеклы, танкистлар өчен легенда булган генерал-полковник Гейнц Гудериан чыкты.

– Солдатлар! – диде ул, каршына тезелеп баскан танкистларны карашы белән йөртеп чыгып. Аның йөзендә җиңелчә елмаю, һәм, әйтерсең, әлеге

елмаю бер генә минутка да югалып тормый. – Безнең алдыбызда бик мөһим миссия тора! Ул яраткан фюрерыбыз, Рейх өчен, Германия халкы өчен бик зур әһәмияткә ия. Безнең юлыбыз көнчыгышка таба юнәлә. Көнчыгышта безнең яшәү чыганагы, бүгенге һәм киләсе буыннарның ризыгы җәйрәп ята. Бронетанк гаскәрләренә бик мәртәбәле һәм изге миссия йөкләнде. Без, беренчеләрдән булып, Советлар Союзына бәреп керергә, аларның оборонасын юк итәргә, нимес солдатларына Мәскәүгә таба юл ярырга тиешбез. Мин ышанам: бу бурычны үтәү безнең хәлдән киләчәк. Сезнең тимер танкларыгыз, сезнең корычтай беләкләрегез Франция, Польша җирләрендә чирканчык алып ныгыды, беркем дә сындыра алмаслык көчкә әйләнде. Шул ук вакытта, дошманын көчсезгә санаган кеше үзе җиңеләчәк, көндәшегез турында булдыксыз, надан дип уйламагыз. Барысын да ныклап уйлап, һәрбер адымыгызны үлчәп ясагыз. Сез Рейхка, әти-әниләрегезгә, туганнарыгызга, сөйгән ярларыгызга исән-имин килеш кирәк! Мин бу кампаниядә бер генә солдатымны да югалтырга теләмәс идем. Мин үзем дә гади бер солдат кына, яу кырында үземнең танк белән сезнең янәшәдә булырмын. Бергәләп, Мәскәүдә Кызыл Мәйданда шнапс эчеп, зур җиңүне бәйрәм итәчәгебезгә бер генә шигем дә юк!

Генерал-полковник Гейнц Гудериан Советлар Союзына һөҗүм 22 июньгә билгеләнгәнен белсә дә, солдатларга бу хакта әйтмәде, бары тик командирларга моннан соң һәр төнне уяу торырга кирәк дигән әмер генә бирде.

Әле 14 июнь көнне үк барлык төр армияләр һәм танк төркемнәре командующийларын Берлинга җыеп, Адольф Гитлер генералларына Россиягә нигә һөҗүм итәргә карар кылуын аңлатырга тырышты. Әледән-әле кычкыруга күчеп, чәчләрен як-якка тузгытып, төкерек чәчә-чәчә, өстәл төя-төя, ул Англияне җиңә алмавына көенечен белдерде. Англияне җиңәр өчен материктагы дошманнарны тар-мар итәргә кирәк. Материктагы дошманнарны тар-мар итү өчен бер генә юл бар – Россияне яулап алу. Өч сәгатьтән артык Адольф Гитлер халыкара вазгыять турында озын-озак нотык укыды. Әлбәттә, аны бүлдереп, сүз әйтерлек кеше табылмады. Үзен рейхның танк гаскәрләренә нигез салучы дип санаган Гудериан да дәшмәде.

Төшке аштан соң Гудерианга бер генә сорау бирделәр – аңа Минскка барып җитәргә күпме вакыт кирәк булачак? Гудериан күзен дә йоммый, «5-6 көн» дип җавап кайтарды. Һәм менә хәзер аңа әлеге сүзләрен гамәлгә ашырасы.

Вермахт – Германиянең Гитлер кулы астында төзелгән өр-яңа кораллы көчләре – Россияне изәргә, таларга, юк итәргә әзер тора. Төп максат – Мәскәү, коммунистларның оясы, аны туздыру Россияне тезләндерүгә тиң. Моннан ун еллап элек Россиядә булган вакытта Гудериан әлеге илнең көчен чак кына тоемлый алды. Аларның бер заводы, чынлап торып алынса, Германиянең барлык заводлары кадәр танклар җитештерергә мөмкин. Табигый байлыклары турында әйткән дә юк. Россиядән кыйммәтле металл, иген төялгән эшелоннар Германиягә дә бертуктамый килеп тора. Мөгаен, кичә дә килгәннәрдер. Аларга алмашка рейх Россиягә төрле җиһазлар, техника бирә. Гитлерның теләге буенча озакламый көнчыгыштан эшелон-эшелон байлыклар рейхка бушлай кайтачак...

21 июнь кичендә Гудериан команда пунктына кире кайтып төшкәндә, дөм караңгы иде. Алда, Брест юнәлешендә, аның тимер армиясе посып, данлыклы генералларыннан һөҗүмгә ыргылырга әмер көтеп тора.

Команда пунктындагы каланчага күтәрелеп, Гудериан тирә-юньне бинокльдан күзәтеп чыкты. Кая карама тынлык, дөнья татлы иртәнге йокыга талган. Кинәт әлеге тынлыкны гөрселдәгән тавышлар ярып үтте, болай да эңгер-меңгер торган җәйге иртә меңләгән туп көпшәсеннән чыккан уттан яктырып китте. Кайдандыр очып килүче снарядлар, һавада сызгырып үтеп, чикнең икенче ягында шартлап ярыла тордылар. Гудериан сәгатенә күз салды. 3 сәгать 15 минут. «Барбаросса» планы башланды.

Гудериан күзәтү каланчасыннан төшкәндә, һавада инде самолётлар өере күренде. Алар, чик артына китеп, әллә үзләренең моторлары тавышында, әллә ташлап калдырылган снарядларының шартлавында эреп юкка чыгалар иде.

Сугыш башланды. Гудериан, аның белән бергә Манштейн, Гот, Гёпнер, Клейстның танклары Россиянең дәүләт чиген үткәндә, Германия вакыты белән иртәнге биш тә тулмаган иде...

Россия чиген узган танкларның берсенең рулендә кайчандыр Берлин сыраханәсендә Сәгыйдулла белән бергә эшләгән ябык кына нимес егете – әдәпле, тәрбияле Вильгельм дә бар. Аның танкы, колоннада хәрәкәт итеп, Буг елгасы аша салынган күпердән чыкты. Бу – дәүләт чиген бозу дигән сүз иде. Менә ул да Россия җиренә аяк басты.

Совет иле, күрәсең, якшәмбе йокысыннан ничек әләксә шулай уянган. Танкның тар гына тәрәзәсе аша Вильгельм формасын кияргә өлгермәгән кешеләрне күрде. Алар, мылтыкларыннан атып, тимер танкларны туктатырга маташалар, гомерләренең соңгы мизгеленә кадәр каршылык күрсәтәләр. Бер окоп өстенә менгәч, командир аңа танкы белән урында әйләнеп, окоптагыларны изәргә кушты. Приказны үтәргә туры килде. Танк механизмнары шатырдыймы, әллә кеше сөякләреме – Вильгельм бу хакта уйламаска тырышты. Аны да өйдә көтәләр, аңа да исән-сау әйләнеп кайтырга кирәк. Ә моның өчен бер генә юл бар – дошманыңны юк итү. Һәм ул танкын алга, очсыз-кырыйсыз Россия далаларына таба юнәлдерде. Әле анда, әле монда, көпшәләреннән ут чыгарып, совет гаскәриләре кулларыннан килгәнчә, дошман белән тигезсез көрәшкә керә иде...

***

Георгий Жуков Генераль штабтагы кабинетында югары ешлыктагы элемтә телефоны чылтыравыннан сискәнеп китте. Урамда инде яктырып килә, ә алар төне буе йокламаган, бөтен Генштаб, оборона Наркоматы хезмәткәрләре эш урынында.

– Жуков тыңлый, – диде ул, төрепкәсен алып.

– Георгий Константинович, бу адмирал Октябрьский! – Кара диңгез флоты командующиеның тавышы үзенекенә охшамаган иде. Жуков эченә салкын йөгергәнлеген тойды, ләкин тынычлыгын югалтмады.

– Тыңлыйм, Филипп Сергеевич.

– Флотның алдан кисәтү системасы диңгез ягыннан күпсанлы самолётлар якынлашуын хәбәр итә. Флот хәрби әзерлектә. Сездән күрсәтмәләр көтәм.

Башланды, димәк, дип уйлап алды Генераль штаб башлыгы. Көтелмәгән хәбәр булмаса да, мондыйга әзер торып булмый икән...

– Сезнең тәкъдимегез нинди, Филипп Сергеевич?

– Тәкъдим бер генә – самолётларны флотның һава оборонасы зениткалары белән бәреп төшерергә!

Жуков янә уйга калды. Әлбәттә, адмирал дөрес әйтә. Аның урынында булса, ул да, ике дә уйламый, ут ачар иде. Ләкин Генераль штаб башлыгының мондый әмер бирергә хакы юк. Аның өстендә торучылар бар. Иң өстәгесе – Сталин. Ә Сталинның теленнән «провокация» сүзе төшми. Хәтта Белоруссиядә үзенекеләрдән качып, советлар ягына чыккан немес дезертирының сүзләренә дә колак салмады. Тегесе сугыш 22 июньдә иртәнге дүрттә башланачак дип әйткән. Сталин ышанмады. Гитлер махсус рәвештә Советлар Союзын котырта, безне беренче булып, һөҗүмгә ташланырга мәҗбүр итмәкче, диде. Имеш, сугыш башлау гаебен Советлар Союзына сылтамакчы, шуңа Гитлер мәчеле-тычканлы уенын алып бара.

– Филипп Сергеевич, элемтәдә булыгыз! – дип, Жуков шап итеп төрепкәне куйды һәм оборона буенча халык комиссары кабинетына ашыкты. Семён Тимошенко аның докладын дәшми генә тыңлап торды да, фикерен җыеп:

«Яхшы», – диде.

Ярты сәгатьтән Жуковның кабинетындагы телефоннар бертуктамый шалтырарга тотынды. Башта Көнбатыш округыннан немес самолётларының Белоруссия шәһәрләрен бомбага тотуын хәбәр иттеләр. Минут та үтмәгәндер, Киев округыннан Украинага дошман авиациясе ябырылуы мәгълүм булды. Озакламый Балтыйк буеннан Каунас һәм башка җирләргә һөҗүм турында җиткерделәр.

– Сталинга шалтыратырга кирәк, – диде Тимошенко, Жуковның докладыннан соң озак кына уйланып торгач.

– Яхшы, Семён Константинович, сез сөйләшкәч тә, мин сездән күрсәтмәләр көтеп калам.

– Юк, – диде Тимошенко, Жуковтан карашын читкә борып. – Сталинга сез чылтыратачаксыз, Георгий Константинович.

– Мин?!

– Әйе. Вакыт әрәм итмәгез, иптәш Жуков.

Коридордан үз кабинетына барганда, Жуков башында йөз төрле уй өере дулады. Тимошенко Сталинга ник үзе шалтыратмый? Куркамы? Начар хәбәр алып килгән илченең башын кисәләр, диләрме әле? Әллә Тимошенко Сталинның Жуковка җылырак мөнәсәбәтен тоеп, аңа каты бәрелмәс дип уйлыймы? Ничек кенә булмасын, Сталинга аңа шалтыратасы.

Жуков Сталинның Кунцеводагы дачасы телефонын җыйды. Төрепкәне озак алмый тордылар. Ниһаять, теге очта Власикның йокылы тавышы ишетелде:

– Сез кем?

– Генераль штаб башлыгы Георгий Жуков. Мине кичекмәстән иптәш Сталин белән тоташтыруыгызны үтенәм.

– Сез нәрсә?! Хәзерме?! – Власик тәмам уянып бетте кебек. – Иптәш Сталин йоклый.

– Хәзер үк уятыгыз – немесләр безнең шәһәрләрне утка тота, сугыш башланды! – диде Жуков, тавышыннан өстәлдәге стакан зеңгелдәп куйды. Власик берара дәшми торды.

– Бераз гына көтеп торыгыз, – диде ул коелып төшкән тавыш белән.

Жуков тирләп чыккан юеш учы белән төрепкәне кысыбрак тотты. Власикның бераз көтегез дигәне мәңгелеккә сузылды төсле. Ниһаять, теге башта Сталинның тавышы ишетелде:

– Тыңлыйм, – диде ул пышылдап диярлек.

– Иптәш Сталин, бу Генераль штаб башлыгы Георгий Жуков, – исәнләшкәч тә, генерал моннан бер сәгать чамасы элек башланган хәлләр турында бәйнә-бәйнә доклад ясады. Сталин дәшмәде. Төрепкәдә аның авыр сулышы гына ишетелә иде. – Сез мине аңладыгызмы, иптәш Сталин?!

Янә тынлык.

– Нинди күрсәтмәләр булачак?!

Сталин кинәт аңына килгәндәй булды:

– Нарком кайда?

– Киев округы белән сөйләшә. – Жуков алдавын сизми дә калды.

– Тимошенко белән бергә Кремльгә килегез. Поскребышевка әйтегез – барлык Политбюро әгъзаларын да җыйсын.

Теге башта төрепкәне куйдылар. Жуков Тимошенко кабинетына ашыкты.

***

– Николай, машинаны әзерлә, Кремльгә барабыз, – диде Сталин, төрепкәне куйгач та, бераз уйланып торып. Кәгазь төсле агарган Власикка ул карамады, бүлмәсенә кереп тиз генә киенде һәм урамга ашыкты. Якшәмбе иртәсе инде тәмам яктырып килә иде.

Димәк, сугыш башланды. Ул аны кичектерергә ничек кенә тырышмасын, Гитлер барыбер һөҗүм итте. Шулай буласын Сталин белде, әлбәттә. Ләкин җаны-тәне белән фюрерны тынычландырырга маташты. ТАССның Советлар Союзы белән Германия арасында мөнәсәбәтләр ал да гөл дигән хәбәре моннан бер атна чамасы гына дөнья күргән иде бит. Сталин аның текстын үз куллары белән төзәтте. Сталинга әзерлек өчен вакыт кирәк иде. Тагын ике, йә булмаса бер ел. Ул вакыт эчендә Кызыл Армия техника белән дә тулыланачак, тәҗрибәле офицерлар да үсеп җитәчәк. Ләкин Гитлер советлар иленең көч җыюын көтеп тормады. Гитлерның астыртынлыгы бөтен дөньяга мәгълүм, ләкин нигәдер нәкъ менә аңа, Сталинга карата фюрер этлек эшләмәс кебек иде. Җәйнең кояшлы якшәмбе иртәсендә бу өметләр чәлпәрәмә килде.

Сталин кабинетының озын өстәле кырына бер-бер артлы Политбюро әгъзалары килә торды. Ниһаять, барысы да җыелгач, Тимошенко белән Жуковны чакырдылар.

Сталинның кулында тәмәкесе тутырылмаган буш төрепкә, кыяфәтенә югалып калу төсмере чыкмаган булса, гадәти җыелыш диярсең. Тимошенко Политбюро әгъзаларына иртәнге сәгатькә тупланган барлык мәгълүматны җиткерде. Ул сөйләгән саен Политбюро әгъзаларының йөзләре карала барды. Мәгълүматлар аннан-моннан җыелган булса да, алар барыбер 22 июнь иртәсенең куркыныч манзарасын тасвирлады. Фронт сызыгы Кара диңгездән

Балтыйк буена кадәр сузылган. Дошман самолётлары ил чигеннән йөзләрчә чакрым эчкә үтеп, шәһәрләрне һәм хәрби объектларны утка тота. Советлар Союзы биләмәләрен инде немесләрнең коры җир дивизияләре таптый.

Сталин төрепкәсен читкә алып куйды һәм куе кашлары астыннан Тимошенкога текәлде:

– Бу немес генералларының провокациясе түгелме икән? – диде ул. Тимошенко гаҗәпләнүен яшерә алмады.

– Немесләр Украина, Белоруссия, Балтыйк буенда безнең шәһәрләрне утка тота. Нинди провокация булсын, ди, иптәш Сталин?!.

– Әгәр провокация оештырырга кирәк икән, – диде Сталин, урыныннан торып, кабинеты буйлап атлап китеп, – немесләр хәтта үз шәһәрләрен дә утка тотачак. Гитлер бу хакта белмидер дип уйлыйм. – Аннан Сталин Молотовка борылды. – Иптәш Молотов, кичекмәстән Германия илчелегенә шалтыратырга кирәк.

Молотов бүлмәдән чыгып китте, кая карарга, ни әйтергә дә белми, Политбюро әгъзалары аның кире кайтуын көттеләр. Тимошенко белән Жуков үрә катып басып тора бирде. Ниһаять, Молотов кире керде.

– Германия илчесе граф фон Шуленбург кичектергесез хәбәр өчен үзен кабул итүне сорый, – диде ул Сталинга.

– Иптәш Молотов, хәзер үк илчене кабул итегез.

– Иптәш Сталин, – диде Тимошенко, – дошманга каршы чаралар күрергә һәм аларга һөҗүм ясарга сезнең ризалыкны сорыйм!

– Ашыкмагыз, – диде тәрәзәдән күзен алмый, Политбюрога аркасы белән торган Сталин. – Молотовны көтик.

Молотов унбиш-егерме минуттан Сталин кабинетына әйләнеп керде. Ул биек авыр ишекне зур саклык белән япты да бүлмәдәгеләрнең һәрберсенә күз төшереп чыкты. Иң соңыннан аның карашы Сталинныкы белән очрашты. Алар беравык сүзсез бер-берсенә карашып тордылар. Бу минутта сүзләр кирәкми иде.

– Германия хөкүмәте безгә сугыш игълан итте, – диде Молотов. Бүлмә янәдән тынлыкка чумды. Политбюро әгъзалары әле бернинди фаҗига да булмаган, әле ялгышны төзәтергә мөмкин дип уйласалар, хәзер өметнең әсәре дә калмады.

– Иптәш Сталин! – Жуков беренче булып сүз башларга җөрьәт итте. – Чик буендагы хәрби округлардагы барлык көчләрне туплап, безнең территориягә кергән дошманнарга ябырылырга һәм аларны туктатырга тәкъдим итәм.

– Туктатырга түгел, юк итәргә, – дип төзәтте Тимошенко.

– Директива әзерләгез, – диде Сталин. – Ләкин безнең хәрбиләр беркайда да немесләр чиге аша узарга тиеш түгел. Авиациядән кала, әлбәттә.

***

...Сәгыйдулла күрше бүлмәдәге радионың каты тавышыннан уянып китте. Кичә шимбә булганга, шактый соңга кадәр эшләргә туры килде, шуңа бүген бераз йоклап алырмын дигән иде, насыйп булмаган икән. Фрау Герда радионы моннан ике еллап элек алды, ләкин беркайчан да болай акырта торган гадәте юк иде. Сәгыйдулла ишек артыннан ишетелүче сүзләргә колак

салды. Аңлашылды, Геббельс чыгыш ясый. Пропаганда министрының тавышына Берлинда яшәүчеләр күнегеп бетте инде.

Сәгыйдулла, халатын киеп, гомуми бүлмәгә чыкты. Ишекне ачу белән Геббельс әйткән сүзләр аермачык ишетелде. Кинәт аларның мәгънәсенә төшенүдән башы әйләнеп китте. Ишек бусагасында катып калып, Геббельсның һәрбер сүзен йота иде ул. Радиодан аерылып, фрау Герда Сәгыйдуллага борылды. Нимес әбисенең күзләрендә яшьләр ялтырый.

– Сагди, сугыш, – диде ул, аннан ышанмасаң үзең тыңла дигәндәй, радиога ымлады. – Германия Россиягә һөҗүм иткән...

Бу вакытта вермахт гаскәрләре Советлар җирен рәхәтләнеп изәләр иде инде. Балтыйк диңгезенә гросс-адмирал Эрих Рёдер җитәкләгән хәрби диңгез флоты – нимесләр телендәге Кригсмарине суднолары кереп тулды. Күкне генерал-фельдмаршал Герман Герингның меңләгән самолётлары каплап алды – анысы Люфтваффе. Җирдә исә, арттан килүче пехотага юл чистартып, Панцерваффе танклары үкерә. Гудериан, Клейст, Гот, Гёпнер, Манштейн җитәкләгән танк төркемнәре үз юлларындагы бөтен нәрсәне тар-мар итә. Алар артыннан җимерелгән ныгытмалар ыржаеп кала. Әле анда, әле монда совет солдатлары, оборона тотып, нацистларга каршы торуны дәвам итәләр, ләкин бу аерым утраучыклар гына. Аларның башына җитәргә дип, нимес пехотасы ашыга...

***

Политбюро әгъзаларын янәдән Сталин кабинетына җыйганда, вакыт төшкә авышкан иде. Бүлмә ару гына тәмәке төтененә чумарга өлгергән.

– Укыгыз, – диде ул, Политбюро әгъзалары өстәл янына утыргач.

Молотов, кулындагы кәгазьне алып, тавышын баса төшеп, текстны укырга кереште. Укып бетергәч тә, Сталин һавага чираттагы төтен болытын җибәреп, Молотовка эндәште:

– Ахырын үзгәртергә кирәк, иптәш Молотов, каләм ал да болай дип яз. – Ул янә тәрәзә каршына килеп басты. – Хакыйкать безнең якта. Дошман тар-мар ителәчәк. Без җиңәчәкбез.

– Дөрес сүзләр! – Каганович, гадәттәгечә, кирәксә-кирәкмәсә куштанланусыз булдыра алмады.

– Сез ничәдә чыгыш ясарга телисез, иптәш Сталин? – дип сорады Калинин, каршындагы кәгазьгә нидер теркәргә әзерләнеп.

– Мин? – Сталин Политбюро әгъзаларына таба борылды. – Ә нигә мин чыгыш ясарга тиеш?

– Соң, иптәш Сталин, сез коммунистлар партиясе һәм совет хөкүмәте башлыгы бит...

– Менә шуңа күрә минем бүген чыгыш ясавым дөрес булмас, – диде Сталин. – Иптәш Молотов безнең мөрәҗәгатьне радиодан укыса, шул җитәр.

– Ләкин...

– Без әлегә кадәр фронттагы хәлләрне ахыргача белмибез. Барысы да ачыкланып беткәч, мин төпле һәм конкрет белдерү белән чыгыш ясаячакмын. Ә хәзергә без бу бурычны иптәш Молотовка йөклик. Уникедә сезнең тавышыгызны радиодан ишетермен дип өметләнәм. – Сталин каршы

төшмәслек итеп әйтте. Политбюро әгъзалары, бу сүзләрнең ни аңлатканын төшенергә тырышып, урыннарыннан торды, сәер бер хис белән ишектән чыктылар.

***

Төшке ашка чакырып, кыңгырау яңгырау белән Сәкинә, станок артыннан торып, завод ашханәсе ягына юл алды. Ләкин урамда аларны ашханәгә түгел, ә заводның төп мәйданчыгына борып җибәрделәр. Бирегә шулай ук башка цехлардан хезмәткәрләр агыла иде. Димәк, берәр төрле митинг-мазар оештырылачак. Әбәт вакытын гына киметмәсеннәр, ни теләсәләр шуны сөйләсеннәр, түзәрбез дип уйлап алды Сәкинә.

Мәйдандагы төп трибунага директор үзе менде. Сирәк була торган хәл, димәк, чыннан да зур кунаклар килгән бүген. Ләкин завод директоры янында бернинди кунак та күренмәде, үзе дә ул әле генә начальствоның кайнар кулына эләккән кеше төсле кабалана, йөзеннән нур качкан. Үзе тирәсендә йөгерешкән кешеләрдән әледән-әле нидер сорый, тизрәк маташырга куша. Ниһаять, зур динамиклар шатыр-шотыр килә башлады, аннан соң мәйданга радио тавышы сибелде. Башта музыка яңгырады, аны үзәк радиода берәр төрле зур җитәкче чыгышы алдыннан куялар иде.

Левитан сөйли башлады. Ул тышкы эшләр буенча халык комиссары Вячеслав Михайлович Молотов мөрәҗәгать ясаячагын игълан итте.

– Гражданнар һәм гражданкалар! – диде Молотов тавышы. – Совет хөкүмәте һәм аның башлыгы иптәш Сталин кушуы буенча мин сезгә хәзер яңгыраячак белдерүне җиткерәм. Бүген, иртәнге сәгать дүрттә, Советлар Союзына бернинди дәгъва да белдермичә, Германия гаскәрләре безнең илгә һөҗүм ясап, күп урыннарда безнең чикне бозды, Житомир, Киев, Севастополь, Каунас һәм кайбер башка шәһәрләребезне үзләренең самолётларыннан утка тотты, ике йөздән артык кеше һәлак булды һәм яраланды...

Аннан соң Молотов авызыннан чыккан сүзләрне Сәкинә инде аңламады. Акылы белән кабул итәрлек хәлдә түгел иде ул. Күз алдына хәрби форма кигән улы Хәмит килеп басты. Ул бит армия хезмәтендә, Мәскәү янындагы частьтә! Хәзер аны сугышка ташлаячаклар! Язмыш Сәкинәдән бердәнбер улын да тартып алырмы икән?!

Тыела алмый, Сәкинә үксеп елап җибәрде. Акрынлап, завод хезмәткәрләре арасында да елаучылар күбәйде. Ир-атлар гына тынычлыгын югалтмады, «Безнең армиябез көчле, күз ачып-йомганчы юк итәчәкбез», – дигән сүзләр белән бер-берсенең күңелен күтәрергә тырыштылар.

Молотовның чыгышыннан соң завод директоры, бер стахановчы трибунадан ялкынлы сүзләр сөйләде. Хәрби завод булгач, хәзер аларга икеләтә көч түгеп эшлисе була. Сәкинәнең яшьле күзләре алдында исә форма кигән улы гына тора... Бу сугышның яман булачагын ул әниләргә генә хас тоемлау хисе белән аермачык итеп аңлады...

Улы белән күрешергә насыйп булмады Сәкинәгә. Сугыш башланып, озак та үтми, ул эшләгән заводны Ленинградтан эвакуацияләделәр. Югары класслы хезмәткәр буларак, Сәкинә дә эвакуацияләнүчеләр исемлегенә эләкте. Озын-озак юллар үтеп, Сәкинә беренче һәм соңгы мәхәббәтенең Ватанына – Татарстанга килеп җитте. Биредә, Казанның Дәрвишләр

бистәсе дип аталып йөртелгән почмагындагы салкын баракта яңа тормыш башларга туры килә иде. Үзенең кайда төпләнүен хәбәр итеп, Ленинградта калган күршеләренә берничә тапкыр язды, улыннан хатлар килсә, Казанга җибәрүләрен үтенде. Ләкин хатлары җавапсыз калды...

***

Хәмидулла тагын бер мәртәбә төенчекләрен барлады. Бөтен әйберләрен дә җыйды кебек. Хәер, нинди малы булсын инде аның? Юлда ашарга дип яшереп җыелган сохари, кашык-тәлинкә, тагын нindидер вак-төяк. Аннан, көрсенеп, тирә-ягына күз салды. Шушы баракта сигез ел гомере үтеп китте бит! Сигез ел гомер – сигез тапкыр сикерү түгел, сиксән төрле газап күрде аның башы... Лагерь тоткыны «стажын» исә намус белән ун елга ук тутырды.

Күрде аның башлары, күпне күрде, бәлки, артыгын да күргәндер. Ләкин язмышына буйсыну, барлык газап-михнәтләрне дә насыйбы итеп кабул итү, туган ягында газиз хатыны белән баласы, кечкенә оныгы көтүен тою аңа яшәү көче бирде. Бүген инде менә бу тормыш белән бәхилләшәсе, үткәннәргә кире кайтасы...

Хәмидулла, авыр сулап, бараktan чыкты һәм лагерь аша җитәкчелек бинасына юнәлде. Бүген иртәнге ашка да бармады ул. Лагерь үзе бушап калган – бригадалар күптән инде урман кисәләр. Ә аңа иреккә чыгасы...

Лагерь начальнигы янына эләгү авыр булмады Хәмидуллага – ишек төбендә чиратка тезелгән кешеләр юк иде. Ул, әйберләрен ишек катында калдырып, кабинет бусагасын атлады.

– Гражданин начальник, мин килдем, – диде Хәмидулла, төз басып торырга тырышып. Ләкин тыныч кына тору ничектер килеп чыкмады. Барлык бүгенге көн аңа төш сыман тоела иде. Лагерь башлыгы, башын күтәрми генә Хәмидуллага карап алды һәм аны күрмәгән дә сыман кабат каршындагы кәгазьләргә чумды. Сабырлыгын җуя башласа да, Хәмидулла дәшмәде, түзде. Өстәлдә ул таушалып беткән папканы абайлап алды. Бу нәкъ менә аның «эше» иде... Ниһаять, начальник, каршындагы кәгазьләрне читкә этәреп, Хәмидулланың папкасына үрелде.

– Тәк, – диде ул, ялкау кыяфәт белән анда беркетелгән кәгазьләрне актаргалап. – Аңлашылды. Троцкист, димәк? – Һәм янә маңгай астыннан гына Хәмидуллага караш ташлады. Хәмидулла дәшмәде. – Троцкист, – диде үз-үзенә начальник. Аннан, нindидер кечкенә генә кәгазь алып, әледән-әле папкага күз салгалап,ниләрдер язарга кереште. Хәмидуллага лагерь начальнигы махсус вакыт суза төсле тоелды. Тоелса да, янә дәшмәде. Ни әйтсен? Тизрәк бул, дисенме? Әллә үзен кулга алганчы, дөньяда Троцкий барлыгын белмәгәнлеген дә әйтсенме? Дәшмәвең кулайрак.

Ниһаять, лагерь башлыгы теге кечкенә кәгазьне тутырып бетерде. Тагын бер кат папкадагы мәгълүмат белән чагыштырды. Аннан кәгазьне Хәмидуллага сузды.

– Транспорт бирә алмыйбыз – кайту ягын үзең кара. Кайткач та, яшәү урыны буенча хисапка басасың. Монда кире эләгәсең килмәсә, озакка сузма. Хокукларыңны без торгыза алмыйбыз, анысын, кирәк булса, кайткач карап бетерерсең. – Начальник әлеге сүзләрне әйткән вакытта Хәмидулла

кулындагы кәгазь кисәге – аңа ирек бирүче кәгазь кисәге! – ут кебек янган төсле тоелды. Тизрәк әйтеп бетерсен дә бу каһәр суккан урыннан чыгарып кына җибәрсеннәр! Хәмидулланы ишеткәндәй, начальник ишеккә таба кычкырды: – Петров!

Ишектә мылтык тоткан хәрби күренде.

– Тыңлыйм, иптәш начальник!

– Гражданинны озат, ул бүгеннән ирекле.

– Яхшы. Минем арттан атлагыз.

Төш булдымы бу, өнме? Чынбарлыкмы, уйдырмамы? Мамык төсле йомшап киткән аякларына чак-чак баса-баса, Хәмидулла теге Петров атлы егет артыннан иярде. Егет тә түгел, малай-шалай гына ул. Ләкин бу малай-шалай аңа хәзер Гайсә пәйгамбәр шикелле күренде. Менә бит ул – Хәмидулланы читлектән иреккә алып чыгучы! Күпме көткән көне килеп җитте, ул көн ябык гәүдәле чандыр Петров озатуында килгән икән! Һәм ул Хәмидулла артыннан лагерь капкасын шартлатып ябып калачак!

Кырык газап аша узса да, лагерьдан исән-имин чыгып китү Хәмидуллага иң газаплысы булып тоелды. Ләкин әлеге газап та озакламый артта калды. Урманга кереп югалганчы, Хәмидулла соңгы тапкыр артына борылып карады. Чәнечкеле тимерчыбык, мылтыклы каланчалар белән уратып алынган дөнья белән бәхилләште. Ходайдан бүтән беркайчан да бу дөньяга кайтармавын ялварып, белгән догаларын укый-укый, Хәмидулла юлга кузгалды. Кайтыр юлга.

Туган авылының кай якта икәнлеген Хәмидулла эчке тоемлау белән генә чамалый иде. Мари урманнарының үзләреннән шактый еракта икәнлеген беләә, ләкин, һәрхәлдә, бу җирләр Беломорканал белән чагыштырганда, кул сузым гына арасы.

Юлда Хәмидуллага бернинди атлы да, җәяүле дә очрамады. Ул туктамый, ашау-эчүгә вакыт әрәм итми, алга атларга карар кылды. Юлы әле дә булса урманнан чыга алмый, әйтерсең, менә хәзер арттан этләр өрүе ишетелер, әйтерсең, аны менә-менә эләктереп алырлар шикелле тоела иде, шуңа күрә ашыгырга, лагерьдан мөмкин булганча ерагаерга кирәк.

Инде караңгы төшкәндә, Хәмидулла урман аланында берничә йортны, аларның тәрәзәсендәге утны абайлап алды. Боларга кереп кунаргамы, әллә урманда гына төн чыгасымы? Җәйге төн булуга карамастан, мари урманнарында караңгы төшү белән бермә-бер салкынайта. Салкыны ярар, аңа күнегелгән. Аю яисә бүре килеп чыкса, нишләр? Тоткыннар урман кискән җиргә ерткычлар көпә-көндез килеп йөриләр иде бит. Инде иреккә чыктым дигәннең икенче көнендә җанвардан ботарланып үлү бик үк күңелле булмас. Шуларны уйлап, Хәмидулла урман аланындагы кечкенә генә авылга юнәлде һәм беренче өйнең тәрәзәсен какты. Аны гына көткәннәр диярсең, ишектән мылтык күтәргән агай атылып чыкты.

– Кем бар? – дип кычкырды ул Хәмидуллага марича.

Сигез елы юкка узмаган – бу якларда яшәп, Хәмидулла мари телендә дә аз-маз сукаларга өйрәнеп өлгерде.

– Төн кунарга кертмәссезме икән, караңгыга калдым, – диде ул, ишек ягынарак килеп. Аның каршысындагы кеше карап торышка Хәмидуллага яшьтәш кебек, мылтыгы булса да, явыз бәндәгә охшамаган.

– Кайдан буласың? – диде тегесе, мари сүзләрен ишеткәч, йомшый төшеп.

– Мин... Мин моннан ерак түгел туганнарга кайткан идем, кичекмәстән китәргә кирәк булды...

Ишек бусагасында, күрәсең, агайның карчыгы күренде, аның кулында керосин лампа иде.

– Кем бар анда, Абдай? – дип сорады ул, лампасын күтәрә төшеп. Ире хатынының кулыннан лампаны алды.

– Кем дә юк, Пайрам, бар, кер, чәй куй, – диде ул, кырыс кына кырт кисеп. Пайрам дигәне шунда ук өйгә кереп китте. Абдай исә, кулыннан мылтыгын җибәрми, керосин лампаны арлы-бирле йөртеп, Хәмидулланы күздән кичерде. – Аңлашылды. Качкынмы син?

– Юк... Мин...

– Кыяфәтеңә кара, нинди кунакка кайткан туган буласың, ди, син? Синең төрмәдән чыкканың әллә кайдан күренеп тора бит!

Хәмидулла Абдайны алдалап булмаячагын, бәлки, алдаларга кирәкмәгәнлеген дә аңлады.

– Әйе, мин лагерьдан. Ләкин мин качкын түгел. Менә, кирәк булса, документым да бар...

– Документыңны чыгарып азапланма. Исемең ничек?

– Хәмидулла...

– Син мари түгелмени?

– Юк, мин татар...

Абдай берара дәшми торды, башта мылтыгын, аннан лампасын төшерде.

– Әйдә, кер, Хәмидулла, бер төнгә кунак булырсың, – диде ул шактый йомшаган тавыш белән.

Өйгә узгач та, Абдай аңа кайда өстен салырга, букчасын кая куярга күрсәтте.

– Пайрам, чәеңне куй, дим! Минем хезмәттәш дустым кунакка килгән бит, танымый да торам. – Абдай Хәмидуллага күз кысты. Хатын-кызга артыгын белмәү яхшырак, янәсе.

Алар табынга утырдылар, Пайрам бәрәңге, ипи чыгарды. Абдай кайдандыр болганчык сыекча салынган шешә алып килде. Зур кырлы стаканнарны тутырып, әлеге сыекчаны салды. Хәмидулланың борынына сасы ис бәрде. Белә ул моның ни икәнлеген – көмешкә. Нишләргә соң? Эчәргә ярамый бит аңа.

– Нәрсә, дустың белән чәкешергә дә ояласыңмы хәзер? – дип Абдай шаркылдап көлеп җибәрде һәм стаканын күтәрде. Хәмидулла кушылмый чара тапмады.

Көмешкәне бераз гына йотып куйды ул. Анысы да җитә калды. Кинәт башы әйләнеп китте, эченә кайнар күмерләр салган төсле булды. Әчкелтем тәмне бетерер һәм ашказанындагы ялкынны басар өчен Хәмидулла тиз генә бәрәңгегә үрелде.

– Эчүнең ни икәнлеген син бөтенләй онытkансың, ахрысы, Хәмидулла, – дип, башын чайкап куйды Абдай һәм үзенә янә тутырып салды. – Мин сине кыстамыйм, шулай бераз йотып куйсаң җитәр.

– Сиңа да күп кирәкми, иртәгә таңнан юлга чыгасың бар, – дип үз сүзен кыстырды читтән ут янып карап торган Пайрам.

– Өйрәтмә, хатын, мин ни эшләргә икәнлеген үзем белермен.

Шактый гына салып алгач, Абдай, тәмәке тартыйк дип, Хәмидулланы урамга чакырды.

– Марича каян беләсең? – диде ул, төнге караңгылыкны тәмәке уты белән тишеп.

– Мин бит сигез ел бирелдә...

– Сигез... Срок... – Абдайның кинәт тавышы үзгәрде. Моңарчы булган көр күңелле, үз-үзенә ышанган агайның эзе дә калмады. – Ә сине ничек чыгарып җибәрделәр?

– Ничек дип, срогым тулды бит...

– Сугыш дип тә тормадылармы?

– Сугыш? Нинди сугыш?!

– Бүген Германия безгә һөҗүм итте.

– Германия?! Без дуслар бит!

– Кемгә дус, кемгә дошман... Менә шулай, сугыш башланды.

– Мин белмәгән идем...

– Димәк, иртүк чыгарып җибәргәннәр үзеңне. Безнең авылда да анымоны белүче юк, мин үзем станциядә эшлим, шуннан гына ишетеп кайттым.

– Монда тимер юл станциясе бармыни?

– Әйе, Казанга барып була, Чувашия ягында ул. Тик сиңа анда тыгылырга киңәш итмәс идем. Хәзер анда энкавэдэ кереп тулды, бөтен кешенең документларын тикшерәләр. Лагерьдан азат ителгәннәрне кулга алалар, диделәр. Яңадан. Гитлер безгә ныклап ябышкан, күрәсең, бик каты кыланалар. Син үз ягыңа басу юллары белән кайтырга тырыш, кеше күзенә артык күренмә. Мин иске киемнәремне, юлга ризык бирермен, калганын үзең карап бетер.

– Ничек бәхилләтим сине, Абдай?!

Абдай шаркылдап көлеп җибәрде:

– Бу заманалар бетеп, дөньялар тынычлангач, бер кунакка чакырырсың, яме? Әйдә, керик, юкса Пайрам теге шешәне яшереп куярга мөмкин, ә ул яшергәнне табам, димә. Эчмә син, теләгең юк икән – эчмә, мин үзем генә дә маташтырам аны. Син янәшәдә генә утырып тор...

...Алар кара төнгә кадәр утырдылар, иртән исә Абдай Хәмидулланы атына утыртып, олы юлга чыгарды, аз-маз кая барырга кирәклеген аңлатты да, бетмәс-төкәнмәс мари урманнары эченә кереп югалды...

Иртән-иртүк Нәсимә Зөбәйдәләргә ашыкты. Бибисара карчык үлеп киткәнгә ике елдан артык вакыт узган, аның вафатыннан соң йорт ничектер бушап калды, җылысы киткән төсле тоела иде. Зөбәйдә әнисен үзләренә күченеп яшәргә өндәп караса да, Нәсимә килешмәде. Көн саен диярлек килеп, Җиһангирның хәлләрен белеп торса да, кичләрен һичшиксез үз почмагына, үз өенә кайтып ята торган булды. Иртәләрен дә башта кызы белән оныгы янына ашыга. Җәйнең кызу печән өсте көннәре булуга да карамастан, иртәсен дә, кичен дә вакытын таба Нәсимә. Ул килгәндә, кызы белән оныгы инде торганнар, чәйләре әзер иде, Зөбәйдә Нәсимәне табынга чакырды. Сүз иярә сүз чыгып, әле анысын, әле монысын сөйләштеләр. Сөйләшүләре әлеге дә баягы Таһир явызлыгына барып тоташа иде. Хәтта өйләнеп, гаиләгә охшаш нәрсә корып җибәрүе дә аны үзгәртмәде, йомшатмады.

Берничә ел элек Таһир авылга яшь килен белән кайтып төште. Аны ул кайдадыр Казан тирәләрендә тапканлыгын авылда чышын-пышын килеп сөйләштеләр. Язылышуын да шунда язылышканнар, имеш, төп йортта туй-мазар уздырып тормадылар. Рәиснең хатыны шунда ук партия оештыручысы урынына билгеләнде. Аңа барча кешеләр, шул исәптән Таһир да Марфа Петровна гына дип эндәшергә тиеш иде. Марфа Петровна төрле чаралар үткәргәндә, урысча гына сөйләшә, үзенең стажлы коммунист булуын һәр очрашу саен кайта-кайта бәян кыла.

Марфа Петровна юан гәүдәле, симез битле, озын буйлы, таза бәдәнле хатын иде. Карап торышка ул Таһирдан олырак күренә, чынында да шулай булып чыкты. Шактый кырыс холкына карамастан, Марфа Петровна кичләрен салып алырга һәм урамга ишетелерлек итеп урысча җырлар җырларга ярата. Авыл халкы арасында ирле-хатынлы Таһир белән Марфаның шешәдәшләр булуы турында күп сүз таралды. Өстәвенә, Марфа Петровна, кешедән оялмыйча, кара яндырып, тәмәке тарта иде.

Нәсимә белән Зөбәйдәгә карата Марфа Петровна коры, кырыс, ләкин түземле булды. Дөресрәге, һәммә кешегә дә шундый мөнәсәбәттә иде партия оештыручысы. Кайвакыт басуга килеп, ызан буена басып, кемнең ничек эшләгәнен карап торырга ярата. Күн тужуркасының төймәләрен ычкындыра, тәмәкесен тартып җибәрә, берәрсенең ялкаулануын күрсә, катлы-катлы итеп сүгенеп тә куя. Нәсимә белән Зөбәйдә беркайчан да тел-теш тидерерлек урын калдырмый тир түгәләр, шуңа аларга бу тозлы-борычлы сүзләр кагылмады. Киресенчә, Таһир кайвакытта җыелышларда Тимерхановларны тиргәргә керешсә, кырыс Марфа Петровна: «Гаепләрен намуслы хезмәт белән юалар, тимә аларга», – дип, ирен курыкмыйча кеше алдында бүлдерә иде. Ә Таһирда ана белән кыз үзләренә карата сакланучы явыз үч барлыгын җаннары-тәннәре белән тоемлыйлар. Авыр эшкә билгеләве дә шуның нәтиҗәсе. Эшенә түзәрләр, балага гына зыяны тия күрмәсен, шунысы куркыта...

– Әби, – диде кинәт Җиһангир, – ә бабай кайчан кайтып җитәчәк?

Нәсимәнең күзләре дымланды, ләкин ул яшь аралаш булса да елмаерга тырышып, инде буй җитеп баручы оныгын кочаклап алды:

– Юлда ул, улым, юлда, менә-менә кайтыр. – Аннан кызына борылып, «ышаныгыз миңа, зинһар» дигән кыяфәт белән өстәде. – Күңелем белән сизәм, ул инде бик якын, бераз гына сабыр итик. Күпкә түзгәнне азга түзәрбез...

...Авылына якынлашуын Хәмидулла тәмле печән исеннән үк тоемлады. Хәлләре бетеп, озак юлдан аяклары кырылып сызланса да, еракта таныш түбәләрне, әрәмәлекләрне күргәч, ул атлавын тизләтте.

Авыл зиратына җиткәндә, инде тәмам караңгы төшеп бара иде. Зиратны ул танымады. Йа Хода, кайчандыр әйләндереп алынган читәннәр җимерелеп беткән, зират өстендә терлекләр йөргәнлеге күренеп тора, әле анда, әле монда сыер тизәкләре аунап ята!

Төенчеген калдырып, Хәмидулла әти-әнисе җирләнгән якка атлады. Аларның каберлегенең читәне дә, башкаларныкы шикелле үк, кыйшайган, ләкин баулар белән булса да маллар кермәслек итеп бәйләнгән. Күрәсең,

Нәсимә кулыннан килгәнчә карап тотадыр. Хәмидулла, әти-әнисе кабере янына утырып, дога укырга кереште.

Караңгы төшсә дә, авылы үзгәргәнлеге күзгә бәреп тора. Мәчетне ул, әлбәттә, тапмады. Нәсимә бу хакта табышмак телендә язып җибәргән иде. Авырлык белән булса да, Хәмидулла мәчетнең туздырылуын аңлады...

Авылга якынайган саен Хәмидулла акрынрак атлый иде. Күңелендә бушлык сизелә. Хыялың тормышка ашкач, һәрвакыт шулай була бит. Хыялланасың, теләгәнеңә ирешәсең, ә күңелдә исә «алга таба ни соң?» дигән сорау кала...

– Кайлардан килә бу юлаучы?!

Хәмидулла сискәнеп китте. Артына борылса, ат җигеп Нәгыйм абзый кайтып килә икән, арбасында шалтыраучы бидон тавышларын да ишетмәгән.

– Нәгыйм кордаш, исәнме! – диде Хәмидулла, чак кына ишетелерлек итеп. Нәгыйм, атыннан төшеп, Хәмидуллага якынрак килде.

– Кем соң син? – дип сорады ул, күзләрен чекерәйтеп карап, аннан йөзе үзгәрде. – Йа Ходай, Хәмидулла хәзрәт, син түгелме соң бу?!

– Мин, Нәгыйм абый, мин бу...

– Әстагъфирулла, зираттан өрәк чыктымы дип торам. Әйдә, утырыйк, дога кылыйк, – Нәгыйм, куш кулларын тотып, юл читендәге чирәмгә утырды да догасын пышылдый башлады. Хәмидулла аңа кушылды, амин иттеләр. – Карале, хәзрәт, сине дә исән килеш күрер көннәр бар икән бит! Йә, утыр әйдә арбага, Нәсимә янына кайтарып куям.

Авыл читендәге кечкенә кыйшайган өйгә җиткәч тә, Нәгыйм атын туктатты.

– Менә шушында яши хәзер Нәсимә, – диде ул, ниндидер гаепле кыяфәт белән, әйтерсең, мулла хатынын аның әмере белән бирегә күчергәннәр. Аннан кинәт күңелләнеп китте. – Хәзрәт, мин башта кереп сөенче алыйм инде, ә?!

– Нәгыйм, рәхмәт, ләкин син каршы булмасаң, мин үзем генә керим инде, яме. Аннан соң, синең бу тирәдә йөрүеңне дә ошатмаска мөмкиннәр... Сөенче күчтәнәче миннән булыр.

– Ә, ярый алайса, – диде Нәгыйм, кинәт боегып.

Ул Хәмидулланың әйберләрен алып, арбадан төшүен көтеп торды да юлга кузгалды. Аның арбасындагы бидоннар шалтыравы тәмам ишетелмәслек булганчы Хәмидулла өйгә керергә кыймый басып торды. Ниһаять, тәвәккәллек җыеп, ишекне ачты. Өй түрендә, ишектән күзләрен алмый, аңа текәлеп карап, Нәсимәсе басып тора иде. Агарган чәчләре иңнәренә сарылган, нык ябыккан, йөзе җыерчыклар белән чуарланган, тик күзләре, күз карашы – һаман да шул, аның кочагына унсигез яше дә тулмас борын кергән Нәсимә...

Таңга кадәр сөйләшер сүз, гәпләшер гәп бетмәде. Нәсимә йөгереп барып, кызын һәм оныгын чакырып килде. Инде кояш күтәрелергә күп калмаган вакытта дүртесе бер йортта татлы йокыга талдылар.

Хәмидулла ишекнең дөбердәп ачылуыннан уянып китте. Гадәттә, надзирательләр шулай барак ишеген тибеп ачалар иде. Мич башыннан тиз генә сикереп төшеп, кем бар икәнлеген карарга ашыкты, хатыны белән

кызы да уяндылар. Бусагада Таһир басып тора иде. Ул берара Хәмидулладан күзен алмады, аннан соң эчкә узды.

– Кайттыңмы, Хәмидулла хәз... Гражданин Хәмидулла?! – диде ул, әйтерсең, Хәмидулладан кыенсынып.

– Кайттым, Таһир энем, шөкер, исән-сау гына.

– Колхозга керерсең бит?

– Керми кая барыйм, керәм, әлбәттә. Тик районга барып, кайбер кәгазь эшләрен бетерәсе бар.

– Анысын беләм. Мин ни, кисәтергә тиеш... Зинһар, дин белән уйнама инде син, Хәмидулла абый, – диде кинәт тавышы үзгәргән Таһир. – Арты хәерле булмас, болай да күрдең...

– Күрдем... – диде Хәмидулла, көрсенеп.

Кинәт ишек янә ачылып китте һәм өйгә юан гәүдәле хатын-кыз атлап керде. Ул башта Хәмидуллага, аннан Таһирга усал караш ташлады.

– Нәрсә, контра, кайттыңмы? – диде ул, урысчалатып.

– Гафу итегез, сез кем буласыз?

– Минме?

– Бу безнең парторг, Марфа Петровна, – дип аңлатты Таһир. – Минем хатыным, – дип урысча өстәде.

– Безнең авылның иң куркыныч халык дошманы син ул, димәк?! – диде Марфа Петровна.

– Гафу итегез, ләкин мин...

– Беләм мин синең кемлегеңне. Контрреволюционер, троцкист, террорчы! Менә нәрсә, контра, мин сиңа бер генә әйтәм, икенче тапкыр кабатламыйм, яме? – Марфа Петровна урындыкка барып утырды, аякларын киң җәеп, ике тезенә ике куллап терәлде. – Син мулла булгансың бит, моны онытырга кирәк. Бер авыз сүз муллалык ишетсәм, кире җибәрәм, бу юлы кайтмаслык итеп. Икенчедән, мин ни кушсам, шуны эшлисең. Бу авылда мин хуҗа. Калганын яши-яши аңлашырбыз. Мин синең кебекләргә юл куя торган кеше түгел. Хатының белән кызың яхшы беләләр – эш кешесен мин хөрмәт итәм. Ялкауларны җенем сөйми. Килешеп эшлибез икән – башың сау булачак. Кирегә сукаласаң, халыкны котыртсаң, үзеңә үпкәлә.

– Мин колхозга керергә дә, намуслы хезмәткә дә риза.

– Риза икән, килештек. Районда документларыңны ясатканда, каршылык чыкса, мин ярдәм итәрмен. Колагыңа киртләп куй – синең срок тутырып кайтуың ул әле гаебең бетте дигән сүз түгел. Кырын эшләрең белән гомерлеккә гаепле булып калдың. Колхоз хезмәте аша бурычыңны кайтарырга туры киләчәк, шылдымы?

– Аңладым, гражданка парторг.

Марфа Петровна белән Хәмидулланың карашлары очрашты. Хәмидулла үзенең күзләрендәге сагышның сәбәбен аңлый, ләкин нигә менә Марфа Петровнаныкы да аныкына охшаш?!

– Миңа гражданка, димә. Мин Марфа Петровна. Таһир, киттек әйдә, иртә баштан кешенең башын әйләндереп йөрмик.

Сугыш дөньяны бик нык үзгәртте. Хәмидулла колхозга керде, кушкан эшләрне үти башлады. Җитәкчеләрнең аңарда кайгысы калмады. Рәис белән парторг тыз-быз районнан колхозга, колхоздан районга чаптылар. Планнар,

йөкләмәләр арткannan-артты. Сугыш акрынлап, авылдагы кешеләрне үзенең канлы кочагына чакыра торды. Повесткалар күмәк исемлек рәвешендә килә башлады. Озату да күмәк иде. Чираттагы чакырышларның берсе белән фронтка Таһир да китеп барды. Аның урынына колхоз рәисе дә, парторг та булып Марфа Петровна берүзе калды...

Әллә сугыш афәте тәэсир итте, әллә яшь ир-атларның фронтка китүе йогынты ясады, әллә Таһирны озату уйланырга мәҗбүр итте, ләкин Марфа Петровна ничектер басылып, тынычланып калды. Тәмәкесен дә тарта, көмешкәсен дә эчә, әче итеп сүгенүдән дә туктамый, ләкин боларның барысын да, әйтерсең, ничектер җылырак, кешелеклерәк итеп кылана иде җитәкче хатын. Хәмидулла да аның дуамаллыгына күнде. Аннан соң, Марфа Петровна Хәмидулланың булдыклы, кулыннан эш килә торган ир икәнен күрде. Хезмәт кешесен барыбер хөрмәт итәсең, элеккеге мулланың тырышлыгы җитәкче хатынның күңеленә хуш килде. Хәер, башка колхозчыларга да артык нык каныкмый. Икенче яктан, каныгырга вакыты да юк инде – районнан кайтып керми, тегесен әзерләү, монысын әзерләү планы белән башны катыралар.

Җәй азагына авылга егермедән артык бала-чага килеп төште – аларны җигүле атлар белән Казаннан ук алып кайттылар. Бу – Ленинградның балалар йортыннан эвакуацияләнгән сабыйлар иде. Үзенең баласы булмагач, болар белән маташу Марфа Петровна өчен тагын бер шөгыльгә әйләнде. Балаларның күпчелеге сүгенү һәм гамәлләр ягыннан Марфаның үзен дә уздыралар, шуңа күрә тәрбия эшләрен ныклап үткәрергә материал җитәрлек иде монда. Сабыйларны, йортларының иркенлегенә карап, икәүләп, өчәүләп, авыл халкында урнаштырдылар. Ике сабый – җиде яшьлек Нюра белән алты яшьлек Максим Хәмидуллаларга тапшырылды. Марфа Петровна балаларны бүлү белән үзе шөгыльләнә иде, кичке якта тарантасына утырып, нарасыйларны Хәмидуллаларга китерде.

– Кара аны, Хәмидулла, бу – урыс балалары, аларны исламга өйрәтеп ятма тагын, – диде ул, авызын кыйшайтып елмаеп. – Православныйлар, үз диннәреннән яздырып, өстеңә гөнаһ алма, диюем.

– Үзләре белер инде, Марфа Петровна, мин андый нәрсәгә кысылмыйм.

– Тагын халык котыртасың дип ишеттем...

– Анысы ни белән тагын?!

– Имештер зират өстен чистартырга, читәнен тотып алырга кирәк дисең, мал кертү ошамый икән...

– Мин генә түгел, бөтен халык ул хакта сөйли, Марфа Петровна. Мәрхүмнәр җәсәде бит, әрвахлар өстендә терлек нәҗесе аунап яту бер дә дөрес түгел. Болын бетмәгән, ә читәнен бөтен авыл халкы дәррәү күтәрелеп, колхоз малына зыян салмый гына акрын гына эшләр идек...

– Артык масая башладың әле, картлач, – дип черт итеп төкереп куйды колхоз рәисе. – Ул зиратыңны миңа кадәр үк терлек кертеп таптатып чыгарганнар иде, миңа кеше гөнаһысы кирәкми. Ләкин синнән башка бу мәсьәләне беркем дә күтәргәне юк, шуңа күрә тик кенә утыр, телеңне тый, зират мәсьәләсен онытЫ, яме. Сукбай булып йөрмәсен бу балалар, хезмәт белән тәрбияләгез.

Марфа Петровна тәмәкесен җиргә ташлап, кирза итеге очы белән җиргә батырды да тарантасына утырып, дөбер-шатыр авылга таба төшеп китте.

Нюра белән Максим башта тыйнак кына утырсалар да, акрынлап ачыла, ияләшә башладылар. Нәсимә урысча бөтенләй дә белмәсә, Хәмидулла рәхәтләнеп тәрҗемә итә. Кичке якка Җиһангирны ияртеп, Зөбәйдә дә килеп җитте. Балалар акрынлап таныштылар, тел белән бер-берсен аңламасалар да, ишарә белән аралашырга тотындылар. Ахыр чиктә Җиһангир аларны урамга алып чыгып китте, һәм балаларның чыр-чу килеп уйнавы кояш баеп авыл дөм караңгылыкка чумганчы тирә-юньгә яңгырап торды.

Марфа Петровна карары белән мәктәп бинасында балалар йорты оештыруга керештеләр. Район үзәгенә барып, дөресе-ялганы белән колхоз рәисе егерме биш сәке, аларга мендәр-юрган кебек кирәк-яраклар алып кайтты.

– Азык-төлекне дә бирергә тиешләр, ләкин бу шартларда аны җиңел генә алып булмый. Йә, аптырамабыз, ярмаларыбыз бар, көн дә фермада сөт савыла. Егерме биш вак тамакны гына ничек тә туйдырырбыз, – диде Марфа Петровна.

– Ә сөт тапшыру планы? – Фазылҗан аңа кинәт гаҗәпләнеп карады. Балалар килгәч тә, Марфаны алмаштырып куйдылар диярсең. Ул чебешләрен кадерләп җыеп утыручы тавыкка охшап калды.

– Йә план, йә норма буенча балаларга каралган азык-төлек. Азык-төлек бирмәсәләр, планны киметсеннәр.

– Тәрбиячеләр, ашчылар булырга тиеш бит бередә.

– Ашчы итеп Нәсимәне куябыз. – Фазылҗанның сискәнүле карашына Марфа Петровна игътибар да итмәде. – Тәрбиячегә Зөбәйдәне. Бер төнге каравылчы да кирәк булачак, анысына авылдан берәр әбекәйне син табасың. Аңладыңмы?

Фазылҗан башын какты.

Яңа эшкә билгеләнү хәбәрен ана белән кызы башта ышанмыйча кабул иттеләр, мыскыл итәләр, көләләр дип уйладылар. Ләкин балалар белән шөгыльләнә башлагач, әлеге шикләр юк булды.

Балалар йортын җылылык, мәхәббәт белән тутырды алар. Марфа Петровна көн саен кереп, нарасыйларның хәлләрен белешеп чыга. Ризыктан өзмәде, районнан да бар мөмкин булган нәрсәләрне талашып булса да алып кайта.

Аларны Казаннан мәгариф наркомы вәкилләре дә тикшереп китте. Марфа Петровна һәркайда озата йөрде. Балаларның чисталыгына, сәламәтлегенә, йоклаган урыннарына, ашаган ризыкларына игътибар бигрәк тә зур булды.

– Ничә кеше эшли? – дип сорады нарком вәкиле.

– Өч.

– Нинди вазифаларда?

– Тәрбияче, ашчы, төнге каравылчы. Каравылчыбыз әби кеше, төнлә балаларга берәр нәрсә кирәксә, ярдәм итә ала, – диде Марфа Петровна.

– Ничә яшь инде ул әбигә? Кайда ул хәзер?

– Өендә, йоклый. Аның каравы төнлә йокламый. Әбиебезгә быел җитмеш тула.

– Җитмеш?!

– Унсигез яшьлекләр кайда икәнлеген үзегез беләсез, иптәш инспектор. – Марфа Петровнаның ачуы кабарды. – Әле ярый әбиләребез бар.

– Ник аны монда чакырмыйсыз? Миңа ул әбиегезнең санитар хәлен күрергә кирәк.

– Йоклый, законлы ялда дидем бит инде, – Марфа Петровна уфтанып куйды, бөтен кыяфәтенә «кайчан бетә бу?» дип язылган иде. – Санитар хәле бик шәп аның. Татар әбиләре пычракка батып йөрми, барысы да чиста-пөхтә. Бетләре дә юк.

– Балаларның кием-салымнарын, урын-җирләрен кем юып тора? Кер юучы штаты да булырга тиеш сездә.

– Әле тагын норма буенча бу балаларга колбаса, атланмай, яшелчә дә бирелергә тиеш. Ләкин, нигәдер, күргәннәре юк, районга барган саен, безгә кадәр килеп җитмәде, диләр. Тиешләр белән аптыратмагыз, иптәш инспектор! Безгә җибәрелгән егерме биш баланың барысы да исән-сау, тамаклары тук, өсләре бөтен. Киемнәрен, әнә, ашчы белән тәрбияче юа. Юалар, ашаталар, тәрбиялиләр.

Инспектор, дуамалланып ук баручы Марфа Петровнадан өркеп калып, башка сораулар бирмәде. Районнан килгән вәкил генә, килеп туган киеренкелекне бетерер өчен:

– Һай, уңган да инде ул безнең Марфа Петровна! Көн саен килеп, балалар өчен әле моны, әле тегене таләп итә. Ашатулары колхоздан, бу нык хуҗалык... – дип, сүзне шаяртуга борды.

Тик Марфа Петровнаның ачуы сүрелмәде. Әйтерсең, юк-барга бәйләнеп, бу түрәләр аны түгел, ул өзелеп яраткан балаларны рәнҗеттеләр. Кунакларга ул чәй дә тәкъдим итмәде, салкын гына озатты. Аннан балалар йортына кереп, Нәсимә белән Зөбәйдәгә рәхмәт әйтеп чыкты. Марфа Петровна авызыннан яңгыраган рәхмәт сүзләре аеруча кадерле иде...

Соңгы вакытта Марфа Петровна белән Хәмидулла арасындагы мөнәсәбәтләрдә күп нәрсә үзгәрде. Авылда калган карт-коры, аксак-чулак ирләр арасында Хәмидулла иң ныгы иде. Тырышлыгын, эшне җиренә җиткереп башкаруны да колхоз рәисе күреп тора. Тыштан белгертмәсә дә, эчтән ул аны үзенең теләсә нинди эштә иң ышанычлы кешесе итеп күрә башлады. Хәмидулла сер дә саклый белә. Үзе көчле хатын булгач, Марфа Петровна җебек, умыртка баганасы сыек кешеләрне бик үк өнәп бетерми иде. Андыйларны йә үз кирәгенә куллана, ничек теләсә шулай боргалый, йә кимсетеп, мыскыл итеп, чүпкә чыгара. Ул Хәмидулланың рухи көчен тоя, шуңа үзе дә сизмәстән, аның янәшәсендә үзен хатын-кыз итеп хис итә. Ул да кеше бит – киеренке хезмәттә тәмам алҗыды, таяныр, киңәш бирерлек бәндә аңа да кирәк. Үзе дә сизмәстән, Марфа Петровна нәкъ менә Хәмидулланы шундый кешесе итеп сайлады.

Зөбәйдә белән Нәсимәне балалар йортына эшкә билгеләгәч тә, Хәмидулла икәүдән-икәү вакытта колхоз рәисеннән турыдан сорады:

– Марфа Петровна, нигә син минем кызымны кимсетмисең, мәсхәрәләмисең, измисең? Таһир аңа күз төшереп йөргәнен беләсең бит.

– Беләм. Тик кызыңнан курыкмыйм. Мин мәхәббәткә ышанмыйм бит, Хәмидулла. Мин көчкә генә ышанам. Синең кызың Таһирны борган икән, димәк, ул аны беркайчан да үзенә якын җибәрмәячәк. Хатын-кыз кабул итмәсә, ир кеше берни дә майтара алмый. Таһир минеке генә, мин аны үземнән җибәрмәячәкмен. Ләкин синең Зөбәйдәгә караганда, күрше

авылдагы чуваш кызларыннан күбрәк көнләшергә кирәк. Алар янына чаба алачак ул, синең кызың янына – юк. Кызың Таһир каршысында күренмәс стена салып куйды инде. Аны беркем дә җимерә алмаячак. Миндә көнчелек дигән хис юк. Гомумән, хис белән яшәргә ярамый. Уй белән, акыл белән яшәргә кирәк. Яисә синең кебек хезмәт белән. Калганы аның уйдырма гына, синең динең шикелле...

Юк, хисләргә ышана иде Марфа Петровна. Бәлки, Ходай аңа, Хәмидуллага бирмәгән шикелле, көнләшүне бирмәгәндер. Ләкин мәхәббәте булмаса, Таһирга ияреп, авылга кайтыр идемени? Бәгыре таш булса, балалар йортындагы нарасыйларны кайгыртып, райондагы түрәләр белән талаша-талаша, әле ризык, әле кием-салым юнәтеп йөрер идемени? Зөбәйдә сөйләгәнчә, кайвакытта колхоз рәисе аларга кергәләп чыга, балалар белән, «шалопай», «разбойник» дия-дия, күңелендә җыелып яткан ана назын чыгара. Хиссез кеше авыр сугыш чорында зур колхозны җитәкләп, планны тутырып, башка авыллардагы кебек хезмәткәрләрен бер башак өчен судка бирмичә яши алмый ул.

Көннәр арты көннәр үтте, авылда ир-атлар сирәгәя барды. Бер-бер артлы әле бер өйгә, әле икенчесенә моннан алданрак киткәннәрнең үлем хәбәрләре килә торды. Мәрхүмнәрнең якыннары, төн караңгылыгына ышыкланып, Хәмидулла янына киләләр иде. Авыл халкы мәрхүмнәрнең җәсәдләрен кайтаруны өмет итми, элеккеге мулладан якыннары рухына дога кылдырып, яу кырында ятып калганнарның җаннары тынычлануына гына өметләнә иде.

Яшьләрне олау-олау фронтка озата тордылар. Урамдагы радио тәлинкәсеннән көн саен Гитлерның җиңелү хәбәрен көтсәләр дә, шатландырырлык сүзләр һаман да яңгырамады.

Көзгә кереп барыш иде, вакыт соң. Кемдер Хәмидуллаларның ишеген сак кына шакыды. Хәмидулла ишек катына килеп, ачып җибәрде. Бусагада Гөлниса карчык – Таһирның әнисе басып тора иде. Гөлниса карчык тумыштан бөкре, шуңа да карамастан күп йөри, күп белә, күпне күрә.

– Сөбханалла, Гөлниса, әссәламегаләйкүм, түрдән уз, – диде Хәмидулла, ишекне киңрәк ачып, төнге кунакка юл биреп.

– Вәгаләйкемәссәлам, Хәмидулла, исәнме, Нәсимә сеңлем, – Гөлниса авырлык белән бусагадан узды, Хәмидулла күрсәткән сандык өстенә утырды. – Йәгез, бер дога.

Алар өчәүләшеп, дога кылдылар.

– Ни йомыш төште кара төндә, Гөлниса, бер-бер хәл булмагандыр бит? – Хәмидулла, гадәттә, үзенең янына хәвефле хәбәр белән генә килүләренә күнегеп беткән иде инде.

– Шөкер, әлегә берни булмады. Ләкин миңа күп калмаганлыгын сизәм, шуңа, бәхиллек сорарга дип, сезгә килдем. – Гөлниса күз читендәге яшен сөртеп куйды. – Безнең нәселдән сез шактый җәбер-золым күрдегез, безгә рәнҗергә дә, карганырга да хакыгыз бар.

– Гөлниса, бер дә карганмыйбыз...

– Каргансагыз да, гаеп түгел. Мин әйтим инде үз сүземне. Таһирым турында. Аны авылда иблискә тиң күрәләр, монысын да мин бик яхшы аңлыйм. Күрәсең, минем тәрбиям, денгә өндәвем җитеп бетмәгәндер. Барысы өчен дә тегендә баргач җавап тотармын. Ләкин бакыйлыкка күчкәнче, фанилыкта аңлашып

китәсем килә. Таһирым ялгышты. Сүз дә юк, бик нык ялгышты. Ләкин аның барлык кылган гамәлләре үз явызлыгы белән түгел. Силсәвит булып эшли башлагач, районга чакырттылар. Соң гына кайтты. Салган, яшермим. Улым, ник кәефең юк, дим. Әни, мулланы сөрергә кушалар, ди. Сөрмәсәң, үзең китәсең дип әйттеләр, ди. Бөтен кәгазьләрне әзерләделәр, ниләр әйтәсен аңлаттылар, ди. Төне буе үксеп елап чыкты. Мин дә аның белән бергә еладым. Зөбәйдәгезне нык яратты. Икенче көнне районга барып, мулланың гаиләсенә тидертмәүне килешеп кайтты. Таһир булмаса, сезне үзгә кеше сөргән булыр иде. Күрше авылларны күрдегез бит...

– Гөлниса, без Таһирга ачу тотмыйбыз бит, күптән кичердек инде аны, – дип тамак кырды Хәмидулла.

– Мин барыбер әйтергә тиеш. Мин гүргә бушанып китәргә тиеш. Кызыгызны яратты, дидем бит. Корсакка узганлыгын белгәч, үрле-кырлы сикерде. Баласын үземнеке кебек үстерәм, дип бәргәләнде. Сезнең кызыгызны аңлыйм – әтисен сөргән кешегә ничек кияүгә чыксын инде ул. Ләкин шул вакытта кавышкан булсалар, Таһирым бу юлга кермәгән булыр иде. Мәчетнең манарасын кисүне дә өстән куштылар. Аның башы җитә торган эш түгел иде бу. Күрше районнардан урыслар китертте, безнең авылдашларга бу эшне кушсам, шунда ук мине бәреп үтерәчәкләр бит, диде. Аннан соң инде, Зөбәйдә белән кавышу мөмкин түгел икәнлеген аңлагач, мин баламны бөтенләй югалттым. Ул эчә башлады, адәм рәтеннән чыкты, күрше авылларга чуваш кызлары янына йөрде. Сезнең рәнҗешләр дә, мәчет каргышы да башын бутагандыр сабыемның. Марфаны ияртеп кайтты. Кеше күзенә күренергә оят бит миңа! Мин инде үз җәзамны исән килеш алдым, өемнән чыгарга җөрьәт итмичә, кеше күзенә күренүдән тартынып, фани дөньяда ук тәмуг утында янам. Ләкин баламны барыбер өзелеп яратам, ул бит минем бердәнбер сабыем...

Гөлниса еламый иде. Күрәсең, күз яшьләре кипкән, ә сүзләре мең тапкыр йокысыз төннәрдә эчтән генә кабатланган, күңеленә уеп язылган...

– Хәмидулла, Нәсимә, миңа, минем балам Таһирга бәхиллек бирәсезме?

– Соң бит, Гөлниса, икегез дә исән-сау бит...

– Минем көннәр санаулы, Таһирым да ул уттан исән кайтмас. Аны бит, җитәкче булгач, армиягә алмыйлар да иде, үзе теләп, кат-кат гаризалар язып китеп барды. Әллә аңа бөтен бу газапларны күтәрү җиңел, дисезме? Тәмуг кисәве буласын белде, үзе минем кулымда шуны кабатлап, кат-кат үксеп елады.

– Риза-бәхил, Гөлниса,– диде Нәсимә, күз яшьләренә буылып.

– Риза-бәхил, Гөлниса, – дип, Хәмидулла Гөлнисаның кулын учларына алды. – Икегегезгә дә риза-бәхил. Мин инде күптән ачу тотмыйм, язмыштан узмыш юк. Тәмуг кисәве дип ашыктырма, Аллаһы Тәгалә кичерүчән ул. Күңеле чиста бит, үзең әйтеп торасың. Аның ярлыкау соравын кабул итми калмас, иншалла. Ә мин Таһирның исән-сау әйләнеп кайтуын теләп, һәрвакыт догада булырмын.

– Кайтмаса, аңа үзенә җиңелрәк булыр, Хәмидулла. Бөтен кеше дә син түгел, кичерүчәнлек һәркемгә дә бирелмәгән. Марфага да ачуланма. Болай начар кеше түгел ул, аны да язмышы ботарлаган. – Гөлниса карчык урыныннан торды. – Ярый, хәзрәт, кайтыйм инде, вакыт соң...

– Гөлниса, бер генә үтенеч бар, ярдәм итә алмассыңмы?

– Нинди үтенеч?

– Марфа белән сөйләшеп булмыймы?... Зират өстен тәртипкә китерәсе иде. Тизәктән чистартып, коймаларын тотасы иде бит.

– Вәгъдә итә алмыйм, хәзрәт, ләкин кулымнан килгән кадәресен эшләрмен. Хуш, тыныч төннәр үзегезгә!

Атна ун-көн дә үтми, Марфа Петровна Хәмидулланы кәнсәләргә чакырып алды һәм, теләге булган кешеләрне оештырып, эштән соң зират өстен чистартырга рөхсәт бирде. Койма тотар өчен колхозның иске-москы такталарын кулланырга кушты. Кышкы суыклар җиткәнче авылның карт-корысы, бала-чагалар һәм әби-чәбиләр белән берлектә зират өстен тәртипкә китереп, матур гына койма белән уратып та алдылар. Ә инде беренче кар төшкән көнне авылга хәбәр килеп төште – рядовой Таһир Фәтхуллин сугышта күрсәткән батырлыгы өчен медаль белән бүләкләнгән иде.

***

СС гаскәрләренең штурмбанфюреры Ганс Шахт хәзер инде кайчандыр Берлин сыраханәсендә клиентларның заказларын үтәгән барменга бер дә охшамаган иде. Ул буйга үсеп киткән, тумыштан ак чәчләре матур итеп артка таралган. Кителенә күз салсаң, шаккатмалы – нәфис буена туры китереп тегелгән кием, әйтерсең, аның төз сынына сыланып ук тора. Ганс җитәкчелегендәге айнзацтөркем солдатлары нацистлар кулына төшкән Киев шәһәренә кергәндә, биредә инде бәрелешләр тынган, җимереләсе җимерелгән, атыласы атылган иде. Айнзацтөркемнең төп максаты – Рейх кулына төшкән җирләрне кирәкмәгән элементлардан чистарту, тәртип урнаштыру, җирле халыкны яңа тормыш кагыйдәләренә күндерү. Тылда хезмәт итсәләр дә, Россия җиренә аяк басу белән айнзацтөркем вәкилләре биредә тыл да фронттан ким түгеллеген тиз аңлады. Советлар халкы бер дә бирешергә җыенмый, котырган эт төсле әле бер яктан, әле икенче яктан килеп бәйләнә. Урманнарда партизаннар күбәя башлады. Тыныч йоклау түгел, көндезен дә як-якка каранмыйча йөреп булмый иде.

Кирәксез элементлар икәү иде – коммунистлар һәм яһүдләр. Айнзацтөркем яулап алынган җирләрдә калган халыкны иләк аша үткәреп, эшкә яраклыларын Рейхка җибәрергә, йә булмаса урында үзләре тиеш дип санаганча язмышларын хәл итәргә тиеш иде. Коммунистлар белән яһүдләргә карата йомшаклык күрсәтергә ярамавы телдән яңгыраган инструкцияләрдә кат-кат кабатланды.

Совет дәүләте немесләрне бөтен явызлыгы белән каршы алды. Киевка кергәч тә, көпә-көндез үзәк урамнарның берсендә каты шартлау яңгырады – коммунистлар, шәһәрдән чыгып китешли, кибетләргә, күпсанлы биналарга миналар куеп калдырган булган. Шактый гына немес солдаты һәлак булды, имгәнүчеләр дә җитәрлек. Ганс Шахт җитәкчелегендәге махсус төркем гаепллеләрне эзләп табарга тырышты. Әйе, шартлаткычны совет гаскәриләре куйган һәм Киевтан чыгып киткән. Ләкин кемдер детонаторга басып, миналарны шартлаткан бит! Диверсион отряд шәһәрдән чыгып качарга тиеш түгел. Әмма беркем дә үз өстенә җаваплылык алмады. Бу мәсьәләдә уңышка ирешә алмагач, Ганс икенчесенә алынды. Ул да булса, шәһәрдәге

яһүдләр өчен гетто төзеп, халыкны шунда туплау. Монысы әллә ни кыен эш булмады. Урамнарда белдерүләр элеп куйдылар, яһүдләргә билгеләнгән урынга килергә кушылды. Әйтелгән сәгатькә, төенчекләрен күтәреп, халык ташкыны агылды. Биредә картлар да, яшьләр дә, балалар да, гарип-горабалар да бар иде. Ганс – әлеге әтрәк-әләмнәрнең язмышларын хәл итәсе кеше...

Урамнан барганда, бер читтәрәк Ганс дүрт танкны күреп алды. Күрәсең, икесе яу кырында зыян күргән, аларны калган ике танк буксирга алган. Хәзер танкистлар туктап, иртәнге ашларын ашый иде. Аларның берсе СС офицерын танып алды:

– Штурмбанфюрер, Хайль Гитлер! – дип сәламләп, ул Ганс каршына атылып чыкты. Дегеткә һәм тузанга баткан танкистның Вильгельм булуын Ганс тавышыннан гына аңлады, таныгач та рәхәтләнеп елмаеп җибәрде.

– Вилли, сәлам! Син дә биредәмени?

– Биредә, Ганс! – Вильгельм шатлыгыннан май кояшы төсле балкый иде. – Сиңа форма бигрәк тә килешә!

– Син дә кимен куймыйсың, чын Рейх солдатына әйләнгәнсең дә куйгансың! Рейх дошманнарын тар-мар итеп буламы, егеткәй?!

– Була да, булмый да, – диде Вильгельм, чын күңелдән кәефе кырылып. – Танкка снаряд эләкте, хәзер менә төзәтергә алып барабыз. Беренче генә тапкыр снаряд эләкми дә үзе, моңарчы зыянлы түгел иде. Бусы хәрәкәт итү системасына зыян китергән...

– Иң мөһиме үзең сау-исән, Вилли! Танк тимер генә ул, төзәтелер!

– Ә син нинди хезмәттә?!

– Беләсең бит инде, мин ССка гариза биргән идем. Менә, хыялым тормышка ашты. Сезнең танклар эзеннән барып, калдык-постык дошманнарны юк итәбез, тормыш киңлеген әшәке элементлардан чистартабыз.

– Аңлашылды, – диде Вильгельм, янә кәефе китеп, нидер хакында бик нык уйланып. – Ә мин Гудериан кулы астында хезмәт итәм.

– Кара әле, легендар генерал белән бергә! – дип, тел шартлатты Ганс. – Сез кайларда фатирда?

– Фатирда түгел, без әле килеп кенә барабыз, механиклар урнашкан җирне табарга кирәк.

– Бәлки, кичкә очрашып, яшь чакларны искә төшерербез? Мин әнә теге бинада эшлим. – Ганс свастикалы кызыл әләм эленгән йортка төртеп күрсәтте.

– Килештек, Ганс, килеп чыгарга тырышырмын!

Ганс СС солдатлары озатуында юлын дәвам итте, Вильгельм иптәшләре янына юнәлде.

Гансның юлы тимерчыбык белән әйләндереп алынган мәйданга килеп төртелде. Биредәге СС сакчылары аңа честь бирде һәм эчкә үткәрде. Ганс, ышанычлы адымнар белән атлап, геттоның коменданты утырган бинага юнәлде. Комендант аны сәламләп, күрсәтмәләр тыңларга әзер булуын әйтте. Ганс кулындагы күн чемоданыннан берничә бит кәгазь чыгарды һәм комендантка сузды.

– Бүгенге исемлек, колоннаны оештырыгыз, – диде Ганс, кискен итеп. Комендант кушканны үтәргә ашыкты.

Вильгельм белән очрашу Гансның кәефен җибәрде. Вилли беркайчан да нацизм идеяләрен якламады. Гансның үз вакытында ССка язылуын да өнәп бетермәде. Сыраханәдә бергә эшләгәндә дә, гел бәхәсләшәләр иде бит алар. Ярый, Вильгельм солдат хезмәтендә, Рейх хезмәтендә. Ләкин аларның икесенең хезмәте ике төрле кебегрәк. Вильгельм хезмәте – мактаулы, ә менә Гансныкы... Каһәр төшкере уйлар! Юк, Ганс барысын да дөрес эшли! Ул немец халкы дошманнары белән аяусыз көрәш алып бара. Һәм, әлбәттә, туган иле, газиз фюреры өчен ул ниндидер танк йөртүчесе белән чагыштырганда, биниһая күбрәк файда китерде!

Ул комендатурадан чыкканда, исемлектә аерып алынган яһүдләр инде колоннага тезелеп басканнар иде. Ганс аларны күздән кичерде. Үз куллары белән сайлап алды ул аларны. Балалар, хатын-кызлар, картлар, авырулар... Һәрберсенең һөнәренә игътибар итте – Рейхка файдасы тиярлек бәндә түгелме? Яшен, авырлыгын, табиблар куйган аерым искәрмәләрне кат-кат укыды. Болар арасында Рейхта берәр төрле хезмәт күрсәтерлек беркем дә юк иде.

Колоннадагылар агарынган, куркынган. Кемнеңдер баласы елап җибәрде. Кайсылары мыгырдый-мыгырдый, әллә дога укый, әллә саташып, нидер сөйләнә. Ләкин күпчелек яһүдләр тыныч, берни дәшмиләр. Алар инде, әйтерсең, үлгән. Гүя, җаннары ирекккә, җәннәт нигъмәтләре өелгән урынга китеп барган да, биредә җилдә селкенеп торучы тәннәре генә басып калган.

– Киттек, – диде Ганс. Автоматчылар колоннадагыларга мылтыклары белән төрткәләделәр. Колонна кузгалды. Аларның аяк астыннан тузан күтәрелде. Колоннадан читтәрәк, сакчылары озатуында Ганс бара иде.

Яһүдләрнең колоннасын күреп калыйк дип, сугыш калдырган хәрабәләр арасыннан Киевта яшәргә тырмашучы кешеләр чыкты. Кайберләре яһүдләрнең болай мәсхәрәләнүенә шатлануын яшерми иде. Ганс колоннада баручыларга кычкырылган сүгенү сүзләрен ишетте. Дөрес, бу тамашага сүзсез генә, куркып карап торучылар да шактый. Алары күбрәк...

Вильгельм танкистлары төркеме әле урыннан кузгалмаган. Ганска янәдән аның яныннан узарга туры килде. Танкистлар арасыннан Ганс Вильгельмны күреп алды. Аның күзләре иптәшенә текәлгән иде. Ганс, ни эшләргә дә белмичә аптырагач, «сәлам» дигән төсле кулын күтәреп, чак кына болгады. Ләкин Вилли җавап бирмәде. Аның күз карашында меңләгән сорау язылган иде. Ул колоннаны, аны оештырып баручы Гансны борылышка кадәр текәлеп карап озатып калды – моны Ганс аркасы белән тойды...

...Шәһәр читенә килеп җиткәндә, борынга укшыта торган авыр ис китереп бәрде. Колоннадагы кешеләрнең аңына бу сәяхәтнең ни белән тәмамланасы аермачык булып килеп басты. Тыела алмыйча, үлемгә хөкем ителгәннәр елаша башладылар. Ганс борынын кулъяулыгы белән каплады.

Ниһаять, яһүдләр тиешле урында. Шәһәр читендә зур гына чокыр. Аның төбеннән яман каркылдап, карчыгалар өере күтәрелде. Сасы ис тә шуннан килә. Бер читтәрәк пулемёт урнаштырылган, аның артында симез немец солдаты утыра. Яһүдләрне яр буена тезеп бастырдылар. Чокыр өстендәге коточкыч мохиткә кешеләрнең кычкырып елавы кушылды. Ганс, кулъяулыгын кесәсенә салып, тирән итеп сулыш алды. Тирә-юньне, барыннан да бигрәк кешеләрнең курку хисе басып киткән иде. Аны һәркем

дә тоя алмый. Ләкин Ганс сизә. Кеше куркуы аңа илаһи бер көч бирә, үзе барган юлның дөрес икәнлегенә инандыра. Мәетләр белән тулып баручы чокыр читенә килгән яһүдләрнең котлары алынган икән – гөнаһларын таныйлар булып чыга. Гаепсез кеше тынычлыгын җуймый ул. Ә боларның намуслары чиста түгел. Димәк – алар дошман!

Ганс колоннаны янә бер тапкыр күздән кичерде. Төрле кыяфәттәгеләр җыелган. Әнә, чебиләп беткән яланаяклы балалар. Алар ихлас күңелдән елый, кечкенә учларына пычранып беткән шыксыз курчак-уенчыкларын кысып тотканнар. Әллә үзләрен шул нәрсәләр саклап калыр дип уйлыйлармы?! Хәер, ышыкланырлык башка кешеләре юк бит. Штурмбанфюрер, атып үтерергә алып барганда, балаларны әти-әниләреннән аерым йөртә. Сабыен тартып алгач, ата-аналар күндәм булалар, ни кушсаң, шуны эшлиләр. Мөгаен, яшәү мәгънәләре шул бала үрчетүгә генә кайтып калгангадыр. Чокыр янына җиткәч, аның төбендә яткан нарасыйларын күргән яһүдләр дә булды. Ганска тегеләрнең бәргәләнүен күзәтеп тору үзенә бер рәхәт иде.

Карт-коры, гадәттә, түзем. Еламыйлар, ялвармыйлар, язмышлары хәл ителүне сабыр гына көтеп торалар. Дөрес, аларга туры карамавың хәерлерәк. Аннан соң ул караш төшкә кереп иза чиктерә, үзеңне гаепле итеп тоя башлыйсың...

Урта яшьләрдәгеләре дә ризасызлык күрсәтми. Шыңшып басып торалар, бер-берсе белән кочаклашып бәхилләшәләр төсле. Бәхилләшсеннәр, гомерләре биш минутка кыскарса ни дә, биш минутка озайса ни...

Ганс пулемёт артындагы солдатка кыска гына әмер бирде. Пулемёт телгә килде. Дык-дык-дык иткән тавыш чыккан саен кешеләр, чалгы белән чабылган төсле, егылып, чокыр төбендә югала бардылар. Курку исенә бераз кан исе кушылды. Яңа кан хәтта мәетләр сасысыннан да көчлерәк аңкый икән.

...Бер мизгелдә барысы да хәл ителде. Пулемёт тынып калды. Аның көпшәсеннән төтен генә күтәрелә иде. Әле генә кешеләрнең җанын кыйган нимес гадәти эш башкарган сыман кул арты белән маңгай тирен сөртеп куйды. Бүгенгә беренче партия яһүдләр генә. Ганс аңа көне буена җитәрлек исемлек әзерләде. Барысын берьюлы китерергә ярамый, артык күп кешене авызлыклап булмавы ихтимал. Ә болай, кечкенә-кечкенә төркемнәр белән йөртү җайлы...

Ганс чокыр янына килде. Җирдә аунап ятып калган бер кулы өзелгән уенчык аюны тибеп төшерде дә, төпкә күз салды. Анда әллә нинди куркыныч рәвештә өсле-өсле мәетләр ята иде. Кинәт берсе селкенгән кебек тоелды. Ганс шунда ук кобурасыннан пистолетын тартып чыгарды да, селкенгән төсле тоелган мәеткә атып җибәрде.

Конторага кайтып кергәч, Ганска яңа күрсәтмәләр килүен хәбәр иттеләр. Ганс, ашыга-кабалана, депешаны ачып укый башлады. Хәбәр бик кыска иде: СС гаскәрләренең штурмбанфюреры Ганс Шахт кичекмәстән Польшага кайтырга тиеш. Анда ул концентрацион лагерьда хезмәткә билгеләнә. Ганс елмаеп куйды. Ниһаять, тыныч, тук эшкә күчә, ничәмә еллар буе күрсәткән тугры хезмәтен ватаны тиешенчә бәяләгән! Вильгельм белән очрашасы барлыгын да онытып, Ганс җыенырга кереште.

Хәер, Вилли болай да Ганс янына килеп йөрмәде. Никтер барасы

килмәде аның. Ә Киевның ерак бер чатында кара төнгә кадәр пулемёт тавышы ишетелеп торды. Ул үзенә генә мәгълүм булган үлем көен чыгара иде...

***

Берлинны һәр төнне диярлек бомбага тоталар иде. Сәгыйдулланың тормышы һәр көн диярлек кабатлана торган бер тәртипкә керде. Төннәрен Берлин метросына төшеп, күпчелек халык белән төн куна, өстә гөрселдәп ярылган бомбалар тавышына йокыга китә. Иртән торып, кечкенә генә бүлмәсенә кереп чыгарга өлгерә. Фрау Герда метрога төшеп азапланмый – әҗәле киләсе булса, кайда да куып тотар дип, өендә генә төн куна. Шуңа күрә иртән фрау Гердада кайнаган чәй, капкалап алырга коры-сары ризык булыр. Аннан соң сыраханәгә юнәлә. Биредә алар сыраханә хуҗасы Фридрих белән икәү генә эшләп калдылар. Башта Ганс үз теләге белән ССка гариза язып китеп барды, аннан соң Вильгельмны хәрби хезмәткә алдылар. Фридрих алар урынына кеше эзләп тормады, бөтен эшне икәү тарталар иде. Сугыш та үзенекен итте – сыраханәләргә йөрүчеләр күзгә күренеп кимеде. Радиодан көн саен Рейх гаскәрләренең туктаусыз җиңүләре, дошманнарны тар-мар итүләре турында матур хәбәрләр яңгырап торса да, хәлләрнең алай ук шатлыклы түгеллеген Берлин халкы бик яхшы белә иде. Кибет киштәләреннән кайбер төр продуктлар юкка чыкты. Социаль түләүләр киметелде. Ләкин аннан да куркынычрак нәрсә – Берлинда күпсанлы кулга алулар башланды. Кыска гына вакытлы очрашулар вакытында, табын янында чәй эчкәндә фрау Герда кемнең гестапо тарафыннан тоткарлануы, нindirәк кеше булуы һәм башка нәрсәләр турында сөйләштергәли иде. Иң кызыгы – сүз бер дә яһүдләр турында гына түгел, немесләр хакында да бара, полиция аларны әллә нинди гөнаһлары өчен җыеп, каядыр илтеп олактыра. Берлинның үзендә махсус төрмәләр ачылуы, аларның тоткыннар белән шыплап тулуы бу көннәрдә беркем өчен дә сер түгел иде...

1941 елның көзенең иртәсендә Сәгыйдулла, гадәттәгечә, таң белән Берлин метросыннан чыкты һәм үзе яшәгән фатирга юнәлде. Фрау Герда каһвә әзерләп көтеп тора иде. Алар, гадәттәгечә, әллә ни мөһим булмаган мәсьәләләр тирәсендә гәп корып алдылар. Фрау Герда үзе ишеткән яңалыкларны сөйләде, метрода нindirәк хәлләр булганлыгын белеште.

– Анда бомба шартлаулар бик ишетелми, тыныч, юкка сез метрога төшмисез, рәхәтләнеп йоклар идегез, фрау Герда, – дип, инде меңенче мәртәбә искәртте Сәгыйдулла.

– Юк, инде миңа алай да үләсе, болай да үләсе. Имгәнергә генә язмасын... Бүген бомбалар бигрәк тә якында шартлады. Белмим, үлгән кешеләр бармы-юкмы икән...

– Зениткалар да эләктерә алмый тегеләрнең самолётларын...

Гадәти, көндәлек сөйләшү иде бу. Бернинди яңалык та юк. Бәлки, бомбаларның якында шартлавы гына гадәти булмагандыр. Инглизләр Берлинның торак кварталларына тимичә, күбрәк промышленность объектларын утка тота иде...

Каһвә эчкәч тә, Сәгыйдулла бераз ятып торды. Үзенең урын өсте

метродагы таш почмак түгел, әлбәттә. Соңгы айларда аның рәтле-юньле йокы күргәне юк, бәлки, фрау Герда хаклыдыр да...

Фрау Герда белән сөйләшүне ул сыраханәгә килеп җиткәч, янә искә төшерде. Бүген төнлә Берлинга төшкән бомбаларның берсе аларның сыраханәсе урнашкан бинаны таш өеменә әйләндергән иде. Янгын сүндерүчеләр әле дә утны басарга маташа, кирпеч, такта арасыннан капкара төтен чыга. Өч катлы бинадан хәрабәләр генә калган. Сәгыйдулла янгын сүндерүчеләрнең җитәкчеләре янына килде.

– Исәнмесез, сез монда күптәнме? – дип сорады ул.

– Яңа килдек. Бүген өченче янгында без. Өчесе дә торак йортлар.

Сәгыйдулла сыраханә хуҗасы Фридрихның шушы ук йортта, өченче катта яшәвен белә иде. Йортта аннан кала тагын берничә гаилә барлыгы да хәтерендә. Хәрабәләрне күздән йөртеп, ул таш астыннан калкып торган кулны күреп алды.

– Исән кешеләр бармы?

– Юктыр. Әлегә утны сүндерәсе бар, аннан мәетләрне эзли башлаячакбыз. Исән калучылар юктыр дип уйлыйм, снаряд йортның нәкъ уртасына төшкән. Биредә беркем дә котыла алмагандыр. Йоклаган килеш киткәннәр дә барганнар.

Фридрих та, фрау Герда сыман, бомбалардан качар өчен метрога төшмәде. Солдат киребеткәнлеге көчле иде Фридрихта. «Бер тапкыр сугышта яраланган кешене үтереп кенә була, насыйбым шул икән, җылы урынымда юрган ябынып йоклаган килеш үләсем килә», – дип аңлатты ул үзенең карарын. Теләге чынга ашуына Сәгыйдулланың бер генә дә шиге юк иде.

Фридрих Берлинда аның өчен ике якын кешесенең берсе иде. Менә ул да китеп барды. Фрау Гердага да күп калмагандыр. Җитмәсә, хәерчелек хөкем сөрә. Кая барып бәрелергә? Мондый шартларда Берлинда рәтле эш табып булуы икеле. Яше дә бар, милләте дә нимес түгел. Бер-ике көн уйланып йөргәч, Сәгыйдулла төенчеген җыйды да, фрау Герда белән бәхилләшеп, Берлиннан чыгып китте. Ул, бергә аралашып яшәгән Гыйльмулланы, Германияне ташлап киткән башка татарларны табарга дип, Франциягә юнәлде. Юлга чыкканчы, Вильмерсдорфка сугылды. Анда Гыйльмулланы Франциянең Нанси дигән шәһәрендә эзләргә кирәклеген әйттеләр. Әлеге шәһәр Германия чигеннән ерак түгел иде. Дөресрәге, элеккеге чигеннән, чөнки хәзер, чынлыкта, Франция территориясе Рейхның бер өлеше. Шуңа күрә чик аша чыгу да әллә ни зур авырлык тудырмады. Сирәк кенә очраган постларда Сәгыйдулланың документларын тикшерделәр, әллә ни төпченмиче генә кая һәм ник барганын сораштырдылар, җибәрә тордылар.

Нанси кечкенә генә борынгы шәһәрчек булып чыкты. Тар урамнар, элеккеге заманнардан калган архитектура, кара көзгә керүгә дә карамастан җылы һава Сәгыйдуллага бик тә ошады.

Гыйльмулланы ул үзәк мәйданнарның берсендәге фермер кибетендә эзләп тапты. Алар бик җылы итеп исәнләштеләр. Гыйльми биредә бер французга ялланып эшли икән. Хуҗа дигәннәре – яше алтмышларга җитеп килгән симез гәүдәле кеше иде. Ул, Гыйльмулла Сәгыйдулла белән таныштыргач, француз телендә исәнләште һәм ихлас елмайды. Гыйльмулла

хуҗасыннан дусты белән сөйләшеп, чәй эчеп алырга ризалык сорады, тегесе каршы килмәде. Алар фермер кибетеннән ерак түгел урнашкан каһвәханәгә кереп утырдылар. Тирә-юньгә татлы каһвә һәм яңа пешкән икмәк исе таралган иде.

– Биредә сугыш бара димәссең дә, – диде Сәгыйдулла, чын күңелдән гаҗәпләнү катыш көнләшеп.

– Карап торышка гына шулай шикелле ул. Чынында, сугыш бара, аяусыз сугыш.

– Бомбага тотылган биналарны да, җимерекне дә, үлем дә күрмәдем... Мин эшләгән сыраханәне инглизләр авиациясе килеп шартлатып китте, хуҗам да шунда үлгән дип беләм. Мин инде ике ел буе диярлек Берлин метросында төн кунам...

– Кайвакыт сезнең якка китүче самолётлар гөрелтесен без дә ишетәбез. Берлинны гына түгел, башка немес шәһәрләрен дә утка тоталар алар. Ә биредә нишләргә? Кемне юк итәргә? Франция – оккупациядәге территория.

– Виши режимы Германиягә хезмәт итәргә ризалык бирде бит...

– Режим бирде, ә халык юк. – Гыйльмулла, як-ягына каранып, пышылдауга диярлек күчте. – Генерал де Голль, Англиядән торып, Францияне азат итү планын әзерли. Без һәр кич саен диярлек әле аның мөрәҗәгатьләрен, әле Черчилль чыгышларын тыңлыйбыз. Би-би-си кызыклы гына мәгълүматлар тапшыра. Немесләр барысын да җиңде дигән сүз түгел, бирешергә ашыкма, дускай...

– Миннән ни файда ул? Бер башымны кая куярга белгән юк... Ничек уйлыйсың, Парижга барсам, берәр эш табып булырмы икән?

– Ә нигә Парижга? Ник безнең белән генә калмыйсың? Эше авыррак, әлбәттә, терлек карыйсы, май чабасы, кәҗә савасы, тегесе-монысы дигәндәй. Ләкин тамагың тук, яшәргә урыны җитәрлек. Кичә генә ике эш урыны бушады, минем хуҗам Франсуа булдыклы хезмәткәр эзли. Үзең кара, әмма мин сиңа монда калырга тәкъдим итәм...

Сәгыйдулланың йөзе ктырып китте, өметсезлектән алҗыган күңеленә җан керде.

Каһвә эчеп бетергәч тә, алар кибеткә киттеләр. Гыйльмулла фермер Франсуага озын-озак нидер аңлатты. Ниһаять, тегесе елмаеп, башта Гыйльмулланың, аннан соң Сәгыйдулланың кулын кысты һәм французча такылдый башлады.

– Сине эшкә алырга ризалашты, рәхмәт әйтә аласың, – диде аз-маз французча сукалаган Гыйльмулла.

Сәгыйдулла революциягә кадәр төрле балларда, бай катлам очраша торган мәҗлесләрдә бераз француз сүзләрен өйрәнгән иде. Ләкин, бердән, алар инде шактый онытылса, икенчедән, мәҗлес лексиконы фермер белән аралашу өчен әллә ни уңайлы түгеллеген ачыклады. Шуңа да карамастан, киңрәк елмаерга тырышып:

– Мин сезгә чиксез рәхмәтлемен, – дигән җөмләне французча ерып чыгарга хәленнән килде.

Кичен алар бер иске машинага төялеп, фермага кузгалдылар. Ферма, чыннан да, шәһәр читеннән ерак түгел урнашкан булып чыкты. Ул зур таш бинадан торган төп утардан, берничә кечерәк сарайдан һәм сарык белән

кәҗәләр абзарыннан гыйбарәт. Сарык-кәҗәләрнең баш саны меңгә якын иде. Сарайларда исә май чабу, сыр ясау җайланмалары урын алган.

Сәгыйдуллага төп утардагы күпсанлы бүлмәләрнең берсен бирделәр. Гаилә башлыгы үзенең хатыны, ике кызы, улы һәм килене белән йортның уң як өлешендә яшәсә, хезмәтчеләр өчен сул як бүленгән иде. Аларның аерым кухнялары, азык-төлек алу мөмкинлеге бар, шуңа күрә ашау кайгысын күрмисең дигән сүз.

Хуҗалык эшләре сарык-кәҗәләрне карау, кәҗә саву, сөт эшкәртү, май чабу, сыр ясаудан гыйбарәт. Моның өстенә зур гына яшелчә бакчасы да бар, аны карап-эшкәртеп торасы. Көзге сезонга кергәндә, Франсуа өч хезмәткәрне генә калдырды: Гыйльмулла, Сәгыйдулла һәм бер французны. Кибет эшләрен Франсуа улы белән бергә алып барды, барлык кара эш шул өч хезмәткәргә йөкләнгән иде...

Фермада яши башлавына атна-ун көн үтмәгәндер, кичке якта кемдер Сәгыйдулланың ишеген какты. Вакыт инде соңга авышкан, шактый гына караңгы төшкән. Бусагада Гыйльмулла басып тора иде.

– Киен, – диде ул ни дә булса сорарга урын калдырмаслык тавыш белән.

Сәгыйдулла ашыга-кабалана киенде. Алар урамга чыктылар. Көзге төн дөм караңгы булса да, амбар читендә кемнеңдер шәүләсе шәйләнде. Якынрак килгәч тә, Сәгыйдулла моның Франсуа булуын абайлады. Хәтта караңгы төндә дә Франсуаның чиктән тыш җитдилеге сизелә иде. Сәгыйдулла, ни булса шул булыр дигәндәй, кушканны тыңларга кирәк дигән карарга килде. Алар басуга таба кузгалдылар. Бик озак кына дәшмитынмый бардылар. Ниһаять, алда куаклык күренде. Куаклык эченә кергәч, Франсуа дөм караңгыда җирне капшап, нәрсәдер эзли башлады. Аннан соң кечкенә генә капкачны күтәреп атчы.

– Аяк асларыңа карап кына төш, – дип пышылдады Гыйльмулла. Аяклары белән баскыч табып, базның таштан корылган диварларына тотынып, Сәгыйдулла Франсуага иярде. Аның артыннан Гыйльмулла төште. Ул базның капкачын акрын гына япты. Франсуа шырпы сызды, стенада эленеп торган керосин лампаны табып, элдереп җибәрде.

Бу – стеналары борынгы ташлар белән ныгытып эшләнгән шактый иркен баз иде. Өстәл, берничә урындык. Өстәлдә зур чемодан тора. Франсуа чемодан янына килеп, ачып җибәрде. Аның эчендә электрон җайланма шәйләнде. Франсуа ашыкмый гына чыбыкларны тоташтырырга кереште. Аның бармаклары бу гамәлләрне күнегелгән, автомат рәвешендә башкаралар иде.

– Мине яхшылап тыңла, Сәгыйдулла, тыңла һәм исеңдә калдыр. Теге очрашуда әйткән идем бит – Франциянең яңа режимы немесләргә бирелсә дә, бу илдә Гитлерга буйсынырга риза булмаганнар бик күп. Аларның берсе мин, Франсуа һәм хәзер син дә дигән сүз. Без – каршылык күрсәтү төркеме вәкилләре. Генерал де Голль Англиядән торып, безгә кулыннан килгәнчә ярдәм итә. Бу хакта беркем дә бернәрсә дә белергә тиеш түгел! Мин сиңа үземә ышанган төсле ышанам. Мине сатмассың дип өметләнәм. Безнең эшебезне сата күрмә. Бер генә сүз ычкынса да, синең дә, минем дә башым бетте дигән сүз. Зинһар өчен, моның белән уйный күрмә! Аңладыңмы?!

– Аңладым!

– Франсуа хәзер безнең янәшәдәге координатларны хәбәр итәчәк, без Ла Маншның аргы ягыннан күчтәнәч көтәбез.

Чемодан эчендәге җайланма теркелди башлады, Франсуа үзенә генә мәгълүм булган телдә серле хәбәрләр җибәрә иде. Сәгать ярым чамасы вакыт узгандыр, ул, булды дип, ике татар егетенә таба борылды һәм җайланманы яңадан сүтеп, чемоданга тутырды. Аннан лампаны сүндереп, кире өскә менделәр. Агачлыкта торган көе күтәргә керештеләр. Гыйльмулла белән Франсуа дөм караңгы күк йөзен күзәтәләр иде. Сәгыйдулла да аларга ияреп карады, ләкин күзләре генә авырта башлады, ул берни дә күрмәде. Кинәт һавадан двигатель тавышы ишетелде. Аларга таба самолёт якынлаша иде. Сәгыйдулла төнге һавада аның шәүләсен күреп калды. Агачлык өстеннән очып китеп, ул юлын дәвам итте, аның артыннан өч парашют ачылып калды. Франсуа белән Гыйльмулла басуга ыргылдылар, Сәгыйдулла да иярде.

Өч парашютка әрҗәләр беркетелгән. Алар ашык-пошык парашютларны җыйдылар, әрҗәләрне куаклыктагы базга илтеп урнаштырдылар. Парашютлар да шунда калды. Янә базга төшеп бикләнгәч, Франсуа зур чүкеч ярдәмендә әрҗәләрнең берсен ачты. Аларның ни өчен шундый авыр булганлыгын шунда гына аңлады Сәгыйдулла – һавадан төшкән әрҗә мылтыклар белән шыплап тутырылган иде. Калган икесендә патроннар булып чыкты. Бүгенгә эш тәмам дип, Франсуа кайту ягына ымлады...

***

1941 ел Советлар иле өчен зур сынаулар чорына әйләнде. Көзгә нимес гаскәрләре инде Мәскәү янына ук килеп җитте. Вермахт «Тайфун» операциясен башлады – исеменнән үк күренгәнчә, дошман көчле бер ташкын булып, Кызыл Армияне изеп-сытып ташларга ниятли иде.

Октябрь башында Сталин Ленинградтан армия генералы Георгий Жуковны чакыртып алды. Алар Сталинның фатирында очраштылар – илбашчыга салкын тигән иде. Жуков, фатирның кунак бүлмәсенә килеп кергәч тә, бөтен мөмкин булган урын – өстәл, кәнәфиләр, хәтта тәрәзә төпләрендә карталар җәеп салынганын күрде.

– Исәнмесез, иптәш Башкомандующий! Генерал Жуков сезнең әмерегез буенча килеп җитте!

Сталин, аны баштанаяк күзләп чыгып, ияген кагып кына исәнләште. Аннан өстәлдә ятучы карта янына чакырды.

– Менә карагыз. Биредә хәлләр аеруча катлаулы. – Ул бармагы белән Вязьма тирәсенә төртеп күрсәтте. – Көнбатыш һәм Резерв фронтлары командующийлары миңа рәтләп, берни аңлатып бирә алмыйлар. Ә дошманның кайларда һөҗүм иткәнлеген, безнең гаскәрләрнең ни хәлдә икәнлеген белми торып, бернинди карар да кабул итеп булмый. Хәзер Көнбатыш фронт штабына барып, бөтенесен дә җентекләп өйрәнегез һәм миңа аннан шалтыратырсыз. Көнме, төнме – шалтыратыгыз, мин көтәм.

– Аңладым, иптәш Сталин! – диде Жуков һәм ишеккә борылды, ләкин Башкомандующий аны туктатты.

– Ничек уйлыйсыз, иптәш Жуков, якын арада нимесләр Ленинградка яңа һөҗүм башлармы?

– Юктыр дип уйлыйм. Дошман зур югалтуларга дучар булды, калган

танкларын Ленинград яныннан каядыр үзәк юнәлешкә күчерде. Бүгенгә калган гаскәрләр белән яңа һөҗүм мөмкин түгел.

– Ә Гитлер Ленинградтан күчергән танкларны кайда кулланырга мөмкин?

– Мәскәү юнәлешендә дип уйларга кирәк.

Сталин Көнбатыш фронты картасына күз ташлады.

– Алар инде хәзер үк Мәскәү юнәлешендә бугай, – диде ул әллә үзенә, әллә Жуковка.

– Китәргә рөхсәт итәсезме, иптәш Сталин?

– Ә? Әлбәттә, барыгыз, иптәш Жуков, барыгыз!

Жуков киткәч, Сталин үзенең фатирына Берияне чакыртып алды. Берия кергәч тә, койрыгын болгаган маэмай төсле ялагайланып, илбашының сәламәтлеге турында сораша башлады. Тик Сталин берни дә дәшмәде, төрепкәсен генә бертуктамый тарта бирде.

– Яков турында хәбәрләр юкмы? – диде ул, уйларын бүлеп.

Берия каушап калды. Яковтан хәбәрләр әле җәй көне үк килүдән туктады. Нимеслар тылына берничә махсус хәрби төркем дә җибәреп карадылар, ләкин берсе дә Сталинның олы улы турында ни тере, ни үле хәбәрен алып кайта алмады. Әледән-әле Яков нимесләр ягына чыккан, Гитлерга хезмәткә күчкән дигән имеш-мимешләр килгәләп торды. Тик Сталин аларның берсенә дә ышанмады. Андый түгел иде Яков. Әтисен дә, Ватанын да сата торган түгел иде.

– Безнең кулда бернинди мәгълүмат та юк, тиздән чираттагы диверсион төркем җибәрәбез. Берлиндагы агентура да бернинди фактлар да таба алмады, – диде Берия, маңгаеннан кинәт бәреп чыккан тирне сөртеп.

– Мәгълүмат юк икән, димәк, Яков та юк дигән сүз, – диде Сталин кинәт боегып. – Күңелем сизә – Яков инде мәрхүм. Күрәсеңме, Лаврентий, бу сугыш мине дә аямады.

– Алай димәгез әле, иптәш Сталин, өмет бар бит.

– Нинди өмет?! Минем улым Гитлер белән әшнәләшкән дигән өметме? – Сталин Бериягә куырып карады.

– Юк ла инде...

– Әлегә кадәр миңа бер фоторәсем генә алып кереп күрсәттең – нимес шинеле кигән Яков рәсеме. Сиңа нимес шинеле кидерсәң, син дә сатлыкҗан инде алайса?! Аннан соң, Яков түгел ул, аңа охшаган кеше генә.

– Тулысынча килешәм, иптәш Сталин...

– Имештер, радиодан тавышын ишеткәннәр, минем Яков совет солдатларын нимесләр ягына аударырга маташа икән... Юк сүз! Теләсә кемнең тавышын яздырып, шатыр-потыр плёнка шатырдавын өстәсәң, теләсә кем дияргә мөмкин, беркем дә танымаячак! – Аннан соң Сталин тынычлана төште. – Диверсион төркемнәр җибәреп, кеше аптыратмагыз. Күңелем сизә – Яков инде мәрхүм. Ходай насыйп итсә, сугыштан соң каберен табарбыз. Юк икән – юк... Минем Яков та бүген яу кырында сөякләрен черетүче меңләгән совет солдаты белән бертигез, шушы җиребез өчен башын салган намуслы солдат. Шуңа күрә, Лаврентий, бу инде минем өчен шәхси сугыш та. Безнең бирелергә хакыбыз юк, аңладыңмы?!

– Аңладым, иптәш Сталин...

– Ә хәзер китә аласың...

Сталин янә уйга батты. Өлкән улы вафат. Ул аны үзе генә белгән кырыс ярату белән яратты. Яков акыллы, намуслы, бик нечкә күңелле бала иде. Ул зур батырлыклар кылырга сәләтле, Иосифны, туган илен сата торган кеше түгел. Моңа аны Сталин өйрәтмәде, аның канында тумыштан бар иде ул сыйфатлар. Чөнки Яков әнисенә охшаган. Беренче хатыны Екатерина да шундый иде. Като дип йөри иде аны Иосиф. Иосифны ул яшерен эшчәнлеккә чыгып киткән вакытларда, кулга алынган чакларда да сабырлык белән көтте, иренә тугрылыгын югалтмады. Кызганыч, иртә китте, Като аңа бүген, бу авыр көннәрдә чын-чынлап терәк булырлык кеше иде...

Яковны искә төшергәч, Сталин өстәл тартмасын ачты. Бу тартмада бары тик балаларына кагылышлы документлар гына ята. Алар арасында кызы Светлананың хатлары да бар. Кызы хәзер Куйбышевта, эвакуациядә. Әтисенә бик еш яза ул. Менә хәзер дә, аның хатын кулына алгач, Сталин мыек астыннан елмаеп куйды.

«Минем сөекле әтием, кадерле шатлыгым минем, исәнме, ничек яшәп ятасың, кадерле секретаришкам? Мин монда әйбәт кенә урнаштым. Эх әти, бер генә көнгә Мәскәүгә кайтасы иде!»

Телефоннан да шалтыратып бимазалый аны кызы. Нимесләр безне җиңә алмас бит, әти, дип сорый. Шул чакларда Сталинның бәгыре өзгәләнә. Кызын тынычландыра, ә үзенең йөрәгендә курку. Ә нимес җиңә калса? Сталин тарихка халкын коллыкка тапшырган җитәкче булып кереп калачакмы? Сталинның үзен, аның кызын, әле исән икенче баласын нинди язмыш көтә?! Иле, якыннары язмышы өчен курка иде илбашы. Үзәкләргә үтеп, төннәр буе йокы бирми торган курку иде ул. Барысы өчен дә җаваплылык бары тик бер аның өстендә. Куштан Берия дә, калганнары да, әгәр дөнья тетрәнүен сизсә, шунда ук качып, юк булачаклар. Болай да коткы таратучылар шактый. Имеш, Сталин Мәскәүдә юк, имеш, аны инде күптән үтергәннәр, дигән гайбәтләр әледән-әле чыккалап тора.

Сталин Бөек Октябрь революциясенә багышланган парадны һичшиксез үткәрәчәк. Генераллар моңа каршы, тик аларның эше – иминлек тәэмин итү. Ләкин ул – Сталин, туган иленең түреннән чыгып, бөтен дөньяга көр күңелен, җиңүгә ышанычын күрсәтергә тиеш. Дошманнар шартласын. Ә ул көрәшәчәк. Яковның якты истәлеге хакына, кызы һәм улының киләчәге хакына, исәбе инде санап бетергесезгә әйләнеп баручы мәрхүмнәр хакына...

Тик парадка кадәр тагын бер мөһим эшне башкарасы бар. Беренче чиратта Сталинның үзе өчен. Ул Власикны чакыртып алды.

– Николай, берничә көнгә булса да, Светлананы Куйбышевтан бирегә кайтарып тору мөмкинлеген табарга кирәк.

– Иптәш Сталин, бүгенге вазгыятьтә бу шактый куркыныч дип уйлыйм, мин Сезне дә Куйбышевка китәргә өндим, анда барысы да әзер.

– Мин беркая да китмим. Ә минем кызымны исән-имин килеш алып кайтып, кире илтеп кую – синең солдат бурычың. Үтәгез!

Светлананың хатын кире тартмага куйганда, аның икенче бер кәгазьгә күзе төште. Бусын Берия китергән иде. Сталинның улы Василий «батырлыклары» хакында донесение. Сталин аны янәдән, инде ничәнче мәртәбә, йөрәге сыкрап укып чыкты.

«1941 елның 8 сентябреннән 9ына каршы төндә, һава тревогасы вакытында иптәш Василий бер кызны утыртып, аэродромга килде һәм машинасы белән ангарга кереп туктады. Автомеханик иптәш Тарановка самолёт моторын кабызырга кушты һәм самолётта һавага күтәрелергә рөхсәт таләп итә башлады. Вакыт төнге беренче унбиш минут, җитмәсә, үзе исерек тә. Василийны тынычландарып, һавага күтәрелү мөмкин түгеллеген аңлаткач, ул: «Алайса мин йокларга ятам, бомбага тота башлагач уятырсыз», – диде. Аңа полковник Грачёв кабинеты бүлеп бирелде, ул шунда машинада килгән кыз белән төн кунды».

Сталин, җирәнеп, әлеге донесениене кире тартмага ташлады. Оят һәм хурлык! Өч баласы – өчесе өч төрле кеше, өч төрле характер, өч төрле язмыш. Василий бөтенләй дә өметсез, эчә, теләсә кем белән чуала, иптәшләрен һәм бер көтү кызларны аның дачасына да алып кайтып, ничә тапкыр күңел ачып ятканнар, бүлмәләрне дуңгыз абзарына әйләндергәннәр. Шулай да, Сталинның Василийны да югалтасы килмәде. Василий батыр, ләкин башсыз, уйлап тормый-нитми, утка барып керә торган. Шуңа күрә этисе улын Хәрби Һава Көчләре штабына урнаштырды. Тагын бер баласын югалту аның өчен күтәрмәслек авырлык булачак, ә аңа әле иле турында, дошманны тар-мар итү хакында да уйларга кирәк...

15 октябрь көнне Сталин Мәскәүне эвакуацияләргә боерды. Бөтен төп дәүләт учреждениеләре һәм илчелекләр ашыгыч рәвештә Идел буена, Куйбышев шәһәренә күчерелә башлады. Метро эшләүдән туктады. Шәһәрдә мәхшәр купты. Әле анда, әле монда талаулар, кибетләрне һәм складларны басып чыгу турында хәбәрләр килә торды. Мондый хәлне туктату өчен, Мәскәү тулысы белән НКВД карамагына тапшырылды. Радиодан Сталинның Мәскәүдә калуы, исән-имин килеш Башкомандующий вазифаларын башкаруы турында хәбәр иттеләр.

Шәһәрдәге барча халык саклану корылмалары төзүгә юнәлтелде. Ә нимес гаскәрләре исә якынайганнан-якыная бара... Сталин барлык төп биналарга, күперләргә шартлаткычлар урнаштырырга әмер бирде. Әгәр башкаладан чыгып китәсе булса, ул Мәскәүне Гитлерга хәрабәләр хәлендә генә калдырачак.

Светлана Мәскәүгә октябрь азагында гына кайта алды. Ул кабинетка килеп кергәнче, Сталин ут йотып торды – башкаланы нимесләр янә бомбага тоталар, берничә зур бинаның шактый зыян күрүен хәбәр иттеләр. Светлана ишектән атылып кергәндә, Сталин Дәүләт Оборона Комитеты әгъзалары белән киңәшмә үткәрә иде.

– Әти-и! – дип, ерактан ук йөгереп килеп кочаклап алды ул Иосифны. Иосиф аның башын күкрәгенә кысты, чәчләреннән кыяр-кыймас кына сыйпады. Аннан, үзеннән аерып, кызының ике иңбашына ике кулын салды.

– Йә, бөтенләй буйга җиткәнсең! Светанка, син бераз көтеп тор, минем кичектергесез эшләрем бар, бушагач та сөйләшербез.

Светлана, зур бүлмәнең икенче башындагы кәнәфигә утырып, өстәл артына җыелганнарны күзәтә башлады. Барысы да үтә җитди. Әтисе чак кына ишетелерлек тавыш белән әмерләр бирә, кулындагы төрепкәсе белән зур картаның әле бер ноктасына, әле икенчесенә төртеп күрсәтә. Башкалар аны дикъкать белән тыңлый, әйтелгәнне теркәп баралар.

Ниһаять, бөтенесе дә чыгып киткәч, Сталин аның янына килеп утырды һәм елмаю тулы күзләре белән кызына текәлде.

– Әти, мин сине шулкадәр сагындым! – диде кызы, янә аны кочып алып.

– Мин дә, кызым, мин дә... Син ачуланма инде, син шалтыратканда, мин кайвакыт җавап бирә алмыйм, эшем бик күп. Чәй эчәсеңме?

– Юк, рәхмәт, юлдан килгәч тә ашаттылар мине. Әти, мин монда гына калыйм әле, Куйбышевта бик күңелсез миңа...

– Ник, Куйбышевта танышырлык кешеләр юкмыни? Яңа шәһәр, үзгә балалар....

– Юк, – диде Светлана. – Анда эвакуацияләнгәннәр өчен аерым мәктәп оештырганнар, минем кебекләр күп анда. Барысын да диярлек беләм мин.

– Алай икән, – дип, кашларын җыерды Сталин. – Менә бит ничек кыланалар! Имештер, хөкүмәт, мәскәүләр килгән, аларга аерым мәктәп китереп бирегез! Власикның эшедер инде бу!

Светлана дәшмәде. Сталин исә, кызып китүенең бер дә юкка булуына оялып, янә елмайды.

– Әти, ә нимес безне җиңмәсме?

– Юк, әлбәттә! Сине әтиең дошманнан һичшиксез саклап калачак, мин сиңа сүз бирәм! – Сталин, честь биргәндәй, кулын чигәсе янына күтәрде.

– Яков турында берәр сүз ишетелмиме, әти?

– Дөресен әйтәм, кызым, без Яковның кайдалыгын әлегә белмибез. Әмма мин аны коткару өчен кулымнан килгәннең барысын да эшлим. Абыең исән, ул нимес ягына күчмәгән, безгә бары тик сабырлык белән көтәргә генә кирәк. Теләсә ни сөйләгәннәргә ышанма – абыең нимесләргә хезмәт итәргә ризалык бирмәс. Монысын мин тәгаен әйтә алам.

Светлана моңсуланып калды.

– Миңа Куйбышевта бик авыр...

– Кызым, озакламый мин сине Мәскәүгә алып кайтачакмын, бу хакта да сүз бирәм. Безгә дошманны башкаладан куып җибәрергә кирәк, әтиең хәзер нәкъ менә шуның белән шөгыльләнә. – Сталин күзләре яшьләнгән кызын кочаклап, күкрәгенә кысты. – Көчле булыйк, кызым, без бу афәтне дә җиңәчәкбез, ышан миңа. Ә хәзер бар, Николай абыең озатып куяр, миңа эшләргә кирәк...

6 ноябрь көнне Иосиф Сталин Бөек Октябрь революциясенең 24 еллыгына багышлап, Мәскәүдә зур тантаналы җыелыш үткәрде. Советлар иле башкаласы өчен бу иң авыр, иң катлаулы көннәр иде. Шәһәр бушап калган, барлык дәүләт учреждениеләре, институтлар, гражданлык хезмәте белән шөгыльләнүче оешмалар кайсы кая – Куйбышев, Казан, Түбән Новгород шәһәрләренә, ә кайберләре хәтта Урал аръягына ук күчерелгән. Чит ил дипломатлары, дәүләт хезмәтен алып баручы төп оешмалар үзара «икенче башкала» дип йөртелгән Куйбышев шәһәрендә. Биредә шулай ук пропаганда чаралары, радио-телевидение хезмәткәрләре дә сыену урынын тапты. Куйбышевның үзендә Иосиф Сталинга ставкасы белән тыныч эшләү өчен барлык шартлар да тудырылды. Шәһәр эчендә хәтта бункер да ясалды – тирән җир катламы астында бомбалардан курыкмый яшәргә, эшләргә мөмкин.

Мәскәү үзе ташландык шәһәрне хәтерләтә иде. Аның өстендә,

бомбардировщикларга комачаулык итү өчен, аэростатлар эленеп тора. Мавзолей, Кремль, тарихи һәм идеологик әһәмияткә ия булган биналар, һәйкәлләр махсус күз буяучы япмалар белән капланган. Бу – дошман авиациясенә каршы тору өчен эшләнә.

Көзге чор якынлашу белән немесләрнең басымы көчәя генә барды. Разведканың кайбер мәгълүматларына ышанганда, Гитлер 7 ноябрь көнне, коммунизмның җиңелүен игълан итеп, Кызыл Мәйдан аша үзенең свастика суккан гаскәрләрен үткәрергә җыена иде.

Шул ук вакытта фронтта төшенкелек очраклары турында да хәбәрләр килеп тора. Мәскәү бушап калгач та, янәдән аннан Сталин да китеп барган дигән сүзләр чыгуы турында донесениеләр бар иде. Мондый вакытта халык алдына чыгып, аларны җылы сүз белән куәтләү, өмет чаткысы бирү бик дөрес булыр дип уйлады Сталин. Башта революциянең 24 еллыгы уңаеннан тантаналы кичә, икенче көнне исә Кызыл Мәйданда парад уздырырга дигән тәкъдимне дә ул кертте. Тантаналы җыелыш оештыру белән азмы-күпме җиңелрәк булса да, парад тәкъдименә генераллар кискен каршы төште. Ләкин Сталин аларның фикерен кайтара алды. Генераллар килештеләр. Кая барсын, ди, алар? Сталинның аргументлары да катгый иде – бердән, сугыш кырындагылырның күңелен күтәрергә кирәк, икенчедән, ноябрь башында бераз суыклар башлану, аннан да бигрәк ишеп яуган кар немесләрнең тизлеген нык киметте. Авиациягә дә башкаланы утка тоту кыенлашты. Шулай да, дошман инде бередә, Мәскәүнең читендәге йортларга ук килеп терәлгән, аның үлем исе аңкып торган сулышы әллә кайдан тоемлана...

6 ноябрь кичендә Иосиф Сталин ике вагоннан гына торган махсус поезд белән Мәскәүнең «Маяковский» метро станциясенә килеп төште. Аның белән бергә поездда Дәүләт Оборона Комитеты әгъзалары Анастас Микоян, Лазарь Каганович, Лаврентий Берия, Вячеслав Молотов, Георгий Маленков, Семен Будённый һәм Мәскәү советына караган тагын берничә вәкил бар иде.

Метро станциясе зур бер залга әверелгән. Тигез рәтләргә урындыклар тезелгән, анда – чакырылган кунаклар. Сталин килгәнне күргәч тә, алар урыннарыннан сикереп торып, залны көчле алкышлар белән шартлар дәрәҗәгә житкерделәр. Сталин, чак кына кулын күтәреп, «ярый, рәхмәт инде» дигән кыяфәт белән аларны сәламләде.

Зал бик матур һәм купшы иде. Идәнгә озын келәмнәр җәелгән. Каршы як юлда ишекләре ачылган озын состав тора – анда табыннар корылган, тантаналы җыелыштан соң, банкет шунда үтәчәк. Станциянең бер башында биек трибуна. Ул кызыл комачлар белән уратып алынган, чәчәкләр белән бизәлгән. Артта Ленинның зур гына бюсты, аның артында Сталин портреты. Сталин үз портретының Ленин фонында зуррак булып тоелуына игътибар итте. Вак кына нәрсә кебек, ләкин барыбер күңелле...

Сталинның чыгышы кыска, ләкин үтемле булды. Сугыш башланганнан соң бу аның беренче тапкыр моның кадәрле халык алдына чыгуы иде. Ул үзенә карата мәхәббәт һәм соклануның бер дә кимемәвен тойды. Аңа ышаналар, аңа таяналар, өмет тулы күзләр аңа таба төбәлгән. Димәк, ул дөрес юлдан бара. Димәк, ул тарихка Ватанын дошман кулына калдырып качкан куркак бәндә булып түгел, ә җиңүче, халыкны азат итүче буларак

кереп калачак. Димәк, дошман белән көрәшендә ул ялгызы түгел, аның ярдәмчеләре биредә, шушы залда, аннан читтә, яу кырында, басуларда, завод станоклары артында.

Зал аның сүзләрен дәррәү кул чабып кабул итте. Чыгыш тәмам булгач та, кечкенә генә концерт программасы тәкъдим ителде. Соңыннан тантанага чакырылучылар озын составта оештырылган банкетка агылдылар.

Сталин банкетта озак утырмады – Дәүләт Оборона Комитеты әгъзалары һәм генераллар белән ике вагонлы составка утырып, Кремльгә кузгалды. Анда төне буе эшлисе бар – 7 ноябрь иртәсенә Мәскәүнең Кызыл Мәйданында парад билгеләнгән, аңа соңгы әзерлек мәсьәләләрен карап бетерергә кирәк...

***

...Таһирны сугышка алгач та, аннан-моннан өйрәтү үткәрделәр дә, канлы бәрелешләр барган иң кызу урыннарның берсенә ташладылар. Биредә аның кебек яу кырының ни икәнен белмәгән чиле-пешле солдатлар. Сугыш бик каты бара, немесләр һаман да басып киләләр, алар көннән-көн артка чигенергә мәҗбүр. Берәр ай үтмәгәндер, Таһир үзенең броньнән баш тартып, фронтка китүенә үкенә дә башлады. Колхозында эше дә тыныч, көмешкә белән аракы да күпме кирәксә – шулкадәр бар. Монда исә көн саен үлем белән күзгә-күз очрашасың. Яу кырыннан кайткач та, мәрхүмнәрне күмәсе.

Командирларының аларны көн саен ачыктан-ачык үлемгә ташлауларын Таһир яхшы аңлый иде. Кулларындагы мылтыклары немесләрнең бертуктаусыз ут чыгарып атучы автоматлары белән чагыштырганда, чүпкә дә яраксыз. Аларда пулемётлар да, ут белән яндыра торган кораллар да бар. Һәм, әлбәттә, танклар. Алары үкереп, өскә килә, берни турында да уйланырга, аңышырга ирек бирми. Таһир ике айлап катнашкан гражданнар сугышы белән чагыштырганда, бусы җәһәннәм төсле булып чыкты.

Шулай да Таһир өчен сугышның да отышлы ягы килеп чыкты. Түшендә медаль ялтырый. Исән-имин өенә кайта алса, барысын да көнләштереп йөриячәк. Әнисе дә чиксез шат, Марфасы да...

Медаль алуының тарихы болайрак булды. Алар, Таһир фикеренчә, чираттагы мәгънәсез атакага җибәрелде. Башта урман эченнән бардылар, анда әле түзәрлек. Аннан соң ачык урынга килеп чыктылар. Иелә төшеп йөгергән җиреннән Таһир үзләреннән соң калган окопларда немесләрнең пулемёт көпшәләрен абайлады. Совет гаскәриләре күренү белән алар телгә килде. Мылтыгын кысып тотып, Таһир бер агач төбе артына барып ятты.

Пулемёт тавышына танклар чылбырының шалтыравы да кушылды. Аларның батальонындагы солдатлар күзгә карап кырыла башлады. Мондый шартларда атакага баруның файдасы юк иде.

Таһир, шуышып, урман куышына таба юнәлде, бераз агачлыкка кергәч торып ук басты. Бер наратка терәлеп уйга батты. Теге якта үлем. Аннан командирларына да, үзенә дә мәгънә юк. Бу якка йөгерсә дә, ахыры хәерле бетмәс. Дезертирлыкта гаепләрләр. Ул гаепләү – ялан басуда немес пулясыннан үлү түгел. Ни булса шул булыр, кире кайтырга кирәк.

Ул янә иптәшләре киткән якка борылып карады. Бер пулемётның тыны беткән, ул урнашкан окоп тирәсендә аның батальоны солдатлары кайнаша.

Димәк, дошманны өлешчә куып чыгара алганнар. Тик икенче яктан танклар белән пехота килә, элеккеге позициядә озак тора алмаслар.

Борылып чабыйм дигәндә, каршысына әллә кайдан гына комбат килеп чыкты.

– Тукта! Син нәрсә, боерыкны оныттыңмы әллә?! Атакага, солдат! – дип кычкырды комбат, кулындагы револьверын болгый-болгый.

Таһир аның сүзен тыңларга гына уйлаган иде, саташкан нимес пулясы сызгырып үтеп, комбатны аягыннан егып салды. Таһир аның өстенә иелде. Комбат ыңгыраша, башы яраланган. Тиз генә бинт чыгарып, яраланган урынны кысып бәйләде дә, комбатны аркасына күтәреп, элеккеге позицияләргә, сугыш барган җирдән кире якка йөгерде.

Үзенекеләрне күргәч тә, ул бар көченә кычкырып җибәрде:

– Комбат яраланды, санитаркаларны чакырыгыз!

Солдатлар, йөгереп килеп, аңа ярдәмгә ашыктылар. Комбатның гомерен саклап кала алдылар. Ике атнадан соң яу кырында күрсәткән батырлыгы, командирын коткарганы өчен аңа бөтен солдатлар каршында медаль тапшырдылар.

Таһир башка язмыш белән качышлы уйнамады. Комбатлар һаман да яраланып тормас. Аннан соң сугыш һөнәренә күнегә төште, нимесне бик үк җиңеп булмаса да, кайвакыт уңышка да очрыйлар иде.

Ә теге медаль исә Таһирга бик кирәк булып чыкты. Ул вакытта алар, чигенә-чигенә, Мәскәүгә үк килеп терәлгәннәр иде...

Кайчан да булса Мәскәүне күрермен дип башына да китермәгән иде. Ноябрьнең салкын көннәренең берсендә Таһирлар ротасыннан берничә кешене сайлап алдылар һәм өс-башларын тәртипкә китерергә куштылар. Мәскәү янында бик каты канлы бәрелешләр барган вакыт иде бу, шуңа да үзләрен фронтның алгы сызыгыннан алып китү бик гаҗәеп тоелды Таһирга. Окопларда калган иптәшләре дә аларны ниндидер көнчелек һәм хәтта үпкә белән озатты.

Таһирны иптәшләре белән йөк машиналарына төяп, башкалага таба юнәлделәр.

Мәскәүнең хәлләре мөшкел иде. Әле анда, әле монда юлларда бомбалардан калган зур-зур чокырлар ыржаеп ята. Ярым җимерек йортлар да шактый күренә. Эчкә үткән саен, күз бояучы сеткалар белән капланган биналар күбрәк очрый. Вакыт кичкә авышканга, шәһәр дөм караңгылык эчендә утыра. Урамда эт тә юк. Аларның каршысына әледән-әле йөк, кешеләр төягән машиналар очрый тора – корал кирәк-яраклары, ә иң мөһиме, кешеләр фронт сызыгына таба, аяусыз үлем уты уйнаган якка таба китеп югала.

Йөк машинасы ике катлы бина янына килеп туктады, аларга арбадан төшәргә кушылды. Солдатлар тезелешеп баскач, алар каршына өлкән лейтенант формасындагы яшь кенә егет чыкты.

– Солдатлар! – диде ул көр тавыш белән. Ноябрьнең салкын һавасында битләре алсуланып киткән, җитди офицер формасы кисә дә, әле аның ябь-яшь егет икәнлеге бу алсулыктан тагын да ныграк тоемлана төсле. – Иптәшләр! – Өлкән лейтенантның тавышы йомшый төште. – Сезгә җитди һәм шул ук вакытта бик мактаулы бурыч йөкләнәчәк! Озакламый сез тигез

стройлар белән парад маршында узып, бөтен дөньяга совет солдатының көрлеген, көчен, ныклыгын, ихтыярын күрсәтергә тиеш булачаксыз. Бу – бик җитди бурыч. Ләкин сезнең аны намус белән үтәп чыгачагыгызга һич тә шигем юк! Совет хөкүмәте нәкъ менә сезне – канкоешлы сугышларда үзенең батырлыгы белән Ватанына мәхәббәтен раслаган кешеләрне сайлап алды. Бу олы ышанычны җиренә җиткереп үтәгез! Парад маршы белән узуга, сезне янәдән фронт, дошман белән күзгә-күз очрашу көтә. Ләкин сез ул көрәштә инде бөтенләй башка кешеләр булачаксыз. Казармадан чыгу тыела. Командасыз йөрү тыела. Бу минуттан сез минем карамакка күчәсез. Мин өлкән лейтенант Хәмит Тимерханов булам!

Егетнең татар кешесе дә икәнлеген белгәч, Таһирга аеруча рәхәт булып китте. Татарлар яу кырында бик күп, алар белән гәпләшәләр, сөйләшәләр. Ләкин парадка татар кешесе кул астында чыгу Таһирга бигрәк тә зур дәрәҗә төсле тоелды. Фамилиясе генә бераз килешсезрәк...

Аларны казармаларга урнаштырдылар. Биредә элек мәктәп булган, күрәсең, бер диварда көрән такта эленеп тора, икенчеләрендә төрле бөек шәхесләрнең портретлары. Һәрбер класс солдатлар белән шыплап тулган. Тәрәзәләр тышка яктылык чыкмаслык итеп ныклап капланган.

Кичке ашка өч төркемгә бүленеп бардылар. Өстәл артына утырып, тыныч шартларда ашау рәхәтен күптән күрмәгән иде Таһир. Аш ашаганда, теш арасында ком шыгырдамаган көнне дә күрәсе бар икән!

Солдатлар идәндә йокладылар. Иртән аларны янә тәмле аш көтә иде, аннан соң мәктәп каршындагы мәйданда парадка әзерлек башланды. Хәмит Тимерханов солдатларга зур түземлек белән Кремльнең кайсы ягыннан керәсе, ничек атлап барасы, стройны ничек тотасы икәнлеген аңлатты.

Бер мәлне Мәскәү өстендә сиреналар тавышы гүли башлады. Алар, әйтерсең, һәрбер почмактан, һәрбер тишектән үкерәләр иде.

– Подвалга! – дип кычкырды өлкән лейтенант, кая йөгерергә кирәклеген күрсәтеп. Соңгы солдат кереп беткәнче көтеп торып, үзе азактан гына черек бәрәңге, кишер исеннән сасыган мәктәп подвалына узды.

Өстә, дөнья, әйтерсең, меңләгән самолёт гөрелтесенә күмелде. Йөзләрчә бомба ярылудан тимер-бетон белән эшләнгән подвал, мәктәп бинасы бии үк башлады. Октябрь бәйрәме алдыннан совет халкына Гитлерның «бүләге» иде бу... Ул көнне совет армиясенең һаваны саклау гаскәриләре Мәскәү өстендә немесләрнең 250ләп самолётын санады. Ләкин шәһәр эчендә төзелгән күпсанлы ялган мавзолейлар, фанерадан торгызылган биналар, күз буяучы сеткалар аркасында Геринг лётчиклары чын Кремльне, чын мавзолейны барыбер таба алмады. Ә икенче көнне иртән иртүк, самолётларга һавага күтәрелергә мөмкинлек бирмичә, ишеп кар ява башлады. Бу – 7 ноябрь иртәсе иде...

Ап-ак кар һавадан коелды да коелды. Таһир башка солдатлар белән бергә төне буе йокламады. Төн урталары булгандыр, барысына да җыенып тезелеп басарга кушылды. Һавада нык киеренкелек тоела. Өлкән лейтенант әмерләрне тыныч кына әйтә, моңарчы булган көр һәм каты тавышы, әйтерсең, каядыр югалган. Ул тезелеп баскан солдатларны күздән кичерде, строй аша йөреп, һәрберсенең килеш-килбәтен тикшереп чыкты. Аннан, тәртип икәнлеген күргәч, колоннаны урамга таба әйдәде.

Урамда солдатларны йөк машиналары көтеп тора иде, шуларга төялделәр. Мәскәүнең урамнары ябалак-ябалак кардан, әйтерсең, яктырып киткән. Машиналар Кызыл Мәйдан янына килеп туктадылар. Солдатлар төз рәтләр булып тезелеп, Мәйданга, мавзолей каршына кереп басты.

Кызыл Мәйдан кызыл комачлар белән бизәлгән. Зур-зур рәсемнәрдән Ленин һәм Сталин, әйтерсең, бирегә җыелган солдатларны, тезелеп баскан техниканы дикъкать белән күзәтәләр. Мәйданда тагын берничә игътибарлы күзәтүче бар – төрле почмакларда зенит җайланмалары урнаштырылган, аларның көпшәләре күккә текәлгән, янәшәләрендә кырыс кыяфәтле тупчылар кайнаша.

Озак басып торудан Таһирның аяклары ойый башлады. Мылтык көпшәсенә бәс кунган иде инде, суык акрынлап, аякларга үтеп кермәкче була. Җил ак карны өермә итеп күтәрә. Ләкин беркем дә урыныннан кымшанмый. Барысы да көтә. Ноябрьнең түбәннән үк йөзгән карлы болытлары кояш нурларына үтеп керергә ирек бирмәсә дә, караңгылык акрынлап, эңгер-меңгергә күчте, аннан яктыра да башлады.

Башнядагы курантларның даң-доң суккан тавышыннан Таһир сискәнеп китте. Эчтән генә, Кремль сәгатенә кушылып саный башлады. «Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез...» Еракта торган мавзолейга күз салды – аның өстендә кешеләр басып тора иде.

Кинәт ат тояклары тавышы ишетелде. Ул тавыш, Кремль диварларына бәрелеп, рикошетлаган пуля сыман бөтен тирә-юньне басып китте. Алдында торган иптәшләренең иңнәре аша Таһир кара атка атланган, папаха кигән озын мыеклы кешене шәйләде.

«Маршал Будённый», – диде янәшәдә кемдер.

Будённый каршына икенче бер атлы ашыга иде. Алар, мавзолей каршында туктап, честь биреп, рапортка керештеләр. Будённый рәтләргә тезелгән частьларны сәламләүгә күчте. Менә ул Таһирлар төркеме каршына килеп, аларны да сәламләде. Таһирны ике нәрсә бигрәк тә сокландырды – Будённыйның ике якка тырпайган озын мыеклары һәм түземсезлектән бер урында биеп торган чем-кара аты. Шул вакытта үзенең авылда калган Буцефалы искә төште. Таһир, күпсанлы халык арасында гына була торган ныклы бер экстазга бирелеп, Будённый сәламләве тәмамлану белән, дөньяны дер селкетерлек «Ура!» кычкыруга кушылды.

Сталинның тавышы Таһирга гына түгел, аны тыңлаган барча кешеләргә дә ышаныч көче бирә иде. Ул тыныч кына, ләкин үзенең көченә һәм хаклы икәнлегенә инанган рәвештә, бик тәэсирле итеп сөйләде. Илбашы Совет дәүләтенең авыр хәлдә калуы белән беррәттән, инде ныклап, аякка басуын һәм дошманны тар-мар итәчәген бер генә мизгелгә дә шикләнми әйтә алды.

– Нимес илбасарларын тулысынча тар-мар итү өчен! Нимес оккупантларына – үлем! Безнең дәһшәтле Ватаныбызны, аның азатлыгы, аның бәйсезлеге мәңгелек булсын! Ленин байрагын күтәреп – алга, җиңүгә! – дип, чыгышын тәмамлау белән, оркестр парад маршын уйнап җибәрде.

Солдатлар марш астында урыннарыннан кузгалды. Таһир мылтыгын кысыбрак тотты, башын югарырак күтәрде. Мавзолей яныннан узганда, ул Сталинны күрде кебек. Сталин хәтта, елмаеп, аңа кулын да болгады сыман. Димәк, алар җиңүгә ирешәчәк, димәк, ул җиңүгә ирешәчәк!

Таһир Кызыл Мәйданнан якты уйлар һәм тыныч киләчәккә ышаныч белән чыгып китте. Алда аны янәдән, аяусыз иттарткыч төсле, сугыш афәте көтә иде...

***

– Фәтхуллин, өлкән лейтенант чакыра! – дип кычкырды, землянка ишегеннән башын тыгып, яшь кенә солдат һәм окоп лабиринтында янә юк булды.

Таһир, урыныннан торып, нык аруына да карамастан, өлкән лейтенант янына юл алды. Урамда көчле буран иде, окоп эченә кар тулган, аны ерып барырга туры килә.

Өлкән лейтенант, аны күрү белән, өстен салып, түргә узарга чакырды. Иң көтелмәгәне – ул чеп-чи татарча сөйләшә иде.

– Йә, утыр, Таһир абый, сөйлә, кай яклардан буласың, – диде ул, кинәт гади бер татар егетенә әйләнеп.

Таһир кайдан икәнлеген әйтеп бирде.

– Татария! Мин үзем Ленинградтан. Бары тик татар кешеләре генә торган, татарча гына сөйләшкән урын бар бит дөньяда! Мин, дөресен әйткәндә, моны күз алдына да китерә алмыйм, – дип, чәй ясый-ясый шаркылдап көлеп җибәрде Хәмит.

– Соң, иптәш өлкән лейтенант, анда күбесе урысча да белми...

– Болай икәүдән-икәү сөйләшкәндә, Хәмит кенә диген, кеше алдында гына мин сиңа өлкән лейтенант.

– Рәхмәт, ләкин мин алай тиз генә күнегә алмам...

– Сугышта күнегергә вакыт юк, Таһир абый!

– Аңлыйм да бит, тәрбия...

Таһир бу егеттә таныш чалымнар күргән төсле булды. Сөйләм рәвешендә, төс-кыяфәттә үзенчәлекләр бар, әйтерсең, алар моңарчы кайдадыр күрешкәннәр. Хәмитнең әтисе ягы нәселенә китүен, атасына суйган да каплаган төсле охшашлыгын Таһир, әлбәттә, башына да китерә алмады.

– Авылыгыз зурмы соң? – дип кызыксынды Хәмит, Таһирга шешәдән аракы салып.

– Шактый зур. Мин анда авыл советы рәисе дә, колхоз рәисе дә булып эшләдем.

– Зур урыннар! Моның өчен күп белем алырга кирәктер! Әйдәгез, иптәш Сталин исәнлегенә!

Алар күтәреп куйдылар.

– Белем дип, без белемне яшьтән эшләп алдык инде, – диде Таһир, эченә кергән аракыдан җылынып, шуңа күрә масая төшеп.

– Аңлыйм, аңлыйм... Гаиләгез бармы?

– Бар, әлбәттә.

– Хатлар язалармы?

– Язалар.

– Ә балалар?

– Малай, – дигәнен сизми дә калды Таһир. Аннан, үзе дә әйткәненә ышанып, күкрәк киереп өстәп куйды. – Малаем бар. Җиһангир исемле.

– Бик матур исем! Хатыныгыз ни атлы?

– Зөбәйдә.

– Минем әнием Сәкинә исемле, – диде Таһир, йөзе караңгыланып. – Ленинградта калган иде, аннан китә алганмы-юкмы – белмим. Ленинград камалышта бит, хатлар да язышып булмый. Син бәхетле кеше, Таһир абый, якын кешеләрең исән-сау икәнлеген белеп яшәү зур бәхет ул... Мине әни берүзе үстерде бит, бабай гына ярдәм итте. Шуңа да әнием аеруча якын. Хәер, әни һәркемгә дә якындыр ул, шулай бит? Синең әниең исәнме соң?

– Исән... – Таһир шул мизгелдә үк әнисен күз алдына китерде. Бәлки, нәкъ менә ул аны чынлап торып яраткан кеше булгандыр да... – Әнием минем кайтуымны көтә, күрешә алырбыз дип өметләнәм...

– Насыйп булсын...

Авыр тынлык урнашты. Хәмит янә шешәдән аракы салып, әниләр исәнлегенә күтәреп куярга тәкъдим итте. Эчтеләр.

– Син, Таһир абый, чын герой, – диде Хәмит, тынлыкны бозып. – Мин бит солдатларны парадка аерып алыр өчен һәрберегезнең шәхси эшен тикшердем. Син яу кырында яраланган командирыңны үзеңнең җилкәңдә күтәреп чыккансың, ә бу – зур батырлык. Уттан чыккансыз бит, күпме иптәшең һәлак булган, ә син командирны коткара алгансың.

– Әйе, булды инде хәлләр, – диде Таһир. Үзенең башына исә: «Яралы командирны сөйрәп чыгу гына коткарды, аннан башка дезертир тамгасы тагып, стенага терәп аткан булыр идегез», дигән уй йөгерде. Ләкин монысын ул үзе генә белә.

– Тукта әле, кайдагы хәлләр әле бу, синең шәхси эшең монда гына, – дип, Хәмит, бераз хәмердән чайкалып, өстәлнең бер башында торган кәгазьләр өеменә үрелде.

Совет властен урнаштырып йөреп, дөньяның ни икәнлеген яхшы үзләштергән иде Таһир. Шәхси эше «Капитал» китабы түгел, бер кәгазь битеннән ары артмас. Ә аның иң беренче графаларына хатыны кем булуы да, балалары юклыгы да акка кара белән язылган. Әлеге уй яшен тизлеге белән миенә китереп сукты. Ул, кинәт урындыгыннан сикереп торып, теге кәгазьләр өеменә шап итеп учын салды.

– Кирәкми, Хәмит энем, – диде ул, өлкән лейтенантка текәлеп карап. – Минем өчен ул җиңел булмады. Мин бик күп иптәшләремне югалттым. Минем олы бүләгем аларның канына да манчылган. Гафу ит, ләкин бүген, парад бәйрәменнән соң ул хатирәләргә кире кайтасым килми. Әйдә, башка темаларга сөйләшик.

Хәмит Таһирга берара шаккатып карап торды да аннан соң аңладым дигән кыяфәт белән янә шешәгә үрелде. Ләкин аларга алга таба да гәп корып утыру язмаган икән. Башта яман сызгырган тавыш ишетелде, аннан землянка белән янәшәдә генә шартлау яңгырады.

– Иптәш өлкән лейтенант, танклар! – дип кычкырды землянка ишеген каерып ачкан яшь солдат. Алар икесе дә сикереп торып, толыплары белән итекләренә таба йөгерделәр.

– Барысын да позицияләргә! – дип, киенә-киенешкә әмер бирде өлкән лейтенант.

Таһир үз землянкасына ашыкты. Снарядлар әле анда, әле монда ярыла торды. Окоплар йокыларыннан уянып бетмәгән солдатлар белән тулды.

Нимес танклары, карлы буранны ерып, аларның позицияләренә таба шуыша иде. Артларыннан кача-поса солдатлар йөгерә. Кышкы киемнәре, күз буяучы кәчтүмнәре булмагач, нимес солдатлары ак карда әллә кайдан караеп күренеп торалар. Таһир, мылтыгын кысып, үзенең позициясендә урын алды. Эчкән аракы да, нык арыгынлык та сиздерә, арлы-бирле йөгерешкән нимесләрне мылтык көпшәсенә тоту бик авыр иде. Авыр булса да, сер бирмәде.

Танклар исә, бернигә дә карамастан, аларның окопларына якынлаша. Әледән-әле снарядлар ярыла. Совет гаскәрләре тәмам аңга килделәр, танкларга таба туп ата башлады. Таһирдан уңдарак бер танкны ут ялмап алды. Аның эченнән танкистлар сикергәләп төштеләр. Бар ихтыяр көчен җыеп, Таһир берсен мылтык көпшәсенә эләктерде һәм атып җибәрде. Ап-ак карга кып-кызыл кан чәчрәде. Нимеснең башыннан танкист башлыгы ук очып төште. Ул, ни булды инде бу, дигән сыман Таһирга әйләнеп карады төсле. Һәрхәлдә, Таһирга шулай тоелды. Ул аның зәңгәр күзләрен күрде. Дөрләп янган танк яктысында яшь нимес солдаты үзенең Газраиленә рәнҗеш белән карый төсле тоелды. Танкист гөрселдәп, карга ауды.

Бу бер мизгел иде, ә икенчесендә аның позициясенә үкереп, танк килеп керде. Таһир башына бик каты итеп китереп бәрүдән артка мәтәлеп китте. Танк, окоп өстенә менеп, дөмбердәтеп каядыр төбәп, атып җибәрде. Таһир караңгылыкка чумды...

Ул колагы зыңгылдаудан аңына килде. Әйтерсең, кемдер колак эченә кереп утырган да бертуктамый сызгыра да сызгыра. Көн яктырып килә иде инде. Таһир кинәт бармаклары, куллары, тәне өшүен тоемлады. Аның тәне яртылаш кар катнаш җир белән күмелгән, ләкин ул исән. Тирә-якка күз салды. Анда бары тик асты-өскә килгән окоплар, әле анда, әле монда иптәшләренең мәетләре аунап ята.

Ул акрынлап, аңга килгән саен тирә-як та ачыла барды. Үзендә булган барлык көчен җыеп, Таһир җир һәм кардан арынып, аякка басты.

Нимесләр, әйтерсең, юк җирдән пәйда булдылар. Берсе, Таһирны күреп алу белән, аңа мылтыгын төбәде һәм үз телендә нидер кычкырды. Таһир шундук окопка сузылып ятты. Калтыранган куллары белән түшеннән парадка дип кадалган медален суырып алды да, астындагы балчыкка тирәнрәк итеп күмеп куйды. Документлары үзе белән түгел иде.

Окоп өстендә өч көпшә мылтык күренде. Колагы әлегә начар ишетсә дә, үзенә торып басарга кушканнарын аңлады. Кулларын өскә күтәреп, аякка басып, мылтыкларга таба йөзе белән борылды.

Өч нимес яшькелт формалары өстеннән шәлләр бәйләгән, кулларына әллә кайдан тапкан бияләйләр кигәннәр.

– Комиссар?! – дип кычкырып сорады уртадагысы.

– Нихт... Нихт комиссар, – диде Таһир, кипкән иреннәрен көчкә селкетеп.

– Коммунист?!

– Нихт коммунист.

Нимес мылтыгы белән ишарәләп, алар янына менәргә кушты. Таһир, кабаланып, окоп өстенә атлады. Нимесләрнең берсе аны тиз генә тентеп

чыкты да алга атларга кушты. Аны әле төнлә генә барган сугыш кыры буйлап алып киттеләр. Янып каралган танк янәшәсеннән үткәндә, Таһирның карашы үзе үтергән нимес егетенә төште. Аның мәетен акрынлап, кар каплый башлаган. Күзләре генә шар ачык. Зәп-зәңгәр, яп-якты күзләрдә каядыр ашыга-ашыга, тиз-тиз йөзүче болытлар чагыла иде. Киевта танкын ремонтлап, Мәскәү янына диярлек килеп җиткән Вильгельмның гомере әнә шулай тәмамланды. Ул үзе теләмәгән сугышта катнашып, үзе теләмәгәнчә үлемен тапты. Тагын бер мескен бәндәнең Язмыш Китабы Мәңгелек киштәсенә куелды...

***

1941 елның декабрендә Вермахтның икенче танк армиясе командующие Гейнц Гудериан Көнчыгыш Пруссиядә урнашкан Растенбург аэропортына килеп төште. Кул сәгатенә күз ташлады – вакыт кичке дүртенче ярты иде.

Аны трап төбендә үк каршыладылар.

– Фюрер сезне ике сәгатьтән үзендә көтә. – СС офицеры самолёттан ерак түгел торган машинага чакырды. Алар икәү арткы урыннарга утырдылар. Аэродромнан чыккач, тагын ике автомобиль иярде.

СС офицеры аңа Вольфшанцега керер өчен рөхсәт кәгазьләрен суздьы. Өч машинадан торган колонна Растенбург урманнарында югалды. Урман эчендә тар гына юл салынган. Барган саен Гудериан әле анда, әле монда яшеренгән ныгытмаларны, алардан чыгып торучы пулемёт көпшәләрен күрде.

Беренче постта арттан килгән ике машина туктап калды. Гудериан белән СС офицерын исә, документларын тикшереп, ары үткәрделәр. Гитлер янына эләккәнче, җиде кат йозак аша узасы. Гудериан генерал-полковник булганга, аны тентемәделәр, ләкин портфелен ачып күрсәтүен үтенделәр.

Гитлерның бункеры таш кыяга ярып кереп салынган биек тимер-бетон бина иде. Аның тәрәзләре дә юк, кечкенә генә ишектән кереп китәсе. Кергәч тә, Гудериан тар гына коридорга эләкте, өске киемнәрен салды. Биредә бөтен яктан да стеналар. Түшәм белән идән, кинәт кысыла башлап, әйтерсең, чакырылмаган кунакларны изеп ташларга әзер. Генерал-полковникка бер кечкенә бүлмәдә көтеп торырга кушылды.

Киңәшмә алдыннан Гудериан үзе белән алып килгән карталарны, документларны тикшерде. Күңелендә үз күзе белән күргән хәлләрне яңартты.

Гитлерга дөресен сөйләргә кирәк. Күрәсең, аның тирәсендәгеләр ялгыш мәгълүмат җиткерәдер. Күптән түгел Гитлер нимес солдатларына чигенүне тыючы фәрман чыгарды. Берничә булдыклы генералны отставкага җибәрде. Үзен коры җир гаскәрләре башлыгы дип игълан итте. Тик куркырга ярамый. Ни булса шул булыр, Гудериан чынбарлыкны сөйләп бирергә ниятли. Ә чынбарлык бик аяныч – совет гаскәрләре көч җыеп, аларны кире кысрыклый, әле аның өстенә каһәр суккан урыс кышы...

Гудерианны чакырганда, кичке алты тулып килә иде. Ул бүлмәдәгеләрне күздән кичерде. Кейтель, Шмундт, Гитлер тирәсендәге башка офицерлар. Ник бер хәрби генерал булсын!

Бүлмә караңгы иде, Гитлер Гудериан белән коры гына исәнләште. Аннан соң Гудериан докладка күчте. Ул үзенә йөкләнгән фронттагы хәлләрнең

мөшкеллеген тасвирлап бирде. Танк армиясенә чигенергә рөхсәт сорады. Гитлер шартлады:

– Юк! – дип кычкырды ул, төкереген чәчеп. – Чигенергә миннән рөхсәт юк, сез генерал-полковник буларак, минем фәрманнарны яттан белергә тиеш!

– Гафу итегез, минем фюрер, ләкин чигенмәсәк, без җәйгә танкларсыз да, солдатларсыз да калачакбыз. – Гудериан бирешмәскә карар кылган иде инде.

– Юк, дидем бит! Яуланганның бер генә карышын да кире бирмәскә, булган позицияләрдә ныгытмалар ясарга!

– Позицияләр кору бик авыр, җир метр ярымга шартлап катты, безнең мескен көрәкләребез аны берни эшләтә алмый.

– Димәк, гаубицалардан атсыннар, шул бүрәнкәләрдә оборона тотсыннар. – Гитлер тынычлана төште. – Без Беренче Бөтендөнья сугышында Фландриядә шулай иттек.

– Минем фюрер, Фландриядә безнең һәрбер дивизия өч-биш километрлы фронт сызыгын тотты. Авыр гаубицалар да, снарядлар да җитәрлек иде. Ә минем дивизияләрнең фронт сызыгы һәрберсенә утыз биш – илле чакрым озынлыкта. Туплар санаулы, аларына да һәркайсына иллешәр снаряд булса ярый, дибез. Әлбәттә, алардан илле тапкыр җиргә атып, тәлинкә зурлыгындагы бүрәнкәләр ясарга мөмкин, тик миңа ул снарядлар урысларга каршы сугышыр өчен кирәк.

Генерал-полковникның фюрер белән бәхәсен киңәшмәдәгеләр дәшми генә тыңлап торды. Гитлер Гудерианга Бөек Фридрих батырлыкларын искә төшерде, соңгы тамчы канга кадәр сугышырга өндәде. Тик Гудериан какшамады.

– Һәрбер нимес солдаты сугышта гомерен фида кылырга әзер һәм моны батырлыгы белән раслый. Ләкин корбан турында сораганда, аның бушка түгеллеген белү кирәк. Хәзер без чигенмәсәк, бик күп солдатны мәгънәсез кырып бетерүгә генә ирешәчәкбез. Зуша-Ока линиясендә көзен төзелгән ныгытмалар бар, анда без армияне саклап кала алыр идек. Россиядә бик суык – госпитальләр кул-аяклары, битләре өшегән хәрбиләр белән тулган...

Гитлер өстәл янында баскан килеш, башын аска иеп, көрсенеп куйды һәм гадәти булган тыныч тавышка күчте:

– Мин сезнең үзегезне аямыйча, солдатлар янында булуыгызны яхшы беләм, генерал-полковник. Мин сезгә моның өчен нык рәхмәтлемен. Ләкин сез күп нәрсәне якыннан гына күрәсез. Масштаб җитми. Сез солдатларның интегүен күреп, аларны артык кызганасыз. Ерактан исә бөтенләй үзгә манзара ачыла.

– Әлбәттә, солдатларны яклау – ул минем бурычым. Тик алар утыз градуслы салкында җәйге униформадан йөрергә мәҗбүр булганда, әллә ни саклап калып булмый шул. Җылы итекләр, кием-салым, бияләйләр – боларның берсе дә бездә юк, булганнары тишелеп бетте.

– Ялган! – дип кычкырып ук җибәрде Гитлер. – Генерал-квартирмейстер миңа боларның барысы да фронт өчен бүлеп бирелде, диде!

– Гафу итегез, бүлеп бирелгәндер, әмма безгә генә килеп җитмәде шул. Ул әйберләр шушы көнгә кадәр Варшава вокзалында ята, тимер юллар җимерек, составны сөйрәргә локомотив юк. Без әле сентябрь-

октябрь айларында ук кышкы киемнәр сорадык, ләкин «сезгә аның кирәге булмаячак, кышка кадәр урысларны җиңеп кайтачаксыз», диделәр...

Шул ук минутта генерал-квартирмейстерны чакырттылар. Ул, дер-дер калтыранып, Гудерианның сүзләре хак булуын әйтте.

– Ничек?! – Гитлер чыгырыннан чыкты. – Без Бөек Германия халкына мөрәҗәгать итеп, солдатлар өчен җылы әйберләр җыйдырттык, ә сез?!!

Тәмам эштән чыккан Гитлер Гудерианга борылды.

– Тагын нинди проблемалар бар, генерал-полковник?

Гудериан азык-төлек, техника, танкларга запас частьләр җитмәү турында тәфсилләп сөйләде. Нимес танкларының ягулык-майлау материаллары салкынга чыдам түгел, катып китәләр, шуңа техниканы кабызып булмый. Танкларның чылбырлары тар һәм пеләш – алар тигез юлдан тиз арада хәрәкәт итәргә җайлы, әмма тирән карда батып калалар. Транспорт урынына чаналар кулланырга мәҗбүр булуын да тәфсилләп сөйләде. Кешеләр җитмәү бигрәк тә зур проблема иде. Гитлер аны сүзсез генә тыңлап торды.

Кораллану министры доктор Тодт доклады Гитлерны бераз тынычландырды. Тегесе солдатларны җылыту өчен махсус уйлап табылган тиз җыела, юлда аз урын ала торган мичләр чыгара башлау турында сөйләде. Мондый казанышлар Гитлерны шатландырды һәм ул янә бөек нимес халкы, аның булдыклылыгы хакында озын-озак нотык тотты.

Кичке аштан соң киңәшмә дәвам итте. Гудериан югары командование штабына сугышта катнашкан офицерларны җәлеп итү тәкъдимен кертте. Гитлер аны ишетмәмешкә салышты, кинәт борылып:

– Рәхмәт, генерал-полковник, сез китә аласыз, – диде.


Гудериан чыккач та, киңәшмә бүлмәсендә үле тынлык урнашты.

– Бу кешегә мин үземнең фикеремне җиткерә алмадым, – диде Гитлер. Аннан соң, кинәт рухланып сөйләргә кереште. – Минем генераллар зарланудан ары китә алмый. Гудерианны өенә кайтарып җибәрергә кирәк...

– Гафу итегез, минем фюрер... – дия башлаган Кейтель җөмләсен дәвам итә алмады. Аңа Гитлер бер генә карап алды.

– Генерал булырлык солдатлар рейхта җитәрлек. Солдат булып калган генераллар бар нәрсәне дә кирегә сукалый. Киләсе елның җәе Россияне юк итү өчен иң җайлы вакыт. Безгә көчләр тупларга, яңа дивизияләр оештырырга кирәк. Мин Берлинда күргәзмәдә булдым – яңа танклар урысларны тиз арада бәреп ташларга сәләтле. – Гитлер каршындагы картага чекерәеп карады. Аннан бармагы белән төртеп күрсәтте. – Рейхның чикләре Урал тауларыннан үтәчәк. Православиене корытачакбыз. Яулап алынган җирдәге халык эшче көчкә әверелергә тиеш. Нимесләргә яңа йортлар, яңа биналар, юллар төзиячәк алар. 1942 елның җәе – безнең өчен хәлиткеч ел. Минем янәшәмдә шуңа инанып, шуны аңлап эш итүче кешеләр кирәк. Һәм Рейхта алар бар!

*(Ахыры киләсе санда)*



Ренат
Харис

# ТАТАР КЫЧЫТКАНЫ[1]

ПОЭМА

*Татар халкының бөек рәссамы*
*Бакый Урманче истәлегенә*

«Гомер буе җаным кычый минем,
ә кашырга вакыт табылмый...
Һәм бүген дә аңа, өтеп-чагып,
хәтер кычыткана кагылды...
Күл Черкенгә[2] барып кайтыйк әле,
берәр транспорт әмәлләп,
остабикә энесе исән бит,
Гыйльмулланы күреп, сәламләп...
Күңелемне кычыттырып торган
бер кулъязма аның кулында!
Мулла абзам үлгәч, китапларын
алып калган кеше ул гына...»

Урманченың үтенече – әмер!
Аны үтәү миңа куаныч –
без бит олы кешеләр акылын
эчеп калыр өчен туган ич!
Өч көпчәкле «Урал» көймәсенә
утырттым да Бакый аганы,
алып киттем туган авылына
Казма[3] каберлеге ягалый.

---

[1] Поэманың идеясе Кычытканлы авылында (Нурлат районы) туып үскән галим, язучы Тәлгат Галиуллинның «Татар әреме» әсәре турында сөйләшкәндә килде.
[2] Күл Черкене – Бакый Урманченың туган авылы. Буа районы.
[3] Казма – әтием туган һәм яшәгән авыл. Күл Черкене янәшәсендә.

---

Ренат ХАРИС (1941) – *Татарстанның халык шагыйре; Россиянең Дәүләт премиясе лауреаты; җиде томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Черкен каберлеге күренгәч тә,
тукталырга кушты... Туктадык...
Дога укыды ул, җаны белән
зират тарафына укталып.
Бакый Урманченың яңгыравык,
туганнары исмен атаган
догалары, Зөя ярларыннан
этәрелеп кайтты яңадан...

«Нәваинең[4] «Фәрхад-Ширин»ен мин
балачакта бик күп тыңладым.
Әнкәемнең көйләп укыганы
колагымда әле тынмады.
Олы табыннарда укый иде,
елый иде кунак хатыннар!
Димәк, китап безнең телдә булган
дип уйларга минем хакым бар!
Ә Нәваи нинди телдә язган?
Унбишенче гасыр телендә!..
Аны хәтта зур-зур галимнәр дә
сүзлек белән аңлый бүген дә...
Димәк, китап безнең телдә булган –
хәтта мин дә, мин дә аңларлык!..
Ярым төрки, ярым фарсы телдән
кемдер безнеңчәгә аударып,
китап итеп төпләгән булган бит...
Бәлки, әткәй... Бәлки, бабамдыр...
Бәлки, минем бабам бабасына
ерак бабалардан калгандыр...
Менә шуны ачыклыйсы иде...
Күл Черкене искә төштеме,
теге китап күз алдыма килә...
Тарих чире йоккан кеше мин!..»

Бакый абзый кузгалырга кушты...
Һич кузгалып китә алмыйбыз –
бөҗралатып төтен ата-ата
чыгымчылый тимер атыбыз.
Стартёрга тибә-тибә тирләп,
тир тозыннан инде күз әрни...
Шул вакытта берни булмагандай,
Бакый абзый җырлап җибәрде.
Ул җырлады башын артка чөеп...
Җәйге күккә зәңгәр күзләре
үз төсләрен өстәделәр бугай,
болытларның ап-ак бүзләре
яктырыбрак китте, әйтерсең лә,
даһи кылкаләмен акбурга
буяды да галәмнәр рәссамы,
күк гөмбәзен куйды матурлап.

[4] Алишер Нәваи (1441-1501) – үзбәк шагыйре.

«Шулай җырлый идем «Соловкида[5]»,
ыңгырашмас өчен берүк мин...
Кыен чакта җырлау гадәтләре
шул ГУЛАГта миңа беректе...
Сүз канаты – бөркет, сандугачтан,
җыр канаты – Сәмруг коштандыр...
Илаһи көч булуына җырның
тәмуг капкасында ышандым...
Газыңны ач, стартёрыңа тип –
кабыначак тимер чыгымчың.
Җыр тимерне хәтта күндәм итә,
әйдә, сынап кара – сүзем чын...»

Газны бордым, стартёрга бастым –
мотоцикл, гаҗәп, кабынды!
Шунда күрдем рәссамның үзе дә
аптырашта калган чагын мин!
Зәңгәрлеге уңган күзләрендә
көтелмәгән, горур яктылык!
Шул мизгелдә ул күренде миңа
заманага хәтта ят булып,
әйтерсең лә, ул үзе Нәваи –
унбишенче гасыр түреннән
үз китабын эзләп, безгә килгән
һәм табачак кебек күренә.

«Сәлам, Габделбакый! Сәлам, яшьтәш!
Күрешәселәр дә бар икән!
Күзләреңдә һаман зәп-зәңгәр яз,
ә башыңда көзге кар икән...
Онытмыйсың, рәхмәт, Җир шарының
кендек каның тамган ноктасын...
Аякларың искергән күренә –
өченчегә таяк тоткансың...
Радиодан ишеткәләп торам –
таш чокыйсың, киндер буйыйсың.
Җитмешне дә вакладык бит инде,
ә рәсемнән һаман туймыйсың...
Ярты гасыр күрешкән юк... Менә
яшәп ятам шунда... Ялгызым...
Хатын булып торырга бик өндим,
ну күндереп булмый балдызны...»

«Шулай булгандыр шул!.. Әй Гыйльмулла,
замана бит хәтәр... Баш исән...
Эшем шундый булгач, рәсем ясыйм,
бакыр сыннар коям, таш кисәм...
Мин бит кайткаладым... Бер кайтканда,
син больниста идең – күз белән...
Гомер үтә – хәлне алып китә...
Чыда гына, яшьтәш, түз генә!..

[5] Соловки – сәяси тоткыннар өчен 1920 – 1930 елларда Ак диңгез утрауларында оештырылган махсус лагерь.

Бөтен төшем минем чыдам булды,
ә аяклар махы бирделәр –
«Соловки»ның дымлы суыклары
тезләремә үтеп керделәр.
Иске татар хәрефләре өчен[6].
ике сәгать бозга тезләнеп
торган чакта бөтен нәрсәм түзде,
тез башлары гына түзмәде...»

«Аһ, шул чакта яшел кычыткан һәм
кара мунча булса... Чабынсаң...
Татар өчен кычыткан – шәп духтыр
яфраклары симез чагында...
Бил кузгалса, нервы дулаганда,
кычытканга ятып аунадым,
аңардан да яхшырак даруны
беркайда да таба алмадым.
Кычыткан ул үләннәр даһие –
үзе чага, үзе дәвалый...
Җир өстендә аны изсәләр дә,
җир астында исән дәвамы.
Бозны тишеп, умырзаядан да
ул иртәрәк чыга һәм яши,
кар кәфене каплаган чакта да
тик кычыткан гына ямь-яшел.
Синең кебек, менә минем кебек,
безнең халык кебек түзем ул,
тимәгәнгә тими, ә тисәләр
кимсетергә бирми үзен ул.
Кычыткан да, безнең халык кебек
кычыттыра өч-дүрт шивәдә[7],
ә барыбер үз исемен саклый,
карамыйча һичбер нигә дә...»

«...һәм яшәүчән – тамырлана ала
ташта, комда! Хәйран каласың:
үзбәкләрне кичитки ут чага,
ә калакай – казах баласын...
Син, Гыйльмулла, такмакчы идең бит –
күрәм: хәзер – шагыйрь-фәйләсүф,
тел төбеңә сеңдергәнсең икән
һәрбер сүзнең шигъри хәйләсен.
Кычытканны татарга бәйләдең,
төшенерлек итеп һәр яктан...
Башкаларын белмим, ә татарда
бөтен шагыйрь чыккан такмактан:
Кандалый да, Тукай, Гафури да,
ә Дәрдемәнд – әдәбияттан!..
Аның йөрәгендә шагыйрьлекне
шәрык шигырьләре уяткан...

[6] 1927 елда 82 татар зыялысы белән бергә Б.Урманче татар язуын латин графикасына күчерүгә каршы хатка кул куя.
[7] Шивә – диалект. Бу очракта кычытканның төрләре күп булуына ишарә.

Такмакларың, ай-һай, усал иде –
кыз-кыркынны күпме елаттың...
Синдә, Гыйльмуллаҗан, якты дөнья
татар Крыловын югалтты...
Киңәшең  дә бик урынлы булды.
Кычытканның беләм дәвасын...
Ә «Соловки» – сәяси кычыткан –
кызганмады адәм баласын...»

Философлар төртмә сүзләр белән
сыйлашканда, тыйнак бер апай
чәй табыны корды җәһәт кенә:
корт, кабартма, юка[8], баллы май...
Керогазда кайнатылган суны
самавырга ипләп бушатты.
Һәм мин аны рәссам сурәтләгән
«Сепаратчы кыз»га[9] охшаттым.
Медаль таккан иске җиз самавыр
балкып тора бүксә киереп,
конфоркага кунаклаган чәйнек
безгә карый борын чөереп.
Бакый абзый аларны таныды...
Балкып хатирәләр  нурында,
һәм шуларга бәйләп сорап куйды
теге – иске – китап турында.
Ә Гыйльмулла абзый газапланды
ул китапны искә төшереп...
Ыңгырашып куйды, әйтерсең лә,
утлы сорау җанын пешерде...

«Җитмимени сиңа, Габделбакый
киндер буяу, мәрмәр таш кисү –
нигә кирәк булды иске китап?
Кычытмаган җирне кашыйсың...
Өч-дүрт еллар элек безнең якта
иснәнгәләп йөрде бер галим...
Миндә иске китаплар барлыгын,
кемнәрдәндер сорап белгән ул.
Мыеклары – карлыгач канаты,
күзе кысык, йөзе кучкыллы...
Тел дигәне – Хозыр төкергәндер,
үзе баллы, үзе очкынлы.
Һәрбер сүзе колакка керә дә
тәмле әче балга әйләнә –
аң исерә, йөрәк юмартлана,
«Юк!» дияргә телең бәйләнә.
Исемеңне фәнгә кертәсең, ди!
Керим, мәйтәм, нидән куркам соң?!
Алып китте... Фамилиясен белмим,
ә исеме истә – Миркасыйм[10]...»

[8] Юка – Буа якларында камыр азыгы (тәбикмәк).
[9] Б.Урманченың мәшһүр әсәре.
[10] М.А. Усманов – күренекле тарихчы-галим, фольклорчы, язучы.

Һәм Урманче минем күз алдында
әверелде-куйды «Сагыш»ка[11] –
гомер буе йөрткән ак хыялы,
ак өмете ничек ялгышкан!..
Ак маңгаен тимгел чуарлады,
кырысланды җайлы кашлары...
Урындыкка аркасын ышкыды
һәм тезләрен уа башлады...

«Бик тә дөрес иткәнсең, Гыйльмулла –
тапшыргансың әйбәт кулга син.
Исемең дә фәнгә кергән икән...
Үкенечкә генә булмасын...
Такта чәең тәмле... Бер күрештек...
Исән-имин генә булсакчы...
Китик инде... Безне мунча көтә –
Мәгъсумҗанның кара мунчасы...
Тезләр сызлый... Бөтен тәнем кычый –
мин корчаңгы суккан ат сыман...

Бүген син дә кузгаткан ачуны
кычытканга кушып чабынсам,
бөтен чирләр, куркып, миннән качар,
җеннәр өркегәндәй догадан,
картлык эзләре дә агып китәр
әрекмәнләп тәнне юганда...
Менә акча сиңа, кил Казанга,
күктән ярдәм көтеп утырма –
күзләрең бик тонык, күрсәтербез
атказанган берәр докторга...»

Юлда туктый-туктый, без кычыткан
эзләп йөрдек, ләкин тапмадык.
Ул елларда иген басуларын
төрле гербицидлар каплады.
Мәгърур кычыткан да чыдамады
тоталитар агулауларга...
Үләннәрнең парламенты юк шул
экологик хокук дауларга...
Мин ташландык алма бакчасында
җыеп алдым зәһәр бер көлтә...
Ул брезент бияләйләр аша
учны чага, җанны өркетә...
...Ике мунча безне көтеп тора,
яккан икән эти агын да...
Бакый абзый карасын сайлады...
Ул ләүкәдә... Һәм ул чабына...
Иске бүрек кигән... Бияләйдән...
Пар өстәтә миннән... Таш чатный...
«Соловки»га нәгъръә ора-ора,
тез башларын әүвәл ул чапты;

[11] Б.Урманченың чикләвек агачы түмәреннән эшләгән сыны.

ә аннары аркасына күчте –
ГУЛАГ хуҗаларын кыйнады,
әллә инде чыгырыннан чыкты,
кычытканны әллә тоймады;
Гыйльмулланы да каезлап алды
ятка биргән өчен китапны
һәм шунда ук аны мактарга да,
рәхмәт әйтергә дә җай тапты:
философча чагыштырган өчен
татар белән кычытканнарны.
Чабынды ул дөнья мәшәкатен
мунча ләүкәсеннән аткарып;
чабынды ул Гыйльмуллага булган
ачу ачысын да онытып...
Шушы булды бугай Урманченың
нирванага чумган минуты!..
Зөя суын эчкән кычытканнар
Зөя рухын аңа күчерде...
Тәне генә түгел, җаны, ахры,
чистарыну мәле кичерде.
Мондый чабынуны Җир Шарында
күргән мунча яки сауна
башка юктыр!.. Һәм мин Урманчены
күргән мунчабызны сагынам.
Аның диварлары һәм түшәме
күз алдымда кара лак кебек –
кара төндә көмеш Айдан гүя
күңелемә ага яктылык!..
Ул ләүкәдән төште... Ике чиләк
Зөя суы белән коенып,
кайтып китте ах-ух итә-итә,
билдән түбән генә киенеп...
Әни инде чәй табыны корган,
эти куйган ир-ат сыйлары:
яңа өзеп кергән помидорын,
яшел суган, шадра кыярын...

«Әй Мәгъсумҗан, кара мунчаң әйбәт –
җанда якты өмет кабызды:
тәнемдәге бөтен күзәнәкнең
юшкыннарын тирдә агыздым.
Тәнгә – мунча, җанга – юк, ди Тукай...
Кире кагар дәлил күренми –
акылдагы ачу һаман тере,
«Соловки» да канда эреми.
Кеше сәер – яхшыны онытып,
нык хәтерли яман эшеңне...
Бу – түзәрлек! Әмма бик тә хәтәр
дәүләт җәберләсә кешене...
Ярар... Бетте... Артык тирән кермик...
Илебезгә талпан кирәкми...
Хәтер сызлау безгә ил-дәүләтне
имин тоту фәнен өйрәтми.

Хәтердә бит  бары үткән заман...
Ә киләчәк тибә йөрәктә.
Хөр яшәргә безне хәтердәге
куанычлар рухы өйрәтә...
Коеп җибәр, әйдә... Юк-юк – чәйне...
Салып җибәр бераз бөтнек тә –
бөтнек бит ул кычыткан агуын
дару итеп тәнгә беркетә...
Зөя кычытканы көчле булды –
үз-үзләрен тоймый тезләрем...
Эх, кычыткан бетералса икән
заман кутырының эзләрен!..»

Бакый абзый баллап чәен эчте...
Күзе сүнде... Тәне оеды...
Ул диванда... Чоңгылына чумды
йокы дигән серле коеның...
Ул йоклады, кәвеш комын коеп,
үрләр бүләк иткәч халыкка,
үз эшеннән бик канәгать калган,
арып-талып киткән Алыптай;
юк, йоклады, җәһәннәмгә төшеп,
утлар сүндерергә тырышкан
билгесез бер пәйгамбәр шикелле...
Гади кеше карап торышка –
җитмеш ике яшьлек бер карт кына,
сынчы гына – ташлар чокучы,
ә бит үзе – сүнеп барган Тукай
баш очында Коръән укучы...
Унбиш минут үткәндерме, юкмы,
ул уянды... Гафу үтенде...
Муенында яткан сөлге белән
майлы тирен сөртте битеннән...

«Менә, Мәгъсум, мин бит бүре кебек –
унбиш минут җылы ял җитә...
Гомер бакый ташлар чокучыны
озак рәхәт шактый алҗыта...
Әйдә әле, коеп җибәр берне...
Юк... Чәй түгел... Әнә тегесен –
тән төерен кычыткан эретте,
җан төерен шунсы эретсен...
Кара мунчаң пакьтин дә пакь булды...
Шәп чабындым, әмма туймадым...
Тезләремне сызлаганга түгел,
тезләнгәне өчен кыйнадым.
«Соловкида» тездә торган чакта
гарьлегемне басар өчен мин,
колак кысып, озын җыр җырладым,
кату тотты хәтта эчемне.
Канвоир да кыйнарга кыймады,
махра тарта-тарта тыңлады...
Күпме кеше сынды хурланудан! –

Ә мин – җырлаганга! – сынмадым.
Кеше җырлый белергә дә тиеш
кергән чакта язмыш утына –
ул үлемнән кача алмаса да,
онытылуыннан котыла.
Һәм халык та шулай!.. Ләкин халык –
акыл ияләре көтүе...
Сират күпереннән баш тәкәсез
мөмкин түгел имин үтүе...
Татар йоклый, мәрткә китә диеп,
ничәнче кат инде кот оча!..
Ә татарның кычытканы – Тарих,
ул кагылса, Хәтер кычыта!
Ә кычынган кеше йоклый алмый!..
Шуның кебек татар халкы да...
Кычыткан җир кашыларга тиеш,
ләкин башны тотып салкында,
күңел күзен төбәп киләчәккә,
арзан данга нәфес сузмыйча,
ата-баба салган тыныч юлны
буш бугазың белән бозмыйча...»

«Шулай, Бакый ага... Мин ничә ел
әдәбият, тарих укытам...
Безнең башлар иртә чалардылар –
кайбер дәресләрдә ут йотам...
Ташка каршы таш та атканбыз без –
әйләнгән дә кайткан башка ул,
ташка каршы аш та сондык күпме –
таба алганбызмы җайлы юл?!
Ташка каршы хәтта баш атканбыз –
мескен ханбикәбез башын без...
Тарих кычытканы чаккан җирне
хәзер менә тырнап кашыйбыз...
Кан чыгарлык кашымыйсы иде –
эренләргә мөмкин ярасы.
Мондый яра яра гына түгел –
яшәү белән үлем арасы!
Бу дөньяны, аның тынычлыгын
тик матурлык, имеш, коткара...
Кемнәрнеңдер матур тормышлары
кемнәрнедер яуга кубара...»
«Дөрес, Мәгъсум, Тарих – шәп кычыткан!
Һәр халыкны бердәй чага ул.
Һәр чагудан файда алу мәлен
акыллылыр гына чамалый...
Ничә гасыр Матурлык тудыра
корыч каләм белән кылкаләм!..
Юк!.. Матурлык кына җиңә алса,
имин яшәр иде бар Галәм...
Матурлыктан өстен нәрсәдер бар!..
Әйтик, явызларча Көнләшү...

Йә булмаса – Нәфес!.. Бу дошманның
Җир йөзендә юктыр тиңдәше...
Куеп торыйк бусын!.. Рәхәт булды –
чын кычыткан белән чабындым
һәм кайтардым кебек яшьлегемнән
акыллырак телле чагымны...»

**P.S.**
Иртәгәсен без Казанда идек...
Күп яз-көзләр үтте, кыш керде...
Бакый абзый татар кычытканын
шактый еллар искә төшерде...
Ул Миркасыйм Госманов белән дә
сөйләшкән һәм аны мактаган...
Һәм галим дә кулъязма китапны
тапканлыгын кире какмаган.
Раритетны университетның
китапханәсенә тапшырган –
шәхси кулда ятудан китапка
фән йортында тору яхшырак!..
Теләк булса, керәсең – укыйсың...
Вакыт тапты микән Урманче
Казан уртасындагы бакчада
бронза сынлы һәйкәл булганчы?!.

Соравыма җавап юк әлегә...
Булмастыр да диеп борчылам –
гомер җебе, ай-һай, тиз урала
Вакыт кулындагы орчыкка...
Хәзер минем хәтерем кычыта –
кычулары инде чамасыз...
Һәм үзем дә, ут-кычыткан булып,
татар җанын килә чагасым.



Рөстәм
Галиуллин

# ХИКӘЯЛӘР

## Яглыбай баһадир

Җиһанның яз кочагына чумган көннәре. Кояш нурларының җылы сулышына түзалмыйча, тау итәкләреннән, кытыклана-кытыклана, кар сулары йөгерә. Алар, куак төпләрендә сагышларыннан моңсу гына карала барган кар катламнарын көнләштереп, берсен-берсе куып узыша, энҗе бөртекләредәй җемелдәп, тау рухының серле авазларын еракларга яңгырата, эреле-ваклы ташлар аша уйнаклап үтеп, кабарынкы дулкыннар хасил итә. Ерганакларда бергә дәррәү кушылалар да боргаланып, ашыгып-ашкынып аккан мәгъру Терек елгасына барып тоташалар. Бу җанлы хәрәкәт бар дөньяны уята: агачларда бөреләр шыта, яшел хәтфә үлән күзгә күренеп, тау итәкләренә җәелә бара. Көньяктан искән йомшак җил биттән сыйпый, назлап чәчтән тарый, бу рәхәтлектән күз йомыла...

Кинәт бер көйгә салмак кына теркелдәгән ат туктап калды, сихри тынлыкны бозып, пошкырып куйды. Иярдә йокымсыраган килеш черем итеп алган Яглыбай баһадир да күзен ачты, бая гына табигать хозурлыгыннан изрәгән күңеленә шундук шом керде. Еракта шау-шулы авазлар яңгырый – Терек буендагы тугайда бихисап атлар, яугирләр...

Яглыбай туктап калган атын кузгатып җибәрде. Тынычлык ягылган йөзенә кабаттан кырыслык әйләнеп кайтты, бер мизгелдә ул кыю яугир кыяфәтенә керде. Хуҗасындагы үзгәреш атка да тәэсир итте, башын чөеп кешнәп алды да юырта башлады.

– Бу, мөгаен, соңгы сугыштыр, – дип уйлады эченнән генә Яглыбай баһадир. – Әле Кондырча елгасы буендагы канкоештан да яралар төзәлеп җитмәде.

Ул инде күп сугышлар кичкән, үлем белән ничәмә кат күзгә-күз очрашкан тәҗрибәле яугир. Олуг Олысны яклап, күпме тапкырлар аңа үз гаскәре белән яуга күтәрелергә туры килде. Кондырча елгасы янында күпме ир туганының гомере өзелде, үзе дә чигенгән чакта аздан гына үлми калды.

---

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН (1987) *– язучы, филология фәннәре кандидаты; «Биш «ике»ле», «Юлларда җил ак иде...», «Васыять» һ.б. китаплар авторы. ТРның Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Туктамыш ханнан чапкын килгәч үк, Яглыбайның күңелен «бу соңгы сугыш булачак» дигән уй сызып узган иде. Кырыкка якынлашып килгән Яглыбай үзе генә дә инде ун ел Туктамыш белән Аксак Тимер бәрелешләренең үзәгендә кайный. Дистә ел элек Туктамыш хан Аксак Тимер кул астындагы Тәбриз каласын буйсындырганда да, Яглыбай баһадир гаскәр башлыкларының берсе иде. Инде менә хәзер дә ул сугышчылары белән нәүбәттәге канкоешта Туктамыш гаскәренең уң канатына басачак.

– Илдә тәртип юк! – Яглыбай баһадир үз эченнән генә сукрануын дәвам итте. – Ыгы-зыгылар, тәхет бүлешүләр дәүләтнең тез астына ныклап сукты. Туктамыш та, тәхеткә килүдән башлап, гаугасыз көн күрми. Аксак Тимергә ни җитми? Мисырдан Кытайгача дөньяны яулап алмакчы, инде хәзер Дәшти Кыпчакны да сытып үтмәкче. Җир җитмиме бу җиһангирларга? Әнә, болын-тугайлар, иксез-чиксез далалар, чүлләр! Тау кирәкме – менә, күккә ашкан калкулыклар, биеклекләр! Су җитмиме? Күр, бу елга-күлләрне! Алар дөнья бүлешә, яу кырында иң гаярь ирләрнең җаны кырыла. Күңелләре таштан яралгандыр бу хакимнәрнең...

Әйе, җитми шул! Һәркемнең шәп җирдә яшисе килә... Кысыр чүлдә кемнең генә иза чигәсе килсен? Җиңүчегә бөтен дөнья рәхәте, ә җиңелүчегә – үлем; үлем бәхете тимәсә, коллык газабы.

Ике якның да төп көчен атлы гаскәр тәшкил итә, төп орышны табигать яңарган вакытка билгеләүләре юктан гына түгел җиһангирларның: таулардан әле кар сулары акса, түбәнлектә инде яңгырлар сибәли, тугайларда утлап йөргән атларга үлән ике көндә яңадан шытып та чыга.

Кондырча елгасы буендагы җиңүдән канатланган җиһангирның хәлиткеч сугышка ныклап әзерләнгәне, хас дошманы Туктамыш ханны тар-мар итүгә теше кыҗраганы, Тәхет илен төбе-тамыры белән корытырга ниятләгәне озынколаклар хәбәре аша ишетелеп торды. Шулай да андый зур канкоешлар үз гомерендә бүтән булмас дип өметләнә иде Яглыбай баһадир. Әмма Аксак Тимер инде күптәннән Туктамыш ханның сакчы гаскәрләрен тар-мар итеп, чигендерә-чигендерә, ил эченә керә бара. Сугыш котылгысыз иде...

***

...Ике көн инде сызгырып, уклар оча, яралы ирләр ыңгыраша, атлар пошкырына, туктаусыз кылыч чыңы яңгырый, һәркайда оран, шау-шу – мәхшәр купкан, диярсең. Яглыбай баһадир орышкан уң канат ике көн инде Аксак Тимернең сул канатын туктаусыз талкый, беренче көнне Аксак Тимернең гаскәрен таратып ташлап, аздан гына үзен әсирлеккә алмадылар. Әмма сугышчыларының саны ишле шул: ярабби, барысы да кырылып бетмичә, канкоеш тукталмасмы икәнни?!

Ул кичне Туктамыш хан гаскәрендә шомлы хәбәр яшен тизлегендә таралды. Имештер, уң канаттагы төп хәрби җитәкчеләрнең берсе Актау әмир Туктамыш ханнан Күнче угланны үзенә тапшыруны сораган һәм аның башын чабарга ниятләвен җиткергән. Күнче углан исә яуның беренче көнендә Аксак Тимер ягыннан үз Ватанына күчеп чыккан иде. Araларында нинди дошманлык яткандыр – анысын беркем әйтә алмады, әмма Туктамыш хан Актау әмиргә Күнче угланны бирмәгән, шәхси исәп-хисапларны орыштан соң ясарсыз дигән, имеш. Бу сүзләр гайбәт кебек

таралса да, Актау әмирнең үз сугышчылары белән яу кырыннан китеп баруы, аңа тагын берничә әмир иярүе билгеле булды. Бу хәбәр Алтын Урда гаскәренең күңелен кара болыт сыман каплап алды.

Яглыбай баһадир гомер-гомергә уң канатта сугышты. Туктамыш ханнан иртәгәсен аңа сул канатта сугышырга дип фәрман килгәч, ул моны начарга юрады, пошаманга төште.

Кондырча елгасы янындагы сугышта да Аксак Тимер ничә төмән башлыгын сатып алып, үз ягына аударган иде. Хәйләкәр төлке бу юлы да үзенең пычрак алымнарын эшкә җиккән, мәкер тозагын корган икән. Яглыбай баһадирның ишеткәне бар иде: Аксак Тимер гаскәре инде менә таркала, чигенә башлый дип торганда, аңа дошман яктан хәрби җитәкчеләр яуны калдырып китеп бара, йә булмаса, сатып алынган кемсәләр сугыш байрагын төшерә дә, гаскәр башлыгы әсир төшкән дип уйлап, яугирләр коткыга бирелә, кача башлый.

Таң сызылды. Җиһан тып-тыныч. Әйтерсең лә, гап-гадәти, язгы матур көн. Яглыбай баһадир бу төнне ут йотып, керфек тә какмый уздырды. Гомер булмаганны, бала чагының күңелле мизгелләре, егет чагындагы сөенечле вакыйгалар яу кырындагы дәһшәтле хәлләр белән алмашынып, бер-бер артлы күз уңыннан чиратлашып узып торды. Нәкъ шушы бәрелештәге сыман: дөньяның иң яшәргән вакытында күкрәп торган ирләр, тынсыз калып, җансыз гәүдәләре белән кичә генә ямь-яшел келәмдәй күзне иркәләгән, бүген исә ат тояклары таптап, актарып бетергән пычрак, кара җиргә авып төшәләр. Бер-берсе белән һич янәшә куеп булмый торган күренеш бу.

Яглыбай баһадир күңеленнән якыннары, туганнары белән хушлашты, бәхилләште. Шулай да аның бу якты дөньяны җиңелүче булып, хурлык күтәреп кичәсе килми иде. Ул үз сугышчыларына күз салды: әле кичә дошманга ачудан ут кебек янган күз карашларында өмет чаткылары кими төшкән. Бүгенге орышның хәлиткеч булачагын һәркайсы яхшы аңлый.

– Тәкъдир тактасына язылганнан узып булмый! – дип уйлады Яглыбай баһадир. – Хәере белән генә бетсен!

Оран салдылар, Алтын Урда гаскәре – ике канат, маңгай – барысы бердәм һөҗүмгә ташланды. Яглыбай баһадир хәйләкәр Аксак Тимернең төп көчне ул җитәклгән сул канатка юнәлтүен, нәкъ менә аның сан ягыннан кимеп калуыннан хәбәрдар икәнлеген белми иде. Сугышчыларына көч-дәрт өстәп, кулындагы сөңгесен югары тотып, Яглыбай баһадир үзе дә сугышка керде.

Орыш кичкә кадәр барды. Бер мизгелдә Яглыбай баһадир сул канатның тәмам бушап калуын, төркемләп-төркемләп чигенүен, дошманның күпсанлы гаскәре каршында үз сугышчылары белән генә калуын чамалап алды. Һәлакәт котылгысыз иде, үзләрен камап алган гаскәрнең зурлыгыннан, күплегеннән түбә чәчең үрә торырлык.

– Чигенмәскә! – диде ул, һәм качмасын өчен үзенең атын тимер чылбыр белән тышауларга боерды.

Сырты сынса да сер бирмәс, дошманына тез чүкмәс Яглыбай баһадирның тау кебек торуы сугышчыларны да дәртләндереп, хәлләндереп җибәрде. Тигезсез, аяусыз канкоеш башланды.

Аксак Тимернең уң канаты башлыгы Усман әмир Туктамыш ханның сул

канатыннан бары Яглыбай баһадирның гына үз сугышчылары белән калуын күреп, яу кырына килде. Чигенмәс өчен атын тышаулап орышкан баһадирның даныннан каны кызды, үзе дә сизмәстән, шул тарафка томырылды.

Яглыбай баһадирның очлы күзе җан сакчылары уратып алган Усман әмирне ерактан ук тотып алды – сукса тимер өзәрдәй таза ир туп-туры аңа якынлаша иде.

– Усман әмир! – Яглыбай баһадир, тавышын күтәреп, дошманына кычкырды. – Батыр булсаң, минем белән бергә-бер алыш!

– Мин синең сөягеңне көл итәм! Сүзем – сүз! – Усман әмир яшелле-күкле тавыш белән шыр акырып җибәрде, кылычын селтәнә-селтәнә, Яглыбай баһадирга ташланды. Көчләр тигез иде, әмма Яглыбай баһадир тәҗрибәлерәк, ул туктаусыз һөҗүм иткән Усман әмирдән оста гына сакланып, уңайлы мизгелне көтте. Кинәт... Яглыбай баһадирның чигенмәсен өчен тышауланган аты сөрлекте дә, авып төште, үзе белән бергә җайдагын да тәгәрәтте. Өстенә хәнҗәрен ялтыратып ташланган Усман әмирнең канлы карашын гына күреп өлгерде Яглыбай баһадир...

***

Яглыбай баһадирның гәүдәсеннән аерылган башы өчен коточкыч суеш башланды. Ахыр чиктә, сугышчылары Яглыбай баһадирның гәүдәсен кулларына төшерә алды – кара көбә киемнән, ак атларга атланган егетләр аны яу кырыннан алып чыкты.

Яглыбай баһадирның гәүдәсен читкә алып китү белән, Туктамыш ханның сул канаты да таркалып бетте. Бу җиңүе өчен Аксак Тимердән «баһадир» аты алачак Усман әмир дә, башкалар белән бергә, Туктамыш ханның чигенеп качкан гаскәрен эзәрлекләп китте.

Үлек тулы яу кырын, коркылдашып, кара козгыннар сырып алды. Гүя: «Курррык, курык», – дип кычкырган козгын тавышыннан куркып, тау итәкләреннән шаулап йөгергән кар сулары да тынсыз калды сыман, күкне сырып алган кара кошлар пәрдәсен ай да ачып керә алмады. Җиһанда тереклек бәйрәме түгел, башка тантана көтелә иде.

Кыр уртасында тышауланган атның үле гәүдәсе ятып калды. Ул исән чагында ук чигенмәскә хөкем ителгән иде...

## Борылышта

Яз җиленә җәй сулышы өртелә башлаган бер көн иде ул. Агачлардан узып, күңел бөреләнгән, соңгы кар суларын күреп, йөрәк сагышланган, баш төртеп килгән үләннәрдәй җанда әллә нинди уйлар шыткан чак иде. Яз җитте, яз үтә, җәй килә... Бу мәңгелек агышта үзеңнең йомычка гына булуыңнан гаҗизләнеп кычкырып еларга да, шушы чиксез дәрьяда сәяхәт итә алу шатлыгыннан бар дөньяны яңгыратып көләргә дә белмәссең...

Менә шундый көнне без Малик абый белән юлга чыктык. Әле таң атмаган, Казан, шагыйрь әйтмешли, уянмаган иде. Хәер, алдыйм: безнең шәһәрнең йоклаганы да юк бугай аның. Иртәнге өчтә дә, әнә, урамнарда машиналар тыз-быз килә.

– Өйләренә кайталардыр болар, – дип нәтиҗә ясады Малик абый. – Һәр юньле ир шулай иртән уяныргa, юыныргa, киенергә һәм өенә кайтырга тиеш! Мин генә ул менә җитмеш яшем дә тулмаган килеш һәркөн өйдә уянам...

Юл йөрергә Малик абыйдан да рәхәт кеше бар микән? Үзе әйтмешли, җитмешнең чабуыннан тотса да, яшьләргә биргесез әле: күңеле дә, күзе дә, сүзләре дә унсигездә аның. Ул – язучы кеше, аның да тегенди-мондые гына түгел, танылганы. Кая гына барса да, кочаклап алалар үзен, әби-бабайлар гына түгел, хәтта кызлар да күрешергә кул сузып килә...

Бу юлы безнең Мордовиядә яшәүче татарлар янына юл тотуыбыз. Таң атты, кояш чыкты, яктылык офыкларны киңәйтте, сөйләшә-сөйләшә, Ульян каласын узып барабыз икән. Машина йөртүче Раил автозаправкага туктагач, Малик абый да яшьлектә калган мәхәббәте турында сөйләүдән өзелде:

– Каһвә эчеп алсаң ярар иде үзе...

– Монда кофе бар, – диде Раил. – Заманча автозаправка бу, теләсәң, ашап та чыгасың.

Урнашкан урыны искитмәле иде аның: без килгән яктан юл Ульян, Казанга китә, аз гына алдарак, икегә аерылып, берсе – Сызраньга, көньяк шәһәрләргә илтә, икенчесе сине Саранск, Мәскәү белән тоташтыра.

– Кара, кара, нинди шәп урынны сайлый белгән моның хуҗасы. – Малик абый үзенә хас хәрәкәтчәнлек, җитезлек белән автозаправканың дүрт ягыннан да урап килде. – Машиналар ташкын булып агыла! Борылышта!

Ул арада автозаправка бинасыннан Раил чыкты.

– Каһвәсе бармы? – Малик абый исеннән борыны кытыклангандай тотырып бер сулыш алды, сабыйларча кулларын угалады.

Раил иң элек аты-юлы белән сатучының җиде буын бабасын искә алды. Аннары тәмәке төтенен, ачу белән, кат-кат эченә йотты да:

– Юньсез хатын! Кофесы да юк, кассасы да эшләми, бәдрәфе дә бикле. Аждаһа! Киттек! Гомерем булса, монда башка туктамыйм! Ууу!.. – Раилнең нерв җепселләре киерелеп тартылган, ул әрле-бирле йөренде, берьюлы ике тәмәке кабызды.

– Тукта, үзем кереп чыгыйм әле... – дидем мин.

Ике апа белән үскәч, хатын-кыз холкын бераз чамалыйм кебек. Ике абый белән үскән Раил аның нечкәлекләрен мәңге аңламаячак. Аның ачудан кан тамып торган карашын канәгатьлек белән күз уңыннан кичереп, эчкә уздым.

Җыйнак кына бинада юлчы өчен бар да бар: чәй дә эчәргә була, салат, камыр ризыклары да күренә, кофе аппараты да әллә кайдан сәлам биреп тора.

Әйе... Мул гәүдәле, озын буйлы кырык яшьләрдәге хатынның кәефе, чыннан да, юк бугай. Миңа ул, әле бер гаебем булмаса да, каш астыннан сөзеп карады. Болай ук яратмыйча караганнарын күптән хәтерләмим. Нindидер мактау сүзе әйтергә телем әйләнмәде. Шулай да мөмкин кадәр ягымлырак булырга тырышып:

– Исәнмесез, кофе ясап бирә алмассызмы икән? – дидем.

– Кофе аппараты ватылды, эшләми! Әйттем бит инде берегезгә! Нинди адәмнәр сез?

Имәнеп киттем, телем көрмәкләнде:

– Алайса, чәй дә ярый инде...

– Чәйнек эшләми!

– Кһм... – сабырлыгым әлегә җитәрлек иде, бу юлы да сер бирмәдем: – Су бирегез инде болай булгач, зинһар...

Ул минем банк картасы аша түләргә җыенуымны күрде дә:

– Карта аша кабул итмим, аппарат эшләми! – дип кырт кисте.

Бу төксе, юан, шыксыз хатын турында ни уйлаганнарымны Малик абый белән бүлешергә дип кырт борылган идем, ишектән җырлый-җырлый үзе килеп керде.

– Киттек, Малик абый! Бу аждаһадан берни дә алмыйбыз, Раил хаклы...

Малик абый минем сүзләрне колак яныннан гына уздырды да «дошман»ның каршысына ук басып тезеп китте:

– Безнең Казанда гына матур хатыннар яши дип уйлый идем, менә кайда икән аның иң чибәрләре! Мондый борылышта, дөнья үзәгендә шундый сөйкемле кеше генә эшли ала. Син бит кояш кебек нурларыңны төрле якка таратасың: бу якка карасаң, җылың Ульян, Казанга китә, икенче тәрәзәңнән яктылык без барасы Саранскины яктырта...

Малик абый өтерсез-ноктасыз, паузасыз укларын очыртып кына тора, әмма хатынның йөзендә, күзендә үзгәреш юк. Мин авызымны учым белән каплап кеткелдәдем: кая инде ул без, яшьләр эретә алмаганны сиңа, җитмеш яшьлек картка, мыегы агарган агайга туң йөрәкне җылыту!

Мин иплап кенә Малик абыйның терсәк турыннан тарттым да ишеккә таба ымладым. Шулчак Малик абый монологын сүзсез һәм хиссез генә тыңлаган хатын телгә килде:

– Сезгә нәрсә кирәк?

– Безгә берни дә кирәкми, синең ягымлы карашың, бер елмаюың җитә! Ә инде синең назлы кулларыңнан каһвә эчә алсак, без инде дөньядагы иң бәхетле кеше булыр идек...

– Аппарат эшләми...

– Туктале, җаный, минем кулым алтын бит, төзәтим әле аппаратыңны, аннан соң гел дә ватылмас...

Малик абый сөйләнә-сөйләнә, витрина артына узды. Мин исә тәрәзәдән кайнаган ачуын төтен белән суытмакчы булып, әрле-бирле йөренгән Раилне күзәттем. Тартуын ташлап йөргән көннәре, инде бер айлап тәүлек саен тәмәке санын киметеп, биш-алтыга гына калдырган иде... Җилгә очты тырышлыклары...

Кофе аппараты шыгырдап алды. Малик абый, кулын угалап, шатлыгыннан балаларча сикеренде.

– Әйттем бит! Үзем генә түгел, кулларым да алтын минем! – Үзе исә, күз кысып, миңа пышылдарга да өлгерде: – Розеткага тоташтырмагач, аппарат эшләми инде ул.

– Ниндие кирәк, американо, капучино, эспрессо? – Явыз хатын елмаймый, шулай да ысылдавы кими төшкән иде.

– Синең кулдан агу эчәргә дә риза без, кайсын телисең, шунысын бир...

Кофе әзерләнгән арада Малик абый аның исемен дә сорашып алды.

– Маша, – дип мыгырдап алды хатын.

– Ох, хороша Маша, да не наша! – Малик абый ничек кенә тырышмасын,

хатынның йөзе аязмый әле. Казанны күргәне юк, татарны күргәне булса да, татарчаны ишеткәне дә юк икән. Шулай да кофесы әзер булды, Малик абый белән бергәләшеп эзли торгач, бәдрәф ачкычы да табылды, картадан акча кабул итү аппараты да кабынды, Ходайның рәхмәте...

Тәрәзә янында әрле-бирле йөренгән Раилне Малик абый кул изәп, күпме генә чакырса да, тегесе ишек бусагасыннан кабат атлап кермәде.

– Минем мондый сөйкемсез хатыннардан аллергия! Тешем дә сызлый башлады, − диде ул, йөзен чытып.

− Күпме яшәп, мондый каһвәне эчкәнем юк иде әле минем. Әгәр сине күрмәсәм, белми үләсе икәнмен. − Малик абый сүзләреннән Машаның бите тартылып куйды. Бәлки, йөзе тартышып куйгандыр, әмма мин аны елмаюга юрадым. – Син һәрвакыт көлеп тор, сиңа елмаю килешә. Менә безнең кебек юлчылар синнән көч алып, илһам алып китә.

Вазифасына кермәсә дә, Малик абый Машадан Саранскига илтә торган юл турында кат-кат сорашты, тегесе исә, ни гаҗәп, шактый тәфсилле аңлатты. Саубуллашканда исә Малик абый Машаның йөрәгенә үк барып җитәрдәй сүз-сөңгеләрен очырды:

− Мин кире кайтканда да, һичшиксез, синең каһвәне эчәргә керәчәкмен. Гомумән, шушы юлдан үткән саен синең янга туктаячакмын, алай гына да түгел, борылышта Маша бар икәнен үлгәнче исемә төшереп торачакмын...

Раил һаман әрле-бирле йөренә, көнлек планын үтәгәч, тартырга тәмәкесе дә калмаган.

– Йөртүченең көеннән торырга кирәк. Тәмәке алып чыгыйммы? – ишеген ача башлаган Малик абый өлгермәде – машина, тәгәрмәчләрен чинатып, кинәт кузгалып китте. Малик абый тәрәзәне ачып, Маша ягына учыннан өреп мәхәббәт очкыннары очырды − тегесе дә кулын селкеп алды бугай.

Кояш күтәрелгәнгәме, әллә кофеданмы, шактый гына эсселәткән иде. Юл көньяккарак илткән саен табигать яшәрә, тәрәзәдән яшьлек-яшәрү исе ургылып керә иде.

Юлыбыз уңды, эшләр тәмамланды. Көн инде кичкә авышты, бик тиздән эңгер-меңгер төшәчәк. Кыбырсык Малик абыйның һич кенә дә кунып каласы килмәде, юлга әйдәде. Ял итәргә өлгергән Раил дә аны хуплады, шулай Казанга таба кузгалдык.

Кайту юлы ул инде һәрчак кыскарак сыман, караңгы төшсә дә, күңелдә ниндидер бер ашкынулы рәхәт халәт. Шулай Малик абый белән сөйләшеп барганда, сүзебезне Раил бүлдерде:

− Бензин салдырырга иде. Тагын теге борылышка җитәбез, − диде һәм иртәнге хәлләрне уеннан кичерепме, сүгенеп куйды.

– Ә, борылыш дисеңме! – Малик абый урынында калкынып алды. – Теге бала янына кереп чыгыйк.

Автозаправка утлары ерактан ук балкып каршы алды. Якыная барган саен тәрәзәне каплап торган Машаның тулы гәүдәсе аермачык күзалланды. Безнең машинаны танып алуга, ул елмаеп, кул болгады. Малик абый әле машина туктар-туктамас борын ук, ишекне ачып төште дә кулларын җәеп, тәрәзәгә таба атлады. Кичкә Маша, сакчыллык йөзеннән, бина ишеген бикләп куя икән. Бензин салдыручыларга тәрәзә аша гына хезмәт күрсәтә.

Малик абый белән күрешергә ул ишекне ачып йөгереп чыкканын сизми дә калды.

Алар кочаклашып күреште.

− Юлыгыз уңдымы, эшләрегезне башкардыгызмы? – диде Маша, кайгыртучанлык күрсәтеп.

− Син ясаган каһвәне эч тә, ничек уңмасын инде? − диде Малик абый. − Тәме көне буе авыздан китмәде.

Катгый тыелган булса да, Маша безне эчкә уздырды. Раил белән бәхәсләшми-нитми генә, машинага бензин да салдырдылар. Иртән шыксыз күренгән бина матурланган төсле, шул вакыт эчендә яңадан үзгәртеп корганнармыни! Эчке бер бүлмәдә кечкенә генә өстәл дә бар икән, Маша, сорап та тормыйча, шунда җыйнак кына табын корды. Шактый тулы гәүдәсен җитез генә хәрәкәтләндереп йөргән бу хатын үзе дә күзгә күренеп матураеп киткән төсле иде.

− Татарстанны бик мактыйлар инде, − диде Маша, безгә әле шоколад, әле печенье тәкъдим итә-итә. – Казан бик матур, диләр...

− Синең шикелле! – Малик абый шәһәр турында сөйләп китте.

Мин авызымны ачып тыңладым: Машаның күзе кебек зәңгәр күлләр икән бездә, бөдрә чәче кебек куе урманнар шаулый, аның тавышыдай саф чишмәләр челтери, тагын әллә ниләр – Малик абый үз чагыштыруларына үзе дә шаккатып, тезде дә тезде генә.

Маша үзе Ульяновск янындагы бер авылда яши икән. Иң гаҗәбе: безнең Машабыз кинәт кенә татарчага күчте, чын исеме Марзия булып чыкты аның. Урыска кияүгә чыккан да Машага әверелгән дә куйган. Хатынның буасы ерылды, сөйли дә сөйли: бер дус кызы Казанга кияүгә чыккан, шунда кунакка җыенам, ди. Татарча китап-журналлар укыйсым килә, дигәч, Раил машинадан берничә китап та табып керде. И-и, аңа сөенгәннәре!

– Марзия, син татарча сөйләшкәндә, йөзең тагын да чибәрләнә! Гел татарча сөйлә син, яме, аппагым? – Малик абый кайдан табып бетерәдер хатын-кызларны эретә торган сүзләрне?

Безгә китәргә кирәк иде. Маша-Марзиянең күзенә моңсулык йөгерде, ул инде Малик абыйга үзенең тормышын, күргән авырлыкларын сөйләргә, күңелен бушатырга өлгерде. Ире эчә, каенанасы явыз икән... Елап та алды, көлгәләде дә. Һәркайсыбыз белән җылы саубуллашты ул. Малик абыйга исә кәгазьгә төреп, сумсалар да тоттырды. Үзеннән бер башка озын Марзиянең күкрәгенә башын куеп торганда, Малик абыйның да күзендә яшьләр җемелдәп алды − әллә чын, әллә багана утларының чагылышы – аңламассың...

Машина кузгалгач, Раил икеләнгәндәй:

− Бу теге явыз түгел, игезәгедер, мөгаен... Кеше көн эчендә ул кадәр үзгәрә алмый! – дип куйды.

Малик абый аңа җавап итеп моңсу елмайды гына. Бераздан аның йокылы-уяулы тавышы ишетелде:

– Ул борылышта, чыннан да, әйбәт... Ә Машага, Марзиягә диюем, авыр сүз әйтмәгез. Көйләнәчәк аның тормышы... бүгеннән...

Мин каерылып, артка борылып карадым: артта тоташ караңгылык, шулай да борылышта, тәрәзәгә капланып, кемдер елмаеп тора сыман иде...

## Фотосурәт

Көннәрнең берендә, башкорт дустым бала чагымдагы фотосурәтне сорап шалтыратты:

– Нәмәкәй, кызыклы, үзенсәлекле булһын, һине башка яктан асып бирһен, – диде ул.

Балачактан минем нибары бер фотоальбом бар, анысы да яртылаш кына тулы. Биләүдә ятканы, мәҗбүриләгәнгәме – балалалар бакчасында уенчык тоткан килеш еламсырап басып торганы, беренче сыйныфка бару уңаеннан һәм...тагын берничә. Аларының да бернинди үзенчәлеге юк. Үзем ошаткан бер фотосурәт бар да барын, әмма ул «Сабантуй»да чыккан, инде саргылт төс сеңгән газетадан малайның йөзе аермачык танылмый да. Әтнә Сабан туенда төшереп алган мине фотохәбәрче агай. Малай-шалайларны үз янына чакырган да, кем дә кем ике потлы герне күтәрә, шуңа миннән бүләк булачак, дип шаярткан ул. Нигәдер ул мәйдан уртасына дәшкән малайлар еламсырап читкә киткән, мин исә ике потлы гергә чытырдатып ябышканмын да үҗәтләнеп, кузгатырга азапланганмын. Тешне кысып, бүләккә өметләнеп, көчәнеп төшкән фотосурәт шулай дөньяга таралган. Әмма аның сыйфаты начар, башкорт дуска җибәрүдән мәгънә юк. Ул теләгәнчә, җанлы, кызыклыны таба алмадым дип, альбомны шапылдатып япкан идем, тылсымлы әкиятләрдәгечә, бер фотосурәт шуып килеп чыкты.

Андагы таныш күренештән җир убылып киткәндәй булды, эчемә салкын йөгерде. Ул вакыйганы оныткан кебек идем югыйсә. Күрәсең, адәм баласының күңел төпкелендә хәтерне җыйнап саклый торган иң яшерен хатирәләр тартмасы бар. Ничек кенә онытырга теләсәң дә, тормыштагы бер генә мизгелнең дә очраклы түгеллеген исбатлап, әнә шул яшерен төенгә төйнәлгән истәлекләр калка да чыга, калка да чыга...

Ул күренешне фотосурәткә апам төшереп алганын хәтерлим. Көнесәгатенә кадәр билгеле – тасмалы фотоаппарат аларын төп-төгәл сугып куя иде. Миңа унбер яшь булган ул чакта. Сабан туе мәйданы. Мин бер малайның билennән кысып күтәргәнмен дә чөеп ыргытырга әзерләнгәнмен. Кулына кызыл тасма бәйләнгән хөкемдарның йөзе шөбһәле, канатын җәйгән тилгәндәй, ике кулын сузып, көрәшүче малайларга омтылган. Бер мизгел һәм көндәш малай аркасына килеп төшәчәк, тирә-якта: «Чистага китте!» – дигән хуплаулар ишетеләчәк. Әмма... Бөтен гәүдәм калтыранып алды, әйтерсең лә, кабаттан шул мәйданга кайтып төштем.

...Безнең авылда сөлге тотып карамаган малай юк бугай. Ир-егетләр тирә-яктагы Сабан туйларында баш батыр кала, ике кешенең берсе – район, республика чемпионы. Өстәвенә, бөтенесе диярлек нәселләре белән көрәшче. Берәр әти кешенең яңа гына район Сабан туенда батыр калган малаен мактыйсы урынга:

– Мин синең яшьтә өч тапкыр районның баш батыры калган идем инде, – дип, бал мичкәсенә бер кашык дегет тамызып куюлары гадәти хәл иде.

Шуңадырмы, каннары кызганда да, ир-егетләр: «Әйдә, сугышабыз», – дип түгел, «Әйдә, көрәшәбез», – дип, «хакыйкатьне» ачыклый иде бездә элегрәк.

Чүлмәкчедән күрмәкче, дигәндәй, сәләтем әллә ни булмаса да, мин дә көрәш түгәрәгенә йөри башладым. Дөресен әйткәндә, башкасы юк та иде. Сөлге тотарга өйрәнгәч, бераз ысулларына төшенгәч, төрле ярышларга йөри башладым, кайчак уңыш та елмаеп куйды.

Малай кешегә көч-куәт белән ышаныч бергә иңә. Әле кичә генә борын сагызын агызып йөргән сыек кына буынлы малай-шалайны карыйсың да танымый азапланасың: кай арада беләкләрендә мускуллар пәйда булган, күрешкәндә үк, кулны ныгытып кысып ала, җилкәләре киңәйгән, тавышы да калыная төшкән үзенең. Иң гаҗәбе – күзгә туп-туры карап, бәясен белеп сөйләшә башлый. Бу үзгәреш көтмәгәндә, кисәк була. Нилектән, нәрсәдән ул – белмәссең. Сабан туена көрәшергә чыкканда, минем дә шундыйрак халәт иде. Вак-төяк турнирларда урыннар алгалап, ышаныч та арткан, аннары әллә кайдан ниндидер тылсымлы көч тыелгысыз өстәлеп торган кебек иде.

Бездә көрәш көне буе бара иде ул чакларда. Яңа тәпи киткәннәрдән таякка таянган бабайларга кадәр сөлге тота. Минем ише малай-шалайларны да, гәүдәгә, яшькә карап, әллә ничә төркемгә аералар. Көндәшләрне ачыклап бау тотканда, бүләк алуымны күзалдыма китереп, татлы уйга талдым: мин көрәшкән төркемгә көчле егетләр эләкмәгән иде. Жирәбәгә дә таныш булмаган кунак малае чыкты. Үзе миннән ярты башка озын, әмма сыек буынлы икәне әллә кайдан кычкырып тора. Кулына кызыл тасма бәйләгән «Ялагай» кушаматлы Айзат абый икебезне мәйданга чакыргач, ышанычым тагын да артты: көндәшем сөлге бәйләү җаен да белми икән.

Тик Айзат абый нигәдер көрәшне башларга ашыкмый, болай да алсу шома йөзе бөтенләй чия төсенә кергән, үзе исә кунак малаен иңеннән кочып тоткан килеш, трибуна ягыннан күзен алмый. Авызын колагына кадәр ерган тагын.

– Ник көрәштермисең, Айзат абый? – дип сорадым, аптырагач.

– Ашыкма, кабаланма. Салих Сафиуллович бу якка карамый бит әле. Малае көрәшкәнне күрсен инде.

Өстемә салкын су сиптеләрмени? Ирексездән, трибунага таба борылдым. Анда кәтәнә булса да, башкалардан озын күренгән түп-түгәрәк кабак башлы, тубал битле, келәй белән ябыштыргандай ясалма тоелган чем кара «Гитлер мыеклы» агайның канәгать елмаеп, өстәлгә таянып басканы күренде.

«Ялагай» Айзат табага төшкән мәче шикелле олы гәүдәсен алпан-тилпән китереп, үз чире токтандай сикергәләп алды.

– Җә, җегетләр, махы бирмәгез, матур көрәшегез, – диде ул.

Трибунадагы агай безгә читтән җитәкче итеп җибәрелгән кеше. Бер туганы зур урында утыра, төрле-төрле җирдә эшләп тә булдыра алмагач, элек-электән миллионер колхоз булган, аягында нык басып торган безнең авылга төрткәннәр моны. Алгарак китеп булса да әйтим инде: ул бер-ике елда безне тәмам бөлгенлеккә төшереп, башка хуҗалыкка күчте. Анда да сатарлык әйбер калмаган; ачудан бер комбайнчы үзен басуда тотып дөмбәсләгәч, ел тулар-тулмас качкан, диделәр. Шуннан соң нинди төшемле урынга куйганнардыр, миңа караңгы...

Без – малайларның да аңа үз ачуыбыз бар иде. Авылда атлар күп иде

әле ул заманда. Көнебез әнә шул киртәләп алынган мәйдан эчендә утлап йөргән тайлар, атлар янында үтә. Аларның беришен җигәргә әзерлиләр, кайсыларындыр тиздән иткә озатылачагын да беләбез, әмма аларның санын киметмиләр, үрчетеп торалар. Һәр малай берәр атны ияләндерә, дускаен сыйларга өеннән ипи ташый. Минем дә «үз» атым бар, төсенә карап, исемен «Алмачуар» дип куштым. Кайсыдыр алтын куллы малай бауны катлы-катлы үреп йөгән ясады, аннан күреп без дә кабатладык. Үз атыбызны киртә буена чакырып алабыз да, «йөгән» кидертеп, туйганчы атланып йөрибез. Эчкә кереп атланырга куркыта, чөнки кызгылт яллы сары айгыр чит-ятларны күрсә, ыжгырып килә дә тибенә башлый. «Үз» атыбызга атлангач та, кешни-кешни куа әле ул. Безгә шул кызык, шунысы рәхәт. Малай кеше өчен моннан да күңеллерәк шөгыль, зуррак батырлык була аламы?

«Гитлер мыек» хуҗа булуга, атлар көнләп кырыла башлады һәм берике ай эчендә киртәләп алынган мәйдан бушап калды. «Алмачуар»ым да шул арада юкка чыкты. Аны эзләп тә таба алмаган көнне үксеп елаганым хәтердә. Кайчандыр атлар пошкырган, кешнәгән мәйданны алабута сырып алды, без ул якка карамыйча үтеп китәргә тырыша идек. Трибунадагы абзыйның симез чыраен күргән саен әнә шул атлы – күңелле чаклар искә төшә дә, ирексездән ачу кабара...

...Кем ничектер, мин көндәшнең биленә сөлге салуга, җиңәсемне яки җиңеләсемне белә идем. Була шундый малайлар: аягын сөйрәп кенә, мәйданга чыга, авыр уһылдап, сөлге урый, тыштан әллә ни көчле дә күренми, әмма сөлге тотуга, сулыш алмаслык итеп куырып ала, биле дә тимер кебек үзенең – кузгата да торган түгел. Монда инде күпмедер тартышып карарга гына өметләнергә кала, бер күтәрүдә үк аркага салдырмаска, хурлыклы җиңелмәскә тырышасың. Кайберләренең биле тал чыбыгы кебек, кысып алуга тартылып килә. Андый солы камырлары үзләре үк сөлгегә ияреп менәргә әзер торган сыман, баш аркан әйләндереп кенә саласы... Бу малай да шул төртсәң аварга торганнар кавеменнән иде. Безнең авылда бер алым да ясамыйча сөйрәлеп йөргәнне, озаклап көрәшкәнне яратмыйлар. Кунак малаен да ипләп кенә янбашка алып, җайлап кына баш аркан әйләндереп салырга ниятләдем.

Айзат абый сыбызгысын җиңелчә сызгыртып алуга, көндәшемне күтәреп тә алдым, чөеп тә җибәрдем. Тик, нигәдер, ул шапылдап өстемә килеп төште.

– Ашыкма, кабаланма, – диде Айзат абый шөбһәле тавыш белән. Үзенең карашы трибунада.

Шулай берничә тапкыр кабатланды: күтәреп ата торам, кунак малае өстемә ава тора. Мәйдан читеннән:

– Ялагай, ник төртеп төшерәсең күтәргәнне?

– Зоотехник буласың киләмени?

– Читкәрәк кит! – дигән тавышлар ишетелде. Бездә ирләр – гаярь: гаделсезлеккә күз йоммыйлар – сүзләрен маңгайга бәреп, турыдан ярып, чатнатып әйтәләр. Кемнең нәрсә кычкырганына хәтле аермачык ишетеп торам.

– Айзат абый, читкәрәк кит әле, атарга комачаулыйсың! – дидем, шартларга җитешеп.

Бу юлы малайны өстемә төшерергә исәп юк иде, тешне кысып, җан ачуым белән чөеп үк күтәрдем, аяклары чәбәләнә-чәбәләнә җилкәдән дә биегрәк узып китте хәтта. Әнә шул мизгелдә фотоаппаратның «черт!» иткәнен дә ишеттем. Шулвакыт ниндидер көч өстән басты да кунак малай бар гәүдәсе белән өстемә ауды. Торып баскач та, әле берни аңламадым, әмма «Ялагай» Айзат, трибунага карап, кунак малайның кулын күтәргәч, әллә нинди гарьлек бәреп чыкты. Сөлгене йомарлап, Айзат абыйның йөзенә аттым да Сабан туеннан кайтып киттем. Ниндидер күзачкысыз буран эченә килеп капкан халәттә идем. Бары «Гитлер мыек»ның ике кулын югары күтәреп чәбәкләвен, алтын тешләрен кояш яктысыннан да уздырып җемелдәтүен генә күреп калдым...

...Бу хатирәләрдән тизрәк котылырга теләп, фотоны ертып атмакчы идем дә ниндидер көч туктатты. Мин аны кабаттан альбомга, Сабан туенда үҗәтләнеп, гер күтәрергә тырышкан малай фотосурәте басылган газета артына яшердем. Иң кызыгы берничә көн узгач булды. Минем әсәрләрне укып барган, кайчандыр җитәкче урында эшләгән бер карт агай шалтыратты:

– Энем, син дә, мин дә белгән Салих Сафиуллович юбилеена үзе хакында китап чыгарырга тели. Бу эшне кем башкара ала икән дип, киңәш сораган иде дә, синнән дә кулай кеше юктыр, дидем. Начар кеше түгел, үзең дә беләсеңдер. Туганын урыннан алгач, аны да эшсез калдырдылар, тормышының көе китте инде. Ярдәм итик әле шуңа?

– Булдыра алмам шул, – дидем агайга. – Әгәр истәлекләр китабына кирәк, дисәгез, миндә аның малае белән төшкән бер фото бар, шуны бүләк итә алам...

Кабаттан ул фотосурәтне сорап шалтыратучы булмады. Ә башкорт дуска исә елмаеп төшкән бүтән фотосурәтне юлладым...

## Өй туе

Мин ул мәҗлескә шактый ук соңарып килдем. Бу вакытка инде Казан урамнары бераз бушый төшкән, суыктан куырылып, авызларыннан бүректәй пар бөркеп, тиз-тиз теркелдәгән берничә кеше генә күземә чалынып калды. Урамда тиктомалдан киләп сарып йөри торган көн түгел иде бу.

Ниһаять, шәһәр читендәге тар бистә юлларында уңга-сулга борылырга кушып йөдәткәч, навигатордагы кызның: «Сез килеп җиттегез!» − дигән җиңүле тавышы ишетелде. Машина ишеген ачуга, суык җил өтеп алды. Якында гына ачык кыр, Казан урамнарында үзенә урын таба алмый бәргәләнгән кысынкы җил монда тәмам үз иркенә чыккан: сызгыра, улый, кар тузгыта...

Шулай да колакны пәлтә якасына качырып, тирә-юньгә күз салам: яңа йортка күчкән хуҗаның күңеленә хуш килердәй сүзләрне өй диварларыннан, коймасыннан, тәрәзәләрдән эзлим. Бу бистә калкулыкта урнашкан, Казан утлары аста җемелдәп тора. Күктә дә, аста да йолдызлар сибелешкән – иҗат кешесенә моннан да матуррак ни бар? Ишек тоткасыннан да хәтта мәгънә эзләп тарттым, йорт хуҗасын эретердәй сүзләр табылган иде.

–А-һа-һа! – берсе дә бикләнмәгән капка, өйалды һәм йорт ишеген ачып керүгә, түгәрәк мул табынның табигый бер дәвамы булган алсу чырайлы Чал шагыйрь күзгә чалынды. Аңа ияреп, төмсә йөзле Йорт хуҗасы да, ак сакаллы Өлкән шагыйрь белән бераз сипкеллерәк Яшь шагыйрь дә күрешер өчен калкынып алды. Сүзләрен бүлгәнгә үземне шактый гөнаһлы санап, буш урынга килеп утырдым.

Соңга калуымның сәбәбе – улымны шахмат түгәрәгеннән өйгә кайтарып кую иде. Әмма нинди генә сәбәпләр булса да, ирләр мәҗлесендә моның өчен кыен ашарга туры килә: «Бигрәк кайгыртучан әти булып чыктың син!», «Хатыныңны бигрәк яратасың инде!» ише «мактаулар»ны сабырлык белән йотып җибәргәч, мин дә хуҗаны яңа йорты белән котларга ниятләдем. Әмма ике сәгать эчендә мәҗлес халкы «милләт», «тарих», «әдәбият» дигән зуррак ешлыкка күчәргә өлгергән, минем вак дөнья мәшәкатьләрен үз эченә алган мәдхия сүзләрен хуҗадан башка берсе дә тыңламады. Дулкын үзгә, дулкын югары ешлыкта, миңа аларны куып тоту юк инде бүген, димәк, язмышыма күнеп тыңларга гына кала. Хәер, мондый мәҗлесләрдә тыңлаучы – иң кадерле кеше...

Күбрәк, әлбәттә, Чал шагыйрь сөйли. Яңа йортның тузан кунмаган ап-ак люстрасы аның баш очында гына эленеп тора, аның көлүенә ул да кушыла сыман. Һәрхәлдә, зеңгелдәп куюыннан шулай тоела. Көмеш чәче, торган саен сыек зәңгәр төс ала барган күзе исә бу аклыкка торган саен үз була бара.

– Туда-Мәнгү хан заманында ил белән бәкләр идарә иткән. Үзе яхшы күңелле кеше, тик дәүләт дилбегәсе аның кулында түгел. Бервакыт аның янына илчеләр килгәч... – Ул яңа гына шулар арасыннан кайтып кергәндәй сөйли иде.

Тарих – Йорт хуҗасының да яраткан белемәсе. Чукмарлы йодрыгын бушап калган бәлеш табасы өстендә уйнатып, җәясыман бөгелгән куе кара кашлары астыннан ук очыргандай, кырыс карашын ерак гасырларга төбәп, сүзне дәвам итә:

– Мәнгүтимер хан тәхетен бертуганының улы Түлә-Бугага багышлый! Аның васыятен үтәмичә, тәхеткә энесе Туда-Мәнгүне күтәрәләр!

Тояк тавышлары чыгарып, йодрыклар өстәлне кыйнап ала, чәнечке-пычаклар кылыч чыңыдай аваз бирә, калкан-тәлинкәләр шаулый... Ниһаять, тарихи дөреслек торгызылды: Алтын Урда ханнарының һәммәсе дә искә алынды, данлысы макталып, үзеннән соң шанлы эш калдырмаганы – эттән алып эткә салынды. Ап-ак чәчле, кап-кара кәчтүмле, үз бәясен белеп, ара-тирә генә сүз кыстыргалап утырган Өлкән шагыйрьнең ул кадәр ерак гасырларны урарга теләге дә, рәте дә юк иде, кинәт кенә бу ешлыкка нокта куйды:

– Кызык кешеләр сез!..

Чәйнек инде ничәнчедер мәртәбә шаулап кайнап чыкты. Табын янында да сүз судан ким кайнамый иде.

– Бармы соң бездә шәхесләребезнең кадерен белү?! – Йорт хуҗасының йомарланган йодрыгы баш очыннан туплар ядрәсе сыман узып-узып киткән саен иелеп калырга өйрәнеп җиткән идем инде. – Казан ханлыгын яклап сугышырлык! Үзенең милли шәхесләрен күтәрә белмәгән халыктан ни көтәргә?! Һәйкәлләр сала белмибез, туган җирләрендә истәлек такталары

юк, урам исемнәре кушмыйбыз, музейларын ачмыйбыз, яңа буынга өйрәтмибез...

Милли-азатлык өчен көрәшүчеләр, Пугачёв каһарманнары, эмиграциягә китәргә мәҗбүр булган, монда калып сытылган-изелгән зыялыларыбызның берсе дә телгә алынмый калмады. Аларны искә төшергән саен Йорт хуҗасының да сөңгеле күз карашына яктылык иңә барды.

Без, дөресрәге, Чал шагыйрь белән Йорт хуҗасы «әдәбият» ешлыгына килеп кергәндә, сәгать уклары яңа көн тууын хәбәр иткән иде инде. Тарих чоңгылларында кузгалган яра-җәрәхәтләреннәнме, башка сәбәптәнме, йөзе чытылган Йорт хуҗасы да никтер тынып калды. Өлкән шагыйрь инде күптән минем кебек тыңлап кына утыра. Чал шагыйрь генә сүз дилбегәсен ычкындырмыйча, гадәттәгечә, сөйли дә сөйли.

Чү! Хәтта Өлкән шагыйрьне дә сискәндереп, куллары белән һаваны кисә-кисә, әле тормыш түле бозмаган җиңел-зифа гәүдәсен җәһәт кенә кузгатып, Яшь шагыйрь урыныннан торды. Чал шагыйрьнең киң маңгаена имән бармагын оста мәргәндәй ерактан төбәп:

– Шигырьдә мин сине узып киттем! – диде.

Әлбәттә, Чал шагыйрьне бу сүзләр белән куркыту һич мөмкин түгел иде. Ул люстра белән бергә рәхәтләнеп шаркылдады. Ләкин Яшь шагыйрь дә арбадан төшеп калмаган:

– Мин бүген беренче номерлы шагыйрь! Син түгел! Синең мичкәңдә дары калмаган. Хәзер мин шигырь укыйм, синең андый шигырьне гомереңдә язганың булмады!..

– Садри Максуди турында әйтим әле... – дип башлаган Йорт хуҗасы телен тешләп тынып калды.

– Кызык кешеләр сез! – дияргә өлгерде Өлкән шагыйрь.

Аларның сүзе чукракка китап уку кебек кенә иде, Чал шагыйрь белән Яшь шагыйрь аны колак яныннан гына уздырып җибәрде.

– Укы әйдә! – Чал шагыйрь, көрәш мәйданына чыгарга әзерләнгән батырдай күлмәк җиңен сызганды. – Аннары мин укырмын!

– Укыйм да шул! – Яшь шагыйрь кесә телефоныннан, аның фикеренчә, бөтенесен аяктан егарга тиешле шигырен эзләргә кереште.

Өлкән шагыйрь аңа мәгънәле генә күз ташлап елмайды да бераз черем итеп алам дип, күрше бүлмәгә чыгып китте:

– Бер-берегезне интектермәгез. Минем шигырьләрне укып ярышыгыз – дөресе шул булыр... – диде ул үзенә хас тыйнаклык белән. Күрше бүлмәдә йомшак кәнәфи авыр көрсенеп куйды – шуңамы Өлкән шагыйрьнең өч ноктадан соң дәвам иткән җөмләсен тәмамлавы ачык ишетелеп бетмәде. Ялгышмасам, урысчалап, «высший пилотаж», диде бугай...

Яшь шагыйрь шигырен Чал шагыйрь тын да алмыйча, яратып тыңлады:

– Афәрин! – дип, кул чапты ул. Үзе исә урындык артына элеп куйган кәчтүменең кесәсеннән китабын тартып чыгарды. – Ә хәзер мине тыңлагыз!

Йорт хуҗасы, үзе романнар гына язса да, шагыйрьләргә каршы төшүнең җүнлегә бетмәсен белә иде, кара коелып, урынында борсаланып булса да, шигырь тыңлый башлады. Үз шигырен сөйли башлаган шагыйрьне кем

генә туктата ала? Качып китсәң дә, куып җитәчәкләр! Аннары үз өеңнең туен калдырып, кая качасың? Шагыйрьләрнең көр тавышыннан түшәм өскә сикереп-сикереп ала иде.

Ярыш дәртеннән тагын да кызарып, җанланып киткән Чал шагыйрь бирешергә уйламады, сөйләү куәсе дә артканнан-арта гына барды.

– Ышандырдың, – дип, килешергә мәҗбүр булды Яшь шагыйрь бераздан. – Миңа тагын берне укырга туры килә инде!

Чәйнекләр кайнады да кайнады, китап укылып бетте, телефонның аккумуляторы утырды, әмма шигырь тәмамланмады. Мәсәгут Гомәров, Бәхтияр Канкаев турында сөйләшергә талпынып-талпынып караган Йорт хуҗасы да кулын селтәде. Кышкы кояшның иртәнге сүлпән нурлары Өлкән шагыйрьне йокысыннан уятты.

Яшь шагыйрь Чал шагыйрьне һаман да тинтерәтә иде әле:

– Килешәсеңме инде җиңелүең белән? Таныйсыңмы мине беренче шагыйрь итеп?

– Әйе, килешәм. Таныйм, – диде Чал шагыйрь. – Шулай да тагын бер генә шигырь укыйм әле...

Ул хәтер сандыгыннан тагын бер шигырь тартып чыгарды. Яшь шагыйрь аны тыңлады да, ачудан ике йодрыгы белән өстәлгә кундырды:

– Ник укыдың инде син моны, ник укыдың? Миңа бит хәзер тагын да яхшы шигырь укырга кирәк. Бирелдем, дип әйтсәң ни була?

Өлкән шагыйрь, икенче бүлмәдән чыгып, чәен йотып куйды.

– Болар һаман юк эш белән шөгыльләнәләр икән әле, хе-хе, – дип кеткелдәде. – Мин сезгә киңәш биргән идем бит инде!

Саубуллашырга дип урамга чыккач, бер-беребезне бүлдереп, яңа йортны мактарга керештек:

– Урынын сайлый белгәнсең, һавасы да һавасы, кашыкка салып йотарлык! – Өлкән шагыйрь һәрвакыттагыча ихлас иде сыман.

Чал шагыйрь бакча-мунча белән кызыксынды, соңгы елларда ул күккә караганда, җирне якынрак күрә иде:

– Бөтенесе уйланылган, малай. Юкка гына роман арты роман язмыйсың инде син!

Яшь шагыйрь дә алардан калышмады:

– Мондый җирдә язмыйча тору мөмкин түгел!

Без машинага утырыштык.

– Исхакыйлар, Атласилар турында күпме сөйләшәсе сүз калды. Вакыт җитмәде, – дип, Йорт хуҗасы машина ишеген ябар алдыннан сагышлы көрсенеп куйды.

– Сиңа тагын киләбез әле, чакыр гына! – диде Чал шагыйрь һәм үз тәкъдименнән үзе үк көлеп җибәрде.

– Әйе, ачыклыйсы нәрсәләр дә калды, – диде Яшь шагыйрь моңсу гына.

– Барысы да күптән ап-ачык! – Өлкән шагыйрь үзенә хас булмаганча башын өскә чөйде. – «Высший пилотаж» ул, дускайларым, һәркемгә дә тәтеми.

Казан урамнары әле уянып кына килә, каядыр офык читендәге кояш, алсуланып, кичә пешкән бәлешне хәтерләтә иде. Йорт исә шул кояш яктысында тагын да матуррак күренде.

## Ике Диләрә, ике Данир

Урам баганаларындагы утлар берьюлы күз кысып алды да дәррәү кабынды. Шул мизгелдә балалар мәйданчыгына гүя яктылык җәймәсе ябылды.

– Әти-ии...– Таганнан мәтәлеп төшкән биш яшьлек Диләрәнең яшел күзләре тәмам түгәрәкләнгән, иреннәре дер-дер килә, керфек арасында сытылып торган күз яшьләре менә-менә алсу бите буйлап тәгәри башларга әзер. Чырыйлап елап җибәрер өчен бары әтисеннән җәлләү-яклау сүзен генә көтә.

– Кызың бигрәк чибәр, Данир. Үзеңә охшаган... – шулкадәр таныш, якын тавыштан сискәнеп, артыма борылдым. Аның сулышы йөземә килеп бәрелде. Каядыр эчтә, йөрәк турысында учакны тергезделәрмени – берьюлы сызлану, эсселек тәнемә хуҗа булып алды.

– Диләрә?! – дидем мин, аңардан карашымны аера алмыйча. Якты яшел күзләре элеккечә елмаеп багалар, куе чәчләрен мин яратканча – таратып ташлаган – әле дә озын, куе икән алар. Тәненә сыланган спорт костюмы исә зифа буеның һәр борылмасын яшерми күрсәтә –кайчандыр кушучыма сыйган биле әле дә нечкә икән...

– Мин, – диде ул, елмаеп һәм күрешергә кулын сузды.

«Һаман да шулай чибәр икәнсең», диясем килә, тик... ярамый!

– Кызым! – дидем мин, әле генә аның таганнан егылганын искә төшереп. Ул исә, берни булмагандай, кайдандыр пәйда булган бер малай белән комлык янында әвәрә килә иде.

– Минем малай, – диде Диләрә. – Кил әле, улым, күреш абыең белән. Карап торышка Диләрә чалымы һич кенә дә сизелмәгән малай искитмәгән кыяфәттә теләр-теләмәс кенә яныма килде дә учыма шартлатып, учын салды.

– Исемең ничек, егет?

– Данир,– диде ул һәм кызым янына йөгереп китеп барды.

Мин аптырап, Диләрәгә текәлдем.

– Мин куштым, – диде ул, елмаеп. – Улыма башка исем куша алмас та идем. Ә кызың бигрәк матур. Күзе – яшел, нәкъ синеке кебек. Исеме ничек?

– Диләрә, – дидем һәм телсез калдым.

Аннары ялганда тотылган баладай, тиз-тиз сөйләргә керештем:

– Мин кушмадым! Өйләнешкәнче үк сүз куешкан идек хатын белән: кызга исемне ул куша, малайга – мин. Ул Диләрә исемен сайлады. Мин каршы килмәдем...

– Ышанам! Ә мин Данир дип үзем куштым! – Ул күземә туп-туры карады. Элеккечә: көлемсерәп, яратып, сагынып... Аның яшел күзләреннән агылган яктылык миемне кармалаган сыман тоелды. Шул ук җылы караш, бары уйнакчанлыгы гына басылган, нindидер моңсу сагыш сирпелә алардан.

Сүзләр артык иде, шулай да чит ир белән хатынның бер-берсенә карашып торуы бернинди кысага да сыймый: үземне кулга алырга тырыштым.

– Син каян килеп чыктың соң безнең ишегалдына?

– Фатир алдык. Бер атна элек.Тугызынчы каттан. Сезнең подъезддан...

– Ә без җидедә...

«Арада сигезенче кат бар», – дип уйладым нигәдер.

– Мин сине күченгәннең беренче көнендә үк күрдем. Көн дә шушы вакытта кызыңны бакчадан алып кайтасың...

«Кызым!» Мин, айнып, мәйданчыктан аны эзлим: һаман да икәү уйнап мәш киләләр.

– Кызларны сөйми иде, синеке яныннан китә алмый...– Диләрә болай да кузгалган күңелемә учак өстәде.

– Чая икән малаең, кара, кочакламакчы булып маташа!

– Кемгә охшаган диген? – Диләрә тагын мине сихерли торган карашы белән күземә туры карый. – Кем сине беренче кочаклады, кем «яратам» дип, беренче әйтте? Мин бит!..

«Йа Хода! Нигә шулай сыныйсың син? Мин аны оныткан кебек идем бит инде?! Иске яраларны нигә кузгатырга иде?»

***

...Безне игезәкләр дип әйтәләр иде. Күзләребез дә бертөрле, йөзләр дә охшаган, аның озын калын чәчләрен кисеп ташласаң – мин, ул толымнарны миңа таксаң – Диләрә килеп чыгар төсле. Ул кесәсеннән кечкенә көзгесен ала да икебезне өйрәнә башлый:

– Минем күз яшелрәк! Юк икән, чукынчык, синеке яшелрәк! Ник синең керфекләрең озынрак? Аларны миңа бир – малайларга нәрсәгә ул? Уф, синең иреннәрең дә калынрак!

– Аның каравы, син – матур, син – чибәр, – дим аңа.

– Чынлапмы? – ди ул, чытлыкланып. – Яратасыңмы мине?

– Әйе! – дип баш кагам.

– Телең белән әйт: я-ра-там, диген!

– Әйтермен, өйләнгәч!

– У-у, аңа кадәр әле! Мин нигә сиңа кияүгә чыгарга тиеш соң? Яратам дип тә әйтмәгәч. Мин әйтәм менә: Данир, мин сине яратам!

– Тәмен бетермә!

– Бетми, киресенчә, арта гына! И саран!

Ул турсаеп, читкә борыла. Мин аның җилкәсеннән кочам. Шул арада үпкәләрен онытып, үзе үк битемнән үбеп тә ала:

– Менә шулай үбеп алырга кирәк андый вакытта! Авыл мокыты!

Минем өч җәем, өч язгы һәм кышкы каникулларым бары тик Диләрә белән генә үтте. Аның әбисе белән бабайсы авылның түбән очында тора, ә без – югары очта. Мин аны беренче тапкыр күл буенда күрдем. Ул классташым Алсу белән иде.

– Исемем – Диләрә, миңа унөч яшь, Казан кызы, – диде ул, үзе башлап танышып. Мин аны шул көнне үк күл буеннан велосипедыма утыртып алып кайттым. Ә Алсу ничек кайтты икән? Менә анысы хәтердә калмаган. Шул көннән мин һәр кичне зарыгып көтә башладым. Бер кичне дә калдырмый Диләрә янына йөгерә идем.

Миндәге үзгәрешне иң элек әни сизде. Ул бер караштан минем халәтне таный белә. Элек тә, хәзер дә. Кыенлыкларны да, шатлыгымны да алдан күрә, алдан сизә. Диләрә белән танышканның өченче көнендә, күрешер минутларны санап көткәндә, берни дә сорашмыйча, яхшы итеп үтүкләнгән өр-яңа кара чалбар белән саргылтрак төстәге күлмәк сузды.

– Болар сиңа таман гына бугай. Күзге каршында киеп кара әле...

Мин бер башка үсеп киттем. Диләрә дә шулай киенеп-ясанып, чәчләрне тарап килгәнне күргәч, беркавым сүз табалмады:

– Син болай ничава гына малай икән, – диде һәм, гадәтенчә, кычкырып көлде.

Безгә беркем кирәкми иде. Дустым Ринат миңа кул селтәде, Алсу Диләрәгә үпкәләде. Без, кулга-кул тотынышып, күл буенда йөри идек, берсендә күрше авылга ук барып чыкканбыз. Шәфәкъта таң эзе күренә башлаганда гына, аны капкаларыннан кертеп җибәреп, аерылыша алмый йөдәгән соңгы парларның күзенә чалынмаска тырышып, өйгә йөгердем.

Диләрәнең бабайсы белән минем бабай дус булган, сугышка да бергә чыгып киткәннәр, әйләнеп кайткач та тату яшәгәннәр. Минеке вафат инде, аның бабасы да нык бетерешкән, хәтере дә бик юк. Шулай да Диләрәне гел тиргәп тора.

– Синең бабаң аркасында күрешүләр тәти, – ди Диләрә. – Сиңа гына мине озатырга рөхсәт.

Мендәргә баш төртүгә, әтинең тимер бармаклары җилкәдән кашып ала:

– Тор, малай, көтү китте. Бозауны арканлап кайт.

Барганда, күз ачылмаган килеш, җиргә сөртенеп атласам, болынга җиткәч уянып китәм дә тиз-тиз чәчәкләр җыярга керешәм. Мин кечкенәдән җәй буе һәркөнне әнигә чәчәкләр җыя идем. Әти бу гадәтемне аңлап бетерми, әнинең күңеле булгач, сүз әйтми тагын. Хәзер исә мин аларны Диләрәгә дә җыям. Өйгә йөгереп кайтам да, әти белән әни күргәнче, велосипедыма атланып, түбән очка элдерәм. Диләрәләр капка төбендәге утыргычка чәчкәләрне таратып, кабат өйгә чабам. Көн дә шулай. Кичен күрешкәч, ул минем ике битемнән үбеп ала:

– Болар – чәчәкләрең өчен!

Бик тиздән алар йорты каршындагы миләш кәүсәсендә, утыргычта, клуб янында, мәктәп капкасында «Данир+Диләрә=мәхәббәт» дигән акбурлы язулар пәйда булды. Баштарак мин аларны еларга җитешеп сөртәм-бетерәм, икенче көнне кабаттан күргәч гарьләнә идем. Кемнәр язганын белмәсәм дә, Диләрә белән икебез арасына тыгылучыларга ачуым кабара. Диләрәне никадәр генә бу язулардан читтәрәк йөртергә тырышсам да, беркөнне ул да аларны күрде. Йә Алсу әйткәндер.

– Да-нир+Ди-лә-рә=мә-хәб-бәт! – дип иҗекләп укыды ул. – Дөрес бит? – ул, балкып, миңа карады, үзе дә сизмәстән, кочагыма сыенды. – Миңа ошый!

Шул көннән ул язуларны бетерми башладым.Тик беркөнне әтинең әнигә әйткән сүзләрен ялгыш кына ишетеп калдым да кәефем кырылды:

– Борын астында маңкасы кипмәгән килеш... Уеннан уймак чыкмасын. Нишләгәнен белми йөри...

Әйе, кырылды кәеф. Минемме маңка кипмәгән? Мин инде... Мин... бик гарьчел идем малай чакта. Хәзер алай ук түгел...

Ә берсендә... Июль иде. Авылда туйлар гөрли... Атна саен безгә бәйрәм – үсмер егет-кызлар, туйчылар тәнәфескә чыккач, бер читтә туйганчы әйләнә ясап биибез. Диләрә минем кулымны мизгелгә дә ычкындырмый. Парлап талгын биюне көтеп алабыз – берсен дә калдырмыйбыз. Ул көнне биюдән туктаганда, туйчылардан бер-ике яшь пар да без генә калган идек. Хәтта кияү белән кәләш тә күренми.

– Әни кайткан иде бу атнада, беттем мин! – Диләрә куркудан калтырана ук башлады.

Әнисен бик усал, ди ул. Әтисе үлгән аның, карап торганы, мактаучысы да, сүккәне дә – шул әнисе инде.

Әле генә күздән-күзне аера алмый балкып биегән идек, хәзер өшәнгән тавыклар кебек карашып торабыз.

– Син мине бүген озатма инде. Урам буйлап эзләп йөридер. Икебезне дә тотып ярачак.

Шулчак миндә әллә кайдан кыюлык калкып чыкты:

– Озатам! Әниеңә үзем тапшырам! Ярса – ярсын, икәү булгач, җиңелрәк ул!

Диләрәгә дә җан керде, кулга-кул тотынышып, өйләренә юл тоттык. Әнисен яхшы белә икән – чыннан да, урам башында таяк тотып каршы алды ул безне:

– Кара син моны! Төн уртасында... оятсыз... юк башыннан... егетләр кулы тотып!..

Диләрә куркуыннан миңа сыланды, таяктан төшәсе авыртуларны кичерергә әзерләнеп, икебез дә куырылып килдек.

–Тукта, тукта, син Даниял малае түгелме соң?

– Әйе, – дидем мин мескен генә сыек тавыш белән.

– Нишләп баштук әйтмисең аны? – Дания апаның тавышы капылт үзгәрде. – Алай кара төнгә үк калмагыз, бала-чага бит әле сез, өлгерерсез үскәч тә...

Диләрә әнисенә танымагандай аптырап текәлде. Ана белән кызны өйләренә кадәр озатып куйдым. Икенче көнне Диләрә көлеп сөйләде:

– Атасына охшаган, әйбәт малай булырга тиеш, йөрегез, төн уртасына гына калмагыз, ди.

Минем әти генә Диләрәне ошатып бетерми бугай. Мин аны үзем болай юрыйм: аның булачак килененә таләпләре бар. «Пунктлар» дип атый ул аны. Беренчесе – татар кызы. Икенчесе – татарча белә торган татар кирәк аңа. Өченчесе – сәхнә кешесе булмасын, ди. Дүртенчесе – авыл кызына өйлән, ди. Диләрә исә – Казан кызы, бу пунктка туры килми. Шуңа сөйми, күрәсең. Кәефенә карап пунктлар санын арттыра әти. Әниең авылыннан булмасын, дигәч, әни белән бәхәсләшеп китәләр дә, калган пунктлары онытыла...

Диләрәнең авылга кайтуын мин өй түбәсенә менеп көтеп ала идем. Моннан олы юл күренә: менә янтайган иске «Паз»ик авылның бердәнбер тукталышында кешеләрне төшерә дә, авыр ухылдап, юлын дәвам итә. Кешеләр төркеменнән мин Диләрәне шундук танып алам: көткәнемне белә, арттарак аерылып кала да кулын болгый. Мин аның каршына йөгерәм... Өч җәй, өч көз, өч кыш, өч яз шулай үтте... Ә аннары... Дүртенче җәйдә мин аны танымадым.

Озын толымнарын кисеп ташлаганын күргәч үк, аһ иткән идем. Ягымлы карашы җуелган. Көлүе дә башкача. Бу минем Диләрә түгел иде... Ул миннән читләште, теләми күреште – арадагы күпер ишелгән иде. Үзе кебек Казаннан кайтканнар белән генә тулганды. Авылда беркайчан сер булмый: Казанныкылар үлән тарта, наркоманнар, диделәр. Ахыр чиктә минем эзәрлекләүдән туйган Диләрә әйтте:

– Мине оныт! Балачак уены тәмам! – диде.

Ул җәй, мөгаен, үсмер чагымның иң кара фасылы булгандыр. Мин үз эчемә бикләндем. Беркем дә, бернәрсә дә мине кызыксындырмый иде. Гадәттәгечә, Диләрәгә дип чәчкәләр җыйдым – аларны мин болын елгасына атып калдыра идем. Бар да бетте, бар да акты... Ул елны кышын аның әбисе белән бабайсы бер-бер артлы вафат булды, башкача мин аны авылда күрмәдем. Диләрәсез авыл миңа да ят иде инде – мәктәп тәмамлап, Казанга китүне бармак санап көттем.

– Мине оныт! Балачак уены тәмам!...

***

– Үткәннәрне уйлыйсыңмы? Ник эндәшмисең?

– Мине оныт! Балачак уены тәмам! – дидем мин, үзем дә сизмәстән.

Диләрә каршыма ук килеп басты – хәтфә үләндә иртәнге чык кебек ялтыраган күзләре яшьле иде.

– Ул чактагы юләрлегемне уйлап уфтанганнарым инде! Ул мавыгулар мине акылдан яздырды бит...

– Белмәгән идем...

– Ярты ел өйдән беркая чыкмадым. Әни башта кыйный, аннан кочаклап елый... Ахыр чиктә, җиңдем мин барысын да. Нәрсә ярдәм итте дип уйлыйсың? Күз алдына да китерә алмыйсың – синең хатларың! Хәтерлисеңме, һәр кичне, хушлашыр алдыннан бер-беребезгә хатлар бирешә идек? Синекеләр бигрәк матур була иде! Төннәр буе кабат-кабат укый идем. Мин аларның берсен дә югалтмадым! Ә син?

Мин эндәшмәдем. Нәрсә диим? Өйләнергә йөргән көннәрдә әни үз бүлмәсенә дәшеп алды.

– Боларны нишләтәбез? – диде ул, Диләрәнең хатларын сузып. – Килен кулына эләксә, матур булмас бу.

– Як! – дидем ниндидер бер ачу һәм җиңеллек белән. Башкача мин аларны күрмәдем. Алар – Диләрә белән бәйләүче соңгы җепләр иде...

– Ә мин сине эзләдем... Университетың янына бардым. Кайда укыганыңны Алсудан сораштым. Күрдем сине – чибәр кыз белән җитәкләшеп, елмаеп чыктыгыз... Син өйләнгәннән соң, бер айдан кияүгә чыктым. Ирем әйбәт: эшли, эчми... Хәтта тартмый да!

Шулчак телефоным шалтырады – хатын икән.

– Сез кайда югалдыгыз соң ул? Табын әзер...

Алдан сөйләшкән кебек, Диләрәнең дә телефоны тавыш бирде. Ире иде, әлбәттә.

– Кайттым, ди. Безне эзли. Ашыйсым килә, ди. Керик инде...– Ул төртелеп калды, сагышлы караш белән күземә тутырып карады.

– Керик, – дидем мин. – Кызым, Диләрә! Әниең көтә!

– Улым, Данир, әтиең кайткан!

Без подъездга таба атладык: ике Диләрә, ике Данир. Җиденче катта да, тугызынчысында да балкып, ут яна иде...



Ибраһим
Биектаулы

# КАН САГЫШЫ

*Тегермән ташы астында*
*Орлык онга әйләнә...*

***

Җитәр, дуслар, ятмыйк сөрсеп,
мышык-мышык!
Кабул итмик эт мисалын,
чинап-шыңшып...
Безне көтә
җиһанның киң далалары!
Юлга чыгыйк,
Без – Ак Бүре балалары!

***

Ач күзең, океан чукмары!
Өч көнлек – дөнья малы!
Бата-калка йөзә Татар –
башына сукма аның!
Мең афәт татыды Кавем...
Тагын күпме татыйсы?
Гасырларга илтәсе бар –
яшәү эстафетасын!

***

Көн иткән Ил-төбәк – бик җайлы:
урманлы, тугайлы, тургайлы...
Шулай да...
Ни диик апрельне – бу айны?
Елата, тетрәтә татарны:

«Очты дөнья читлегеннән»
Күңел кошы Тукайның!

---

Ибраһим БИЕКТАУЛЫ (1937) – *шагыйрь, публицист; Удмуртиянең атказанган журналисты. «Бәйрәм белән!», «Җирдән җиде җиһанга», «Галәм серләре» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Прогресс – арба.
Күчәренә дегет – Син.
Татарлыкта – бәһаң олуг –
Тукайлы егет Син!

Тукайлык – чын татарлык!
Дөньялар шаккатарлык!
Богауларны ватарлык!
Хөрлек татып, чалкан ятып,
Күккә карап ятарлык!

Татар җаны – горурлык –
баһадирлык вә зурлык –
давыл-утлар сүндерерлек,
үлем чигендерерлек!

Син – Милләтнең җан калканы,
фида йөрәк-бәгыре –
Каумең хакын күккә чөйгән
газиз угылы – шагыйре!

***

И шагыйрем, йөрәгеңдә
утларын чәчә гөрзи...
Сүзләреңне үлчи-үлчи,
иреннәрең дерелди.
Күңелең коштай очына.
Телең-тының кысыла...

***

Урам этенә хөрмәт юк.
Нишләсен эт? Ул – мескен!
Исән чакта онытылган
Шагыйрьнең эше мөшкел...

***

Татарга ниләр күрәсен
әйтмәс бае, түрәсе.
Әйтсә дә, ишетмәс милләт,
суыныр ашы-өйрәсе...
Бүгенге ил агасы –
Җиргә күктән төшмәгән,
ул, әлбәттә, җирдә туган,
тик күзләре очлы булган,
аң-акылы ушлы булган –
зирәк авыл баласы...
Ташка кадак кага белгәч,
аның да киләдер ипле-
җайлы яшәп каласы.
Тир түгеп менгән баскычтан
килмәс колак кагасы.
Кан хәтерен җуеп булмый:
янәшә – «Зур ага»сы...

***

Йорт башы – гаилә ташы.
Җанашы – йөзек кашы.
Шифалы – инешләре.
Өлгерә җимешләре...
Нәфесе – гади, тыйнак.
Фанилык итә кунак…
– Инде Аллам сакласын!
Уңышны боз сукмасын!

«Тел бетә!», «Милләт бетә!» – дип,
көчәнеп зык чыкмасын!
Ни бирә татарчасы?
Ничә адым барасы?
Инглизчә белсен бала,
килсә яшәп каласы...

Суыр татар токмачын,
Чөмер Лаеш шулпасын,
Сыпыр солы боткасын –
корсак зарың туктасын!
Кысып тот та токкасын,
Тип – чәнчелсен дөньясы!
Сугыш кына чыкмасын!

***

Әй, анда, нинди шәүлә?
Әйт, белсәң: хикмәт нидә?
Җир тетрәткән яугирләрнең
Токымнары кайда ул?
Хөр мәмләкәт юкка чыккан!

Ни җимерде? Ни давыл?
Ни усал афәт актарган
Җирнең тимер-ташларын?
Бөркетләре һәлак булган,
Сибелгән юашлары...

***

Гаҗәеп хәл, һәр халыкта
яши философ затлар.
Андыйлар – акыллы башлар
үз кавемнәрен яклар,
көндәшләрен, мантыйк белән,
(сүз тапмаса – мылтык белән)
мәсхәрә итеп ташлар...
Елгырлыкны өскә куя

Галиҗәнап Табигать:
сугышсыз, сүз көрәшендә
ачыклана хакыйкать...
Сабыр! Сабыр! Тын калыйк,
кечкенә сабак алыйк,
оппонентларны таныйк,
сизгер элпә-мембрана
кулланыйк – колак салыйк...

***

Хәрәкәттәдер бәрәкәт.
Саннар сыйфатка күчә.
Бер явызлык туса кичә,
меңләп бүгенгә күчә.

***

Азамат затлар – бүреләр
Серләшә улап кына.
Кыйналган инсан токымы –
эт сыман чинап кына –
чабатасын түргә элми,
көн күрә тыйнак кына...

***

Ана үстерде Сабыйны,
җырлап-көйләп, тирбәтеп...
Марҗа назлады Егетне,
эчертеп-похмельләтеп...
Мәктәбе юк. Телсез калды.
Дәшми татар милләте...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

*«Мәйдан – батырлар өчен!» әдәби конкурсы*



Хисаметдин
Исмәгыйлев

# БЕРЕНЧЕ САБАНТУЙ

хикәя

«Урал» колхозының чәчү алдыннан була торган гадәттәге гомум җыелышы быел озакка сузылды. Шуңа да алып баручы, барысын да исәпкә алып, җыелышны ябарга әзерләнде. Әмма шул вакыт җыелышларда дәшми утырган Солтангир абзый урыныннан торып басты, тамакларын кыргалап алды да сүз башлады:

– Кыхым, кыхым. Җәмәгать, дим, җәмәгать, бер тәкъдимем бар. Шуны әйтергә рөхсәт итегез.

Җыелышны алып баручы Шәрәфетдин ризасызлык күрсәтеп:

– Солтангир абзый, моңа чаклы ни уйлап утырдың? Болай да озакка сузылды. Гөлем белән карнайларга кайтасы да бар бит әле. Җыелышны ябарга вакыт. Нәрсә, инде таңга чаклы утырабызмыни?

Гөлем белән Карнай авылыннан килгәннәр бераз шаулашып алды.

– Шулай шул. Инде күпме утырырга була?

– Кайтасы да бар бит әле. Сезгә, яңгырчыларга, рәхәт тә бит, безгә дә кайтырга вакыттыр.

Яңгырчылар авылдаш абзыйны куәтләп:

– Кеше үз гомерендә ниндидер сүз әйтергә җыена. Нәрсә әйтергә тели икән, әйтсен.

Карнай авылыннан Чынтимер, гадәтенчә:

– Бетмәс монда яңгырчыларның сүзләре. Кайтырга кирәк. Инде ярты төн җитеп килә. Таралышырга вакыт, – дип, утка утын өстәде.

Әхмәт абзыйның тавышы барысын да басып китә. Шуңа да ул Чынтимерне тиз туктатты.

---

Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ (1953) *– язучы-прозаик; «Зимагур», «Никах» исемле китаплар авторы. Башкортстанның Стәрлебаш районында яши.*

– Монда Карнай авыл җыелышы гына түгел, гомум колхоз җыелышы. Кешенең авызын япма! Сөйләсен. Сөйлә, чордаш, сөйлә!

Җыелышны алып баручы соңгы сүзне Солтангирга бирергә мәҗбүр булды:

– Әйдә, абзый, әйт сүзеңне. Тик озынга сузма. Кыскарак тот.

Чынтимер тагы уенын-чынын бергә кушып:

– Сүзеңне Өршәк елгасы кадәр сузма. Өршәк Уфага чаклы җитә, – диде.

Халык тагы шаулашып көлешеп алды. Кемдер Рабиганың бәләкәй арбага ике бала утыртып, Өршәк буйлап, Алкин лагерена ирен ашатырга барасы барын да искә төшереп алды. Тагы көлештеләр. Писер вазифасын үтәп, барысын да язып утырган Тәлгать, халыкны тынычландырырга теләп, өстәлдәге буш графинны тимер ручкасы белән каккалап:

– Нәүбәт, нәүбәт. Җәмәгать, әзрәк шауламый торыйк инде. Син, Чынтимер, кайткач Нәкыя белән командовать итәрсең. Сөйлә, Солтангир абзый, әйт сүзеңне. Кыскача гына булсын, – диде.

Җыелышны алып баручы канәгатьсезлек белдереп, Тәлгатькә карап алгаласа да, бер сүз дә дәшмәде. Кулын селтәп, Солтангир абзыйга сөйләргә кушты. Солтангир абзый тагы тамагын кыргалап:

– Кыхым, кыхым. Мин менә нәрсә әйтергә телим. Еллар әйбәт килергә охшаган, шулай бит, иптәшләр. Җир әзрәк җилләгәч тә, Ходай насыйп итеп, чәчүгә төшәчәкбез. Чәчүне тиз арада башкарып чыгарбыз дип өметләник. Ул эшне дә уңышлы тәмамласак, әзрәк тугарылып алырга кирәктер. Ягъни һәр бригадада буразна бәйрәме үткәрик. Инде күпме йомылып яшәргә була? Әнә, карамалылар да үзләрендә байтимерләр белән берлектә буразна бәйрәме үткәрергә җыеналар икән дип ишеттем.

Җыелыш бетте. Таралышыйк, туганнар, дигәнне көтеп, үзара гәпләшеп, гүләп утырган халык, Солтангир абзыйның тәкъдимен ишетеп, тып-тын калды. Шунда Баймый абзый Солтангирны куәтләп:

– Э-е, теге, кем, Солтангир туган, дөрес әйтәсең. Нәрсәдер оештырырга кирәк. Сабантуймы, буразна бәйрәмеме шунда.

Шул сүзләрне ишеткән халык, кырмыска оясына таяк тыккан кебек тагы шаулаша башлады. Кемнәргәдер кызык булып китте. Һәркем үзенең сүзен, үз тәкъдимен әйтеп калырга тырышып кычкырышырга тотынды. Тәлгать халыкны тынычландырырга теләп, тагы өстәлдәге буш графинга тимер ручкасы белән сугарга тотынды.

– Нәүбәт, иптәшләр! Нәүбәт! Тавышланмый гына утырыйк.

Шунда түрдәге өстәл артында утырган колхоз рәисе, үзенең бәһасен белеп, җай гына урыныннан торды. Үзенең чем-кара күзләрен, куе кашлары астыннан, җыелышта утыручылар өстеннән йөгертеп, барлап чыкты. Алдында яткан кәгазьләр арасыннан ниндиендер алып укый башлады.

– Менә, иптәшләр, минем алда дүрт айда эшләнгән эш нәтиҗәләре язылган белешмә, эш кәгазьләре. Алда әйтеп кителгәнчә, әллә ни мактанырлык нәтиҗәләр булмады. Колхоз кассасына кергән керем дә чамалы. Шуңа да зур бәйрәмнәр оештырып, бәйрәм итәргә хуҗалыкның хәле юк. Ягъни мәсәлән, акча ягы такыр, – дип әйтергә өлгермәде, җыелыштагылар барчасы бергә Сабантуй үткәрергә кирәклеге турында

гүли башлады. Рәис тә хәйләкәр, мондый гына җыелышларда халыкны тиз тынычландырырга өйрәнгән. Шуңа да кулын күтәреп, халыкның тавышын басарга тырышып, сүзен дәвам итте: – Җәмәгать, бу турыда төптән уйларга кирәк. Өстәге түрәләр нәрсә әйтер. Рөхсәт итәрләрме, юкмы, шунысы да бар бит әле.

Шулвакыт мәңге җыелышларга йөрмәгән Хәйрулла урыныннан торып басты да:

– Итәрләр, итәрләр. Халык сорый, диярсез. Барча халык шулай тели. Үзегез беләсез, патша вакытында да без – гөлемнәр, Сабантуйлар үткәрә идек. Верхатин урыслары да, Өязебаш чувашлары да үз бүләкләрен күтәреп, безнең Сабантуйга төшә торганнар иде. Чамалыйсыздыр инде Сабантуйның ничек үткәнен. Яңгырчыдан Әхмәт абзый ул елны көрәшеп, сарык та алган иде әле. Патша вакытында үткәргәч, әле нигә үткәрергә ярамый ди ул?

– Хәйрулла абзый, син әллә кайчан түнтәрелгән патшаны мактап утырма. Себер киң. Үзеңне тагы Себер җибәрүләре дә бар. Аннан кайтканыңа ничә ел үтте әле? Монда патша да патша дип, Николай канечкечне мактыйсың, – дип, яңгырчылардан кемдер кычкырды. Хәйрулла да бирешә торган түгел, ул тагы телен чарлап һәм сүзен бөтенләй икенче якка борып:

– Мин ул Микулай канечкечне мактамыйм. Ул рөхсәт итмәгән заманда да Сабантуйлар үткәрә торган идек, дим. Син, туганым, теге, кем дип әйтим үзеңне, едрит-кудрит япунский... э-ээ, теге, ни, әниеңнең юылмаган сөлгесе кебек, юк-бар сүз сөйләп утырасың.

Хәйрулла чүт сүгенеп җибәрмәде. Үзенең кайда утырганын исләп, әйтәсе сүзләрен дә әйтмичә, чак тыелып калды. Баягы сүзләрне әйткән кешене кыска муенын боргалап, үрелеп-үрелеп арткы рәтләрдән эзләде. Һәм сүзен дәвам итеп:

– Әйе, Себер киң, чиксез киң. Аркылы-буйга йөреп чыктым. Себер дә татар җире икән. Кайсы почмагына барсам да, татар авыллары бар. Ызначит, Себер үзебезнеке – татарныкы. Анда барудан курыкмыйм. Анда китүдән курыксам, Верхатин урысларына кунакка йөрмәс идем.

Арттагы рәттән теге бәндә һаман Хәйрулланы үртәп:

– Алайса сөйләп җибәр, ничек итеп верхатиннарның сөлгесен колгага бәйләдең?

Яңгырчының бу бәндәсе Хәйрулла абзыйның Верхатин урысларыннан ничек итеп үч алуыннан хәбәрдар иде. Чөнки урыслар килгәч, зимләмир Хәйруллаларның имана җирләрен тартып алып, урысларга бирде. Хәйрулла шуның өчен җае чыккан саен тегеләрдән төрлечә үч ала торган булып китте. Әле абзарларын ут белән үрти, әле малларын урлый. Соңгы явызлыгы верхатиннарның иң бай исәпләнгән старостасының йортын басып, аның өеннән зур гына сандыгын алып чыгуы иде. Йортларын Хәйрулла басканын белмәсләр дә иде. Шул Сабантуй буласы җәйне Хәйрулланың бичәсе урыс сөлгесен, бүләк җыйганда, колгага чыгарып бәйләгән. Сабантуйда староста үзенең сөлгесен танып ала. Кем Сабантуй колгасына бәйләгәнен сорашып беләләр. Әллә ни тавыш күтәреп тормыйлар. Карамалы базарыннан кайтканда, Хәйрулланы сагалап торып, урман эчендә эләктерәләр. Верхатинга алып кайталар. Аның белән

тагы кемнәр булганын, иптәшләре кемнәр икәнен белергә тырышалар. Хәйрулла әйтми. Шуннан каракны бик каты кыйныйлар. Тышта җилләп-давыллап, яңгыр коярга тотына. Үтердек дип уйлап, мәетне ни эшләтергә дә белмиләр. Сәке астына тыгып куеп булмый бит инде. Басурман мәетеннән тизрәк котылырга булалар. Бакча артларыннан гына аккан биек текә ярдан инешкә очыралар. Үзләре староста йортына кайтып, karaktan котылу уңаеннан табын корып эчәргә утыралар. Хәйрулла инеш төбендәге ташларга бәрелми. Шунда ятып үскән таллар өстенә барып төшә. Яңгыр астында һәм тирән булмаган инеш суында аңына килә. Ничек итсә-итә, шуыша-шуыша кача. Һәм исән кала. Икенче көнне Хәйрулланың гәүдәсен якында гына булган каенлыктагы иске бакыр шахтасы эченә ташларга уйлыйлар. Тик Хәйрулла карактан җилләр искән. Шул атнаны ук каракны кыйнаучылар өйләрен юк-бар хакка гына сатып, тиз-тиләмән авылдан чыгып качалар. Эш моның белән генә бетми. Карак урыслардан үчен кайтарырга була, җил уңаен чамалап, Верхатин авылына ут төртә. Тик Аллаһның рәхмәте, җил тынып, яңгыр ява башлый. Авыл башындагы бер өй генә яна. Бу Хәйрулланың гына эше икәне ачыклана. Суд булып, каракны биш елга Себергә озаталар. Әмма революция булып, ул ике елдан авылга кире кайтып төшә. Сорау бирүченең каракка шул турыда исенә төшерүе иде. Хәйруллага бирелгән бу сорауны ишеткәч, җыелыш тынып калды.

– Бәйләдем шул. Себердән курыкмаганга бәйләдем.

Җыелышны алып баручы силсәвит рәисе җыелышның рәте китә башлаганын сизеп:

– Җәмәгать, тавышланмагыз! Колхоз рәисе үзенең сүзен әйтеп бетерсен. Аннан кычкырышырсыз. Син, Хәйрулла абзый, утыр урыныңа. Юк-бар сөйләп, баш катырма.

Колхоз рәисе:

– Шулай иптәшләр. Без буразна бәйрәме үткәрүгә каршы түгелбез. Бу турыда идарә әгъзалары белән аерым сөйләшергә кирәк. Иң тәүдә чәчүне вакытында сыйфатлы итеп башкарып чыгыйк. Бәйрәм качмас. Хәзер вакыт та соң, таралышыйк, – дип, сүзен очлады.

Җыелышны алып баручы тиз чамалап алды һәм җыелыш ябык дип игълан итте. Ә халыкның кайберләре Солтангир тәкъдименең һавада эленеп калуына ризасызлык белдереп, үзара сөйләнә-сөйләнә, урамга агылды. Ә инде иртәгәсен «Урал» колхозында барча кеше кичә үткән җыелыш турында гәп куертты. Күпләре, чәчү беткәч, Сабантуй булачак дип хәбәр таратты. Җыелышта булганнар, әле бу сорау һавада эленеп тора, суга сәнәк белән язган кебек, диде.

Быел, картлар фаразлаганча, яз үз вакытыннан алдарак килеп, чәчүгә дә иртәрәк төштеләр. Чәчү уңышлы һәм вакытыннан алда тәмамланды. Шуңа да бәйрәм үткәрергә кирәк дигән сорау колхозчылар арасында яңарып һәм төрләнеп калкып чыга торды. Бу мәсьәләгә райондагылар да каршы килмәде шикелле. Һәм беркөнне сорау идарә утырышында каралып, Сабантуй, йә булмаса, буразна бәйрәме үткәрергә кирәк дигән карар кабул ителде. Тик шундый шарт белән: бәйрәмгә бүләкләрне халыктан җыярга. Хәбәр тиз арада хуҗалыктагы барча авылларга таралды. Һәр авыл үзенчә

Сабантуйга әзерләнә башлады. Булачак урыны да билгеләнде. Ул урын колхоз үзәге булган Яңгырчы авылыннан районга бара торган юлның сул ягында, тау башындагы тигез болын иде. Сабантуй буласы көнне дә ачыкладылар. Ай ярым чамасы вакыт бар.

Мәш килеп барча халык Сабантуйга әзерләнә. Гөлемнәрдән ике-өч кеше көрәшергә теләк белдерде. Йөгерү буенча бурзай Фазлыйны билгеләделәр. Ул каршы килмәде. Чөнки исеме җисеменә туры килә иде. Юкка гынамыни, ләкаб исеме «бурзай» бит. Карнайлылар бигрәк инде, үзара яшерен генә сөйләшүләр алып барды. Бүтән бригадалар серне белмәскә тиеш. Һәм көрәш буенча озын гәүдәле Хөснулланы көрәшергә күндерделәр. Хөснулла үзе Дим буендагы Илчегол авылыннан булып, Карнайдагы бер тол хатынга йортка кереп, шуның белән торып ята. Үзе авыл тимерчелегендә эшләп йөргән була. Самавырлар төзәтеп, шуларга торбалар, ямкә-кисәү, агач-мазар ясап көн күрә. Әле Яңгырчыдагы тол хатыннарда яшәп ала, әле кире шул Карнай авылындагы бичәсенә кайтып яши. Бөтенләй югалып торган чаклары да булгалый. Анда инде Илчеголына, элеккеге хатынына кайтып киткәндер, диләр. Үзенең төпле генә тамырланып яшәгән йорты да, гаиләсе дә юк шикелле. Басу читләрендә үсә торган пәри арбасы исемле үсемлек-үлән кебек, җил уңаена, авылдан авылга тол хатыннарда, кемдә атна, кемдә ай дигәндәй, тәгәрәп йөреп яшәп яткан чагы. Әйтүе буенча, Аллага шөкер, аңарга насыйп булган тол бичәләр сугыштан соң бөтен гомеренә җитәрлек. Менә шул озын, көче әллә ни булмаса да, ашауга һәм гәүдәгә таза күренгән Хөснулланы көрәшергә күндерделәр күндерүен. Тик ул үзенең төп шартын катгый итеп карнайлыларга белдереп, болай диде:

– Мин риза. Сезнең авылга Сабантуй батыры Карнайдан булды дигән данны һәм батыр исемен алып кайтырмын да ул. Бу бәхәссез. Тик миңа көн саен төшке ашка симез итле аш, бәрәңгеле майлы шурпа булсын. Ит-май ашамыйча көрәшеп булмый. Көн саен бер дистә күкәй. Ашау шулай итеп авыл өстеннән була. Сөт-катыкны әйтеп тә тормыйм. Анысы билгеле бит инде. Ашаган саен бер-ике стакан әче бал. Кинҗәбикә балы булмасын. Ул бал коя белми. Әнә теге очтагы Сәмига балы шәп, ул әйбәт коя.

Менә шулай итеп, Хөснулла белән авыл халкы арасында яшерен килешү төзелде. Тик яңгырчылар белән гөлемнәр белмәсен.

Булачак Сабантуй батырына бәйрәм көннәре башланды. Булачак батырны ничек сыйламыйсың инде?! Күрше-тирә кулдан килгәнен дә, килмәгәнен дә тырыштырды. Ул каклаган каз, ул яңа суйган бәрән ите дисеңме, халык барысын да әзерләп, Хөснуллага ярарга тырышты. Бер атна-ун көннән булачак батыр иртәгә сыйланачак йортка кереп, үзен нинди ашлар, нинди сыйлар белән сыйларга кирәклеге турында әйткәләп, күрсәтмәләр биргәли башлады. Гел генә симез сарык ите дә туйдыра бит. Шуңа да әле пәрәмәч, әле кыстыбый белән пилмәннәр дә таптырды. Ул тавык шулпаларыннан туеп китсә, каклаган тана, каз ите пешерттерде. Бу яктан карнайлыларга җиңел иде. Чөнки ул заманда колхоздагы башка авыллардан аермалы буларак, аларга гына малларны икеләтә артык тотарга рөхсәт ителгән. Әмма бәрәңгеләре юк. Бердән, чәчмиләр. Икенчедән, бакчаны зурайтып, бәрәңге чәчәргә силсәвит җир бирми. Районнан рөхсәт

юк. Шуңа да җыелышып май, сары май, эремчекләр төяп, яңгырчылардан ике капчык бәрәңгегә алыштырып кайттылар. Колга Хөснулла эшкә бик һәвәс булмаса да, ашау ягына бик тә таза ашый иде. Бер утыруда ике кешелек өлешне дә авырыксынмый ашап куя. Ашы тәмлерәк булса, тагы өстәтеп тә алырга һич тартынмый. Авырыксынып, кыенсынып тора торган вакытмы? Ул бит бу авылга күптән кулдан ычкынган Сабантуй батыры Карнайдан дигән данны кайтарырга җыена.

Вакыт шулай җайлап кына үтә торды. Сабантуй үткәрергә билгеләнгән көн дә якынайды. Кызлар Сабантуйга дип, тастымал-яулыклар чикте. Заманалар авыр булуына карамастан, ир-егетләр кәчтүм-чалбарларын яңартырга тырышты. Булдыра алганнары итек-сандали тектерде, дигәндәй. Ә безнең булачак «батыр» – колга Хөснулла, ай буе сыйланып, авыл буенча чиратта йөреп, бөтенләй симерде. Күзләре кысылып, хәтта бераз корсагы да бүлтәеп чыкты. Аш алдыннан стакан-стакан ярым Сәмига балы белән симез ашка юл ярып куя торган булды. Төшке аштан соң ике сәгатьләп черем дә итә әле. Ашаган малда өмет бар, дигәндәй, булачак батырга хәл керде. Наз һәм яратудан мәхрүм булган тол хатыннар өметләнеп, алдан ук аш-су әзерләп, Хөснулланы көттеләр. Тик беркем дә үз чиратын бирергә ашыкмады. Һәркем Сабантуй батыры исемен авылга кайтару өчен үз өлешен кертергә тырышты.

Гөлемнәр дә тик ятмады. Бурзай Фазлый белән сөйләшеп куйдылар. Син, диделәр, ләкабеңә хилафлык китермә. Сабантуйда йөгерү буенча авылга беренчелекне син алып кайтырга тиеш, диделәр. Ул инде үз чиратында: «Тырышырмын, егетләр, тик яшьләрне узып булыр микән?» – дигән шиген дә белдерде. Гөлем тавында нефть эзләүче буровой эшчеләрен дәшмәскә булдылар. Сәбәбе гади иде. Анда төрле яктан җыелган кешеләр эшләп, күпчелеге – урыслар. Урысның Сабантуй батыры булганын кемнең күргәне-ишеткәне бар? Алар көрәшү түгел, сөлге дә тота белмиләр. Булмастай хәл бу. Икенчедән, Сабантуй батыры булып чит-ят калса, барча колхоз гынамы, барча тирә-як авыллар бот чабып көләчәк бит. Гөлемнәр үзләре булдыра алмагач, чит кавемне яллаганнар дип, бигрәк тә яңгырчылар күз ачарга да ирек бирмәсләр. Чөнки элек-электән Гөлем белән Яңгырчы арасында яшерен генә тарткалаш-ярышу бара. Кемнең бригадасы алда, кайсы бригадада халык яхшы эшли, дип, бер-берсеннән көнләшәләр. Моны колхоз җитәкчеләре дә белеп, ике бригаданы ярыштыра иде. Ә Карнайга килсәк, аларның бригадасы, Яшелкүл авылын бергә кушсаң да, бәләкәй бригада исәпләнә. Яңгырчы бригадасы иң зуры. Ул бригадага егерменче елларда Яңгырчыдан аерылып чыккан Ирекле авылы да керә. Ә инде Иске Гөлем бригадасы үзенә аерым. Алар да Карнай кебек бәләкәй бригада дип исәпләнә.

Менә Сабантуй буласы көн дә килеп җитеп килә. Яшьләр алдан ук мәйданын әзерләп куйды. Йөгерү-сикерү урыннарын ясадылар. Ун метр ук булмаса да, озын гына багана да утыртылды. Капчык сугышы һәм башка ярышлар өчен урыннар билгеләнде. Тик җәй башыннан ук ява башлаган яңгыр гына һаман туктамый. Бу яңгырлар киләсе уңышның мулдан буласына ишарәләсә дә, халык Сабантуйны ашкынып көтә иде.

Менә шаулап-гөрләп яуган яңгырлар да үтеп китте. Җир әзрәк җилләгән көе халык Сабантуйга чыгачак. Шулай булды да.

Һәр бригада үзенә билгеләнгән урынга казан асты. Аллага шөкер, унар чиләк сыешлы казаннар бригада саен бар. Борыннарны кытыклап, Сабантуй мәйданына каен-имән утынының төтен исе таралды. Аш-су осталары мәш килеп, бәйрәмгә килгән халыкка аш әзерләргә тотынды.

Иң тәүдә ярышка атларны җибәрделәр. Үрге Гөлем белән Иске Гөлем бригадасы Сабантуйда бергә булырга вәгъдәләшкәннәр иде. Ат чабышы белән бәйрәм башланып китте. Иске Гөлем бригадасыннан килгән ат беренче урынны алды. Ат муенына чигелгән сөлге бәйләнде, атта чапкан Киләшчә Миңнеханга чалбарлык товар тоттырдылар. Халык атта ярышучыларны бүләкләүне карап та тормады, көрәш буласы урынга ашыкты. Атлар өстендә чапкан малайларның туган-тумачалары җиңүчеләрне котласа, җиңелүчеләрне тынычландырып, аларга пешкән йомырка белән яулыклар өләшенде.

Көрәш буласы мәйданны халык алдан ук уратып алды. Тәртип саклаучы комсомоллар уң беләкләренә кызыл тасма бәйләп кысылган мәйданны киңәйтергә тотынды. Иң тәүдә бала-чага чыгып көрәште. Җиңгәннәргә дә, җиңелүчеләргә дә кульъяулык белән кәнфит бирделәр. Аннан инде яшь егетләр чыкты. Алар да бүләксез калмады. Менә күптән көткән, Сабантуй батыры булырга җыенган ир-егетләр бил алышырга әзерләнә башлады.

Сабантуйга барырга җилкенеп йөргән Миңнегәрәй иртән хатыны Рабигага үзенең итекләрен дегетләп куярга кушты да колхоз эше белән чыгып китте. Ул шулай бит инде, бәйрәм булса да, эшеңне онытырга ярамый. Миңнегәрәй гомер бакый, үзе белә-белгәннән бирле урман кисте, урман чыгарды. Сугыштан исән-имин кайткач та, шул эшен дәвам итте. Әле дә урман хуҗасы булган Кыям, киселәсе урманны күрсәтергә дип, аны иртә таңнан үзе белән алып китте. Урманнан сәгать уннарда гына кайттылар.

Миңнегәрәй, чәй дә эчеп тормыйча, бәйрәмгә барырга әзерләнә башлады. Хатыны кичә үк үтүкләп куйган шакмаклы күлмәген киде. Тик менә аякка кияргә дигән итеккә чират җиткәч, кәефе кырылды. Итек бит майланмаган. Миңнегәрәй тавышын күтәреп:

– Бәй, нигә итекне дегетләмәдең? Иртән үк әйтеп чыгып киттем бит. Нәрсә эшләп яттың, шул итекне дә майламагач? Мин кеше алдына ничек барып басыйм иске итек белән? – дип кычкырды.

Рабиганың бүген эше каты иде. Әле чак ипиен әвәләп, мичкә тыкты. Җитмәсә сөт аертырга Миңсара сепаратына барасы бар. Эшләре бүген бигрәк тә тыгын. Барчасы бергә килеп өелде. Суга башлаган паласын да бетерергә кирәк. Кирәк тә кирәк, һич кенә дә бушарлык түгел. Кая ул тау башындагы бәйрәмгә бару, ди. Җитмәсә, ире ачу китереп, нәрсә сөйләп тора? Кызмаган җиреңнән кызарсың.

– Бәйдән ычкынган ата эт кебек, чыгып китү ягын гына карыйсың. Кичтән үк майлап куярга иде итегеңне. Олы малаеңа кушарга иде. Майласын иде.

– Соң нигә берәрсенә кушмадың? Нәрсә сөйләп торасың тагы. Ата

эт, имеш. Мин дә уйнап йөрмәдем. Эш буенча йөрдем. Булсын дип тырышам.

– Балаларың да үзеңә охшаган. Синең арттан ук бәйрәмгә дип чыгып шылдылар. Күрми дә калдым.

Шулай әйткәләшә-әйткәләшә, Миңнегәрәй тиз-тиләмән итеген дегетләп, ишегалдына чыкты. Хатынының, ичмаса чәй эчеп ал, дигәнен дә ишетмәде. Рабига ирен чәй табынына чакырырга ишегалдына чыкканда, ул инде тыкрыктан ашыга-ашыга, тау ягына китеп бара иде. Хатын эчтән генә: «И-и, шушы кара йөрәкне, һич кенә дә ипкә кертеп булмады инде. Баш бирмәс нәмәстәкәй», – дип калды.

Ә Сабантуй гөрли. Хөснулла әле генә чираттагы үзенә каршы чыккан берәүне баш аша очырып, аркасына салды. Шатлыгыннан кулындагы җитеннән тукылган кызыл башлы сөлгесен баш очында болгап, көрәш мәйданын ике тапкыр урап чыкты. Көрәш мәйданында судья булган Зөфәр Хөснуллага каршы чыгып көрәштерү өчен әле яңгырчыларны, әле гөлемнәрне үгетли башлады. Юк, озын Хөснуллага каршы чыгучы табылмады. Шулчакны юктан кызык ясарга яраткан һәм өченче ел гына Себердән кайткан Гөлемнең атаклы карагы Хәйрулла уртага чыгып:

– Әйдә, курыкмасаң чык миңа каршы! – дип, сөрән салды.

Барча мәйдан «ах» итеп тынып калды да шаркылдап көлеп җибәрде. Китте шау-шу. Карнайлылар: «Батыр ял итсен. Инде ничә кешене әйләндереп салды. Алай булмый ул. Батырга да ял кирәк, судья нәрсә карый!» – дип шаулаштылар. Хөснулла үзенең иңбашыннан гына торган Хәйруллага карап:

– Бу кесә карагы белән мин көчемне әрәм итеп көрәшеп тә тормыйм инде, – дисә дә, сөлгесен уң кулында әйләндерә-әйләндерә, уртага чыкты. Халыкка горур гына өстән карап, Хәйрулланың башына сөлге белән суккалап алды. Шулай итеп каракны үзенчә мыскыллады. Мәйдан әле тып-тын торды, әле шаркылдап көлде. Хәйрулла үзеннән көлгәннәрне бер вакытта да буш калдырмады. Авылдашлары аңа беркайчан да карак дип әйтмәде. Алай гына да түгел, артында да угрылыгы турында кычкырып сөйләмиләр иде. Ә монда барча Сабантуйга фашладылар. Әллә шуңа гарьләнеп, Хәйрулла мәче җитезлеге белән Хөснулланың биленнән сөлгесе белән кысып күтәреп алды. Булачак батыр сөлгесен көндәшенең биленә салырга да өлгермәде генә түгел, сизми дә калды. Юк, Хәйрулла колганы күтәреп бәрмәде. Кинәт кенә батырны ычкындырды да халыкка:

– Бу самавыр морҗасы белән көрәшә алмыйм. Кырынмыйча килгән. Әллә иртән юынып та тормаган инде, – дип, сөлгесен мәйданга очырды. Халык тагы шаркылдап көлде. Хөснулла җавапсыз гына бер елмаеп алгач, урынына барып утырды. Хәйрулла шулчакны ашыга-ашыга, көрәш мәйданына якынлашып килгән Миңнегәрәйне күреп калды да: – Әнә минем белән көрәшерлек кеше килә. Мин шуның белән көрәшәм, – дип, судьяга дәште. Иелеп, сөлгесен кулына алды. Халык, кызык табып, каракны әйдәләп өндәргә тотынды. Төрлечә дәртләндерә башладылар.

Миңнегәрәй килеп җитмәстән үк, халык икегә аерылып, юл ярды. Аптырап калган ирне әйдәләп, мәйдан уртасына чыгардылар. Ир мәйдан уртасына чыкмас та иде, уртада аны чакырып, Хәйрулла абзасы тора.

Хәйрулла бәләкәй генә буйлы, ябык кына гәүдәле, әмма бик җитез һәм күзләре янып торган ир уртасын узган абзый. Миңнегәрәй аны яхшы белә. Берничә тапкыр ялланып, Каенүзәкләргә урман да кисештеләр әле. Хатыннары да Әнәч авылыннан шикелле. Хәйрулла мәзәк уйлап табып шуны кылмаса, Хәйрулла булмас; ул ирнең дегетләнгән итегенә ишарәләп:

– Нәрсә Миңнегәрәй, яңа итегеңне күрсәтергә килдеңме? Әллә булмаса, көчеңнеме? Көчеңне күрсәтергә уйласаң, сал итегеңне. Югыйсә пычрануы бар, – дип, иргә күз кысып алды.

Аңлады, барысын да аңлады ир. Бу халыкның күңелен күтәрү өчен шаярып алу гына иде.

– Икесен дә күрсәтергә килдем.

Менә ике ир көрәшә башлады. Берсе төптән юан, киң күкрәкле, җилкәләре колхозның тегенди-мондый үгезеннән калышырлык түгел. Миңнегәрәй, дөресен генә әйткәндә, тауга терәп, үгезнең койрыгын гәүдәсеннән суырып алырлык бәндә булса да, бик басынкы. Әмма кыздырсалар, күзенә ак-кара күренми, утка да ташлана торган кеше иде. Икенчесе, әйткәнемчә, чандыр гына гәүдәле, арурак төчкерсәләр дә, егылып китәр төсле кеше. Ләкин шундый булуына карамастан, ут бөрчәсе кебек җитез һәм күзеннән дә ут бөркелеп тора торган җиңел гәүдәле, тирә-якта даны чыккан карак. Әмма олы яшьтә булып, комы коела башлаган иде инде.

Хәйрулла мәйдан уртасында яланаяк басып тора. Гадәттә көрәшүчеләр яланаяк көрәшәләр. Шуңа да ул Миңнегәрәйгә итеген салырга кушты. Менә шулай яланаяклы ике ир көрәшә башлады. Берсе – Яңгырчыдан, икенчесе – Гөлемнән. Карнайдан килгән озын Хөснулла карнайлылар таләбе буенча ял итә. Мәйданда бер-берсенә көчләре буенча да, гәүдәләре буенча да туры килмәгән ике ир хәлдән таеп көрәшәләр. Әле берсе, әле икенчесе күтәреп ала. Тик ега гына алмыйлар. Читтән карасаң, чынлап та бу ике ир манма тиргә батып көрәшә, диярсең.

Хәйрулла Миңнегәрәйнең колагына пышылдап кына:

– Мине күтәреп бәрә күрмә. Бераз мәйдан буйлап йөртеп каныңны кыздыр. Үзем әйткәч, җайлап кына аркама салырсың. Беләсең инде, Верхатин урыслары кыйнап, өч кабыргамны сындырдылар. Шуңа күрә чамалап кылан. Беләм, көчең җитәрлек. Син колганы җиңәчәксең. Билеңне бирмә. Матри малай, билеңне бирмә! Йә, хәзер җайлап кына, мине егып салсаң да була, – диде.

Шулай итеп, Миңнегәрәй Хәйрулланы кинәт кенә күтәреп алды да җай гына аркасына китереп салды. Судья таләбе буенча Миңнегәрәй белән тагы бер-ике кеше көрәшеп алды. Алар да Миңнегәрәйдән тиз җиңелде. Мәйданда ике батыр калды. Халык түземсезләнеп көтә: кайсы җиңәр? Шунда түбән очтан әллә Келәшчә Шәмсетдин булды, Миңнегәрәйнең этисенә:

– Чыгарма улыңны. Имгәтүләре бар. Күрмисеңмени, карнайлылар нинди мужикны әзерләгәннәр. Малаеңнан ике баш югары бит. Гәүдәсе генә нәрсә, дүсмәт. Аяклары Өршәккә салынган күпер баганасыннан да юан.

Карнайлылардан да бер-ике ир Миңнегәрәйнең кыска буеннан көлеп алды. Җитмәсә берсе:

– Әле соң түгел. Малаеңны алып кайтып кит. Хөснулла түбәсенә берне сөлгесе белән сукса, тезенә чаклы җиргә кереп китәчәк бит, ботына чаклы батмаса әле, – дип кычкырды.

– Карама беләккә, кара йөрәккә.

– Карадың, карамадың. Сезнең йөрәкнең нинди икәнен беләбез инде, – дип куйды тегесе. Халык сыек кына көлешеп алды. Әлеге дә баягы, әл-пи, ти-си таягы, дигәндәй, Миңнегәрәйнең кушаматы «карайөрәк» иде. Чөнки нәкъ ирнең йөрәк турысында бала учы зурлык кара миңе бар. Шуңарга карап бирелгән кушаматы иде бу.

Менә алыш башланды. Хөснулла нинди генә озын таза гәүдәле булып күренсә дә, төптән юан Миңнегәрәйне җирдән күтәреп ала алмады. Үз чиратында Миңнегәрәй колга буйлы Хөснулланы җирдән бер-ике тапкыр аерса да, тегене алып очырырга осталыгы җитмәде. Колганың аяк-куллары озын шул. Менә шул вакытта мәйданның әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып, йөгереп урап йөргән карак кына:

– Күтәреп бәр, шул самавыр морҗасын! Күтәреп бәр! Баш аша очыр! Баш аша, баш аша! – дип кычкырып, Сабантуй яланын яңгыратты.

Юк, булмады. Бер батыр да җиңмәде дә, җиңелмәде дә. Инде көрәшчеләр манма тиргә батты. Икесе дә арыды. Колхоз үгезләре сөзешкәндәге кебек, мышнап төштеләр. Ниһаять, башка ярышларны үткәрүчеләр дә үзләренә йөкләтелгән эшләрен тәмамлап, көрәш мәйданына җыелды. Ә көрәш һаман дәвам итә. Инде зур казаннарда пешкән ашлар да суына башлады. Шунда силсәвит рәисе мондый тәкъдим кертте:

– Аркан тартышсыннар. Кем җиңә – шул батыр була.

Шулай килештеләр. Тиз арада читтә тугарылып куелган атлар кырыннан ике дилбегә алып килделәр. Дилбегәләрнең очын бер-берсенә бәйләделәр. Зур бoҗра сыман аркан хасил булды. Тәртип буенча көрәшчеләр арканны ике култык асларыннан үткәреп, җилкәләренә киеп тартышырга тиеш.

Шушы шартны ишеткән көе Хәйрулла карак шатлыгыннан үрле-кырлы сикереп, учын учка уа-уа:

– Бетте, Яңгырчы җиңәчәк! Карнайларга капут! Без җиңәбез. Самавыр морҗасы-пажар каланчасы, ишетәсеңме? Сиңа хинде хох!

Хәйрулла шулай сугыштан кайткан фронтовикларның үзара сөйләшкәндә, нимес сүзләрен кушып сөйләшүләрен кабатларга ярата иде.
Карнай Чынтимер:

– Тилегә тиле дисәң, тигәнәк буе сикерә, ди. Син кесә карагы бөтенләй шаша башладың, – дип үртәде.

– Мыскыл итмә мине! Мин беркайчан да кесә карагы булмадым. Мин – настоящий вор! Сезнекеләр ул кесә карагы. Без андый-мондый вак-төяк белән кул пычратмыйбыз. Кеше кесәсендәге көнбагыш карагы түгел без. Кирәк булса, иртәгә үк казаклардан ат алып кайтып бирәм үзеңә. Атларыгыз да беренче урын ала алмады бит. Ичмаса, ат белән күңелеңне юатырсың.

Карак белән карнайлар сүз көрәштергән арада батырлар мәйдан уртасына чыгып басканнар иде. Шунда Хәйрулла көрәшне алып баручы судья кисәтүенә дә карамыйча, Миңнегәрәй кырына чыгып, аның җилкәсенә эленгән арканны рәтләгән булып пышылдап өлгерде:

«Тартыша башлагач, тезеңне бөкмә. Киеренке вакытта тезеңне бөкми генә артка чигенеп куй. Шул чакта каланча йә алга иелеп каплана, йә тураеп баса башлый. Менә шул чакны чамалап алга ыргыл. Барча җан ачуың белән. Озын колга авып төшәчәк. Миңа карап тартыш. Мин баш какканда эшләрсең бу эшне. Ярый, Ходай кушмаган эш булмас. Ышан, без җиңәбез. Теге урман кискәндә, сазлыктан бүрәнәләр өстерәгәндәге кебек өстерә. Күзең атылып чыкса чыксын, әмма нык көчән. Син килгәнче күтәреп карадым мин аны. Көче чамалы. Коры куык. Гәүдә генә бар».

Барча Сабантуй икегә аерылды. Бер якта – Миңнегәрәй яклылар. Икенче якта – озын Хөснулланыкылар. Хөснулла тарта башласа, аның яклылар, әйтерсең лә, арканны аңа кушылып тартышалар, гәүдәләре белән читкә авышып, «а..ах», «ааах» дип ыңгырашып куялар. Инде Миңнегәрәй көчәнеп әз генә теге колганы өстери башласа, бу яктагылар «ах» та «ух» килеп көч бирәләр. Көрәшкән вакытта ук юеш, йомшарып беткән җиргә аркан тартышучыларның аяклары шайтан сөягенә чаклы үк батып бетә. Әллә Хәйрулланың киңәше ярдәм итте, әллә Хөснулла ялгышты: Миңнегәрәй арткарак чигенгәндә, колга, алга капланмас өчен, ниндидер мизгел арасында гәүдәсен турайтты. Шул чакны Миңнегәрәй кинәт бар көченә алга ыргылды. Хәйрулла әйткәнчә, Самавыр морҗасы гәүдәсен тота алмыйча, авып төште. Егылган кешене өстерәп сызык аша чыгару Миңнегәрәйгә әллә ни кыен булмады. Теге вакытта урман кискәндә, сазлыкка баткан атны ничек өстерәп чыгардылар да аннан шул сазлык аша күпме бүрәнә өстерәделәр. Менә шул вакытта алган күнекмә-тәҗрибәләр бик тә ярап куйды. Барча Сабантуй «ах!» итте. Яңгырчылар дәррәү «урра!» кычкырып җибәрде. Тик карнайлар гына бераз ни булганын аңламый тордылар да, гүләшеп:

– Хәрәм, бу хәрәмләшү була!

– Яңгырчы ягы авыш, түбән таба. Шуңа да безнең батыр җиңелде.

– Яңадан тартышсыннар! Яңадан! Урыннарын алышып.

Тавыш китте. Карнай халкы – кызу халык, мәйдан уртасына ук чыкты. Түбән Гөлемнән килгәннәр белән Үрге Гөлем кешеләре арасында чак бәргәләш-сугыш чыкмады. Чөнки Түбән Гөлемнәрнең күбесе карнайлар яклы булып, Үрге Гөлем барчасы диярлек Яңгырчы авылын куәтләде. Сугыш чукмарларын, бәйрәмне бозмагыз дип, тиз бастылар.

Бераз икеләнеп торганнан соң, көрәшне җитәкләгән судья башка уеннарны җитәкләүчеләр белән бергәләп киңәшеп алды. Мәйданны таратып, читкәрәк китеп, аркан тарткан урынны карадылар. Чынлап та, көрәш мәйданы Яңгырчылар ягына таба авышрак төсле күренде. Шуларны җентекләп ачыклаган арада аркан тартышучылар һәркем үзе яклылар арасында ял итәргә утырды. Ә самавыр морҗасы Хөснулла, күкрәгендәге тирләрен сөртә-сөртә, Яшелкүл авылыннан килгән Әбүбәкердән:

– Кара әле, кордаш, синең бал бик шәп була торган иде. Алай-болай берәр нәрсә алып килмәдеңме? Тамак кипте. Су эчсәм, аякка төшәргә мөмкин. Булса, берәр стакан салып бир әле. Бал кыздырып та җибәрер. Мин теге бөкеч бүксәне «хә!» дигәнче сызыктан тартып чыгарам аны.

Әбүбәкер йөгертеп кенә, арбасыннан шешәгә тутырылган әче бал алып килде. Кеше-кара күрмәсен дип, карнайлылар Хөснулланы каплап

торды. Ярты шешә бал «хә» дигәнче самавыр морҗасының ашказанына төшеп ятты һәм хуҗасын кыздыра да башлады. Бу бик тә шәп итеп әчетелгән бал балы иде. Менә тагы көрәш – аркан тартышу башланды. Хәзер Хөснулла яклылар – бу якта, ә яңгырчылар – каршы якта. Халык та тизрәк ярышны карарга уңайлы урынны алып калу өчен шау-гөр килеп, урын алыштырды. Тәүдә Миңнегәрәйнең җиңүенә шикләнеп караучылар да аның ягына чыгып, ирне дәртләндерергә тотындылар. Ә инде Хәйрулла карак, артына ут капкан кеше кебек кайда басарга белми үрсәләнеп кычкыра. Кычкырмый ни, кычкыра шул, аны бит бүген кесә карагы дип хурладылар. Менә хәзер күрерләр инде, кем ягы җиңәр дә, кемнең кем икәне беленер:

– Мин әйткәннәрне тыңла! Миңа кара, миңа!

Тик Миңнегәрәй генә аны күрми дә, шәйләми дә шикелле. Кызарынып-бүртенеп көчәнә. Ә менә Хөснулла корсагына төшеп яткан әче бал үз эшен эшли башлады. Тик умарта балыннан коелган балның шундый үзенчәлеге бар. Башың шәп эшләргә мөмкин. Телең дә, зиһенең дә ачылып китә, әмма аяк-куллар йомшара да куя. Әйтерсең лә гәүдәгә тегеп куелган бау инде. Һич тыңламый башлый. Әле дә шулай булды. Булмый ни, булыр шул. Буыннан буынга умарта асраган Әбүбәкер нәселе балны коя белә ул. Былтыр көз үк коеп, суык базга төшереп куйган иде ул аны. Бал бик киселеп китмәсен өчен әзләп-әзләп зимләп тә торды. Әле дә Сабантуйда танышлары белән бәйрәм итеп алырга исәпләп алып килгән иде. Менә бит кемнең ризыгына насыйп булган. Булса була инде. Булачак батырга берни дә жәл түгел.

Бу юлысы да Миңнегәрәй карак абзасының киңәшенә колак салды. Баягы алымны кабатларга булды. Җаен туры китереп кинәт кенә, артка чигенде. Хөснулла гөрселдәп алга барып төште. Ул гына да түгел, үзләре йомшартып инде баткаклана башлаган җиргә бите белән кадалды. Авыз-борынына гына түгел, күзләренә үк баткак тулды. Нәрсә булганын аңламый да калды, аңлап башын күтәргәндә, бите адәм карамаслык булып баткакка буялган. Ә Миңнегәрәй аны бүрәнә урынына өстерәп китеп бара. Яңгырчылар дәррәү «урра!» кычкыра. «Афәрин! Маладис! Шулай кирәк мактанчыкка! Пажар каланчасы, белсен кем белән көрәшәсен дә, кем белән ярышасын! Монда тол хатыннарның, әби-чәбиләрнең төзәтергә биргән самавырларын сатып эчү түгел, бу – Сабантуй! Сиңа – Сабактуй. Сабактуй!»

Кемдер, килмешәкләргә шул кирәк, дип тә ычкындырды шикелле. Әллә шулай тоелды гынамы? Белмәссең, бу мәхшәрдә колагыңа әллә нәрсәләр дә ишетелергә мөмкин.

Миңнегәрәй өстерәвеннән туктап, җиңүен раслап, кулларын күтәрде. Ул да шатлана иде. Дуслары Миңнегәрәйне кочаклап-кочаклап, рәхмәт әйтәләр. Тик Карнайдан әлеге шул Чынтимер:

– Җиңү дөрес түгел. Яңадан тартышсыннар. Менә карагыз, кара. Хөснулла сызыктан чыгып бетмәгән, – дип, сөрән салды.

Халык ни әйтергә дә белми борылып, Хөснуллага карады. Чынлап та Хөснулланың ярты гәүдәсе сызыктан чыгып бетмәгән икән. Ә Хөснулла аягына басарга тырышып торырга чамалый. Шул вакытта бөтенесен таң калдырып Хәйрулла карак «каланча»ның арба тәртәсе кебек аяклары

арасына кереп, тегене әллә ни көчәнми генә урынында борып, сызыкның бу ягына өстерәп чыгарып та куйды. Барча халык гөр килеп хәтта кул чапты.

Сабантуй шулай тәмамланды. Бер көтү ир-ат Миңнегәрәйне җиңгән бүләк сарыгы белән өйләренә чаклы озатып куйды. Миңнегәрәйнең балалары әле кайтмаган. Алар Сабантуй боткасы ашарга дип, казан янында торып калды. Ир өйгә кергәндә, Рабигасы соңлап кына төшке ашка өстәл әзерләп йөри иде. Ире килеп кергән көе ризасызлыгын белдереп:

– Нәрсә, ашавыңны да онытып йөрисең. Әллә теге очтагы түтәң сыйлап кайтардымы? – дип, теге очтагы ире сугышта үлгән Миңсылу турында төрттерүе иде.

Миңнегәрәй шатлыгын яшерергә теләп, хатынына елмайган йөзен икенче якка борып, өстендәге кәчтүмен сала башлады. Хатыны иренең көрәшкәндә пычранып беткән чалбарын күреп, тагы әллә нинди тавыш күтәрергә чамалаган иде дә, ире елмаеп хатынына карап:

– Әйе шул. Миңсылу сыйлады. Балаларны да алып калды әле. Алар да тамак туйдырып кайтыр. Җитмәсә сарык та биреп җибәрде әле. Ышанмасаң, абзарга чыгып кара.

Шулвакыт олы улы Барыс ишектән керә-керешли үк:

– Әни, әни! Беләсеңме, безнең әти Сабантуй батыры булды. Бүләккә сарык бирделәр. Үзе көрәшкән сөлгене биленә бәйләделәр! – дип кычкырды.

Нәкъ шул чакта Миңнегәрәй кәчтүмен чишеп хатынына борылды. Чынлап та билендә бик матурлап тукылган кызыл башлы бизәкләп чигелгән киндер сөлге иде.

Ә самавыр морҗасы Хөснулла Сабантуйдан җәяүләп кайтты. Авылдашларыннан берәү дә аны арбасына утыртмады. Җитмәсә, яшьләр авылга кергән урындагы күпер төбендә көтеп алып, иманын укыттылар. Хөснулла биш елсыз Карнай авылына килмәде. Илчегол авылында ята икән дип сөйләделәр азактан. Менә шулай тәмамланды «Урал» колхозындагы сугыштан соңгы тәүге Сабантуй. Әллә ничә еллар үтсә дә, һаман бик күңелле булды дип, картлар әле булса искә төшерә.



Ләйсән
Фәтхи

# УТ КАПКАНДА ЧЫГЫП ЙӨРӘГЕҢНӘН...

***

Бу шәһәрдә син телеңне җуйдың
Һәм югалттың ихлас йөзеңне.
Танырсыңмы икән, көзгеләрдән –
Ун ел элек булган үзеңне?

Салкын җилләр алып китте булыр
Күңелдәге милли көйләрне.
Балаларың синең үсеп җиткәч
Тик чит телдә генә сөйләрме?

Йөрәгеңнән синең төшеп калган
Хәтереңнең алтын тартмасын
Бер сагынып искә алырсың да
Эзләп-эзләп, кире тапмассың.

Бу шәһәрдә – тарихыңны җуйдың,
Нәселеңне өздең тамырдан,
Кемнәргәдер ияргә теләп...
Үкенерсең инде ахырдан.

«Кемгә кирәк соң ул?» дия-дия,
Әлифбаңны таптап ташладың.
Мирасыңны, дәүләтеңне җуеп,
Чит милләттә яши башладың.

Ә бары да кызык башланды күк:
Ике телне кушып уйнадык.
Тик уенны өзә алмадык шул,
Вакытында нокта куймадык.

---

Ләйсән ФӘТХИ (1990) – *шагыйрә; «Тере тынлык», «Файдалы туңдырма» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Кышкы буран курай моңы белән
Колакларга үтеп сызгырды.
Юк колакны түгел, ә үзәкне
Уй камчысы белән сыздырды...

***

Төн элпәсе лепердәсә таң атканда,
Сызып-сызып юлын ярса кояш нуры...
Һичбер бәндә күрмәгәндә киләчәген,
Кем соң белә кайсы юлы булыр туры?

Кемнең хаклы, кемнең ялган икәнлеген,
Бүген түгел, әйтә алыр вакыт бары.
Белеп булмас сөенченең бәясен дә,
Ни нәрсәгә алышасын аһ вә зарның.

Таң сызылып аткан чакта – ике мизгел:
Төн алышыр көн белән дә килер якты.
Тормышта да бер ишекләр ябылганда,
Икенчесе ачылуын белү яхшы.

***

Шырпылардан корган ханлыгыңа
Ут капканда чыгып йөрәгеңнән,
Бирешмәскә, янгыннардан чыгып,
Көл астыннан яңарырга өйрән!

Ефәк канатларны җил өзгәндә,
Чыгармыйча торса кыяларың...
Син онытма күңел төпкелендә
Кыяр-кыймас якты хыял барын!

Әйтер сүзләреңне җир йөзендә
Аңлар адәм бетсә, булса кыен.
Таянырлык кеше калмаганда,
Үз көчеңә һәм Ходайга сыен.

Еллар буе ярган юлларыңны
Буран-давылларда кар капласа...
Син тагын да тирән(е)рәк итеп,
Өр-яңадан, өр-яңадан яса!

***

Чемер-чемер килә хәтер,
Уйлар хәзер башка төстә.
Күңелдәге борчуларга
Вакыт китә утын өстәп.

Мизгелләрне югалтканда,
Алмаш булып кала хисләр.
Таң арты таң узып китә,
Узыш алып бара кичләр.

Агып китә, диңгез булып,
Вакытыбыз тамчылары.
Җыерчыклар уяр өчен
Әзер аның камчылары.

Тик шулвакыт дәва да ул,
Яраларга дару да ул.
Өметләрен өзгәннәргә
Бер таяныч табу да ул.

Мөмкинлекләр ташкыны да,
Өр-яңадан башлар өчен.
Зөбәрҗәткә әйләнерлек
Гади генә ташлар өчен.

Хыялларны җитәкләүче,
Җилкәләргә куеп канат.
Бик кадерле һәр минуты,
Тик кайтарып булмый кабат.

***

Җитмәде үҗәтлек, кырыйдан күзәттек.
Тиешен алмадык – оялдык.
Башкалар мәҗлестә йорт түрен бизәсә,
Урыныбыз булды тик өй алды.

Дәшергә курыктык, кыймадык, ничектер.
Уңайсыз шикелле, кем белсен…
Кыюлар, әрсезләр заманны күтәрер...
Күзәтеп торучы – кем соң син?

Чүт кенә җитмәде, кермәдек чутына,
(Нигә соң? Кирәкме чуртыма...)
Башкалар тиешен алганда умырып,
Утырдык күзләрне томырып.

Китереп бирсеннәр, дәшсеннәр, имештер...
Алмадык лаеклы өлешне.
Шуңа да башкага таҗлары килешсә,
Безгә эт бүреге килешле…

## Таләпләр

Күп кирәкме кыз-кыркынга бу заманда?
Йорт, машинаң, чибәрлегең булса – җитә…
Һәм, әлбәттә, бер егерме яки илле
Меңләп акча салоннарга-фәлән китә.

Күлмәк-киемнәрнең шәбен алып торсаң,
Ай саен бер чит илгә дип план корсаң,
Чәчәк бәйләмнәре белән кайтсаң өйгә,
Бар тормышың салган булсаң җайлы көйгә.

Хатын-кызга хөрмәт белән карап торсаң,
Ярдәм итсәң кирәк чакта үзең белеп.
Риза булып чыгар алар кияүгә дә,
Яшәрсез сез шатланышып һәм дә көлеп.

Егетләрнең исә хәзер таләп әзер –
Чибәрлегең, буй-сыныңа карар алар,
Һәм яшең дә егермедә булса яхшы –
Бар дуслары көнләшсен, дип карап ала!

Өстәвенә тыйнак кирәк, сабыр кирәк,
Булгач булсын йомшак күңел, изге йөрәк.
Һәм тагын бер нәни генә искәрмә дә –
Риза булсын дөя түгел, энәгә дә...

Сүз әйтмәсен соң кайтканга эштән арып –
Шулай яши Россиядә бөтен халык.
Шат күңелле булсын һәрчак, шаян булсын,
Ә кулыннан бөтен эше килеп торсын!

Һәм туктаусыз барысы да сукраналар –
Берсе ялкау, берсе юан йә хәерче…
Йә Ходаем, бәхет бир син барсына да,
Һич булмаса акыл яки... көзге бирче…

***

Ясалма теш. Ясалма каш. Ясалма тел.
Үзе татар – ә теле юк. Ела йә көл.

Һәр җөмләсе чалыш-чолыш, хәзер бата!
Кайда синең, балакаем, анаң-атаң?

Кем өйрәтте сөйләшергә, кайда телең?
Авызыңда бәлеш пешә, әллә белен?

Гасырларда бар нәселең телне белгән!
Шушы тарих бетәрмени синең белән?

Вакыт узып, ясалганнар юкка чыга.
Телең бетәр, тик оятың ничек чыдар?

## COVID

Бар дөньяны тезләндерә алды.
Курку салды һәрбер йөрәккә.
Бу вакыйга ялгыш, дисезме сез?
Ә минемчә, бары кирәккә.


Хәрәкәт тә җирдә туктап калды.
Алыш-биреш юлы өзелде.
Бәхетеңне кәҗә сөзсә, диләр,
Күпләр өчен, ахры, сөзелде.

Бөекләрне җиргә төшерде дә,
Сүзсез итте оста телләрне.
Тагын кем бар буйсындыра алган
Шәһәрләрне түгел, илләрне?

Һәр кешене тигез итте дә ул,
Биетте дә тик бер кубызга.
(Кемнәргәдер гомер кирәк түгел,
Куркытадыр бары «сыбызгы»...)

Кемдер хәзер акча санавында,
Ә кемнәрдер гомер сорады...
Ходай кулында бар тормышыбыз:
Вирус – бары Остаз коралы.

*«Казан утлары» журналының 1965-1982 еллардагы баш мөхәррирләре*



*Рафаэль Мостафин*
*(1963 – 1968)*



*Гариф Ахунов*
*(1971 – 1974)*



*Зәки Нури*
*(1968 – 1971)*
*(1974 – 1982)*






Х. ТУФАН　Ф. ЯРУЛЛИН　М. ХӘСНИМӘРДӘНОВ

М. ВӘЛИЕВ　Х. САРЬЯН

Котлыйбыз!







*«Казан утлары» журналы редакциясендә (уңнан сулга): Яхья Халитов, Әмирхан Еники,*
*Аяз Гыйләҗев, Вакыйф Нуруллин, Рабит Батулла. 1968 ел.*



*Рәшит Гәрәй.
1959 – 1967 елларда
«Совет әдәбияты» (соңрак
«Казан утлары»нда)
поэзия бүлеге мөдире.*



*«Моабит дәфтәре» фильмында Муса Җәлил ролен уйнаган
Пётр Чернов (РСФСРның халык артисты) Татарстан
Язучылар берлегендә. Уңда: берлек рәисе Ибраһим Гази. 1968 ел.*



*Калмык халык шагыйре, совет әдәбияты классигы Давыт Көгелтинов
бөек сынчы Бакый Урманче остаханәсендә. 1981 ел.*



*Якташлар – шагыйрьләр Әхмәт Гадел (1942 – 2012) һәм
Кадыйр Сибгатуллин (1942 – 1994). Быел аларның тууына
80 ел тулган булыр иде.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

# СИНДӘ ТУДЫМ...

Татар баласы өчен безнең чор әллә ни мәрхәмәт күрсәтмәсә дә, күпләребез Казанга – бәхетебез башкаласына килеп сыенды. Казанны күрү, монда булу, уку, яшәү – Максим Горький әйтмешли, «минем университетларым». Тукаебызда мәркәзебез турында фикерләр хәттин ашкан:

*«Мондадыр безнең бабайлар гүрләре, почмаклары;*
*Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.*
*Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;*
*Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...»*

Әйе, без дә монда чыныктык, кыйблабызны барладык. Милләтебезнең дөнья тарихында тоткан урынын билгеләдек. Мескенлек, коллык, күндәмлек, буйсынучанлык хисеннән арындык. Дәүләт тоткан бөек халык булганлыгыбызны, данлыклы әдәби һәм мәдәни мираслы кавем токымнары һәм бабаларыбызның шанлы еллар гамәлен дәвам итүче варислары итеп тойдык. Шуңа, шулай булу өчен аң-белемебезне арттырдык. Кулдан килмәгән эшебез юк иде. «Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс», ди бит татар халык мәкале. Үзем язмышыма рәхмәтле: монда төзелештә дә эшләргә, институтта да укырга, филармониядә, җырчы буларак, гастрольләрдә дә йөрергә, заводта аппаратчы хезмәтенә дә өйрәнергә; клубта директор, сәнгать җитәкчесе вазифаларын үтәргә, телевидениедә редакторлык кылып, күп кенә тапшырулар чыгарырга, театр училищесында да укытырга туры килде. Бөек шагыйребез Хәсән Туфан шигъри юлларына игътибар биреп:



Алмаз Хәмзин мәктәп укучыларын «Казан утлары» белән таныштыра.

*«Дөнья мине*
*Үзгәртте:*
*Еламаска өйрәтте.*
*Күлмәк җиңен ертасымы? –*
*Бәйлисе бар*
*Йөрәкне»,*

– дип әйтәсе генә калды.

Ә менә «Казан утлары» журналында эшләгән елларым – аеруча мөһим чор. Тормыш тәҗрибәләрен куллану һәм исәпкә алу мондый күркәм журнал өчен бик тә кирәкле сыйфат булып чыкты. Йөз еллык тарихлы басмада нинди генә абруйлы редакторларыбыз көч куймаган да, классик әдипләребез романнарын, поэмаларын, шигырь-хикәяләрен бастырмаган. Исемнәрен санап китсәң, аларның гүзәл әсәрләре янәшәсендә үзеңне бөтенләй югалтасың... Ә эшләргә кирәк! Милләт сыйфат сорый!..

Җаваплы чор – журналны укучылар саны чамадан тыш нык кимегән вакытлар... Мине тапканнар – янәсе мин генә бу эшне булдырам. Киттем мир буйлап: концертлар куям, журнал таратам. Редакциягә яңа таләпләр куям: басманың товарлыгын, ягъни эчтәлеген баетыгыз! Югыйсә мин аның әһәмияте, кирәклеге турында сөйләп мактый алмыйм. Товарлы-акчалы мөнәсәбәтләр заманы бит. Район җитәкчеләре белән сөйләшәм,

журналыбызның абруе турында аңлатам, баш редакторыбыздан үтенеч хатлары күрсәтәм. Әйтәләр: «Үз исемеңнән яз!» – диләр. Язам. Кул куялар. Ләкин, соңыннан, чәй янында сөйләшеп утырганда, мондый сүз ычкындыралар: «Алмаз абый, (яки энекәш) сиңа болай көчәнеп эшләү ни пычагыма кирәк, син, әйдә, халыкка концерт куй, акчасы үзеңә булыр», – диләр. Шаярып, мине сынап карыйлар... Шулай итә-итә, концертлар, очрашулар оештырып, без – редакция хезмәткәрләре белән, югарыдан таләп ителгән тираж нормасын тутырдык. Рәхмәт коллегаларыма! Дүрт ел эшләү дәверендә «Казан утлары» журналы эчтәлеге белән дә баеды, дәрәҗәсе дә күтәрелде, авторларыбызның да активлыгы артты. Тәкъдим ителгән әсәрләр дә басмабызның товарлыгын көчәйтте. Үземә дә кайбер кечерәк күләмдәге әсәрләрне редакцияләү вазифасын йөкли башладылар. Журналда үз сәхифәмне – «Бәләкәйләр» циклын алып баруны тапшырдылар. Яза торгач, уй-фикер арта икән – «каләм үзе тарта», диләр осталар. Эстрадада байтак еллар эшләү дәверендә бик күп күренекле артистлар белән аралашырга туры килде. Бу очрактан шуны әйтеп үтәсе килә: алар турында китаплар чыга иде. Ләкин ул китапларда артистларның, шәхес буларак та һәм чын кешелеге кебек сыйфатлары, ягъни холкы, язмыш четереклекләре язылмый – бар да ал да гөл, калганын үзең бел, сыманрак төгәлләнә. Китабының беренче битендә үк ул Президент белән фотога төшкән, аннан соң Премьер кырыенда, тагын берсе – спикер янәшәсендә... хәтта мин дә чагылып алам, кайчагында соңгы биттә... Ләкин монысы китап калынайту өчен генә бугай...

Хыялымда үзем оештырган мәзәкчеләр төркеме – «Биш татар» артистлары турында язасы килү иде. Моны максат итеп куйгач, тормышка ашыру мөмкинлеге дә туды. «Казан утлары» журналында бөек артистларыбыз: Равил Шәрәфи, Рәшит Шамкай, Хәлим Җәләйгә багышланган бәяннарым басылып чыкты. Һәм алар җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде. Журналның 100 еллыгы алдыннан минем иҗатка уңай караш алу – зур дәрәҗә дип уйлыйм. Хәзерге вакытта татар язучыларының Үзәк басмасы – «Казан утлары» коллективы зур үзгәрешләр кичерә – әдәбиятыбызга яшь иҗатчылар туплана. Аларның көче белән милләтебезнең алгарыш юнәлеше тагын да биегрәк югарылыкка күтәрелер дигән өметтә калам.

**Алмаз ХӘМЗИН**

## Кадерле укучыларыбыз!

Озакламый бер гасырлык олуг юбилеен билгеләячәк журналыбыз һәрвакыттагыча әдәбиятыбызның алгы сафларында бара. Һәр яңа санда сез «Казан утлары» битләреннән өр-яңа әсәрләрне укыйсыз. Бер үк вакытта калын журнал – ул әдәбият тарихының сагында торучы да, аны барлаучы, кадерләп саклаучы да. Бу җәһәттән редакция заманча формаларны, яңа мәгълүмати технологияләрне куллана. Яңа әсәрләр белән сез «Казан утлары»ның **www.kazanutlary.ru** рәсми сайтыннан танышсагыз, әдәбият тарихына кагылышлы кызыклы мәгълүматны **YouTube** видеохостингыннан таба аласыз.

«Казан утлары»ның YouTube каналында яңа ачылган **«Классика тарихы»** рубрикасында без сезне татар әдәбиятының йөзен билгели торган әсәрләрнең язылу тарихлары белән таныштырып барабыз.

Безнең YouTube каналга шушы QR-код аша кереп, рәхим итеп, тапшыруларны карый аласыз.

# СҮЗ СӘНГАТЕ МАЯГЫ

Әдәбиятыбызның төп журналы минем гомерлек юлдашым булды дип әйтсәм дә, дөрес булыр. Чыны шулай. Дүртенче сыйныфта укыгандамы икән, беренче тапкыр без аны мөгаллимәбез Ниса апа кулында күрдек. Ул тышына «Совет әдәбияты» дип язылган китаптан (ул чагында аның журнал икәнлеген кем белгән?) бик матур бер әсәр укып күрсәтте. 1957 елда мине үзебезнең Арпаяз авылы клубына мөдир иттеләр. Андагы бер иске генә шкафта әлеге басманың байтак саны бар иде. Араларында хәтта утызынчы елларныкы булуы да хәтердә калган. Күбесендә юлбашчыларның зур-зур рәсемнәре дә бар. Аларның барысын да укып чыктым дип әйтә алмыйм, әмма шактые белән таныштым. Күңелемдә аеруча нык урнашып калганы Гомәр Разинның (Бәшировның) «Намус» романы булды сыман.

Алтмышынчы еллар башында өч ел армиядә хезмәт иткәндә дә, «Совет әдәбияты» журналын алдырдым. Димәк, миндә аны укып барырга кирәк дигән ихтыяҗ булган. Әллә кайдагы Тамбов, Липецк өлкәләрендә ул мине эзләп таба иде. Хезмәтемнең соңгы елындагы (1965) җәй айларының берсендә ул, исемен алыштырып, «Казан утлары» булып килде. Анысы күңелемә тагын да якынрак булды, чөнки ул Татарстаныбызның башкаласы исеме белән аталган бит.

Журналның бер санында Фатих Хөснинең «Минем тәрәзәләрем» дигән автобиографик әсәре дә басылган икән. Миңа бу язучының исеме генә түгел, үзе дә таныш. Әле армиягә киткәнче, ул абый Ш.Галиев белән бергә Кукмарага килгән иде. Шунда «Ил» дигән мех фабрикасы клубында булган очрашуда мин аның «Йөзек кашы» әсәреннән өзекне яттан укыган идем. Шунда ул бүләк итеп, «Җәяүле кеше сукмагы» дигән китабын да бирде. Шәп китап! Шуңа күрә аның «Тәрәзәләр»ен дә бер утыруда укып чыктым. Ленин бүлмәсенең бер почмагында уку белән мавыгуыма игътибар итеп, хезмәттәшем Власенко фамилияле егет, журналның тышындагы исемен карады да әйтеп куйды:

– Рус телендә түгел икән, син икенче бер телне дә шулай онытылып укырлык итеп беләсеңме?

– Әлбәттә, беләм. Татар теле – туган телем бит.

– Синең башың ике дөньяны берьюлы сыйдыра икән, алай булгач!

Әлеге әсәр миңа шулкадәр ошады, аны тагын бер тапкыр укып чыктым һәм алган тәэсирләремне шактый күләмле итеп язып та куйдым. Мин аны болай гына, үзем өчен генә язган идем. Ләкин тора-бара боларны әдипнең үзенә дә укытасым килә башлады. Ләкин кая җибәрергә? Чехов хикәясендәгечә авылга, бабайгамы? Тоттым да, «Казан утлары» журналы адресын язып, хатны почтага илттем. Ходай рәхмәте, бер ай чамасы вакыт узгач, Фатих абый Хөснидән хат килеп ирешмәсенме! Ул, әсәренә игътибарлы булганым өчен рәхмәт әйткән. Синдә әдәбиятчы булу куәсе бар, шулай яза торган бул, дип тә куйган.

Ә инде журнал белән чын-чынлап иҗади элемтәм Казан педагогия институтында укыта башлагач урнашты. Эш шунда, Г.Ахуновның «Хәзинә» дилогиясе турында төрле җыелышларда, матбугат битләрендә каршылыклы фикерләр күренә башлады. Бу исә ни өчен әлеге әсәр хакында үзем дә фикер белдермим әле дигән уй барлыкка килүгә сәбәп булды. Яздым да турыдан-туры баш мөхәррир Зәки Нуриның үзенә кертеп бирдем. Ул әлләни исе китмичә генә:

– Калдыр мәкаләңне, егетләр укып чыгарлар, аннан соң хәбәрләшербез, – диде.

Бер ай, ике ай да узды, әмма ул тарафтан нинди дә булса хәбәр алмадым. Инде онытылып барганда, кафедра мөдиребез Фәрит Хатипов шалтырата:

– Котлыйм, «Казан утлары»нда синең мәкаләң чыккан.

Икенче көнне кара-каршы очрашкач, ул үзенең карашын да җиткерде:

– Син Г.Ахунов иҗатына әдәбиятыбыз исеменнән бәя биргәнсең, әлегә шәхси мөнәсәбәтең белән чикләнү мәслихәт булмадымы икән? Шунысы әйбәт, каләмең барлыгы күренә. Инде сиңа бер тәкъдим дә бар: 1976 елда Казан педагогия институтына нигез салынуга 100 ел тула. «Казан утлары» журналының һәм аның «Безнең юл», «Совет әдәбияты» исемнәре белән чыгып килгән элгәрләренең үсеш юлында безнең институтның да өлеше бар. Син югары уку йортыбызның үткәнен өйрәнеп, нәтиҗәсен журналда бастыра алсаң, рухи тамырларыбызны барлауда бер әйбәт эшең булыр иде.

Мин шунда ук ризалашмадым.

– Бу тарихны бездә күбрәк эшләгән галимнәребезнең берәрсе белебрәк язар иде. Минем бит әле, кемдер әйтмешли, башым керсә, аягым кермәгән.

Мөдир бу турыда да уйланган булса кирәк, шунда ук җавабын да бирде:

– Безнең сине егерменче гасыр әдәбиятын укытучы итеп күрәсебез килә. Агымдагы сүз сәнгатебезнең үсеш юлын татар галәмендә беренче тапкыр татар теле һәм әдәбияты кафедрасы булдырылган югары уку йорты тарихын өйрәнүдән башлау һәр җәһәттән караганда да отышлы булыр дип уйларга кирәк.

Алай зурдан кубып әйткәч, нихәл итәсең, килешергә туры килде. «Үткәне данлы, киләчәге матур» дигән мәкалә шулай туды һәм әлеге басмада урын алды (ул вакытта кем уйлаган, «киләчәге матур» дип ышаныч белдерүем генә тормышка ашмас хыял булган икән). Редколлегия утырышында С.Хәким белән Ш.Маннурның да бу язманы кертергә кирәк дип әйткәннәрен ишеттек. Моның сәбәбе дә бар, алар икесе дә сугыштан соңгы елларда шушы уку йортында белем алган затлар. Әдәбиятыбызның әнә нинди зур талантлары үзләренең илһам канатлары ныгуына сәбәп булган уку йортына гомер буе мәхәббәт сакладылар дияргә урын бар. Ш.Маннурны бик белмим, әмма С.Хәким төрле чараларга чакырган саен шатланып килә торган иде.

Әдәбият гаме белән яшәү көннән-көн аның тарихын, төп хасиятләрен тирәнрәк аңлау ихтыяҗын барлыкка китерә. Монда үзеңнең уйлануларыңа, эзләнүләреңә тирә-юнеңдәге башкалар юлыккан тәҗрибәгә һәм нәтиҗәләргә дә таянырга туры килә. Чөнки фән әнә шулай күмәк эш нәтиҗәсендә генә үсә, камилләшә, тулылана бара. Җитмешенче елларда фәнебезне аеруча алга алып китүчеләрнең берсе Нил Юзиев булды. Аның «Әдәбият хәзинәләре» (1978) дигән хезмәте, кайсы яктан алып карасаң да, фәндә гомумиләштерелгән яңа сүз иде. Бер сөйләшкән вакытта Х.Госман әйткән сүзләр колакка эленеп калган. «Хезмәтне язу гына түгел, аның турында белеп фикер әйтү дә мактаулы һәм кирәкле эш», дигән иде ул. Шуны истә тотып, Нил Гафур улының китабына бәяләмә яздым. Бу юлы аны журналның баш редактор урынбасары Әхсән Баяновка кертеп бирдем. Бу язучыбыз, билгеле булганча, фәнни фикерләү ягыннан да шактый югары дәрәҗәдәге каләм әһеле иде. Аңа тартылуым шул сәбәптән булгандыр. Мәкаләм басылып та чыкты. Җитмәсә, шул ук Ә.Баянов алга таба да язгалап тор, дип тә үсендерде. Мондый ягымлы сүз ишетү минем кебек бу даирәдә берниндитаянычы булмаган кешегә бик тә тансык иде.

Шунысы мөһим, басмада эшләүчеләр авторларның нәрсә дә булса китерүләрен генә көтеп тормый, бәлки, үзләре тоткан гомуми юнәлешләргә туры килә торган әйберләрнең язылуын да оештыралар иде. Әйтик, 1980 ел башында тәнкыйть бүлеге җитәкчесе Ринат Мөхәммәдиев миңа Гариф Ахуновның иҗат портретын яза алмассыңмы дигән теләген җиткерде. Әле минем бу жанрга мөрәҗәгать иткәнем юк иде. Г.Ахунов әсәрләрен алтмышынчы еллардан бирле өйрәнеп барсам да, тулаем иҗатын бер хезмәт кысасында бәяләү бик үк җиңел булмады. Ике-өч вариантта язып карадым. Үземчә уңышлы дип тапканын да Р.Мөхәммәдиев шунда ук кабул итмәде, тагын бер тапкыр уйлан әле дип, кире бирде. Шуннан соң гына ул журнал битләренә менде, анда үткәрелгән карашлар әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан кабул ителде.

«Казан утлары»на рәхмәтле булуымның тагын бер сәбәбе бар. Хәер, мин генә түгел,

фән юлына төшкән күпләр журналның бу ярдәмен тоймый калмыйдыр. Мәгълүм ки, диссертация яклауны максат иткән кешенең саллы һәм җитди басмаларда дөнья күргән мәкаләләре дә булу мәҗбүри таләпләрнең берсе, ягъни аның тикшеренү нәтиҗәләре, укучыларның киң даирәсенә җиткерелеп, сынау үткән булырга тиеш. Матур әдәбият, тел, сәнгать һәм рухи тормышыбызның башка өлкәләренә караган хезмәтләрне тудыручылар өчен мондый басма, әлбәттә инде, «Казан утлары». Бу хәзер дә шулай. «Казан утлары»нда басылу – ул инде, совет чорындагыча әйткәндә, хезмәтеңә сыйфат билгесе куелу иде.

Ел саен журналда басылган материалларны тикшерүгә багышланган махсус җыелышлар уздырылып барылуның да әһәмиятен онытырга ярамый. Мондый фикер алышулар әдәби тормышның бик җитди вакыйгалары булып әверелә иде. Ул төрлечә оештырылды. Мәсәлән, 1980 елның февралендә уздырылганын ачканда, Г.Ахунов сүзен болайрак башлады:

– Без бу юлы бер тәҗрибә ясарга уйладык – докладчылар билгеләмәдек. Кем нинди жанр яки аерым бер әсәр турында сөйләргә тели, шул хакта чыгыш ясый.

Залда тирән тынлык урнашты. Бу җайсыз хәлдән чыгарга кирәк иде. Тәвәккәллек күрсәтеп, шул ният белән, мөнбәргә таба атладым. Әйтергә теләгән сүзем хикәя жанрына карый иде. 1979 елда басылган хикәяләрне тагын бер тапкыр күздән кичереп тә килгән идем. Алар арасында Ә.Еникинең «Тынычлану», М.Мәһдиевнең «Таңы ерак төндә», Ә.Гаффарның «Бер йотым су», Ш.Маннаповның «Чехолдагы ракеталар» хикәяләренә мөмкин кадәр сәнгатьчә эшләнеш җәһәтеннән бәя бирергә тырыштым. Азактан төп фикерем шул булды: хикәя жанрында бу кадәр уңышлы ел сирәк була торгандыр. Бу елгыларының һәрберсен, әдәбиятыбызның бер казанышы, сүз сәнгатебез байлыгының югары дәрәҗәсен күрсәтүче өлгесе итеп бәяләргә мөмкин.

Бүген, кырык ел үткәч, моның шулай икәнлеген кем кире кага алыр икән?

Гариф абый җыелышка йомгак ясаганда әйтте:

– Фоат сөйләгәндә, мин президиумнан залны күзәттем. Хикәяләре турында сүз бара торган авторлар һәрберсе залда утыра, зур осталарның күзләренә карап, әсәрләренә бәя бирү шактый авыр гамәл. Күрәбез, алар ул биргән бәяләрне кабул иттеләр, нинди дә булса ризасызлыкларын белдермәделәр.

1980 елдагысы гадәттәгечә уздырылды. Әйтик, тәнкыйть буенча Фәрваз Миңнуллин доклад ясады.Чыгышында миңа да, һәм хуплап, һәм теләкләрен белдереп, аерым өлеш чыгарды. Нәкъ шушы җыелышта (әйтерсең, утызынчы еллар кире кайтты) шактый киеренке хәл дә булып алды. Җәвад Тәрҗеманов яшьрәк каләмдәше Г.Ахуновның «Йодызлар калка» дигән автобиографик повестена карата гадәттән тыш тәнкыйть сүзләре белән чыгыш ясады. Аның төп әйткәне шул булды – Г.Ахуновның шәхси тормышын тасвирлаган әсәрне язарга әлегә башы яшь!

Бу вакытта Гариф абыйга илле биш яшь булган икән. Ләкин инде шактый гыйбрәтле тормыш юлы үткән. Язучылыгы белән бергә илдә сәяси эшлекле буларак та билгеле кеше. Үзенең үткән юлын ил язмышы җирлегендә сурәтләп бирергә дә вакыт җиткән дип санагандыр. Күпләр болар хакында картайгачрак язармын дип, бу эшне артка чигендереп киләләр дә кәгазьгә төшерергә өлгермичә, китеп тә баралар. Ә бу язган, шактый гыйбрәтле итеп, хәтта үзенә тәнкыйть күзе белән карап язган. Әмма Җ.Тәрҗемановка кушылып, тагын берничә язучы үзләренең ризасызлыкларын белдерделәр. Гариф абый, башка хәлләрдә кыю, тәвәккәл булса да, үзен яклап, әлләни әйтә алмады. Газиз Иделле, Атилла Расихлар гына, мондый хәлнең әдәп кысаларына сыймавын әйтеп, җыелыштагы кайнарлыкны бераз сүрелдерә алдылар.

Күрәбез, төп журналыбызда басылган әйберләр һәрвакыт игътибар үзәгендә була килде, бүген дә шулай. Бу аның дистәләрчә еллар буена тупланган абруеннан, басманы тагын да яхшырак, үтемлерәк итеп күрергә теләүдән килә иде. Ул нигезләнүенә йөз ел тулган бу айларда да үзенең сүз сәнгатебез диңгезендә маяк булып калуын дәвам иттерә.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**

# ЯШЬЛЕККӘ ГАШЫЙК ӘДИП

## РӘФКАТЬ КӘРАМИГӘ – 65 ЯШЬ

Мәкаләмнең исемен шулай дип язып куйдым да уйга калдым. Яшьлек – кеше тормышының иң гүзәл, ашкынулы, романтик чоры. Шуңа күрә кулына иҗат каләме алган затларның һәрберсе гомер таңына кагылышлы хатирәләрен, назлы хисләр кичергән мизгелләрен кәгазь битләренә түкми кала алмыйдыр. Кешене образлы фикерләүгә этәрүче көчләрнең берсе дә гомергә җитәрлек хис чыганагы булган мәхәббәт бит. Аның яшьлек чорындагысы аеруча нәфис, кайнар, дәртле булганлыгы белән гомер юлыңның барлык борылышларын яктыртып тора, кешене затлы тойгылар белән илһамландыра.

Ләкин кеше табигать баласы гына түгел. Ул бер үк вакытта социаль яшәешнең үзен әйләндереп алган мохитендә аңа гына хас күңеленә, холкына, эчке инануларына бәрабәр урын били, шул ноктадан җәмгыять белән бик күп мөнәсәбәтләргә керә, үзе дә шуларга хәленнән килә торган нәрсәләрне өсти. Кулында иҗат каләме тотучы бу җәһәттән аеруча киң мөмкинлекләргә ия була.

Сиксән яшьлекләр буыны егерменче гасырның кырыгынчы елларыннан башлап, гаять катлаулы хәл-әхвәлләр кичерде. Башларыбызның күрәчәге әле яңа гасырга тагын да хәтсез булып калган икән. Без моны аерым бер шәхес – язучы Рәфкать Кәрами иҗатында да күрә алабыз. Узган ел 1941 елда туганнар сиксән яшьлекләр капкасын ачып кергәннәр иде. Быел кеше гомеренең менә шушы шактый биек үрен кырык икенчеләр үтә башлады. Алар арасында күңеле белән генә түгел, үзенең тышкы кыяфәте белән дә җегәрле булып күренгән Рәфкать кордашыбыз да бар. 18 февральдән ул да сиксән яшьлекләр исәбендә йөри башлый. Һай, бу гомернең, бармаклар арасыннан коелган ком кебек тиз генә үтә торуына исең китәрлек. 1992 елның 14 февралендә Актёрлар йортында бу каләмдәшебезнең илле яшьлегенә багышланган кичә уздыруыбыз төштә генә булган кебек хәтергә эләгеп калган. Бәлки, үзем башлап йөргәч, оештыру мәшәкатьләре белән дә мәшгуль булгангадыр? Айрат Арсланов, Равил Шәрәфиев, Хәлим Җәләловларнең оста укулары белән язучы каләменең сәнгатьчә камиллеге тамашачыларга зәвык белән ачып бирелгәнгәдер? Ихтимал, моң алиһәсе Флёра Сөләйманова кебекләрнең кичәне җыр белән бизәүдәге маһирлыклары дә сәбәп булгандыр? Ул кичәнең кайбер катнашучылары инде бакыйлыкка күчәргә дә өлгерделәр. Тормыш исә дәвам итә. Гомеребезнең түгәрәк саннары да бер-бер артлы үз нәүбәтләре белән тула тора. Сигез дистә ул инде уен эш түгел. Элек алтмыш яшьне бик зурга санап йөрткәннәр.

Миңа шулай тоела: Рәфкать Кәраметдин улы тормыш юлы башында, ихтимал, язучылык юлыннан кереп китәрмен дип гамьләнмәгәндер дә. Әмма шул ук вакытта күңел түрендә матурлыкка гашыйклык, рухи камиллеккә омтылу булганлыгы бәхәссез. Шулай булмаса, ул – авыл малае, нигә шул вакыттагы күпләрне ымсындырган механизаторлыкка, агрономлыкка, ветеринария белгечлегенә тартылмаган? Сарман районы Рангазар авылында җидееллык мәктәпне тәмамлаган үсмер өчен, шул юлларны сайласа да, табигый булыр иде. Юк, ул Алабуга мәдәни-агарту мәктәбенә бара, һәвәскәрләрнең музыкаль җитәкчесе һәм баянчы булуга өстенлек бирә.

Сүз уңаеннан, әлеге урта-махсус уку йорты турында, берничә җөмлә белән генә булса да, җылы сүз әйтәсе килә. Әле Казанда мәдәният институты ачылганчы,

биредә бик күпләр чын мәгънәсендә сәнгать һәм мәдәният кешеләре булып әзерләнеп чыктылар. Газиз Сөләйманов, Әхмәт Хәйретдинов, Гәрәй Әгъләмов кебек затлы остазлар тәрбияләгән кадрлар, клубларда һәм мәдәният йортларында гына түгел, республикабызның профессиональ коллективларында да талантлы иҗатчылар һәм башкаручылар булып танылдылар. Галим Мансур Хәсәнов, театр артистлары Илүсә Саттарова, Фәез Бәдриев, Рөстәм Муллин, җырчы Вафирә Гыйззәтуллина исемнәре янына тагын бик күпләрне өстәргә булыр иде. Республика радиосында диктор булып эшләгәндә, мин үзем дә Гәрәй Гыйлемхан улыннан алган белем-күнекмәләрдән күп файда күрдем. Р.Кәрами дә – шушы игелекле уку йорты шәкерте.

Ул да баштарак туган районы мәдәният йортында баянчы булып эшли, авыл клубы мөдире дә була. Эшен дә ярата, талантлы яшьләр белән аралашудан тәм-ямь дә таба, әмма… Мәдәният өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хаклары, әбием сүзләре белән әйткәндә, ул вакытларда да бик тә хөрти иде. Моны үземнән дә беләм. Ник дигәндә, илленче еллар ахырында үзем дә авылыбыз клубында хезмәт иттем. Әҗере нибары 360 сум иде, 1961 елда акча алышынганнан соң – 36 тәңкә. Бу – авыл кешеләренең хезмәт көне дип аталган таякка эшләп йөргән вакытлары. Шуңа күрә «кесә тутырып» акча алуыма көнләшеп караучылар да булмады түгел. Әмма яшь кеше ул акча белән генә нәрсә эшли ала? Безнең Рәфкать тә тормышның рухи өлкәсеннән аның тимер-томырлы, мазутлы-дегетле ягына кучүне мәгъкуль күрә – Әлмәткә – нефтьчеләр тарафына юл тота. Монда хезмәтен гади эшче булудан башласа да, тора-бара нинди дә булса белгечлек алуны максат итә – электрик һөнәрен үзләштерә. Таза-сәламәт егетне армия хезмәте дә чыныктыра. Күпләрне ымсындырган Хәрби диңгез флотында кырыс чынбарлык мәктәбе уза. Гомеренең яшьлек таңы дип аталган беренче чорын, әнә шундый баскычлар аша үткән Рәфкать, ниһаять, Татарстаныбызның башкаласы Казанга килә. Ул инде гәүдәгә, килеш-килбәткә дә, күңел дөньясы җәһәтеннән дә чыныккан ир-ат булып өлгергән. Мондый егеткә өстән-өстән генә шомартып эш итү хас түгел, кайда авыр һәм катлаулы – аңа шундый урыннар кызыклы булып тоела. Югыйсә ул беренче белгечлеге буенча, берәр клубта һәвәскәрләр белән эшләү юлыннан да китәргә мөмкин иде. Юк, аңа ирләргә хас җир җимертеп, тир агызып эшли торганы кирәк. Шул омтылыш аны Казаныбызның төньяк-көчыгыш кырыенда җәелдерелеп килүче зур төзелеш – Органик-синтез заводын күтәрүчеләр янына алып килә. Чөнки инде хәзер аның монда яраклы техник белгечлеге дә бар, ул үзен биредә чын мәгънәсендә хезмәт кешесе итеп раслый ала. Шул ук вакытта үз алдына куелган бурычлар өчен генә түгел, төзелешнең гомуми барлыгы белән гамьләнүче, кешеләр белән мөнәсәбәтләрдәге ачыклыгы һәм таләпчәнлеге, шәхес буларак җитдилеге аны алгы планга чыгара – ул төзелешнең профсоюз оешмасы җитәкчелегенә лаек дип табыла. Меңнәрчә кешедән торган коллективта мондый җитәкче булу өчен кырык җирдә кырылып ятучы эшләрнең үзеген табу, шул төп юлдан тайпылышсыз эзлекле бара белү кирәк. Тормыш Рәфкатьне шундый җитәкче итеп тәрбияли. Моңа исә әйләнә-тирәдәгеләрнең күңел дөньяларын, ниләр белән сулаганнарын, эшкә-тормышка карашларын белмичә, өйрәнмичә ирешеп булмый. Бу хактагы уйланулары әкренләп, күңелдән кәгазьгә күчә бара. Ул үзе көн дә аралашып, хезмәттәш, фикердәш булып яшәгән кешеләр турында мәкаләләр, ә инде каләме бераз шомара төшкәч, очерклар яза башлый. Сан сыйфатны барлыкка китерә дигәндәй, тора-бара каләм очыннан хикәяләр дә төшә башлый. Читтән торып, Казан дәүләт университетының тарих бүлеген тәмамлавы да аның карашларын киңәйтеп җибәрә (Юкса, ул инде бу яңа мохиттә инженерлык сукмагына да кереп китәргә мөмкин иде. Юк, һаман да гуманитарлыкның тарту көченнән арылып китә алмый). Бу хәл аның укучыларга үз сүзен әйтүгә булган теләген тагын да көчәйтеп җибәрә. Шуның белән яшәешенең тәкъдир тарафыннан билгеләнгән эзенә кайтып төшүе тәэмин ителә – ул рухи катламда яшәү юлына кабат килә һәм инде бу юлы гомерлеккә. Мәскәүдә өч еллык Югары әдәби курсларда укуы

да аның әдәби иҗатны төп кыйбла итеп каравын раслый иде. Хикәяләр артыннан «Дүрт кешелек каюта», «Кичке уйлар», «Капитан Хәкимов» кебек повестьлары аның сүз сәнгате өлкәсенә кыклап килгәнлеген күрсәттеләр.

Язучы – каләм көче белән яңа дөнья тудыручы. Ләкин ул, бик теләсә дә, үзе үткән юлдан, көн иткән даирәсеннән, тормыш тәҗрибәсеннән аерылып бетә алмый. Бу – Р.Кәрами иҗатында да шулай (Бары тик «Каргышлы этаплар» романы гына моннан чыгарылма дип карала ала). Аның нефтьчеләр арасында, армиядә, төзелештә үткән еллары нигездә үзедәй яшьләр арасында, алар тормышы белән яшәп үтә. Бу тәэсирләр исә иҗаты өчен гомер буена җитә дияргә була.

Мин үзем аның иҗатына Оргсинтез заводын төзүчеләр турындагы трилогиясе языла һәм укучыларга җиткерелә башлагач игътибар иттем кебек. Бу җитмешенче еллар ахырына туры килә. Исеме дә романтиклыкка ишарә иткән «Очар кошлар белән янәшә» дигән беренче кисәге (1978) күңелне үзенә бәйләп куйды. Аннан соң әсәрнең икенче, өченче кисәкләрен дә көтеп алдым. Ихтимал, алар бүгенге укучыны дулкынландырган нәрсәләргә күпмедер туры килеп тә бетми торганнардыр. Әмма ул елларның күп кенә якларын танып-белү җәһәтеннән бу әсәрләрнең әһәмияте әле дә җуелмаган. Ник дигәндә, алар шул чорларда хакимлек иткән идея-эстетик таләпләрне исәпкә алып иҗат ителгәннәр. Кеше күңеленең яхшылыкка, әхлаклылыкка омтылышы, шул юлдагы маҗаралар мохитендә сурәтләнгән хәл-әхвәлләр бервакытта да искерми. Тәрбия мәсьәләләренә игътибар кимеп, кешене кесәсендәге акчасына карап бәяләү гамәле урнаша килгән бүгенге заманда да инженерның, укытучының, табибның, икмәк пешерүченең эшен ничек башкаруына битараф түгелбез. Димәк, хезмәткә караш – кешенең ниндилеген күрсәтүче ачкыч булып тора. Р.Кәрами трилогиядә нәкъ шушы нигез-фикерне үзәккә куя да.

Әсәрнең үзәгендә унҗиде-егерме яшәр Гөлүс исемле егет язмышы торса да, автор бу героеның үсеш-үзгәреш юлын шактый катлаулы хәл-әхвәлләр барышында һәм күпләр белән багланышларда тасвирлый. Бу хәл исә сюжетның тармаклануын тәэмин итә, димәк, әсәр тукымасына күп кенә язмышлар чигелә. Яшьлек – төсләр балкышыннан, ашкыну-канатланулардан, мәхәббәткә кагылышлы тирән кичерешләрдән башка була алмый. Р.Кәрами әсәрләрендә боларның барысы да бар, нәкъ менә шулар укучыны мавыктыра да.

Автор, әлеге унъеллыкларга хас булган «коммунистларча хезмәт», «социалистик ярыш», «комсомол намусы» кебек сүзтезмәләрне кулланса да, алар әсәрдән килеп чыкканча, кешеләрнең эш-хәрәкәтләрендә әлләни урын ала алмыйлар, бәлки, формаль нәрсәләр икәнлекләре ул елларда ук әллә кайдан күренеп тора, һәрхәлдә авторның объектив сурәтләвеннән шул аңлашыла. Бу инде җәмгыятьтә әлеге ялтыравыклы күренешләргә булган карашларның үзгәрә бару галәмәтләренең үзләрен сиздерә башлаган чор иде. Р.Кәрами моны шулай ук сизгер тотып ала алган. Мәсәлән, әсәрдә сурәтләнгәнчә, төзелеш идарәсе җитәкчесе Ислам Мәхмүтов өчен дә фирканең әһәмияте кими башлаган. Әйтик, әлеге җитәкченең оешмадагы бюро утырышына соңга калып килүе аның бу өскормага салкын мөнәсәбәтен күрсәтә. Коллектив алдына үтәве мөмкин булмаган бурыч куеп маташкан өстән килгән партия вәкилен сүгеп ташлавы әле бер-ике ел элек кенә коточкыч гамәл булып бәяләнер, шуңа җөрьәт иткән җитәкче, фронтлар аша үткән зат булса да, ике аягында басып кала алмас иде. Мәхмүтов исә белер-белмәс акыл сатучыга әнә шундый «көферлек» белән җавап бирә.

Әлбәттә, бу рәвешле тәртәгә тибү эзсез генә калмый, шул ук көнне трестта, шушы хәлгә бәя бирү өчен фирканең тагын да югарырак органы – комитет утырышы чакырыла. Мәхмүтовның хаклы икәнен белсәләр дә, аңа шелтә чәпелә. Эш аның белән генә дә бетми. Главка начальнигы Кабышевны да әлеге баш күтәрүчене тәртипкә чакыру эшенә тарталар. Тик аның Мәхмүтовны кыздыруы өстән кушу буенча гына булганлыгы әллә каян күренеп тора. Ул дөресендә әлеге җитәкченең эшне яхшы белүен, коллективта абруе зурлыгын, бу очракта хаклы икәнлеген күреп тора. Чөнки

бу матавыклар бер карьеристның Мәхмүтов урынын алырга омтылуы сәбәпле килеп чыгуын чамалау кыен булмый. Ахыр чиктә Мәхмүтов идарә башлыгы буларак сакланып калына.

Р.Кәрами биредәге шуңа охшаш хәл-әхвәлләрне нечкәләп белә. Бигрәк тә урта һәм түбән буын җитәкчеләренең тиешле әзерлекләре булмау, сызымнарны грамоталы укып, дөрес итеп төзи алмаулары, ваемсызлык аркасында брак җибәрүләре, бер төзегәнне җимереп, яңадан күтәрүләре, кешеләрне ял көннәрендә дә эшләргә мәҗбүр итүләре, тик торуларның булуы, өстәп язулар – болар һәммәсе бездәге «планлы» хуҗалык итүнең гадәти «өстенлекләре» икәне күренә. Шуңа тагын, төркемнәргә берләшеп, урлашу, агай-эне ак мыек, бер-беребезне какмыйк дип, әшнәләнүләрне дә өстәсәң, хәлнең тагын да катлаулы булуы раслана. Төзелеш җитәкчелегенең бюрократлашуы шул дәрәҗәгә җиткән, корылмадагы иң җаваплы һәм нечкә эш – реакторны урнаштыру вакытында түрәләр һәм белгечләр киңәшмә уздырып утыралар. Бездә һич кирәкмәгәнгә сүз боткасы болгату эш эшләү, дип атала иде шул. Бу каләмдәшебезнең чынбарлыгыбыздагы тискәре якларны рәсми идеологиягә каршы барып күрсәтүенә сокланырга гына кала. Романның «эш сызыгы» әнә шундый уйлануларга этәрә.

Заманында Р.Кәрами бу циклын социаль заказ белән язган, дигән сүзләрне дә ишеткәләргә туры килде. Мондый хөкем чыгару әлеге әсәрләрне тәфтишләп укымаудан, күзгә бәрелеп торган урыннарын да күрмәмешкә салынудан гына килә иде. Менә без күрсәтеп үткән шул заманга хас узынулар һәм җитәкчелектәге валюнтаризм күренешләрен искәртү үзе генә дә Р.Кәрами каләменең фирка кубызына тибрәнмәгәнен күрсәтә иде. Ихтимал, аңа сурәтләүдә колачлылыкның җитмәве бераз комачаулык та иткәндер. Әмма авторның авыл яшьләренең шәһәрләшә бару хәрәкәтен, тормышта үз урыннарын табу юлындагы эзләнүләрен күрсәтеп бирүне максат итеп тудырган әсәреннән төзелештә инкыйлабый хәлләр куеруын җәелдерүне күрергә теләү үзе табигый булмас иде. Һәрнәрсәнең үз җае, үз урыны бар. Шуңа күрә биредәге хезмәт мәйданында үз урыныңны табу, булдыклылыгыңны раслау, мәхәббәт, гаиләле булуга омтылыш мәсьәләләренә бәйле сызыкларның уңышлы гәүдәләнеше трилогиянең тәэсир көчен арттыра. Һәркем ярата, ләкин үзенчә ярата. Зиннәт белән Тәскирә арасындагы гашыйклык отыры көчәя генә барса, Гөлүс белән Миләүшә яшьлеккә хас үпкәләшеп алулар аша да үтәргә тиеш булалар. Татар егете Илфирнең Ярославльдән килгән рус кызы Галяга өйләнүенең нигезендә дә мәхәббәт ята дип уйларга кирәк. Әмма хатынының «татарча телсезлеге, гореф-гадәтләребезгә илтифатсызлыгы» да күренеп кала. Алга таба бу пар ничек яшәп китәр иде – билгесез. Илфирнең якын-тирәдәгеләрнең гомерен саклап калу бәрабәренә һәлак булуы моңа чик куя. Аның батырлыгын Р.Вәлиевнең «Яшисе килә» повестендагы Рифкать Миргазизов каһарманлыгы белән янәшә куеп карыйсы килә.

Яшьләр арасында да төрлесе бар. Кешеләргә акыл өйрәтеп, тол калган Халидәне күңел ачу максатларында файдаланучы комсомол сәркатибе Әзһәм, хезмәт урыныннан файдаланып, яшь кызларны мәсхәрә кылучы Җиһангирлар, үз рәхәтлекләреннән баш тартып, башкалар өстенә кояш чыгарырга сәләтлеләр дияргә өмет юк. Димәк, әхлаклылык белән гамәл үзара шулкадәр керешкәннәр, алар еш кына бер-беренең алшарты булалар, кеше холык-фигыленең асылын тәшкил итәләр.

Р.Кәрами боларны гыйбрәтле язмышлар мисалында күрсәтеп биргән. Шуларны җанлы гәүдәләндерүдә табышлар булмаса, әсәрләрнең сәнгатьлелеге нык кимер иде. Әле болай да анда очеркны хәтерләткән, төзелеш нечкәлекләре белән мавыгылган урыннар очрап тора. «Ашкыну» дип аталган икенче кисәге, мәсәлән, шул сәбәпле, гомумән, авыррак укыла. Әмма бу әле иҗат тәҗрибәсе җитмәүдән килә иде. Заманында мин әлеге әсәргә багышланган бәяләмәмне авторга тормышны кыюрак, тирәнрәк һәм сәнгатьлерәк сурәтләүдә уңышлар теләп тәмамлаган идем. Аннан соңгы иҗатында Р.Кәрами каләме бу юнәлештә сизелерлек камилләште, дип раслый алам. Монысы – иң мөһиме.

Язмабызның тар мәйданында каләмдәшебезнең бай иҗатын иңләүне максат итү колач җитмәслек мәһабәт тирәкне кочагыңа сыйдырырга азаплану кебек кабул ителер иде. Р.Кәраминең каләм тибрәтүче буларак тагын бер бәхете бар, аның иҗатына, көне-сәгате белән дигәндәй, башлангыч чорыннан алып, Г.Әпсәләмов, Б.Камалов, Т.Нурмөхәммәтов, М.Вәли-Барҗылы кебек остазлар игътибар итеп бардылар. Алда искә алынган повестьлары өстенә «Сагышлы кояш», «Ындыр тулы кибән», «Мәхәббәт бураннары», «Йөрәкне ут алган» һәм башка әсәрләре хакында һәм уңай һәм тыенкырак фикерләр мәйданга чыга торды. «Өзелгән чәчәк» дигән хикәяләр җыентыгы исә аның бу жанрда да уңышлары шактый саллы булганлыгын раслады. Боларны искә алып кына үтеп, Р.Кәрами иҗатында, кайсы җәһәттән карасаң да, аерым урын алып торучы романы турында сүз кузгатасы килә. Ул да булса «Каргышлы этаплар» (баштагы исеме «Каргышлы юллар») романы хакында. Мин аңа карата язган бәяләмәмне «Миллионнарның берсе турында кыйсса» дип атаганмын. Бу очраклы түгел. Белгечлеге буенча тарихчы булган Р.Кәрами әсәрне нык әзерлек белән язган. Романда утызынчы еллардагы фаҗигаләрнең аянычлылыгын дәлилләгән бик күп мәгълүматлар тупланган. Шулар арасында күңелне иң тетрәткәне менә будыр: 1935 елдан алып сугыш башланганга кадәр булган 5-6 елда илебездә 19 миллион 840 мең кеше кулга алынган, шуның 7 миллионы һәлак ителгән. Әлеге бәхетсез кешеләрнең кем булуларын тәфтишли башласаң, исең китәр: хәрби һәм гражданлык өлкәсе җитәкчеләренең, төрле белгеч-инженерларның, галимнәрнең, язучы-шагыйрьләрнең, башка иҗат кешеләренең иң талантлылары, иң эшлеклеләре! 9 Май бәйрәме көннәрендә уйлап куям: илнең барлык тармаклары, шул исәптән армиясе дә кансызландырылган безнең ил кешелек тарихындагы иң явыз көч булган фашизмны ничекләр итеп җиңә алды икән? Сугыш кырларында өстенлек алуыбыз ничә миллион корбаннар бирелү бәрабәренә дип, әле бүген дә кистереп кенә җавап бирә алмыйбыз бит. Автор укучыларын әнә шулар турында уйландыра.

Р.Кәрами әсәрендә гап-гади тормыш алып баручы кешеләрдән ничек итеп «халык дошманнары» ясалуын күреп торабыз. Мотаһир Нәбиуллин дигән кешене кулга алырга килгән «кара козгын»дагы явыз бәндәләр, аны өйдә туры китермәгәч, шундый ук исемле Фәрукшин дигән фамилияле кешене төрмәгә алып китеп ябалар. Ягъни аларга, баш саны булгач, шул җиткән. Бер-беренә карата кайнар ярату хисләре белән яшәүче ир белән хатынны бер дә юкка һәлакәткә дучар итәләр. Мәхәббәт җимеше булган малайлары ятим кала. Ун елга сузылган мәхшәрнең бөтен ачысын башыннан кичергән Мотаһир, бәхеткә, кешелек сыйфатларына зыян китерми. Рухын бөтен итеп сакларга аңа мәхәббәте көч бирә.

Болар Р.Кәрами туганчы булган хәлләр. Ягъни бу гаделсезлекләрне ул үз башыннан кичермәгән. Ләкин язучылык таланты аңа үзе күрмәгәннәрне дә булганынча, җан тетрәтерлек итеп сурәтләргә ярдәм иткән. Романда җан тетрәткеч итеп гәүдәләндерелгән хәл-әхвәлләр укучыны биләп ала, ул Мотаһир кебекләрне язмыш тагын нинди ярларга алып чыгар дип хәвефләнә. Автор каһарманнарының күңел дөньяларын ачып бирүнең төрле ысулларын файдалана. Вакыйгаларның башланып китүен сурәтләгән сәхифәләр, ягъни сюжетның төенләнеше аеруча тетрәндерә. Гаилә әле генә мунчадан кайткан. Ир белән хатын һәм өч яшәр малай. Парланган, эсседән изрәгән тәннәренә сихәт бирә торган чәй эчәргә генә ниятләгәндә, өйләренә, кулларында наганнарын уйнатып, милиционерлар бәреп керә. Менә шушы контрастлык бу көтелмәгән хәлнең киеренкелеген үтә көчәйтеп җибәрә. Һәм шушы халәт укучыны китапның соңгы битен ябып куйганчы дәвам итә. Тәнкыйтьче Мансур Вәли-Барҗылы романнан алган тәэсирләрне менә ничек язып куйган иде: « Аны чын әдәбият әсәре буларак, онытылып, бирелеп укыйсың. Алга таба, бәлки, үз чорыбыз тормышыннан да менә шушындый әйбәт роман иҗат итәр безнең бу язучыбыз?» *(Вәли М. Каргышлы еллар... // Казан утлары. – 1996. - № 8. – Б. 174).*

Р.Кәрами бу өметне аклады. Егерме беренче гасырга кергәч, әдәбиятыбызга тагын

бер трилогия тәкъдим итте. Ул «Олы юл да сикәлтәле» дип атала. Аның баш герое Габделнур, сугыш елларында туып, аннан соңгы унъеллыкларда дөньяга күзен ачкан, тормыш юлыннан атлап киткән чор буыны егете. Безнең күз алдына ул үзенең холык-фигыле, бигрәк тә менә нәкъ алтмышынчы елларда формалашкан күңел дөньясы белән килеп баса. Укучы шуннан соңгы дәверләрне аның күзаллавы аша һәм бәяләве эзлеклелегендә кичерә бара. Халкыбызның сәламәт яшәү мохитендә тәрбияләнгән егетнең уйланулары, теге яки бу хәл-әхвәлләргә мөнәсәбәте ачык аңлаешлы. Шуңа күрә укучыларыбызның хәзерге буыны трилогия белән танышудан үзенә күп мәгънә таба, ачышлар ясый, параллельләр үткәрә. Яшьрәкләргә исә әсәр егерменче йөзнең икенче яртысы чолганышындагылар күңелендә барган хис-кичерешләрне аңлауның билгеле күләмдә ачкычы булып хезмәт итәчәк. Әйтергә кирәк, алар бер дә тискәре нәтиҗәләргә килмәс, күңелләрен Габделнурларның кордашларына карата уңай карашлар белән баетырлар, әхлаклы яшәешкә, игелеклелеккә кеше үз кул көче, әйләнә-тирәдәгеләргә игелекле мөнәсәбәт күрсәтүе ярдәмендә ирешергә тиеш дигән уй белән калырлар. Ник дигәндә, әсәрдә тәрбия үрнәге бирүнең мөмкинлекләре бик иркен файдаланылган. Габделнурдан кала Шәмсун, Дөбәрис, Фәнсит (исемнәре дә исемнәре!) һәм башка яшьләр тормышларын намуслы юл белән матурлау омтылышлары белән яшиләр.

Шунысы да бар, хәзерге вакытта матур әдәбиятның тәрбияви әһәмиятен кире кагучылар да очрап тора. Әйтик, безнең илдә шагыйрь булып танылган берәү хәзерге вакытта Израильдә яшәсә дә, әсәрләрен рус телендә иҗат итә. Ул, укучылары белән очрашу, китапларын бастыру мәсьәләләрен хәл итү өчен, еш кына Россиядә дә була. Бер кайтуында радиодан да чыгыш ясады. Аның бер җөмләсе мине уйландырды. Үзен каләм әһеле дип йөрткән бу әфәнде: «Әдәбият һич тә тәрбияләргә тиеш түгел», – диде. Алай икән, нигә әсәрләреңне кешеләргә тәкъдим итәргә? Язганда ук нинди дә булса фикереңне, карашыңны башкалар белән бүлешүне, аларга тәэсир итүне күздә тотмаган китабыңның җәмгыятькә нигә кирәге бар? Р.Кәрами исә, җитди әдәби традицияләрдә иҗат итүче буларак, язучының халык алдындагы җаваплылыгын бик яхшы аңлап эш итә.

Укучыга шактый катлаулы, уңай һәм тискәре сыйфатлары белән тәкъдим ителгән Габделнур образы автор иҗатында гына түгел, тулаем әдәбиятыбызда нинди урын алыр? Моңа кистереп кенә җавап биреп булмыйдыр. Чөнки бу образны бәяләүгә бер үлчәм белән генә якын килү шактый кыен, Габделнур күз алдына бөтен каршылыклары белән килеп баса.

Тәүге адымнарын намуслы рәвештә башлаган, яшьтән үк чын сөюнең тәмен аңлаган, шул ук вакытта үзенә карата хыянәтнең ни-нәрсә икәнлеген күргән, шуның ачысын бөтен күңеле белән татыган, тора-бара интим мәсьәләләрдә шактый тотнаксыз булып киткән Габделнур тормыш диңгезендә үз-үзен ничек тотар да кайсы ярга килеп бәрелер дип, укучы һаман әсәрнең эченәрәк кереп баруын сизми дә кала. Төп герой юлында очраган яшьләрнең һәрберсе турында диярлек холык-фигыльләренә хас гамәлләрен, яшәү рәвешләрен, авторның аларга карата булган мөнәсәбәтенең тәфсилле күрсәтеп барылуы да заман кешеләренең аерым-аерым гына түгел, бәлки, гомуми сыйфатларын да ачарга ярдәм итә. Тагын да дөресрәге, әсәр алтмышынчы-җитмешенче еллар яшьләренә хас яшәү рәвешенең чынбарлыктагы шактый камил чагылышы булып чыккан. Г.Ибраһимовның «Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек» дигән мәгълүм сүзләре әсәргә мәгънәле эпиграф булып хезмәт итәр иде.

Чыннан да, Габделнур безнең буын кичкән баскычларының барысын да табигый рәвештә һич авырсынмый уза. Тормыш борылышларының һәр этабының кызыклы якларын таба, аларны мөмкин кадәр романтикларча күтәренке күңел белән җиңеләйтергә омтыла. Акыл утырткан егет буларак, иптәшләре арасында абруй казанган. Юк, ул фәрештә түгел, кеше кыланганнардан ул да читтә калмый. Рәхимсезлек күрсәткән бәндәләргә шундый ук юл белән җавап бирерлеге дә бар. Үзенә кул күтәрергә җөрьәт иткәннәрне гомерләренә онытылмаслык итеп тәпәләп ташларга да хәленнән килә. Хокук

белгечлеге алырга хыялланып та, халкыбызның үткәннәре белән кызыксына башлавы аны тарихны өйрәнү юнәлешенә алып кереп китә. Төзелештәге куркынычсызлык хезмәте җитәкчесе Шәйгазамов кебекләрнең очраган саен күңеленә халкыбыз өчен яну кебек затлы фикер орлыклары сала торуы да эзсез калмый. Ул бәян иткәннәр «университет курсында, лекция һәм семинар дәресләренең берсендә дә юк. Алар аның өчен яңалык иде. Әллә кайчан юкка чыккан Урарту, Ассирия дәүләтләре, Рим империясе тарихын укып-ятлап «койрык» калмасын дип тырыша, ә үз халкы тарихы... читтә кала бирә». Болар совет чорында тарих фәненең асылын күрсәтә торган яклар. Мондый шартларда Шәйгазамов дигән элекке офицер әле алтмышынчы-җитмешенче елларда ачыктан-ачык сөйләшергә ярамаган нәрсәләр турында да яшь коллегасы белән, ышаныч күрсәтеп, күңелендәгесе белән уртаклаша. Шул ук вакытта аны кисәтергә дә тиеш таба: «Бөтен белгәнеңне һәрчак әйтмә, әмма һәрчак ни әйтергә икәнен бел!»

Шулай да Габделнурларның аңлы яшьлеге «җепшеклек чоры» һәм шуннан соңгы елларга туры килде. Хәзерге либераллар «торгынлык чоры» дип атаган бишьеллыклар дәресендә илнең ныгуы, халыкның тамагы туйганчы ашау мөмкинлеге тудырылган, иртәгәге көнгә хәвефләнүе булмаган дәвер иде. Бу исә кешеләрнең күңел дөньясында, үз-үзләрен тотышларында да күренә. Эшлиләр, төзиләр, бер үк вакытта шәхси тормышларын да җайлап баралар, бушлай фатирлар алалар, хезмәт баскычларыннан күтәреләләр, балалар үстерәләр, уку, медицина ярдәме бушлай... Габделнур да, өйләнеп, үз куышын булдыра, шәһәр үзәгендәрәк тагын да яхшырак фатир алуга ирешә. Тормышы түгәрәкләнә, эшнең дә тынычрак, төшемлерәк булганына урнаша.

Шул рәвешле, уңган-булган, белемле, татар җанлы бу кеше үзгәртеп кору елларына тормышы түгәрәкләнгән, җаны тыныч булган гап-гади йорт-җанлыклы кеше булып килеп керә. Яңа шартларда да аның күңелендә әле сизелерлек үзгәрешләр күренми. Казанга кунакка килгән әтисен Мәрҗани мәчетенә җомга намазына алып килә килүен, тик аны эчке якка кертеп җибәреп, әлегә үзе ишекнең тышкы ягында кала. Шул ук Шәйгазамовның яңа чорда беренчеләр рәтендә хаҗ сәфәренә китүен күреп, дөнья үзгәрешенең үз даирәсенә шактый ук якын килгәнен дә абайлый. Әмма укучы Габделнурның күңел тынычлыгы артык бозылмавына игътибар итми калмый. Дөрес, утыз ел табынып яшәгән партиясе дә таралгач, аптырап кала калуын. «Хәзер нәрсәгә табынырга? Алда ни көтә?» дигән сораулар аның да аңына барып җитә. Җавабын да таба шикелле: «Бәлки, үз халкың турында борчылырга вакыт җиткәндер?» Шуларга өстәп әйтеп куясы килә: болай акрын кыймылдаса, гомер юртагыннан читтә салулап калырга да мөмкин бит! Әлегә Габделнур кайнар митингларга йөрүче, өздереп чыгышлар ясаучы, халыкны үзе артыннан барырга өндәүче түгел. Ләкин башына мөстәкыйль рәвештә шундый уйлар килгән икән, тора-бара ул да гомуми агымнан читтә калмас, милләтебез гамьнәренең асыл мәгънәсен аңлый торган кеше булырга мөмкин дип ышанасы килә.

Әйе, олы юлның да төрле борылышлары, сикәлтәләре була. Габделнур да яңа борылышларда халык белән бергә булыр кебек. Аның сыман күп нәрсәләрне яңача аңлый башлаучылар, шуңа омтылучылар күбрәк. Тормыш барышы мондый хәрәкәтнең көннән-көн киңрәк җәелүенә китерә. Бу беренче карашка үзен сиздерми торган аң хәрәкәте кешеләрнең үзләрен дә күп яктан үзгәртә. Р.Кәрами шушы барышны эзлекле бирүе белән бик әһәмиятле эш башкара. Аның тулаем иҗатын да егерменче гасыр татар яшьләре дөньясындагы үсеш-үзгәрешләрне эзлекле рәвештә бөртекләп, сәнгатьчә өйрәнүгә багышланган дип әйтергә буладыр. Димәк, каләме белән ул заманыбызны образлы танып-белүгә даими өлеш кертеп яшәгән дигән сүз. Бу инде иҗади шәхес өчен аз түгел. Моның алга таба да дәвам итүен теләргә генә кала.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**

# ЗАМАНА ШАГЫЙРЕ

## РАФИС КОРБАНГА – 65 ЯШЬ

Һәрбер чорның кабатланмас үзенчәлеге: өмет-шатлыклары, борчулары, гөнаһсыз сабыйлары, гайрәтне чигергән үсмерләре, күңелне канатландырган омтылышлары, жанны шомландырган жиңелүләре, жаваплы бурыч-вазифалары, үтәлми калган үкенечле вәгъдәләре, сукмак ерып барган каһарманнары, арттан сөйрәлүче гамьсез гавам... кыскасы, үз табышлары һәм үз югалтулары була.

Җәмгыять артыннан тагылып, тузанлы такыр юлдан көчкә-көчкә өлгереп баручы замандашларыбыз турында ниндидер берәр яңа сүз әйтү ифрат та кыен булыр иде, әмма каләмдәшебез Рафис Корбан, бәхетебезгә – мондый типларның нәкъ киресе. Аның белән бергә утыз ел буена аралашып-дуслашып яшәгән кешегә бу яктан бик җайлы: биографиясендәге ул кылган гамәлләрне гади санап чыгу гына да әдип хакында тулы бер романлык материалга тиң. Инде әлеге шәхеснең эчке дөньясына кереп, аның уй-фикер сөрешен, кичерешләрен, көндәлектә җилләп-давыллап, һәр сәгатьтә үзгәреп-кайнап торган самими хис-тойгы, эмоция тирбәлешләренең җанлы шаһиты да булсаң, үзеннән-үзе аңлашыла: эш бер-ике роман белән генә чикләнмәячәк... Бу очракта әдәбиятның бөтен жанрларын да үзенә иңләп алган, аз дигәндә, саллы җиде томлык иҗат материалы турында сүз алып барырга туры киләчәк.

Р.Корбан – тумыштан, табигатеннән шагыйрь. Тормыш-яшәешендә дә, артык түгел, ким түгел дигәндәй, ул – нәкъ шундый. Аның әледән-әле үзгәреп, яңарып торган яшәү планнары белән килешергә була, килешмәскә була, сөенергә, бәлки, кайчак уфтанырга да мөмкиндер... Әмма бер нәрсәгә инанмыйча калмыйсың – ул һәрвакыт үз-үзенә тугрылыклы, аның үз интуитив тойган хакыйкать, дөреслек кыйбласы бар. Рафис тынгысыз, ашкынучан, туктаусыз алышынып торган хәрәкәт стихиясенә бирелеп, үзенә якын да, ят та булган четерекле, катлаулы тормыш эченнән үз рухи кыйммәтен табарга омтыла – яңа дөньялар, дуслар, проблемалар, гаделлек эзли.

Р.Корбанның мәктәп һәм университеттан соң, ике дистәләп, төрле җаваплы эш вазифаларын башкарып та, төрле жанрлардагы иллеләп китап чыгарып та, алтмыш биш яшенәчә, нигездә, балалар, үсмерләр, яшьләр әдибе, аннан да бигрәк, нәниләр шагыйре булып калуы да шулай ук күп нәрсә хакында сөйли: аның холкы, яшәү рәвеше, тормыштан чын иҗат ләззәте ала белүе турыдан-туры шушы эчкерсез сабыйлык табигате белән бәйле.

Рафис гомер-гомергә үзеннән өлкән яшьтәгеләр белән аралашырга ярата. Ярата гына түгел, алар белән ул тизрәк уртак тел таба. Үз итә, аларга тиңе кебек син дип эндәшә. Сабыйлык дөньясының өлкәннәр тормышына даими бер тартылуымы икән инде бу, олы тормышның бүлгәләнмәгән-вакланмаганлыгын, бербөтенлеген күрергә теләвеме? Әллә күбрәк кыен ашаганнар янында булу үрнәк алу, гыйбрәт алу, җитдирәк проблемалар кузгату, зур иҗатка рухлану өчен ансатракмы – белмәссең. Бу хакта ул шигырьләрендә дә тукталып уза: янәшәсендә иң якын дуслары, яшьтәшләреннән дә бигрәк – шул картлачлар! Үземчә моның бер серен ачтым да кебек: миңа калса, өлкән дуслары Рафисның игелекле эш-гамәлләрен күпкә фәлсәфирәк бәһали, аның юмарт җанын күпкә нечкәрәк, тирәнрәк аңлый. Янында мондый дуслар булудан да зуррак бәхет бармыни?!

Һәр эшен булсын дип, чын ихластан башкаруы аның Язучылар берлеге рәисе булып эшләгәндә дә, кат-кат чагылыш тапты югыйсә. Дөрес, аның бу игелекле гамәлләрен күрердәй каләмдәшләре бүгенге кыбырсык заманда азрак булып чыкты. Кардәш

төрки әдипләр белән үзара аралашу, тәрҗемә эшләрен җайга салуны да, яңа милли геройларыбызга багышланган әдәби әсәр-хезмәтләр яздыру өчен каләмдәшләренә акча табуын да, хәтта бүгенге көн татар әдәбиятының горурлыгы булган Ш.Галиев, И.Юзеев, Т.Миңнуллин, А.Тимергалин, Зөлфәт, М.Әгъләмов, Р.Бохараев, Роб. Әхмәтҗанов, Ә.Гадел, В.Корчагин, Д.Гыйммранова, Ф.Латыйфи, Г.Садә, М.Юныс каберенә аларның шәхесенә лаеклы затлы кабер ташы куюны да Язучыларның исәп-хисап җыелышы «Безнең шәһәрнең серләре» спектаклендәгечә: «Отказ!» бәясе белән тамгалады. Әмма Рафисның мондый фани дөнья исәп-хисапларыннан күпкә өстенрәк торган игелекле эшләре, Ходайга шөкер, һәр туган яңа көндә эшләнә тора. Бу аның рәсми эш хакы өчен, файда алыр өчен, хисап өчен кылынган гамәле түгел, бу аның – табигый үз эчке яшәү ихтыяҗы. Артта калган кырык ел эчендә ул башкарган эш-вазифаларны бәрәмтекләп карап чыктым. Аларның һәрберсендә шигъри җан эзләнүе, милли фидакарьлек очкыны дөрләп калган. Ниһаять, соңгы дүрт елда басылган дүрт романы, быел ябык конкурста җиңеп чыккан – «Казан» поэмасы безгә аның тагын бер гаять кыйммәтле сыйфатын – шагыйрь күкрәгендә гаделлек утының (бу милли республикабыз җитәкчелегеннән башлап, барча әдипләребезгә, хәтта классик шагыйрьләребез иҗатына кадәр бердәй карый), хакыйкать эзләү ялкынының тагын да яктырак булып кабынуын күрсәтте. Милләт язмышы хәл ителгән бүгенге шыксыз, караңгы елларда кәгазьдә генә түгел, көндәлек яшәешебездә, заман көрәшендә шагыйрьлек утының балкып януы, һичшиксез, бермә-бер әһәмиятлерәк!

Татар әдәбиятының ике гасыр арасы чоры тудырган киң колачлы шәхес, күпкырлы әдәби талант ияләре арасында Рафис Корбан исеме бүген аерым бер урын алып тора. Аның лирик, эпик һәм публицистик шигърияттә, шигъри тәрҗемәләр өлкәсендә, балалар поэзиясендә, нәниләр драматургиясендә, яңа заман прозасында, публицистикада, бүгенге иҗтимагый һәм әдәби хәрәкәт үсешендә сизелерлек йогынты ясаган җитди иҗади казанышлары, Язучылар берлеге оешмасы эшен оештырудагы бәхәссез уңышлары, игелекле гамәлләре, каләмдәшләре арасында абруй яулаган кабатланмас үз йөзе бар.

***

Рафис Харис улы Корбанов 1957 елның 1 гыйнварында Татарстанның Дөбъяз (хәзерге Биектау) районы Кече Битаман авылында крәстиян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылында ала, аннары күршедәге Олы Битаман авылында урта мәктәпне тәмамлагач, 1974 елда Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга килә. 1977 елда университетның өч курсын тәмамлап, «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясендә, аннан Буага китеп, ике елдан артык «Байрак» исемле төбәк газетасында эшләп ала. 1980 елдан ул янәдән Казанда: шәһәрнең автозаправкалар идарәсендә рәссам, 1982 – 1989 елларда Татарстан радиокомитетында эшли. 1989 елдан соң төрле газета-журнал редакцияләрендә – «Салават күпере»ндә, «Идел»дә, «Әдәби җомга» газетасында, Татарстан язучыларының Әдәби фонды идарәсендә, төрек-татар газетасы «Заман»да, «Шәһри Казан»да төрле вазифалар башкара, Казан дәүләт курчак театрының әдәби бүлек мөдире, «Мәгариф» китап нәшрияты әдәбият һәм балалар әдәбияты редакцияләрен җитәкли. 1996–2008 елларда Р.Корбан Татарстан китап нәшриятында китап тарату бүлеге мөдире, редактор, редакция мөдире, баш мөхәррир вазифаларын башкара. 2009 елдан шәхси эшмәкәр, 2012 елдан 2016 елга кадәр Татарстан Язучылар берлеге рәисе булып тора. Бүгенге көндә «Казан утлары» журналының проза бүлеге мөхәррире.

1987 елда аның кече яшьтәге балалар өчен «Буран кайда йоклый?» исемле беренче шигырьләр китабы дөнья күрә. 1990 елдан Р.Корбан – СССР һәм Татарстан Язучылар берлекләре әгъзасы. Бүгенге көндә Р.Корбан – төрле жанрларда татар, рус, балкар, казакъ, кабарда телләрендә басылган илледән артык китап авторы.

***

Рафис Корбанның әдәби иҗат казанышлары барыннан да бигрәк нәниләр шигърияте белән бәйле. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки ул үзенең бөтен рухы белән бала күңелле шәхес. Рафис Корбан иҗатта һәм иҗтимагый-әдәби эшчәнлегендә, нинди генә яшькә җитүенә, нинди генә хезмәтләр башкаруына да карамастан, табигате белән һәрчак актив һәм алга омтылучан, эчкерсез-ихлас, балалар шигъриятенә, нәниләр дөньясына да гомер буена үз һәм тугрылыклы булып калды.

Нәниләр әдәбияты – гаять катлаулы, нечкә һәм гаҗәеп үзенчәлекле бер өлкә. Монда чын-чынлап уңыш казану өчен көчле теләк, тырышлык, балалар теленә яраклаштырып яза белү генә аз, моның өчен, В.Г.Белинский сүзләре белән әйтсәк, табигатьтән нәниләр әдибе булып туарга кирәк. Нәниләр шигърияте ул – берәмтекләп табыла торган тауар. Шуңа монда шигъри табышларның үзкыйммәте бермә-бер кадерлерәк. Алардагы һәр уңышлы психологик яки эстетик җәүһәрнең милли нәниләр шигърияте хәзинәсен баетуда аерым бер әһәмияте бар.

Рафис Корбан – үз иҗатында дистә еллар дәвамында әнә шушы четерекле өлкәгә тугрылыклы хезмәт итүчеләрнең берсе. Ул Г.Тукай, Ә.Фәйзи, Б.Рәхмәт, Ш.Галиев, Р.Миңнуллин иҗатларындагы уңай традицияләрне кыю дәвам итә. Без биредә аның, димәк, татар телле нәниләр шигъриятенең дә уңышы саналырлык егермеләп әсәренә тукталып үтәрбез.

Үзенең нәни укучысы, дөресрәге бәләкәй тыңлаучылары белән үзара аңлашырга ниндирәк уртак телләр таба соң әдип?

Барыннан да элек, шагыйрь буларак, нәни дусларына ул үзенең сәнгатьле-сурәтле шигъри фикерләвен тәкъдим итә: *Искитмәле бу төн,/ әкият күк серле! / Күктә йолдызлары / алма кебек эре! / Урман, болын, кырлар / ай нурында йөзә./ Офыкта аҗаган / күктән алма өзә. / Керми күзгә йокы, / тыңлап ятам тынып: / Бакчада төн буе / алма коела тып-тып. («Алмалы төн»); Күбәләкләр оча уйнап, / ә һавада бал исе. / Чәчәкләр дә канатланып / очып китәрләр төсле.Чикерткә концертын тыңлап, кояш та киткән оеп; җилләр дә талган йокыга, үләнгә башын куеп. («Җәйге көндә»).*

Авторның шигъри фикерләве еш кына баланың берәр шөгыленә яки уенына килеп үрелә: *Ә бакчада мине бер кош уздыра – ничә көннәр сыздырыпмы-сыздыра! Ул чынлап та курайчыдыр, мөгаен... Томшыгыдыр – аның моңлы курае. («Курай»); Инде белдек: буран нигә туктаган – ул бит безнең өйгә кереп йоклаган. («Буран нигә туктаган?»).*

Шигырьдән-шигырьгә баланың яшәеше, аның танып белүенә бәйле төстә уй-фикерләве, тойгылары тирәнәя, киңәя, тармаклана бара.

Әнә ул дус-ишләрен үзе белгән күп төрле бакчалар белән таныштыра һәм гөлләр-чәчәкләр бакчасы, яшелчә бакчасы, җиләк-җимеш бакчасы... дип саный торгач, азакта үзләренә аеруча якын булган тагын бер бакчага туктала:

*Нинди бакча дип тормагыз, / Бу бакчаны күрсәгез; / Бу бакчада ни үсәме? / Бусында – без үсәбез!* – дип, аның белән горурлану җаен таба («Бакчалар»).

«Җиләктә» шигырендә бала ямьле табигать кочагында. Биредә дә автор үз героеның психологик үзенчәлеген бик төгәл тотып алуга ирешә: *Җиләклектә / Җиләк күп; / Җиләклектә / Чиләк күп. / Һәр малайда / Бер чиләк, / Каян җыярга / Кирәк / Моның кадәрле / Җиләк? / Барыбер булмас / Тутырып... / Ашыйм гына / Утырып.*

Шагыйрь нәни геройларын җанлы табигать эчендә сурәтләргә ярата. Монда алар кызыграк та, мавыктыргычрак та булган чын тормыш каршылыклары белән очрашалар: *Йөгерә сукмак, чаба, / Элдерә болын буйлап. / Үләннәр белән уйнап, / Чәчәкләр белән уйнап.*

Озын-озын юллар үткәч, балалар алдында сукмак кинәт юкка чыга. Әмма табигать, баланың үзе кебек үк, һәрчак серле, шигъриятле. Анда балага өлкәннәргә лаеклы булып үсү өчен файдалы булган хикмәтләрнең әледән-әле чыгып торуы да һич гаҗәп түгел:

*Сукмакны бит кайчандыр / Кешеләр салып үткән. / Димәк, сукмак салырга / Безгә дә чират җиткән. («Сукмак»).*

Баланың яшәеше турыдан-туры өлкәннәр тормышы белән тыгыз бәйле. Алар белән бергә ул борчылырга, бергә сөенергә – кыскасы, чын-чынлап яшәргә өйрәнә. Тик аерма шунда – эчке халәт кебек шактый гына абстракт төшенчәләрне дә бала үз күңел дөньясына якын булган рәвештә сиземле итеп күреп-танып ала: *Авызларны ера шатлык – / Көлү булып йөзгә чыга. / Шатлык керсә бүлмәләргә, / Тәрәзәләр шыр ачыла. / Урамнарга чыга шатлык, / Калмый торып өйдә генә...*

Өлкәннәр күңелендә йөргән абстракт идеяләр дә аның нәкъ үз телендә – тоемлы рәвештә килеп ирешә: *Шатлыклардан шатлык туа, / Әверелә матур җырга. / Бары тик бер шатлык кирәк / Җир төренсен өчен нурга. / («Шатлык»).*

«Мин бәйрәмнәр яратам» шигырендә, бәлки шуңадыр, бәйрәмнәрнең көн саен булып торуына да бала һич каршы түгел. Чөнки күмәк сөенеч алып килгән ул бәйрәмнәрдә аның теләк-фантазиясе, уены-чыны могҗиза булып бергә кушыла. «Минем туган көнемдә» тәрҗемә шигыре дә моның бер ачык мисалы: *Мин торт состым, өлкәннәр / Эчтеләр шампанский. / Ә тәмле тамак песи / Каймак ашагански.*

Авторның гади генә тормыш күренешләреннән дә шигъри мәгънә, хикмәт-могҗиза таба белү осталыгы «Үзем башлыйм» шигыренә дә үтеп кергән: *Батыр калу өчен әле / Миңа бераз иртәрәк. / Тик шулай да Сабан туен / Үзем башлап җибәрәм.*

Халкыбыз, димәк, Сабан туенда да нәниләргә чын бәйрәм тантанасын – тормыш белән хыялның бергә кушылу шартын элек-электән тудыра алган булып чыга.

Баланың табигый халәте, холкы, барыннан да бигрәк аның уенчыклары белән уйнавында, аларга булган мөнәсәбәтендә ачык чагылыш таба. Авторның дистәләгән шигырьләре әнә шундыйлардан: *Әти миңа туган көнгә / Бүләк итте автомат. / – Син хәзер чын солдат, – диде,– / Автоматтан ат та ат! / Әйбәт атты автоматым. / Ике көн буе аттым. / Курыкмагыз атар бу дип... / Мин инде аны ваттым. («Автомат»).*

«Сөйләшергә өйрәтәм» шигырендә баланың мәхәббәте аның курчагына төбәлгән. Бөтен шартын туры китереп – чын әниләрчә итеп, ул аның белән аралашу, аңа карата үзенең ярату тойгыларын аңлату җаен таба: *Булсам да бик / Нәни мин, / Курчагыма / Әни мин. / Ашатам да / Йоклатам, / Елаганда / Юатам. / Аннан юам / Керләрен: / Оек белән / Күлмәген. /*

Әмма тәрбия хәтта уенда да каршылыксыз гына бара алмый. Ул әнә, әнисе кебек, кызының бөтен сораганнарын да үтәр иде дә, курчагы сөйләшә белми икән: *Сөйләр иде,– / Шуны да / Белми торам, / Карале, / Курчагымны / Сөйләшергә / Өйрәтәсем / Бар әле.*

Әле аның бер тыңлаусыз шәкерте дә бар. Ул – Муйнагы: *Мөмкин түгел өйрәтергә / Һичбер ничек! / Уенчык эт түгел шул ул, / Ул – чын көчек! («Уенда уен гына»).*

Автор баланы укырга өйрәтү, аны мәктәпкә әзерләү һәм, гомумән, нәниләрнең фикерләү сәләтен үстерү мәсьәләләренә дә якыннан торып катнаша. Аның шигъри табышмаклары шуның бер мисалы: *Беркем аны югалтмаган, / Ләкин һаман табалар... / Сез дә табышыгыз әле, / Нәрсә соң ул, балалар?*

Шагыйрь нәниләргә сатирадан да өлеш чыгармый калмый. «Каюмның дуслары» шигырендә без нәниләрнең үз алыш-бирешенә тап булабыз: *– Каюм, Каюм, / Дустың кем? / – Әлбәттә инде, / Гөлсем! / Ишетәсеңме, / Гөлсем? / Бир алмаңның / Берсен!*

Берсеннән икенчесенә, өченчесенә күчеп, дуслык тойгысын шулай раслата торгач, дуслыкны ныгыту чираты Әюпкә җитә: *– Бүген дустың кем, Каюм? – Әйдә, син дус бул, Әюп! – Ләкин минем Кесәмдә / Юк шул һичбер нәрсә дә!..*

Көлке дә кызганыч та... Әмма нишләмәк кирәк, монысы инде безнең бүгенге үз тормышыбыз.

Авторның «Капкорсак» шигыре дә бик күпләрне чеметә торган итеп язылган. Ул кулинария һәм берочтан ана телен югалту, әхлак-тәрбия өлкәсенә дә тигез кагыла:

*Капкорсак, капкорсак, / Ашаган күп бавырсак. / Ашаган күп тәбикмәк, / Коймак, бәлеш һәм икмәк. / Чәкчәк, сумса, кош теле /Һәм ике табак белен. / Ашаган чакта белен, / Йотып җибәргән телен. / Аңа соң тел ник кирәк? / Ашарга бир тизрәк!*

Шагыйрьнең рус әдәбияты классикларыннан файдаланып иҗат ителгән тәрҗемәләре дә әнә шушы милли хәзинәбезне баету ягыннан зур әһәмияткә ия булуын әйтеп үтәргә кирәк.

Аларның «Минем туган көнемдә» дигәне белән алда танышып үткән идек инде. Биредә мисал итеп тагын берсен атап үтик. Ул – «Санамыш»: *Бер, ике, өч, дүрт, биш. / Бакчага кергән куян. / Кәбестәне кимергән, / Китергән бик зур зыян. / Сунарчы аңа аткан, / Куян һушын югалткан. / Өйгә алып кайткачтын, / Куян чыккан да качкан. /*

Санамыш булгач, уен башлана... Димәк, шау-шулы, шигъриятле балачак дөньясы дәвам итә.

***

Р.Корбанның шулай ук нәниләр драматургы буларак, курчак театры репертуарын баету юнәлешендәге иҗат эшчәнлеге дә аерым игътибарга лаек. Казан курчак театры аның «Куркуын җиңгән Куян» (1994), «Бардым күлгә, салдым кармак» (1995), «Ак күлмәктә кара елан» (1996) исемле пьесаларын сәхнәләштерде. «Керпе малае дуслар эзли» (1995), «Бүре һәм Кәҗә» пьесалары Татар дәүләт яшьләр театры сәхнәсендә куелды. Чаллы, Әстерхан курчак театрларында «Куркуын җиңгән Куян» (1998), Уфадагы «Нур» татар театры һәм Чаллы татар драма театры сәхнәләрендә «Патша кызы һәм җырчы» (2001) исемле пьесалары уңыш казанды.

***

Поэзиягә әүвәл балалар өчен язган шигырьләре белән килеп кергән Р.Корбан популяр җырлары белән дә танылу ала. Авторның мәшһүр җырчыбыз И.Шакиров тарафыннан халык көе нигезендә башкарылган «Уян, татар!» (1989) исемле садасы (хор белән башкару өчен язылган декламация) туксанынчы үзгәртеп кору елларында бөтен татар дөньясын хәрәкәткә китергән кырыс көрәш гимны булып яңгырый: *Кояш чыкты, ул калыкты, / Тәрәзәдән нур балыкты. / Уян, татар, уян инде, / Уяныргa вакыт җитте.*

Соңыннан да үзешчән һәм профессиональ композиторларыбыз тарафыннан аның шигырьләренә йөзләп җыр языла. Күпләгән җыр текстлары авторы булуы авторның күңел нечкәлеге, шигъри фикерләвенең халыкчанлыгы, заман үзгәрешләренә сизгерлеге, рух активлыгы турында сөйли. Шагыйрьнең лирик һәм публицистик шигырьләрен исә без биредә биш төп юнәлештә төркемләп күзаллый алабыз.

Беренче төркемгә аның туган авылы, әти-әнисе, гүзәллеккә күзен ачкан туган як табигате, шунда узган балачагы, мәктәп дуслары, яшьлек еллары, ерак юлга озатып калган, кайтса һәрчак колач җәеп каршы алган эчкерсез авылдашлары, бөтен татар дөньясында танылу алган – горурланырлык якташларына багышланган шигырьләрен кертеп карыйбыз.

Инде хыялый балачак, романтик яшьлек артта калган. Шагыйрь ешрак бүгенге көн тормышы – яңа кырыс заман чынбарлыгы белән очраша: *Мин авылга хәзер бик еш кайтам. / Кадерле дә миңа, ят та ул. / Тик без үскәндәге авыл түгел, / Әллә нинди, үзгә, ят авыл. («Авыл», 2014).*

Әлеге юллар авыр сагышка бирелгән картлар сукрануы түгел. Бу – яшәүдән биздерелгән, халыкны тереләй үлемгә куып кертелгән дәртсез-өметсез, перспективасыз сәясәткә корылган тереклек. Табигый ки, «яшәүне бөтен йөрәк күзәнәге белән яраткан» шагыйрь мондый яшәешне кабул итә алмый – аның әрнегән җанында шигъри бер бунт баш калкыта: *Таллар елый, таллар елый, / Чын яшь тама таллардан. / «Әллә бармы кайгыгыз?» – дип / Сорадым мин алардан. / («Таллар елый», 2013).*

Әмма шигырьдә «таллар җавап бирми» – автор бу сыкрау-әрнүнең эчке сәбәпләрен ачуга керешмәстән, «таллар елый, әйтерсең лә болыт кунган талларга» дип, бу әсәрен әлегә бары эстетик сурәт тасвиры белән генә очлап куярга кирәк таба.

Әмма сәнгатьнең төп предметы – кеше язмышы, милләт язмышы. Автор моны яхшы белә һәм ул инде әлегә күңеленә яшерелгән «серне» ачып, бар дөньяга аваз салырга да әзер. Ул тумыштан – шагыйрь, ул тумыштан «туры Тукайлык»ка өйрәтелгән: *Кырларда тартар кычкыра. / Кычкыру – аның җыры. / Җырчысы итеп яшәтә / Тартарын иген кыры.*

Иген кыры – табигать өчен генә түгел, бигрәк тә Кеше һәм кешелек табигате өчен кирәк ул кош бүген: *«Тартар теленнән табар», – дип, / Тапкыр сүз әйткән татар. / Тик тормый минем дә телем, / Мин дә, ахыры, тартар.*

Һәм шагыйрь әлеге ифрат хәвефле миссияне үз өстенә алырга хәл кыла: *Туган якта кырга чыксам, / Җырын тыңлыйм тартарның. / Мин – бер тартарың, туган як, / Мин – тартары татарның. («Тартар», 2013).*

Алга таба бу иҗатта без чын шагыйрьләр сүзен дә ачык ишетеп алабыз.

Авторның туган як шигырьләренә аның яшьлеге һәм кайнар сөю тойгыларын ачкан ихлас мәхәббәт шигырьләре килеп кушыла: *Нурга тулы, моңга тулы хәзер / Минем өчен таңнар-иртәләр. / Кешеләр дә, миңа карап, гүя, / Сандугачлы тал, дип үтәләр. («Гашыйк булгач», 1981).*

***

Кеше гомере шулай корылган – канатлы сөю, ялкынлы мәхәббәт кичерешләрен югалтулы аерылышулар, сагыну сагышлары алыштыра. Авторның 1986 елда язылган әнә шундый «Кайларда йөрисең, сөйгән яр?» шигыренә композитор Илгиз Закиров көй яза, бу моңсулык белән өртелгән аһәң дистә еллар буена һәрбер милли тәрбия алган татар йөрәге өчен якын бер җыр-табышка әверелә: *Кәккүкләр моңая, / Кәккүкләр еракта, / Кешеләр шикелле алар да. / Гомерләр юрасын, / Бәхетләр сорасын / Кәккүкләр без сөйгән ярларга.*

Тормыш-яшәү мәгънәсе турындагы уйлануларын үз эченә алган фәлсәфи шигырьләре шагыйрь иҗатында шулай ук аерым кызыклы юнәлеш хасил итә.

Автор игътибарын барыннан да элек Вакыт агышы, гомернең фанилыгы биләп ала. Әсәргә шуларга бәйле сагышлану аһәңнәре килеп керә: *Карлар кунды инде башкаема, / Эремәслек, язлар килсә дә. («Карлар кунды…», 2003).*

Дөрес, бу дошман көч белән көрәшү әмәлен ул инде күңеле белән тоя да сыман. Һәрхәлдә, аның моңа сукранып кайгырып утыруы бик күренми: *Эх, дусларым, бер көн картлык килер / Агач таягына таянып. / Саклар өчен безне афәтләрдән / Ярап куяр, бәлки, таягы. / Тик мин, дуслар, ул таякка әле / Башкача бер гамәл табармын. / Малай чакның агач аты итеп / Атланырмын да бер чабармын. («Эх, дусларым…», 2003).*

Әмма гомер узудан да бигрәк, «кылган эшләреннән мәгънә эзләп җавап сораган» үткән еллары бик хәтәр. Тормышның җан өшеткеч, җан биздергеч яклары турыдан-туры яшәү максатың һәм яшәү принципларыңа да барып тоташа икән: *А, бу дөнья! Нинди гаҗәп икән: / Бүлгән безне дуска, дошманга. / Дошманым юк, – үзем дошман икән / «Кеше бул!» дип дәшкән дусларга. («Мин бер генә яшим дөньяда», 1998).*

Иң аянычлысы – тормышта тоткан үз максатың, үз кыйблаң булмавы, гомереңнең ярым-йорты, файдасызга узуы: *Тырык-тырык ташлы юлдан / Арбасын тарта гомер. / Шәһәрнеке дә түгел мин, / Авылныкы да түгел. («Яшим шулай», 1999).*

***

Инде шагыйрьнең милләт язмышы турында борчылып язган шигырьләренә, шул исәптән алда сүз булган атаклы садасына әйләнеп кайтыйк. Бу сада (халык көе – күмәклек авазы) нәрсә турында? Ни өчен ул тәкбир әйткәндәгечә, күмәк бер

авазга кушылып кичекмәстән милләтне уяныргә өнди? Моның нинди тарихи, сәяси, психологик сәбәпләре бар? Саданың алдагы куплетларында без бу сорауларга тулы җавап табабыз: *Үз җиреңдә үз телеңдә / Сөйләшергә гаҗиз бит син!*

Монысы эчке төп сәбәп. Әсәр милләтнең психологик халәтен дә тасвирлап бирә: *Милләтче дип аталудан / Куркасыңмы әллә һаман?*

Иң мөһиме әсәрнең уйландырырлык фәлсәфә-идеясе дә ачыктан-ачык аның үзендә белдерелә: *Татар өчен кем көрәшсен / Көрәшмәсә татар үзе?! («Уян, татар!»,1990).*

Монысы шагыйрьнең публицистик көрәш авазы булды. Лирик-фәлсәфи шигырьләрендә автор үз милләтенең тарихы-үткәннәре аша эчке күңел дөньясына күз ташлый: *Мин татарны күзләреннән таныйм, / Карашыннан таныйм мин аны. / Карашлары аның мәхәббәтле, / Күзләрендә балкый иманы. / Күзләрендә балкый бар үткәне, / Гасырларның тирән эзләре. / Сагыш аша карый бу дөньяга / Хәсрәт эчкән татар күзләре. («Татар күзләре», 2003).*

Шагыйрь еш кына табигать белән милләте арасында параллель үткәрә: *Әрсез үлән – дөрестән дә, / Татардан һич ким түгел. / Таптап, изеп киткәндә дә / Юк итү мөмкин түгел. / Ялан кул белән ябышып, / Маташмагыз утарга. / Тиккә генә урыс аны / Охшатмаган татарга. («Шайтан таягы», 2013).*

Шагыйрь иҗатына социаль көрәш мотивлары килеп керә: *Милләт яши – милләтем дип янып / Яшәгәндә генә түрәләр! («Милләт һәм түрә», 2013).*

Авторның бу хакта төгәл үз инануы, үз фәлсәфәсе бар: *Шагыйрьләрне сүгеп бүген / Берәү сата сафсата. / Милләтне шагыйрьләр түгел, / Аны морзалар сата. / («Шагыйрьләрне… »2013).*

«Халкыма» (2002) шигырендә автор ассимиляция процессы фаҗигасенең без уйлаганнан күпкә тирәндәрәк ятуын ача, әлеге фикер киләчәк буыннарга шактый ук җитди искәртү буларак җиткерелә: *Татар урыслашамыни? / Урыс бит татарлаша!*

Бу буш сүз түгел, әлеге хакыйкать эчендә Россия язмышын алда көткән төп фаҗига ярылып ята: *Теленнән язган татар ул, / Дененнән язган татар! / («Халкыма», 2002).*

***

Авторның үз рухи ишләре – шагыйрьләргә багышланган шигырьләре иҗатында аерым бер төркем хасил итә. Шагыйрьлек, табигый ки, «туган телнең әлифбасы» булган бишек җырыннан башлана: *Бишек җыры. Аны җырлар өчен / Кирәк түгел хәтта гармун да. («Бишек җыры», 2003).*

Авторның өлкән буын әдипләре – иҗатташ дуслары Г.Шәрәфи, С.Хәким, Т.Миңнуллин, Ш.Галиев, И.Юзеев, Р.Миңнуллин, М.Юнысларга багышлап язылган шигырьләре дә укучы күңелендә аерым бер кызыксыну тудырмый калмый. Р.Корбан – әлеге олы шәхесләрдән яшь ягыннан күпкә яшь булса да, шактый заманнар алар белән бергә якыннан аралашып, бер Казанда кайнап яшәгән әдип. Алар турында истәлек язарга да, уйланырга да тупланган тәэсирләре җитәрлек: *«Юлыгырга мөмкин бүген / тик сине укып кына / милләт хакында хисләрнең / тугызынчы валына». («Миргазиян Юныска», 2007); Юлдаш кына түгел алар, / алар шул – якты маяк! («Юлдашлар», 2015).*

***

Үзгәртеп кору елларыннан соң Р.Корбан иҗаты тагын да киңәеп, тармакланыбрак үсеп китте. Аның шигърият, драматургия, публицистик эшчәнлегенә шигъри тәрҗемә, бераздан соң проза жанрлары килеп кушылды. Соңгы елларда ул рус, казакъ, якут, балкар, мари шагыйрьләренең әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп, унбер китап бастырып чыгарды. 2017 елда 60 яшьлек юбилее уңаеннан тәрҗемәче егерме ике тугандаш халык шагыйре иҗатын «Дуслар җыры» дигән китабында укучыларыбызга тәкъдим итте. Күренекле балкар әдипләре Кязим Мечиев, Кайсын Кулиев, Кәрим Отаров, Тәнзилә

Зумакулова, Муталип Беппаев, Әскәр Додуев, Хәсән Шаваев, авар шагыйре Мөхәммәт Әхмәтов, казакълар – Галим Җайлыбай, Маралтай Райымбәкулы, Касыймхан Бегманов, Шаһизадә Абдикәримов, якут шагыйре Иван Мигалкин, марилар Геннадий Ояр белән Анатолий Тимеркәевләрнең китаплары Р.Корбан тәрҗемәсендә аерым җыентыклар булып татар телендә басылып чыкты. Аның үз китаплары да рус, казакъ, балкар, кабарда телләрендә дөнья күрде. Балалар өчен шигырьләре якут, калмык, чуваш, мари, кумык, балкар, кабарда, азәрбайҗан, төрек телләрендә төрле газета-журналларда шул халык балаларына барып җитте. Әдәбият галиме Р.Сверигин язып чыкканча: «Рафис әнә шулай төрки телле кардәшләребез белән соңгы егерме-егерме биш елда шактый ерагайган элемтәләрне яңарту, араларны якынайту җәһәтеннән гаять зур эш башкара».

***

Проза жанрында Р. Корбан чынлап торып, әле 5-6 ел гына шөгыльләнеп килә. Бу өлкәдә дә ул үзенең югары иҗат потенциалын күрсәтергә өлгерде – автор укучыларга бер-бер артлы дүрт күләмле әсәрен – «Ватан» (2018), «Әхмәров» (2019), «Артык кешеләр» (2020) һәм «Җидегәннән төшкән нур» (2021) романнарын бүләк итте. Әсәрләр һәммәсе дә укучылар тарафыннан зур кызыксыну белән кабул ителде һәм матбугатта югары бәя алды. Аларның беренчесе рус һәм балкар телләренә дә тәрҗемә ителде, аерым китап буларак та дөнья күрде.

«Ватан» романы М.Җәлил һәм җәлилчеләр батырлыгын тасвирлауга багышланган. Бу хакта язылган әдәбият һәм сәнгать әсәрләре аз түгел. Китапның «Соңгы сүз»ендә автор мәсьәләнең бу ягына аерым тукталып: «Җәлил һәм җәлилчеләр турында әдәби әсәр язарга алыну бик зур тәвәккәллек сорый. Чөнки бу темага бик күп әсәрләр иҗат ителгән. Ш.Маннурның «Муса», Г.Әпсәләмовның «Агыла болыт» романнары, Ә.Давыдовның «Муса абый» повесте Җәлилнең батырлыгын әдәби әсәрләрдә мәңгеләштерү омтылышыннан язылган булсалар, Н.Исәнбәт, Р.Ишморат, Т.Миңнуллин, Ә.Гаффар кебек драматурглар бу теманы сәхнәдә яктырту җәһәтеннән үзенчәлекле әсәрләр иҗат иттеләр. Рафаэль Мостафин үзенең бөтен әдәби эшчәнлеген Җәлил һәм аның көрәштәшләре батырлыгын мәңгеләштерүгә багышлады дисәк тә ялгышмамдыр. Төрле елларда галимнәр Исхак Зәбиров, Абдулхак Әхтәмҗан һ.б.лар әтрафлы хезмәтләр язып калдырдылар», – дип билгеләп үтә һәм тагын да үзе файдаланган дистәләгән саллы хезмәт исемен атый. Галимнәр теле белән әйтсәк, мондый «бай фәнни аппаратка» нигезләнеп, эш башлау авторның теманы ачуга шактый җитди якын килгәнлеге хакында сөйли.

Иң мөһиме авторның түбәндәге сүзләре игътибарны җәлеп итә: «Ватан» дип исемләнгән бу романда өстә исемнәре аталган әдәби әсәрләрдән һәм эзләнүләрдән аермалы буларак, Җәлил, җәлилчеләр һәм «Идел-Урал» легионы тарихы бүгенге күзлектән чыгып, бөтенләй яңача яссылыкта бәян ителүе белән үзенчәлекле».

Әдәбият галиме Фоат Галимуллин авторның уңышын «чорлар казанышы» буларак аңлата: «Әлеге каһарманнарыбыз хакында мәгълүмат күп еллар буена бөртекләп җыелды», – дип яза ул. Сүз дә юк, Ш.Маннурның М.Җәлил турында язган алтмышынчы еллар башы белән Искәндәр Гыйләҗевнең «Легион «Идел-Урал» (ТКИ, 2005) китабы чыкканнан соңгы язылу шартлары нык аерыла. Әмма шунысын истән чыгармыйк: бередә хикмәт объектив шартлар үзгәрүдә: мәгълүмат чыганаклары арту, хәтта сүз иреге ачылуда гына да түгел, төп хикмәт авторның заманнар үзгәрешендә максат уртаклыгын тоемлавында, көрәш асылының мәгънәсен ачык аңлауда, бөтен йөрәге белән шушы мәңгелек азатлык идеясенә барып кушылуында. Хикмәт аның шигъри талантында, шәхесенең дөреслеккә, олы хакыйкатькә омтылышында!

Мәгълүматлар күбәю нәтиҗәсендә үзгәртеп кору елларында бу теманың бер яктан икенче якка ташланган юнәлешле әсәрләрнең дә барлыкка килүе матбугатыбызда кискен һөҗүмнәр, аптыраш, бәхәс уятуы очраклы түгел иде. Бу бәхәскә заманында тиешле ноктасын куйган хезмәт итеп мин үзем олы әдибебез Фәнзаман Батталның

«Хакыйкать кадерлерәк!» исемле саллы язмасын саныйм. Мәкалә перестройка елларына кадәр безгә хакыйкатьнең эталоны булып тоелган Р.Мостафинның «дөреслеген» тамырыннан күчереп, тиешле үз урынына утыртуы белән әһәмиятле. Р.Корбан романы да – укучыларыбызның сәяси карашын һәм әдәби зәвыгын ачыклауда бүген үзенә күрә бер лакмус кәгазе ул.

«Рафис Корбанның «Ватан» романы минем өчен аеруча куанычлы табыш булды, – дип язып чыкты роман турында күренекле әдибебез Айдар Хәлим. – Дөресен әйткәндә, мин әле берничә көн элек кенә Корбан туганымның мондый четерекле, тыштан караганда «тапталган», эчтән караганда юньле-рәтле өйрәнелмәгән, еллар тузаны белән капланган, бик тә катлаулы, сәясәт, политиканлык белән актарылып беткән темага тотына алуын күз алдына да китерә алмаган булыр идем. Инде бүген «Ватан» романы – минем өчен генә түгел, әдәбиятыбыз, милләтебез өчен ләззәтле табыш һәм серле табышмак».

Әдип фикере белән килешми мөмкин түгел, аны куәтләп, мин хәтта: Муса Җәлилнең иҗаты бездә иң күп өйрәнелгән һәм иң аз ачылган иҗатларның берсе, дип өстәр идем.

Әсәрдә романның төп каһарманы М.Җәлил образы да, аның көрәштәшләре эшчәнлеге дә, әлегәчә без башка як лагерьда итеп кенә һәм бары тик кара буяуларда гына күрергә гадәтләнгән Шәфи Алмас, Әхмәт Тимер, Галимҗан Идриси, Әхмәтвәли Мәңгәр, Искәндәр Яушев кебек мәгълүм затларыбызның да шул мохиттәге яшәеше үз йөзләренә туры килерлек итеп, тулы канлы, табигый, ышандырырлык итеп сурәтләнә. Аларның үзара аралашу, мөнәсәбәт, көрәшләренең үсеше дә гаять мавыктыргыч, кызыклы һәм табигый. Нәтиҗәдә укучы күз алдында татар мөһаҗирләренең, хәрби тоткыннарның, татар милләтенең аерылгысыз җанлы, реаль бөтенлеге тудырылган. Бу – безнең мохит: шул ук кырыс шартлар, шул ук моң, шул ук чарасызлык һәм өмет.

Р.Корбан романында әсәрне чын заман биеклегенә күтәргән гүзәл сыйфатларны бик озаклап санарга мөмкин булыр иде. Тел-стиль җәһәтеннән, композицион корылышы, тасвир-сурәтләү байлыгы, образлар бирелеше, идея-фикер ачыклыгы – кайсы гына яктан алып карасаң да, романның бу теманы яктырткан элеккеге әсәрләрдән бер башка өстен торуына ышанасың.

Шулай да авторның иң зур казанышы, минемчә, нәкъ менә шушы – бөек Хакыйкатькә тугрылык саклап иҗат итүендә. Р.Корбанның төп уңышы «дөреслекне берәмтекләп җыю»да түгел, «Ватан» дигән бу олы символик мәгънәле төшенчәгә ул комплекслы якын килә. Аңа иң әүвәл милләт азатлыгы яктылыгыннан фәлсәфи караш ташлый. Укучысына заманыбыз таләбе – асыл көрәш рухын җиткерә.

«Әхмәров» (2019) романы шулай ук тарихи теманы нигезгә алып, күренекле разведчик, якташыбыз (Рафисның авылдашы) Исхак Әхмәров батырлыгын бәян итә. «Артык кешеләр» (2020) исә мәшһүр композиторыбыз Салих Сәйдәшев һәм аның фаҗигале язмышка дучар ителгән иҗатташ дуслары тормышын үзәккә куеп яктыртуга багышланган.

Заманыбызның бик күп тискәре яклары арасында, күзгә күренеп торган бәхәссез бер уңай ягын бүген кат-кат ассызыклап үтми булмый: без акрынлап, ачы хакыйкатькә кайтабыз! Бик күп әдипләребезгә җитмәгән иң кыйммәтле сыйфат та ул, һичшиксез – хакыйкатькә тугрылык! Ә бит бу үзлек Рафис Корбан иҗатының үзәк кыйбласын тәшкил итә. «Җидегәннән төшкән нур» романы да – аның чираттагы көрәш батырлыгы. Бу әсәр безгә барыннан да элек татар халкының чын галиме, күренекле әдип Нәкый Исәнбәт исеменә ташланган пычрак ялалардан бу зур шәхесне йолып алу максатына хезмәт итүе белән кадерле.

Игътибар итсәгез, бу романнарның һәркайсында уртак бер сыйфат булуы бәхәссез – алар тормыш чынлыгына тугрылыклы калып, ялганнарны фаш иткән, барыннан да элек дөреслек, хакыйкать күзенә туры карап язылган талантлы әсәрләр.

**Равил РАХМАНИ**

# ЙӨРӘГЕ – ТОТАШ СӨЮДӘН, КҮҢЕЛЕ ҖЫРДАН ТОРА

## ГАЛИМҖАН ГЫЙЛЬМАНГА – 65 ЯШЬ

Галимҗан Гыйльман әсәрләре беренче җөмләләреннән үк укучыны тулаем җәлеп итүе белән үзенчәлекле булды, алар, гомумән, совет чоры укучылары ияләшкән системага сыймавы белән үк башка иде. Аның әсәрләре әкияткә охшаган яки мифларга әверелә, яңа тема, яңа идеяләргә нигезләнә.

Ул – татар реалистик, бигрәк тә социалистик реализм кысаларында тәрбияләнгән укучы өчен дә, аеруча шул кысаларда тәрбияләнеп, фикер йөртергә өйрәнгән тәнкыйтьчеләр өчен дә бик үзенчәлекле, фәлсәфи фикерле кабатланмас язучы. Татар әдәбиятының Фатих Әмирханнардан, Галимҗан Ибраһимовлардан килә торган үз реалистик традицияләре бар. Аның шул реалистик кысалардан чыгып иҗат иткән Гаяз Исхакый, Шәриф Камал, Мәхмүт Галәүләре бар. Димәк, безнең бүгенге чор татар әдәбияты үз йөзен өр-яңадан яулау алдында. Бүген татар әдәбиятында нинди язучы һәм ни рәвешле яңача, милли рухта ачыш ясый алыр икән? Гаяз Исхакыйлардан килгән хөрлек, миллилек байрагын дөнья әдәбияты алдында ничек күтәреп бара алыр икән дигән сорау туа. Чөнки нәкъ менә бүгенгедә безнең әдәбиятыбызның киләчәк йөзе формалаша. Шуңа да чорның сүз сәнгате казанышлары турында сөйләгәндә, һәрвакыт әйдәп баручы язучыларны барлыйбыз. Язучы Галимҗан Гыйльман – шундый әдипләрнең берсе. Язучылык эшчәнлеген лирик әсәрләр иҗат итүдән башлап җибәргән булса да, бүгенге укучылар аны татар әдәбиятының сыйфат, үсеш дәрәҗәсен билгели торган һәм мавыктыргыч катлаулы сюжетлы, борынгы мифлар рухында язылган «Албастылар» дилогиясенең, үзенчәлекле сюжетка корылган «Оча торган кешеләр», «Җанбалык», «Фәрештә», «Күрәзә» кебек повестьларның, күпсанлы хикәяләрнең авторы буларак беләләр. Бу әсәрләр «Тәкъдиргә юл» (2014) һәм «Ходай бүләге» (2016) дип исемләнгән җыентыкта урын алганнар.

Г.Гыйльманның прозаик буларак дөньяга карашлары формалашып җитүе XX гасырның соңгы дистә елларында чорлар алмашуга туры килә. Нәкъ шушы дәвердә татар әдәбиятында милләтнең дәүләтчел үткәненә генә түгел, тагын да борынгырак катламнарына – ислам динен кабул иткәнче булган чорларга да мөрәҗәгать итү күзәтелде. Күпме генә баш тартырга, йөз чөерергә тырышсак та, милли-мәдәни мохитебезне яңа рух чолгап алды. Аның матур чагылышын без татар сүз сәнгатендә дә күзәттек. Мисалга сүз сәнгатебезнең эре һәм кыю адымнар белән мифологиягә, миф тудыруга, күпмедер дәрәҗәдә дини фәлсәфәгә борылуын алыйк. Мондый иҗади кыйбла табигый кабул ителде, чөнки дини мифология – ул бүгенге мәдәниятнең чишмә башы, кешелекнең килеп чыгышын, Галәм һәм Җирнең яратылышын аңлаткан карашларны, белемнәрне туплаган өлкә. Мифологиягә мөрәҗәгать итү татар халкының «тарихи аңы»нда сакланган архаик-нигез образларны, элементларны кабат өскә чыгаруга, аларны бүгенге укучының «исенә төшерүгә», хәтерендә кабат яңартуга ярдәм итә. Миф борынгы рухи мәдәниятне билгеләүче генә түгел, кешелек дөньясына бәяләмә бирүче система итеп кабул ителә, хәзерге сәнгатьтә әнә шушы аспектларны чагылдыручы художество алымы да булып тора.

Г.Гыйльманның мифларга мөрәҗәгать итүендә татар мифларын җыю, туплау белән шөгыльләнүе дә зур роль уйный, бу аның икенче чор әсәрләренең корылышында ук сиземләнә. Әдип аңлы рәвештә әсәрләрендә ирреаль дөнья моделен торгызуны ике яклы, ике планда алып бара. Тышкы яктан караганда, ул әсәрне архаиклаштыруга кайтып кала

кебек. Ягъни язучы әсәрен борынгы риваятьләр рухында борынгылаштырып сурәтли. Әсәрләренең эчке дөньясына кереп китсәк, язучының аңлы рәвештә генә түгел, интуитив рәвештә дә үз әсәрен мифологик модельгә коруын, борынгы мотивларны алып, үзенчә үстерүен, үзгәртүен күрәбез. Ул кулланган геройлар, образлар архаик фикерләүдә булмаска да мөмкин. Автор бары аларның тышкы формаларына охшатып, үз образын, үз мифын тудыра. Мондый характердагы әсәрләрне XX гасыр татар әдәбиятының буеннан-буена күрсәтеп чыгып булыр иде. Мисалга, Г.Исхакыйның «Зөләйха», «Локман Хәким», Һ.Такташның «Җир уллары трагедиясе», «Күктән сөрелгәннәр», Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә» әсәрләрен һ.б. китерергә мөмкин. Совет чорындагы социалистик реализм методы мондый төрдәге әсәрләрне кабул итә алмады, чөнки аларда тормышны революцион үсештә күрсәтү, реальлелек юк, һәм алар укучыны үзенең яшәешенә үзе хуҗа икәнен аңлаган хөр фикерле кеше итәләр иде. Шуңа да совет татар әдәбиятында яшәешне экзистенциаль («экзистенция» – яшәү дигән сүз) яссылыкта сурәтләгән, нигезенә Яшәеш, Җиһан хакында дини-мифологик идеяләр салынган мондый әсәрләр юк дәрәҗәсендә булды. Г.Гыйльманның «Оча торган кешеләр», «Фәрештә», «Күрәзә», «Җанбалык» һ.б. әсәрләрен берләштергән сыйфат шунда: үзәккә фәлсәфи як (яшәеш фәлсәфәсеме ул, дөньяны танып-белү яки кабул итү рәвешеме), рухи кыйммәтләр һәм татар халкының ислам, мәҗүсилек белән бәйле образлары, фикерләре куелган, алар аша экзистенциаль идеяләр үткәрелгән. Әлеге әсәрләр гел реалистик буяулар белән генә сугарылган татар әдәбиятында яңа юнәлеш «метафизик реализм» юнәлешен формалаштырдылар. Метафизик реализм – Яшәешнең метафизик дәрәҗәсен ачуны үзмаксат итеп куйган, рухи эзләнүләрне нигез итеп алып, кеше күңеленең яшерен урыннарын, дөнья яратылышының серле, билгесез якларын үзенчәлекле итеп сурәтләгән алым. Әлеге алымның нигезе булып, реализм кала Һәм аңа «яшерен дөнья», «яшерен чынбарлык», «хакыйкый чынбарлык» дигән параллельләр өстәлә.

Г.Гыйльман әсәрләренең беренче уртак сыйфаты миф тудыруда икәнен күпчелек галимнәр таныганнар иде инде, икенчесе исә – борынгы күзаллаулар тәэсирендә формалашкан «архетип»ларны күпләп һәм уңышлы куллануда. Архетипларны монда (грекчадан «башлангыч образ» дип тәрҗемә ителә) мәдәниятнең, аның башлангыч өлеше булган мифларның, халык иҗатының нигезендә ятучы борынгы гомумкешелек символлары дип аңларга кирәк. Бу образлар мәҗүсилек чорында аңның өске катлавында ятса, ягъни кешеләр һәр нәрсәдә Җир Һәм Күк белән бәйләнеш күреп, аларны символлар буларак кабул итсәләр, гасырлар дәвамында мәдәният үсеше алга китү сәбәпле һәм тарихи тәҗрибәләрнең кысрыклавы нәтиҗәсендә, әлеге образлар игътибар үзәгеннән төшеп калалар. Ләкин алар юкка чыкмый, кешенең «аңсызлык өлкәсе»нә күчә бара. Анда да тик кенә ятмыйлар, ә яңа чор фикерләвенә яраклашып, символикалылык аша мәдәнияттә чыгыш ясыйлар. Нәтиҗәдә, бүгенге чорга килеп җиткәндә, «кешелек хәтере» дигән өлкә төрле чорларның мәдәни казанышларын, фикерләү рәвешен, дөньяны күзаллавын туплаган катлы-катлы бинаны хәтерләтә. Менә шуларны немец галиме К.Юнг «коллектив аңсызлык» дигән төшенчә белән гомумиләштерә. Аныңча, «коллектив аңсызлык» дигән бу өлкә һәм аның һәр күзәнәгенә тиң архетиплар дөньяны кабул итү формасына да, кешенең үз-үзен танып-белүнең тарихи-поэтик юнәлешенә дә, миллилеген саклап калуының нигезенә дә нык тәэсир итә. Димәк, мондый төр әсәрләрнең язылуы юктан уйлап чыгарылган хикәят кенә түгел, ә ул язучы шәхесенең, дөресрәге, аңының «халәте», аның фикерләү, дөньяны күзаллау рәвешенең чагылышы, милләтен, милли сүз сәнгатен саклап калуның, үстерүнең бер чагылышы икән.

Әгәр хәтерләсәк, Г.Гыйльманның XXI гасыр башында матбугатта дөнья күргән «Албастылар» романы бүгенге татар әдәбиятын уятып җибәргәндәй итте. Әлеге әсәр татар сүз сәнгате «мичкәсендә» әле «дары бетмәвен» дә, укучыларның фәлсәфи эчтәлекле, кабатланмас образлы, яңа сурәт чаралары белән иҗат ителгән мондый төр әсәрләрне йотлыгып укуын, аларга ихтыяҗның югалмавын, сүнмәвен раслады. Моңа

кадәр татар әдәбиятында бу юнәлештәге әсәрләр юк иде. Әлеге программ характердагы әсәре язучының иҗатын, аның татар әдәбиятында тотачак урынын шундук күз алдына китереп бастырды. Бу әсәр әкият-фантастика гына түгел. Бу әсәр – язучының күпме еллар татар әдәбиятын өйрәнеп, аны яңа дәрәҗәдә тәкъдим итү теләгенең матур чагылышы. Бүген тәкъдим ителә торган «Ходай бүләге», «Тәкъдиргә юл» кебек бәяннар, новеллалар, хикәяләр җыентыкларының Казык йолдызы. «Албастылар» әсәрендә эзоп (яшерен) теле белән әйтелгән рухи, милли, дини, гуманлылык афәтләре атап үтелгән җыентыкларда инде түзә алмаслык гаҗизлектән, милләте өчен ачынудан кычкырып әйтелгән. Милли яшәешне болай киң колачлау, язучы җанының халкы өчен Җир һәм Күк арасында бәргәләнүе җиңелме?

Г.Гыйльманның «Албастылар» әсәрендә мифологик мотивлар дип күрсәтелгән мотивлар бүгенге татар кешеләренең яшәеш асылына әверелмәгәнме? Без күрә торган чынбарлык чыннан да хакмы? Әллә без күреп-аңлап бетерә алмаган зур фаҗига – проблемалар бармы? Албастылар дөньясы кешедәге явызлыкның метафорасы булып тормыймы? Романның сюжеты үстерелеше дәвамында аны җиңү идеясе туарга тиешлегенә басым ясалмыймы? Болар гына түгел, автор татар әдәбиятында беренче тапкыр үзенчәлекле метафорик сюжет кора: егетнең Албастылар утарында нурлы җанны – Майяны күрүе, аны коткаруы; егетнең вакытлыча аңы югалу аның кешелек хәтеренә тоташу юлына басуы, егет реаль чынбарлык белән янәшә ирреаль пространствоның булуын, аның зурлыгын, чиксезлеген, серлелеген, аны ачып бетереп булмавын һәм анда керү юлын үзе генә белә.

Әлеге мотивлардан түбәндәге фәлсәфи-җыелма нәтиҗә тудыра алабыз. Беренчедән, албастылар дөньясы бүгенге дөньяда кешелекне басып алырга тырышкан Кара көчнең тышка чыгуы буларак гомумиләштерелсә, икенчедән, чорның заман ахырына җитүе, явызлашуы аның шәхси яшәеш һәм көнкүреш проблемасына әверелүне дә искәртә. Шул ук проблемалар «Шартлау» әсәрендә инде ачыктан-ачык чаң кагу рәвешендә тасвирлана.

Әдәби әсәр иҗат итүченең фантазиясе тормыштан алынган реаль картиналар белән яки уйлап чыгарылган вакыйгалар белән эш итүгә генә кайтып калмый; әсәр иҗат итүче мотивлар белән «фикерли», психологлар раславынча, бу мотивлар кешедә (һәр кешедә) генетик дәрәҗәдә салынган гештальтлар рәвешендә яши. Шушы гештальтлар – «рәсемле картиналар» бүгенге кешенең дә дөньяга карашын формалаштыра, аңа тәэсир итә. Димәк, мотивлар – кеше аңында, хәтерендә яши торган һәм аерым ситуацияне күзаллата торган, тотрыклы мәгънәләр җыелмасыннан торган мөстәкыйль фикер элементлары булып чыга.

Г.Гыйльман борынгы мифологик, әкияти мотивларны «тергезеп», алар эчендә кечкенә сюжетлар хасил итә. «Албастылар» романындагы мотивлар эченә сыйган ситуация-вакыйгаларны барлап яки анда катнаша торган персонажларны анализлап, мондый нәтиҗәгә килергә була: бу роман татар халык авыз иҗатында яратып кулланылган тылсымлы әкиятләрнең структурасын кабатлый. Моңа исә әсәрнең сюжетын кора-төзи торган мотив кебек мөстәкыйль берәмлек сәбәпче булган. Хәлимнең татар авылыннан чыккан бер батыр кебек дию-аждаһага каршы көрәшкә күтәрелүгә охшаш көрәшкә баруы сурәтләнә. Әкиятләргә хас мотивлар чылбырының «Албастылар» романында иҗади үстерелешен түбәндәге схемага салып була: бу дөнья тормышы (бүгенге татар авылы) – сәбәп чыгу – юлга кузгалу – икенче дөньяга (албастылар утарына) эләгү – сынау, шарт – (албастылар дөньясы турында) сер әйтелү – геройларның бер-берсенә ант бирүе – туган йортка кире кайту – серне чишү – туганнары хәйлә кору – төп геройның хәйләне белми калуы – параллель дөньядан кайткан вәкилнең үлеме – геройның антка тугры калуы – фаҗигале (яки бәхетле) нокта. Димәк, романның халыкның милли фикерләве белән уртаклыгы бәлки шуңа да укучылар тарафыннан яратып укылуга сәбәпче булып торгандыр. Татар мифларына, татар әкиятләренә мөрәҗәгать итүнең максаты нидә? Әнә шул гаять тирән, гаять көчле катламга «төшеп», язучы татар халкының үзаңын куркаклык, сатлык, хыянәт, маңкортлык кебек сыйфатлардан арындырып, татар

мифларында тасвирланган каһарманнар кебек кыю, батыр булырга өнди. Үз язмышы, тормышы өчен көрәшкә өнди.

Албастылар язмышы хакындагы эпизод әлеге утарны характерлаучы явызлык сыйфатын алып ташларга мөмкинлек бирә. Әлеге повестьта Г.Гыйльман аллегорик мәгънәви метаморфоза куллана. Явызлык оясы булган албастылар, асылда, җир-ананың серләрен, сакраль сыйфатларын үзенә яшергән һәм кешеләрнең борчу-тыкшыну, басып алуларына үзенчә җавап кайтара торган җир-анага хезмәтчеләр генә. Явызлыкның асылы, пародокс кебек яңгыраса да, Табигатьтән түгел, кешеләрдән килә. Сихерче карчыкларга «сихер» саклануның бер чарасы булса, адәми затларда ул бәндәләрнең явыз «асылы» дәрәҗәсенә җиткән.

«Албастылар» әсәрендә әдип «албастылар» образы ярдәмендә мәгънәви символик уен куллана, ул әсәр идеясен ачучы төп категория: албастылар дөньясының коточкычлыгын һәм сихерлелеген алып ташлау белән кешеләрнең үз асылы хакындагы белемсезлек, аларның икейөзлелеге ачыла.

Албасты дип аталган затлар яшәгән урынны авыл иткән «кечкенә кеше»ләр үзләренең Табигать-Космос алдында кечкенәлелеген, көчсезлеген аңламаганнар, үзләрен Җирнең төп идарәчесе итеп, аның үзәгендә яшим дип уйлаганнар. Романны укып чыккач, идея дәрәҗәсендә борчыган төп фикер – ул кешелекне, кешеләрне ана карыныннан читтә калган ярым туган бала хәлендә икәнебезне аңлау. Гүя без аннан чыкканбыз да, уй-акылыбыз белән аның турында онытканбыз. Табигать-ана белән бәйләнешебезне бары «аңсызлык өлкәсе»нә яшеренгән әнә шул мифологик мотивлар гына саклап, искәртеп тора. Язучы да укучыларны шушы элемтәне онытуын, Табигать-Кеше бәйләнешенең яшәеш өчен мөһим икәнен дәлилли. Әсәр герое Хәлим албастылар утарының серенә төшенергә омтылса да, үзе яшәгән мохитнең яшәеш серенә төшенә алмый, аны яхшы якка үзгәртә алмый, кешеләрнең аңына тәэсир итә алмый. Романда ментальлекне нигезли торган мифологик мотивларга нигезләнеп, автор рухи сафлык, җан-күңел азатлыгы, сафлыгы өчен көрәш темасына заманча караш ташлый. Г.Гыйльман иҗатында тудырылган «бүгенгенең мифологиясе» архаик Җир-ана һәм аның серле көчләренең «аңсызлык өлкәсе»ннән аңына күчә баруы, чыгышы белән Илаһияттән булган «күңел нурын» җуя баруы дәлилләнә.

Матбугатта дөнья күргән роман, повестьларыннан күренгәнчә, Г.Гыйльманның үзенә генә хас сурәтләү алымы бар. Бу – әдәби әсәрдә яңа дөнья, дөньяның үзенчәлекле моделен тудыру алымы. Әйтик, «Албастылар» әсәрендә ачыктан-ачык кулланылган мифлаштыру «Оча торган кешеләр»дәге яшерен мифлаштыру белән чагыштырып карарга мөмкин. Нәтиҗәдә, икесендә дә Г.Гыйльманның мифологик карашлардан «ерагаймавы», киресенчә, тагын да «якынаюы» күренә.

Татар мифларындагыча фикерләү белән сугарылган әлеге романда вакыйгаларның үзәген тотып торучы төп урын бар. Без аны «вакыйга бишеге» дип атыйбыз. Монда вакыйга үстерелгән җир – Тау – хронотоп (Вакыт Һәм Пространствоның үрелеше) белән этносның үзара тәэсире һәм үзара бәйләнешен төшенү үзәге буларак чыгыш ясый. Кала-тау серле урын гына түгел, ә рухи кичерешләрнең, җан сафлыгының чишмә башы булган һәм аларны Илаһият белән бәйләп торучы урын. Кала-тау – дөньяның космик үзәге, Рух чишмәсе исә – яшәү һәм үлем елгасының типик образы.

Һәр очракта да Г.Гыйльман әсәрләрендәге мондый урыннар үзенчәлекле маргиналь зоналар буларак кабул ителә. Һәм әсәрләрдә Җир кешеләренең аларның асылына төшенә алмавы, шуңа күрә аларга тискәре караш урнашуы, сихер, явызлык, убыр урыны дип аталуы күрсәтелә. Әмма әсәрләрнең ахырында бу оппозицион каршылык кешеләрнең дә, әлеге маргиналь зоналарның да асылын ачарга ярдәм итә. Үзләрен дөрес юлда, гадел гамәлдә, изге нияттә дип белгән кешеләр изгелек, рух, илаһият белән бәйләнештә торган һәм аларның җаннарын саклап торучы бу маргиналь урыннарга караганда явыз, начар булып чыгалар. Тормыштагыча.

«Оча торган кешеләр» повестенда кулланыла торган Тау поэтик образы төрле халыкларның мифологиясендә дә бердәй чагылыш тапкан. Борынгы төркиләрдә Тау образы изге (сакраль) җир буларак кабул ителгән һәм ул Җир-Су культының бер өлешен тәшкил иткән. Әлеге образга нинди мәгънә салынган соң? Галимнәр фикеренчә, мифологиядә Тау галәм моделен чагылдыручы образ, дөньяның үзәге саналган (В.Топоров). Галәм күчәре менә шушы тау аша үтеп, югарыга таба дәвам итә һәм Казык йолдызының урынын күрсәтә. Тауның аскы өлеше җир асты дөньясын фаразлаган. Мондый тау өч дәрәҗәле итеп күзалланган. Тауның башы – Аллаһ урыны, уртада – Җирдә – адәм балалары яшәгән, тауның астына төрле рухлар хуҗа. Мондый бүленеш, күргәнебезчә, Г.Гыйльманның «Оча торган кешеләр» әсәрендә дә чагылыш тапкан. Тауның эчендәге мәгарәнең түбәсенә дә Җир белән Космосны бәйләп торучы Чулпан йолдызы ясалган. Язмышлары Чулпан йолдызы белән бәйле Сәүбән, аның әтисе, улы һәм Сәвия аны Тәңре-Алланың тәхете буларак кабул итәләр.

Татар мифларында, гадәттә, тауның куышы булуы әйтелә. Кала-тауның да куышы сурәтләнә, аның аша өлкән Сәүбән дә, аның улы да икенче дөньяга – серләр дөньясына керә. Шушы урында татар язучысы Адлер Тимергалин иҗатында тау-мәгарә образлары искә төшә. Мәгарәгә алып керүче бу куыш серле генә түгел, куркыныч та. Бу куышны бары Сәүбән кебекләр генә белә, чөнки алар гына әлеге тау белән нindидер бәйләнештә тора. Бу бәйләнешнең асылын эзләү әсәрнең буеннан-буена сузыла һәм бары ахырда гына ачыла. Нәкъ менә җаннары Илаһият белән бәйле затларга гына Тауның (Яшәешнең) яшерен куышы (эчке ягы) билгеле.

Автор «Оча торган кешеләр»дә КЕШЕне төрле вакыт аралыгында мөстәкыйль яшәүче образ итеп карый. Моннан үткән – бүгенге – киләчәк кебек ВАКЫТның төп категорияләре хронологик тәртиптә итеп түгел, ә бәлки, бер-берсенә параллель агучы-яшәүче күренешләр итеп кабул ителә. Балачак образы романда күпчелек кешеләрдә Җир тормышы шартларында уяна алмый калган Илаһият чаткысы булган РУХның метонимик чагылышы итеп карала. Әлеге Рух-балачак үзенең яшәү фәлсәфәсе белән реаль Сәүбәннән күпкә өстен тора.

Мондый сурәтләү стилендә без авторның «җан мифологиясен», ягъни дөньяны тою (кабул итү генә түгел!) рәвешен күрәбез. «Оча торган кешеләр» повестен укый башлау белән үк фәлсәфи фикерләрнең күп булуы күзгә ташлана. Хәтта вакыт-вакыт «вакыйга үстерелгәнме», «кайчан үстерелгән» дигән фикерләр дә онытыла башлый, чөнки автор укучыны яшәеш, аның мәгънәсе хакында уйланырга этәрә. Әлеге романда чагылыш тапкан онтологик карашлар әдипнең Җир тормышын ике яссылыкта каравын дәлилли: беренчедән, бу – вертикаль линиягә куелган Тудыручы һәм Җир яссылыгы; икенчедән, горизонталь линиядә тасвирланган Чор һәм Гомер яссылыгы.

Тудыручы һәм Җир – Җиһан метафизик вертикаленең үзәгенә җан-күңел категориясе куела. Монда дини-суфыйчыл әдәбияттан ук килә торган «Тәңрегә омтылган» күңел мотивы өстенлек итә. Бу яссылыкта «җан» яшәеш дәвамында, Тукайча әйтсәк, «төрле тап-тутларга өртелгән», әмма һәрдаим «югарылык белән типкән» субстанция рәвешендә күзаллана һәм гәүдәләндерелә.

Г.Гыйльманның кайсы гына әсәренә тукталсак та, аның тирән дәрәҗәдәге экзистенциаль әсәр булуына шик калмый. Аларда бүгенге кешелекнең яшәү рәвеше яктыртыла. Шушы яктан шәхсән «Оча торган кешеләр» әсәре күпмедер дәрәҗәдә икенче бер күренекле әдибебез Миргазиян Юнысның «Җәяүле философ» новелласына охшаш. Миргазиян Юныста цивилизациянең рухны үтерә торган казанышлары санап кителгән булса һәм герой шуннан арынуны рухи-җисми бәхет итеп тойса, Г.Гыйльмановта җәмгыять белән шәхес арасындагы каршылыкның нигез сәбәпләре эзләнелә, һәм автор аны табып, укучыга сәнгатьчә җиткерә. Бу – Күкләрдән, Илаһияттән «күндерелгән» җаннарның Җир кысаларында үз тиңнәрен таба алмыйча газаплануы. Нигә? Чөнки – Җирдә дөрес-гадел яшәлми.

Төрле халәттәге образларны (Сәүбән һәм бала Сәүбән) һәм төрле чор буынны якынайту, очраштыру, аларны бәхәстә, каршылыкта күрсәтү бу геройлар арасындагы бәйләнешнең чынлыгын, зурлыгын, мөһимлеген ача, бер образның эченнән икенчесен чыгару һәм ирреаль «балачак» образының метонимик кысаларда рухи халәтне аңлатуы, әсәр ахырында автор кулланган метаморфоза-әверелү (геройларның әллә физик, әллә астраль дөньяда Җирне ташлап очып китүләре) борынгы чорларда булырга мөмкин вакыйгаларны гына түгел, ә киләчәкне дә фаразлый кебек. Бу исә поэтик күзаллау, поэтик фикерләүнең аерылгысыз чагылышы. Димәк, Г.Гыйльманның «Албастылар» әсәрендә генә түгел, ә «Оча торган кешеләр» әсәрендә милли-менталитетны формалаштыручы, тәшкил итүче мирас (үткән) һәм күрәзәчелек (киләчәк) үрелеп бирелгән. Мәңгелекнең шушы ике полюсы (ә бит ул безнең һәркайсыбызның чагылышы) Җиргә килү, яшәү серен, мәгънәсен ачыкларга тырыша. Аны бары тик киләчәккә үтеп, аннан бүгенгегә борылып карап кына аңларга мөмкиндер. Бүгенге татар әдәбиятында укучыны чаң кагып уята торган фәлсәфәләрнең мәҗбүрие шушы. Шуны аңлаган милләт белән генә без тарихыбызны дөрес, ихлас аңлый алачакбыз. Шуны аңлаган милләт кенә татарның үсеш стратегиясен, сәясәтчеләр кулына бирмичә, үзе әйдәп барачак, үз телен, динен, милли рухын саклап калачак.

Г.Гыйльман әсәрендә чагылыш тапкан тормыш-чынбарлыкны шул рәвешле сурәтләү, әлбәттә, реалистик юнәлеш кысаларына сыймый. Әмма монда традицион ислам–мөселман фәлсәфәсе генә түгел, минемчә, бу әсәр мөселман платонизмы кысаларында карала алыр һәм тулырак шәрехләмәләр табар иде. Реалистик сурәтләүләр әсәрне тотып торса да, Г.Гыйльман вакыйгаларны чынбарлыктагыча бирүгә омтылмый, ул, фани дөньяның ахырзаманга таба баруын күрсәтергә омтылган кебек, символиклыкка мөрәҗәгать итә, мифлар кимәленә якын килергә тырыша. Ләкин шул ук вакытта аның әсәре илаһилыкны төп сурәтләү объекты итеп алган дип тә әйтеп булмый, бәлки, әсәр дә, автор да бары шул илаһилык эчендә генә карала алалардыр. Инглиз язучысы Айрис Мердокның кешелеккә карата әйтелгән: «Мы путники, застигнутые ночью врасплох, охваченные ужасом бытия» дигән сүзләрен Г.Гыйльманның әлеге повестенда Сәүбән образына карата да, тәүге экзистенциаль романы «Албастылар»ның идея-эчтәлегенә карата да эпиграф итеп кулланырга мөмкин булыр иде.

«Албастылар» романы күпмедер дәрәҗәдә язучының иҗади эксперименты итеп каралган, кабул ителгән булса, аннан соң дөнья күргән повесть һәм хикәяләре әдипнең ныклы экзистенциаль карашларын чагылдыруын дәлилли алдылар. 2005 елда Г.Гыйльмановның «Китек ай», 2014, 2016 елларда «Тәкъдиргә юл» һәм «Ходай бүләге» повесть һәм хикәяләр тупланмалары басылып чыкты. Биредә әлеге җыентыкларга кергән әсәрләрнең экзистенциаль фикерләү параметрларын җыеп, аларны да бер системага салып карарга тырыштык. Китапка кергән әсәрләрнең төп идея эчтәлеге катлаулы: ул – тормышның мәгънәсен тану өчен кешенең яшәү максаты акыл белән кабул итеп була торган дөнья чикләреннән чыгарга тиешлек турындагы карашка тоташа. «Фәрештә», «Күрәзә», «Җанбалык» кебек повестьларда, хикәяләрендә дә фәлсәфи эчтәлекне тудыруга булышлык иткән төп нигез шундый. Бу әсәрләрдә дә авторның фәлсәфи карашлары өчен реализм методының тарлыгы үзен сиздерә, шуңа да вакыйгалар тудыруның яңа алымнарына мөрәҗәгать итү зарурилык булып чыга.

«Ходайга юл» җыентыгына кергән повестьларның күбесендә яшәү һәм үлем кебек мәңгелек темалар өстенлек итә. Мисалга, «Җанбалык» әсәрен алыйк. Монда инсан яшәешенең асыл мәгънәсе һәм үлем темасы калку гәүдәләндерелә. Яшәеш темасын автор берничә яссылыкта ача. Иҗтимагый планда бу – авыл, аның кешеләре, Газиз карт белән Фатыйма карчыкның тормышы. Әмма биредә ул әдип өчен үзмаксат түгел, ул арткы планга чигә. Әсәрнең конфликты исә этик яссылыктагы яшәү фәлсәфәсенә күчерелә. Г.Гыйльман Газиз картның яшәве һәм аеруча үлеме – Җирдә яшәешнең төп аспектларын чагылдыручы категорияләр буларак күзаллана. Газиз картның тыныч һәм зирәк акыл

белән кабул ителгән тормышы, үлеме, яшәүдә артык сабыр, талымсыз булуы, яшәүнең мәгънәсен аңлауда фикерләренең ачыклыгы, үлем каршысында бераз куркуга төшсә дә, аның котылгысызлыгын (!) һәм бөеклеген (!) аңлап, тыныч күңел белән кабул итүе – болар барысы да Сабан туе мәшәкатьләре белән мәш килгән, табигатьнең олуг үзгәрешләрен (көз җитү, яз, җәй фасылларының асылын) гадәти күренеш кебек кабул иткән һәм башка җан-җисемнәрне бары үз мәнфәгате өчен яратылган дип санаучы адәм балаларының кыланышларына каршы куеп сурәтләнә. Болай тасвирлауның максаты – Үлем каршысында Яшәешнең бөеклеген, матурлыгын аклау, ачу да, инсаннарның башкарган гамәлләренең абсурдлыгын (үлеп яткан Газиз картка кыздырган балык китерү һ.б. эпизодлар) раслау да булып яңгырый. Авылның көндәлек мәшәкатьләре табигый кебек кабул ителсә дә, без анда ныклы иман-ышануның юклыгын, кешеләрнең күбесенә рух, җан тынычлыгы төшенчәсенең – ят, сүзләрнең һәм гамәлләрнең буш, файдасыз булуын да тоябыз. Шул рәвешле, әсәрдәге иҗтимагый контрастлык повестьның төшен тәшкил иткән этик аспектны (Яшәү этикасы, кирәк икән Үлем этикасы) яктырту аша җиткерелә.

Этик яссылыкта Г.Гыйльманов өчен әхлакый критерийлар мәсьәләсе һәрдаим мөһим булып кала бирә. Җанбалык кебек беренче карашка фантастик тоелган образның гәүдәләндерелүе аша без яшәеш турындагы бөек һәм ахыргы хакыйкатьне таныйбыз, танырга мәҗбүр булабыз. Бу яктан караганда, Газиз карт бәхетле, чөнки ул илаһиятнең яшәеш белән бәйле серенә төшенеп, дөньядан уза.

«Фәрештә» һәм «Күрәзә» повестьларында югары фәлсәфи мәгънәсендәге дөньяны кабул итүгә хезмәт иткән аң-акыл һәм яшәү, сайлау иреге төшенчәләре арасында каршылык җитешә. Беренчесе шәхеснең эчке асылын, сурәтен чагылдыручы категория булса, икенчесе яшәешне дәвам итү, хәрәкәткә китерү өчен әһәмиятле фактор итеп кабул ителә. «Күрәзә»дәге Рухия гадәти яшәештә күреп бетерә алмаган ирреаль яссылыкны әсәр дәвамында күзгә күренеп үскән, камилләшә барган аңы-акылы белән үлчәп, үзенә бирелгән җаваплы миссиядән – язмышларны алдан күрүдән баш тарта.

«Фәрештә» әсәрендә шушы ук фәлсәфи мәсьәлә Үлем темасына бәйле рәвештә Йосыф образы аша ачыла. Кешелек сыйфатларын югалту эчке яктылыкны, нурны, рухи асылны югалту бәрабәренә ирешелә. Бомж кыйфәтле, тышкы асылыннан ваз кичү аша Йосыф эчке, рухи бөтенлеккә ия була. Рухи бөтенлекне формалаштыруга сәбәпче итеп бирелгән Бакый образы илаһилык белән яши һәм илаһилыкта эреп югала. Бакый фәрештә-пәйгамбәр итеп кабул ителә. Моны интуитив кабул иткән Йосыф та үзендә җан Һәм рух тынычлыгын тоя. Икенче бер герой Рәмиләнең элекке «мине» белән яңа формалашып килгән «мине» арасында көрәш туа. Аның үрнәгендә Җир тормышындагы хаосны бары тик көчле, бөтенлекле рухлы инсаннар гына җиңеп чыга, аңа каршы тора ала дигән фикер калдырыла. Бу повестьта да Яшәешнең хакыйкыйлыгы адәм баласының илаһияткә якынлыгы белән үлчәнә.

Повестьта иҗтимагый пласт инсан образы аша ачыла. Яшәешнең төп фигурасы булган инсан категориясен монда Йосыф, Рәмилә, Фәүзия карчык, өлешчә Бакый образлары формалаштыра. Укучы өчен Йосыф Һәм Рәмилә кебекләр үз асылына кайтучыларның күңел диалектикасы, фикерләре әһәмиятле урын тота. Повестьта ачылган иҗтимагый, әхлакый-этик һәм психологик аспектлар Яшәеш категориясе тирәсенә «тупланып бирелгәннәр». Әсәрнең мәгънәви һәм композицион төзелеше шушы әһәмиятле төшенчәне ачуга корылган, шуңа да бу әсәрдә төп метод итеп реалистик тасвир тудыру алымы сайланган. Ныклабрак карасак, яшәеш белән бәйле фәлсәфи абстракцияләнгән ситуация юк та кебек; ул реалистик планда тасвир ителгән вакыйгалар артына яшеренгән. «Албастылар», «Оча торган кешеләр» әсәрләренең экзистенциаль яссылыгын кабул итүгә күнегә барган укучыны реалистик тасвирлау монда ялыктырмый, киресенчә, зур фәлсәфи мәгънәне ачуга корылган повестьның хакыйки асылын аңлаешлы итә. Шулай итеп, экзистенциаль фикерләгән әдипнең иҗади эзләнүләре бу юлы реализм алымы кысаларында сәнгатьчә тормышка ашырыла.

«Фәрештә» әсәре дөнья һәм кеше арасындагы мөнәсәбәтләрне традицион тасвирлау белән экзистенциаль проблематика берлегендә җиткерә алган.

Без бу язмабызда Галимҗан Гыйльман әсәрләрен фәнни яктан тикшерүне нигез итеп алдык. Максатыбыз да татар әдәбиятын үз әсәрләре белән югары баскычка күтәргән иҗатка хас булган һәм XXI гасыр татар әдәбиятының йөзен, сыйфат үзгәрешен билгели торган яңалык-ачышларын барлау, әдипнең дөньяга карашларын ачыклау иде. Тикшерүче булсын, укучы булсын – аларның әдипкә куйган таләпләре зур. Яңадан-яңа образлы, идеяле әсәрләр тудырып торган язучыдан без тагын да кызыклы, тирән фәлсәфәле, психологизмлы роман, повестьлар, хикәяләр көтәбез. Шул ук вакытта гади укучы буларак, миндә туган теләкне дә чорның танылган шәхесенә ишеттерәсе килә. Яшәешне Тудыручы-Алла һәм Җиһан вертикаленә салып үлчәгәндә, әдип күбрәк тормыш-хәятның ниндилеген, нәрсә икәнен күрсәтүгә ныграк әһәмият бирә, ә менә аның ни өчен бирелгәнлеген ачу читтә кала сыман. Без тормышның үзенә карап уйлаудан, яшәү максаты, мәгънәсе хакында уйланудан читкә киттек. Ә бит сәнгать ул формалар-образларның коры төзелмәсе генә түгел, ә нәкъ менә билгеле бер метафизик карашларны ачу-чагылдыру өчен кулланылган, нәтиҗәдә, артында тирән фәлсәфә яткан киң бер дөнья. Бүген татар кешеләренең күпчелеге абстракт, экспрессионизм рухында иҗат ителгән рәсем сәнгатен, фәлсәфи музыканы кабул итә, аңлый алмый. Моның башы әнә шул XX гасырның 30 елларында халыкны рухи тамырыннан – диннән аеруга барып тоташа. «Дин белән сәнгатьнең ни бәйләнеше бар?» дияр кайберәүләр. Асылда, сәнгать (музыкамы ул, рәсем, әдәбиятмы) бөтен тамырлары белән дини-фәлсәфи өйрәтмәләргә барып тоташа, дини-фәлсәфи тәҗрибәләргә таяна. Бу тәҗрибәне авторлар үзләренчә үзләштереп, үзгәртеп бирә алалар, ләкин алардан баш тарта алмыйлар. Фәлсәфи эчтәлекле сәнгать әсәрләре диннән баш тарткан, аерылган, денсез укучы, тамашачы аңына барып җитмәскә дә мөмкин, чөнки аларның аңында мондый образ-тәҗрибә (архетиплар) аң-акылның өске катлавына чыга алмый. Шул сәбәпле халык (укучы, тамашачы) мондый әсәрләр белән кызыксынмый, аны кабул итә алмый. Әмма талантлы әдип, рәссам бернигә карамый, туктамыйча, укучыны шушы яктан «уятырлык» әсәрләр язарга, үз иҗаты белән аның аңын үстерергә бурычлы. Бу – язучылыкның төп миссиясе, вазифасы.

Г.Гыйльманның метафизик реализм кысаларында язылган, экзистенциаль проблемаларны яктырткан һәм онтологик карашларны гәүдәләндергән романнары, повесть һәм хикәяләре бүгенге татар сүз сәнгате кысаларында Шәрык Һәм Гареб синтезын матур итеп формалаштыралар, гасырлар дәвамында анык җавап табарга тырышкан яшәеш турындагы белемнәрне яңача дәвам итәләр.

Бу җәһәттән милли менталитетның архаик нигезләрен сәнгать дәрәҗәсендә ачарга омтылуда ул итальян Умберто Эконы хәтерләтсә, яшәештә илаһилык белән бәйле билге-тамгаларны гади укучыга күрсәтүдә һәм аны исән-имин Тудыручысына кайтарып бирергә тиешлекне искәртүдә Җанны «чәй кашыгына тамызган өч тамчы зәйтүн мае» символына төргән аргентиналы Пауло Коэльега охшап куя, Яшәешнең гаять катлаулы, гомер озынлыгына тиң туктаусыз хәрәкәт иттерә торган «юл» булуын ачуда төрек Орхан Памук, һәр күренештән, вакыйгадан яшәү-тормыш өчен кулланма эзли торган япон Харуки Мураками белән дә чагыштырып карыйсы килүдән әдип өчен дә, татар әдәбияты өчен дә горурлык хисе туа. Яшәеш турындагы милли карашларны чагылдыруда Галимҗан Гыйльман аларның барысына берьюлы охшаган да, охшамаган да; талантының үзгәлеге, индивидуальлеге белән ул үзенең бары милли татар җирлегендә генә туа һәм иҗат итә ала торган, дөнья һәм кешелек масштабында фикер йөртергә, шул ук вакытта милли менталитетның катлаулы күренешләрен милли җирлеккә салып аңлата алган сәләтле татар рәссамы буларак танытты, исбатлады.

**Алсу ШӘМСУТОВА,**
*филология фәннәре кандидаты.*

# РӘССАМНЫҢ ШИГЪРИ ИҖАТЫ

Бакый Урманченың исеме сәнгать дөньясында күпләргә таныш. Ул иҗат иткән уйма һәм рәсем сәнгате XX гасырның 20 елларыннан алып 80 еллар ахырына кадәр милли мәдәниятнең йөзек кашларыннан саналып килде. Моңа рәссамның табигый таланты да, тырышлыгы да, хезмәтенә тугрылыгы да ярдәм иткәндер. Тырышлык, хезмәт сөючәнлек, талантның органик бәйләнеше белән генә сайлаган һөнәреңдә нинди дер югарылыкка ирешергә мөмкиндер. Б.Урманче иҗатында болар бер-берсеннән аерылмас юлдашлар. Без фәкыйрегезгә татар халкының талантлы рәссамы һәм сынчысының шәхси архивы белән танышканда, аның фәнни тасвирламасын төзегәндә, бу фикергә кат-кат инанырга туры килде.

Рәссамның шәхси архивы хакында сүз кузгалгач, аның язмышын да искә алып үтү урынлы булыр. 2017 елда Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музее директоры Розалия Миргалим кызы Нургалиеваның тырышлыгы белән улы Айдар Урманчедан шәхси архивы музейның фәнни архивы фондына алынды. Шәхси архив бик тә бай, анда график әсәрләр, рәсемнәрнең төрле эскизлары һәм аларның каралама вариантлары белән янәшәдә шактый күләмдә рәссамның язма мирасы да тупланган. Язма мираста Урманченың төрле характердагы мәкаләләре, аларның кульъязма караламалары, аңа килгән шәхси һәм рәсми хатлар, тәрҗемәи хәлен эченә алган документлар, яза башлаган, күбесе каралама хәлендә калган хатирәләр һәм истәлекләре, 1930 – 1990 еллар дәвамында язылган шигырьләр, поэма, шигъри пьеса, тәрҗемә әсәрләрнең кульъязмалары, тарихи темаларга караган язмалар һ.б. белән танышырга, очрашырга мөмкин. Мирасны күз алдына китерәсең дә, Бакый аганың рәссам гына түгел, шагыйрь дә, галим дә, публицист та, язучы да булуына ышанасың. Әдипләр дә, галимнәр дә Урманченың бу сыйфатларын белмәүләре дә ихтимал, белсәләр дә, гаҗәпләнеп кенә карарлар. Бу – Бакый Урманченың яраткан шөгыле генә. Аңа югары таләпләр куярга кирәк тә түгелдер. Шунысы ачык: ул шөгыльләренә гомере буена тугрылык саклаган Бөек шәхес. Әдәби һәм сәнгати иҗат рәссам иҗатының бер-берсенә үрелеп барган аерылгысыз өлкәләре. Рәсемнәре, уйма иҗатында әйтеп бетерә алмаган фикерләрен кәгазь битләренә төшереп, сорауларына җавап та табарга теләгәндер.

Б.Урманченың истәлек-хатирәләрен күзәткәндә, рәссамның гомере буена әдәби иҗатка, шул исәптән шигърияткә тартылган, соңгы көненә кадәр шигырь язуын ташлый алмаган шәхес образы күз алдына килеп баса. Шигърият Урманченың сынлы сәнгатьтә илһам чыганагы да булгандыр, күрәсең. Җанына тынычлык таба алмаган кешенең ул кадәр сәнгать әсәрләре калдыра алуына ышану кыенрак, әлбәттә.

Урманче хатирәләрен укыганда да, тәрҗемәи хәлен язган язмалары белән танышканда да, иҗатка тартылуы инде бала вакыттан ук сизелә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган елларда, мәдрәсәнең иҗади мохите дә табигать биргән сәләткә тәэсир итми калмагандыр. Аның бер кулында гомер буена пумала, икенче кулында каләм тибрәнә. Рәссамның хатирәләре арасында иҗатка тартыла башлаган вакытын тасвирлаган бер чыганак та сакланган. Бу язма Б.Урманченың кайчан әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлавын ачык дәлилли дип уйлыйм. Түбәндәге мисал ул вакыйганы төгәлрәк раслый. Гомумән, рәссамның әдәбиятка килү теләген күрсәткән төп язмаларның берседер. Ул: «1918 елда мин әдәбиятка керешергә тырышып карадым. 1914 дә язгалаган нәрсәләрем бар иде. Аларны берәүгә дә күрсәтмәдем дә. Әмма 1918 дә шахтёрлар тормышыннан язылган әсәремне «Аң» журналына илтеп карадым. Сафа

Бакиевка укытып караган идем әүвәл. Әхмәдгәрәй абзый Хәсәни кайбер сүзләр хакында көлемсерәп алды да, язуымны шундук кире кайтарып бирде. Күңелсез булды, әлбәттә. Шуннан соң мин бары шигырьләр генә язгалый башладым. Анысын ташларга көчем, ихтыярым җитмәде», дип яза.

Б.Урманченың әдәби әсәрен «Аң» журналында басмасалар да, аның публицистик язмаларында әдәби әсәр алымнарын күрми үтү мөмкин түгел. Дөрес, алар шактый соң язылганнар. Шуңа карамастан, ул язмалар рәссамның әдәби талантын күрсәтә, дип саныйм. Бу очракта әдәби алымнар белән язылган берничә язмасын гына атап үтәрмен. Мәсәлән, «Ак беретлы кыз», «Гаҗизлек» мәкаләләре шул традициянең дәвамы дип карарга кирәктер. Рәссамның шәхси архивында шигъри әсәрләре бихисап. Ләкин алар 1930 еллардан гына сакланып калганнар. Бу – рәссамның шигырь язуга 30 елларда гына тотынган дигән сүз түгел әле.

Б.Урманченың шигърияте шигъри формалар белән дә, шигъри әсәрләрендә Шәрык һәм Гареб шигъриятенең синтезы яшәве белән дә әһәмиятле. Шигырьләрен күзәткәндә, рәссамның шигърият кануннарын яхшы белүенә игътибар итмичә булмый.

Шулай да рәссамның шигъри иҗатында Шәрык шигъриятенең роле зур. Бу аңлашыла да: Б.Урманченың «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә уку дәверендә Шәрык мәдәниятен, әдәбиятын өйрәнүе иҗатына да тәэсир итмичә калмый, әлбәттә. Ул, иң беренче чиратта, XX гасыр башы татар шигъриятендә Шәрык стиле, классик үрнәкләре, шул традицияләрне саклаган Дәрдемәнд иҗатына өстенлек бирә. Фарсы телен яхшы белгән Урманчега Шәрыкның бөек шагыйрьләре – Гомәр Хәйям, Сәгъди, Хафиз Ширазиларның да тәэсире сизелә. 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң, Россиянең иҗтимагый хәрәкәтендә барган үзгәрешләр мәдәни һәм әдәби барышка да зур йогынты ясый. Татар әдәбиятында Европа мәдәнияте һәм әдәбиятына хас алымнарны, юнәлешләрне кабатларга омтылу, жанрларга тартылу, шуларны пропагандалау, аларга сукырларча иярү башлана. Яңалыкка омтылган Б.Урманче да болардан читтә кала алмый, әлбәттә. XX гасырның 20 елларында рус шигъриятендә өстенлек иткән Маяковский стиле татар әдәбиятына да үтеп керә: Һ.Такташ, М.Җәлил, Г.Кутуйлар аның тәэсирендә иҗат итә башлый. Бакый Урманче да мондый өслүб белән мавыгып ала. Кыскасы, рәссамда ике мәдәният, ике әдәбиятның матур башлангычлары параллель яши, үсә, камилләшә.

Б.Урманченың шигъри әсәрләре арасында Шәрык әдәбиятының классик шагыйре Г.Хәйям традицияләрен дәвам итүе дә әһәмиятле. Рәссам шигърияттә берьюллыклар, икеюллык, өчьюллыкларга да битараф түгел. Аның шигырьләрендә боларга да мисаллар шактый.

Рәссамның фикерләү киңлеген, тирән уйлый белүен, дөньяга карашын билгеләгәндә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыганда, аның гарәп телен, Коръәнне ныклап өйрәнүен, «лаеш шулпасы» эчкән елларда рус телен өйрәнә башлавын, Мәскәүдә укыган елларында фарсы теле буенча белем алуын, инглиз, алман телләрен үзлегеннән үзләштерүен, хатирәләреннән күренгәнчә, төрки, рус һәм славян халыкларының күренекле шәхесләре белән аралашуын, фикер алышуларын искә алырга кирәктер. Боларның берсе дә Б.Урманченың фикерләү сәләтенә, сәнгате һәм шигъриятенә йогынты ясамыйча калмаган. Аның шигъри әсәрләрендә бөтенләй башка дөнья, башка алымнар, башка стильләр хакимлек итә. Тематикасы киң. XX гасырның дәһшәтле вакыйгаларына карата рәссамның үз мөнәсәбәте бар. Ул мәңгелек мәхәббәт турында да, туган якка, табигатькә, Иделгә карата илаһи мәхәббәт турында да яза. Рәссам лирик-фәлсәфи шигырьләрендә фаҗигале татар тарихын эчке психологик кичерешләре аша тасвирлауга ирешә. Аның шигъри мирасы оригиналь әсәрләрдән генә тормый, ул тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. Тәрҗемә эшчәнлегендә аеруча төрки һәм фарсы телле шагыйрьләргә өстенлек бирә. Шулай ук ул Американың күренекле шагыйре Генри Уодсворт Лонгфеллоның «Гайавата турында җыр» поэмасын инглиз теленнән турыдан-туры тәрҗемә итәргә алынган. Беренче өч бүлеген тәрҗемә иткән. Караламада инглиз теленнән аерым сүзләрнең

тәрҗемә вариантларын язып кую Урманченың әсәр белән оригиналдан эшләвен дәлилли. Дөрес, XX гасыр башында бу әсәрне рус теленә танылган рус әдибе И.Бунин тәрҗемә иткән. Әмма И.Бунинда булмаган урыннарның, шигырь техникасындагы үзгәлекләр Урманче иҗатының бер үрнәге булуын раслый. Болардан тыш, ул Шәрык әдәбиятының классик әсәре – «1001 кичә» кыйссасы буенча «Шаһрезадә» исемендә шигъри пьеса да язарга алынган.

Күренә ки, Б.Урманченың әдәби иҗат таланты да ташып торган, рәссамның иҗатка дәртен, тормышка, яшәешкә дәрманын бервакытта да сүндерми саклап килгән энергия чыганагы буларак хезмәт иткән.

Түбәндә Б.Урманченың шигъри иҗатыннан үрнәкләр тәкъдим ителә. Укучы укып, фикер әйтер, рәссамның әдәби мирасына үзе теләгәнчә бәя бирер.

**Зөфәр МӨХӘММӘТШИН,**
*шигырь текстларын басмага әзерләүче.*

***

Киң илемнең кырларында гизгән заман,
Ямьле гөлләр, ал чәчәкләр күрер булдым.
Аһ чәчәкләр тулы илем, моңлы илем,
Йөрәгемдә сызландырыр яра булдың.

***

Тормыш кагылмаларында кагыла-сугыла
Ямьшәйгән, уалган вә таушалган,
Күңелеңдә минем өчен, и йончылган җан,
Нинди дәрт вә нинди наз калган?!
*1934*

***

Башымда гөнаһлы уйлар кайный.
Бер исерсәм көннәр гаугасыннан,
Соңра янә уйлар, янә айныйм.
*1935*

## Чучка

Чучкага куштылар гөлзарда[1],
Арулык вә җыйнаклык сакларга.
Әгәр шакшы түксәләр юлларга,
Чүпләсәләр почмакларны,
Барын да арындырырга һәм пакьләргә...
Дөрест,
Чучка
Киереп бер батман бутка,
Тулгандай бер корсагын,
Танавын мыркылдатып йөрде,
Почмактан почмакка.
Гүя шакшыларны арындырды,

[1] Гөлзарда – чәчәклектә.

Ләкин артында,
Сөйләр хәл юк,
Шундый шакшы,
Вә шундый җирәнгеч
Эз калдырды.
*28.02.1936*

***

Меңнәр, меңнәр узган
Иске тарих лабиринтларының,
Туфракка әверелгән хәрабәләрендә,
Ниләр булган?
Мин бихәбәр.
Меңнәр вә меңнәр алда.
Томанлы киләчәк юлларында,
Таңнарында ниләр туачак.
Ни булачак?
Мин бихәбәр.
Ниләр бу минут җиһанда,
Ниләр көтә мине туачак таңда,
Бәхетем арттамы, әллә алда
Ни булыр?
Мин бихәбәр.
*31.07.1936*

***

Бөтен дәрт вә теләкләремне горбәттә[2]
Ташып, үзем белән караңгы гүргә,
Алып китәрмен, ахры.
*1942*

***

Караңгы кич. Төннәрнең күкләрендәй чиксез тирән,
Күңелемә исәпсез сагыш, хафа, моңнар тулган.
Шул тирән сагышлар дәрьясында җемелдәшеп,
Бер-ике нур. Башка өмид, ышанулар бар да сулган.
Күкрәгем ләхеттәй тар,
Гомерем буе чиккән җәфа алынмаган,
Очар һәм ирешмәгән,
Көчле сөю, кайнар гашыйк табылмаган назлар минем,
Шулай кылган.
*1942*

***

Ходаем, изге иҗат күк яраткан,
Җиргә юлдаш булсын диеп, көн йөзенә,
Җир шикелле үк түгәрәк ай яраткан.

Дөньяны нурлау өчен көн яраткан,
Көнгә авыр булмас диеп алмаш өчен,
Күгелҗем йолдыз тулы төн яраткан.
*1942*

[2] Горбәттә – иленнән, туганнарыннан читтә, ялгызлыкта.

***

Раббым, син
Кодрәтең, иркең киң.
Югарыда, биектә гарше әгъляң[3],
Түбәндә, төпсезлектә, зәмһәрирең[4].
Син – бөтен җиһан,
Бөтен җиһан – син.
Чиксез, ниһаясез[5],
Иңсез һәм гаясыз[6].
Мин фәкыйрь,
Микробка тиң.
Минем өчен
Бу җир йөзе дә киң.

*1943*

***

Аерылышкан сәгатьтә нинди уйлар,
Нинди моңлы сагыш уйладым.
Күзләреңә карап үбеп-үбеп,
Назларыңны алып туймадым.
Күк күзләрем,
Наз сүзләрең,
Биткәйләрең үбеп туймадым.

*1944, 16 март*

***

Агып ел-ел булып гомерем,
Тулып гамь – кайгыдан күңелем,
Чайпалды гомерем,
Сазланды күңелем.

***

Дәрьяның йөзе кайчан дулкын була,
Кайчан дәрья көзгеләнгән тик тын гына.
Күңелемдә кайчак һәйҗан[7]: кайчан җаным
Сабырланып, назга талып, тып-тын була.

*1944*

## Базар

Монда гыйzzәт, оят, монда вөҗдан,
Кайсы хаҗәт –
Бар да сатыла.
Кайсын теләсәгез – бирик шуннан.
Бу малларың синең бар да калган,
Үтәлмәгән иске зәкяттән[8].

*1945*

[3] Гарше әгъляң – күкнең иң югары катлавы, биеклек, югарылык.
[4] Зәмһәрирнең – көчле суык, каты салкын.
[5] Ниһаясез – ахыры булмаган, тәмамланмаган.
[6] Гаясыз – чиксез, ахыры булмаган.
[7] Һәйҗан – дулкынлана, эчтән курку төшә.
[8] Зәкяттән – ислам дине буенча сәүдәгәрләргә еллык керемнең 40 тан бере күләмендә салынган еллык салым.

***

Мәхәббәтем күңелемә наз бирмәде.
Егетлегем җаныма яз бирмәде.
Бәгыремдә күпме дәртләр тупласам да,
Җырлар өчен кулыма саз бирмәде.

Гыйшкымнан көн саен хурлык алдым,
Наз сөйләсәм, каршыга тиргәү алдым.
Җир йөзенә гөл игәм, дип тырмаласам,
Гүремә түшәк кылып гамьләр салдым.

*1945*

***

Аз-азлап барыннан күңелем кайта,
Дөньяның күбен хәзер кире күрәм.
Нәфрәт туа, кәмите тормыш булып,
Тормыш шакшы тамашага әверелә.

*1949 лардыр*

***

Казанда юк учак,
Мәскәүдә почмак.
Гүя телиләр күңелемә
Кадарга канлы пычак.

*1949*

***

Ходай сиңа таләпне, комсызлыкны,
Муллап биргән.
Җан көзгесе – чырайны хурлап биргән.
Оятсызлык, әрсезлегең һәр хәлдә,
Күренсен диеп, сәләтне кимләп биргән.

*1950*

## Дустлар юк

Караңгы-караңгы төннәрдә,
Мамык мендәр белән шыпырт кына сөйлим.
Әмма ул,
Миңа серле җавабында,
Шомлы дастан, моңлы аһәң белән көйли:
Акрын!
Мамыклар ишетмәсен,
Безнең караңгы, караңгы төн серләрен.
Кем булса фаш итмәсен.
Гаҗәп, дөнья тулы халык, халык...
Әмма дустлар юк,
Дустлар юк...

*1951*

***

Кайчан кем, Аю
Рәис булып алды урманга,

Куяннар, бүреләр,
Хәтта төлкеләр
Кагылдылар бер якка.
Игълан кылды Аю урманга бөтен:
«Инде тыныч, татулык
Бу урманда кылсын хөкем».
*1954*

***

Гомерендә кем абынмый, җан иясе,
Тойгысына кол булмый? Кан иясе.
Гыйшкының куәтенә чыдый алмый,
Йолкынып алга омтылса,
Дәртле күңел,
Шул вакыт күрмәсә аяк астын,
Анда чокыр...
*1954, Балхаш.*

***

Дәртләр бар,
Дәрман да бар иде.
Узды яшьлек,
Буыннар какшады,
Җитте гомернең,
Эңгере, ахшамы.
*1956*

***

Явыз дошман
Үзен дуст дип атады.
Ышандым мин,
Вакытында белә алмадым хатамны.
Дәригъ[9], кайгы,
Белеп булмады ла алдан хатамны.
*1957*

## Васыять

Күзләрем бу дөньяга йомылса,
Каным җансыз, тәнем дәртсез суынса,
Барабаннар кагып,
Зинһар,
Йөрмәгез.
Тәңремнең дәргяһенә[10] лаек,
Тын гыйбадәт белән
Җирләгез.
Мөселман мин,
Тәмам исламча гүрләгез.
*1958*

[9] Дәригъ – үкенеч, кызганыч.
[10] Тәңремнең дәргяһенә – Тәңремнең ишек төбенә.

***

Гомерләр үтте, имәнеп, шикләнеп,
Эшләп булмады чынлап, ипләнеп.

*1958*

## Казанга кайту

Гыйшкым сиңа изге гыйшык яшьлегемнән
Сабырсызлык кылдым һаман яшьлегемнән,
Назыңа көфран кылып[11] азгын булдым.
Чыдамсызлык күрсәттем шул яшьлегемнән.
Кәгъбәгә кайттым кире яшьлегемнән,
Эзләгән кәгъбәдән юл сапканмын, буйлап китеп
Инде йөз синең нәзек[12] өмид итеп,
Эзләгәнне йөз тайдым яшьлегемнән.

*1958*

***

Юк, мин сине сызланып көтмим инде,
Йөрәгемдә кабызган тойгыларым.
Ялгышудан туктады,
Синең җиңел
Уйнавыңны белгәннән соң,
Күргәннән соң.
Бәхеттән өмид өзеп инде күңдем,
Ялкынланыр тойгыларны.
Болганчык су
Сибеп, үзең сүндердең.
Җибәр, дустым,
Ниләр булды? Аңламадым теләгеңне,
Татлы назың ачы булды,
Агу куштың.

*22.08.1960*

## Гөл вафат

Ал чәчкә дөньяга күзен ачты,
Кояш күреп, гөл йөзенә нурын сачты.
Чәчкә нурдан таңга калды,
Күреп шашты.
Үз күркенә сокланып,
Күңелен ачты.
Әйләнә-тирәсенә
Хушбуй назын сачты.
Бер гашыйк күреп гөлне
Күзе төште.
«Бүләк булыр ярыма», – дип,
Чәчкәне өзде.
Чәчкә сулды,
Чәчкә үлде.

[11] Көфран кылып – кадереңне белмичә.
[12] Нәзек – аз.

Шулай
Сылу гөлкәйнең гомере сулды.
Чәчкә вафат,
Чәчкә сулды,
Чәчкә үлде,
Чәчкә янә
Дөньяга күзен йомды.
*1960*

***

Бәдбәхет дип
Әйтергә сәбәбем юк.
Сагышлардан, хәсрәттән,
Җан, күңел тук.
*1960*

***

Күңел буш,
Чүлләнгән сахра.
Ниндидер бер өмид,
Кайдадыр чакыра.
*1960*

***

Күңел яшь,
Картайдым сагыш белән.
Хафаландым,
Бер яман табыш белән.
Кайгы-хәсрәт,
Күпләргә таныш, беләм.
Минем кайгым
Ил белән, халкым белән.
*1962*

***

Бүген күңелем буйлады[13],
Яман уйлар уйладым.
Бер керәле, бер чыгалы,
Үземне дә хурладым,
Керәле-чыгалы уйларым.
*1962*

***

Янар йолдыз дип уйласаң ул йолдызны
Нуры калган.
Йолдыз үзе күптән сүнгән,
Күптән сүнгән.
Йөрәгемдә гыйшык уты давырсыган,
Хыял кылма,
Тойгылар инде үлгән.

[13] Буйлады – буйсынмады.

Җаным тормыш давын даулаша дип,
Уйласаң син,
Ялгышасың, юк, уйлама,
Дауламаска җаным күнгән,
Җаным күнгән.
Аһ, изге нур, гыйшык нуры, бер балкыган,
Сөйгәнем белән бергә
Ул шаукымнар,
Гүргә иңгән,
Гүргә иңгән,
Гүргә иңгән.

*1962*

***

Гариб булдым[14], бу дөньяга
Ияләшәлмим.
Үз күреп күпләрне
Сөйләшәлмим.
Ни кылыйм, дөнья тулган ялган белән,
Хамнар[15] белән хамлашып көйләшәлмим.

*1962*

***

Яманлык кылганым юк,
Берәүгә дә,
Килер бер чак,
Әйтерләр,
Әйе, әйбәт тә иде
Соң ул.
Кызганыч, инде мәрхүм,
Инде юк ул.

*1964*

***

Олугларның олугы,
Кодрәтләрнең кодрәте,
Көчләр, дәрманнар хаканы,
Тәңрем – Табигать.

*1966*

***

Төрле моңнан йөдәгән
Тулган күңел,
Инде күптән корышкан,
Сулган күңел.
Могҗизалы кочагында,
Гөлбостаны[16],
Өмидле хыяллар корды күңел.

*13.06.1967*

---

[14] Гариб булдым – мосафир булдым, чит җирдә яшәргә мәҗбүр булдым.
[15] Хамнар – тупаслар.
[16] Гөлбостаны – гөлбакчасы.

***

Гомеремнең төшлеге күптән
Үткән,
Эңгернең алтынсу төсләре –
Хәбәрчеләр төннең килүен
Күренә күктән.

*1969*

## Айгөл

Гомеремнең ахырында килеп җиттең.
Могҗиза!
Исем китте. Хәйран калдым.
Нинди гаҗәп
Яшь мәхәббәт!
Күңелеңнең йомшаклыгы,
Сафлыгы тойгыларның –
Кайдан? – дидем.
Ай йөзле, кара күзле
Тубыл кызы!
Гомеремнең соңгы чагын син бизәдең.
Айгөлем!
Тагы бер Ай –
Айдар белән шатландырдың,
Гүя мине тулпарга атландырдың.
Ялгыз үзең җаныма ил булдың,
Башкаларның һәммәсен ятландырдың.
Көннәремнең нурлы юлдашы,
Төннәремнең моңлы тулган ае.
Аерма зур гомердә,
Һәй, булмагае!..
Янымда кара кашлы Тулганаем,
Син миңа баккан саен,
Айгөлем, Айларым,
Дөньяның бар хәсрәте онытыла
Син, назлап, кочагымда яткан саен.
Укуың, сөйкемле тавышың белән
Күпме тыңлаттың инде миңа.
Үзе бер сер, бер тылсым, бер гыйбадәт.
Укуың бер музыка бит.

*1970*

***

Уразасыз, намазсыз, ниязсызмын[17],
Ходаемнан.
Рәсүлемнән[18] башкага имансызмын.

*1971*

[17] Ниязсызмын – үтенечсезмен, ялварусызмын.
[18] Рәсүлемнән – пәйгамбәремнән.

***

Әлсерәдем, йөдәдем бу күренештән,
Җаным бизде, туйдым инде бу күренештән.
Үзебезнең көчебезгә өмид бетте,
Кайчан Хода коткарыр бу күренештән.
*1972*

***

Әҗәл житәр,
Газраил кичекмәс ул.
Ялыну, ялваруга
Бирешмәс ул.
Эше шул.
*1976*

## Өн

Давылдан килде бер өн,
Котырына диңгез көн-төн,
Бер көн...
Шашынып, хәлсезләнеп тынар,
Җилкәннәрен киереп,
Ярып дулкыннарның сыртын,
Йөзәрсең иркен,
Бер көн.
*1978*

## Сагыш

Йөрәгемнең ярасы бар уңалмаслык,
Ачынулар, көенечләр төзәлмаслык.
Аңымның үзәрендә авыр хәсрәт,
Гүя җанны басып яткан зур албасты.
*1979*

***

Вакыт тиз үтә,
Гомер җебен сүтә.
Гүя мине сагынып,
Каберем көтә.
*1980, февраль*

***

Яшьлектә гомер зур океан иде,
Инде калды кечкенә бер сазлык булып.
*1980*

***

Юк,
Матур ярны сөюдән ваз кичәлмим,
Сызландырыр гыйшыктан ваз кичәлмим.

Җирдә йөрим, җирдән алам көч, җирчә сөям.
Ходай биргән мәхәббәт тоткыныннан,
Корыган дәрвиш буласым килми минем.
Гашыйк булу тойгысыннан ваз кичәлмим.
*1980*

***

Башта кар.
Аякларда сызлау яман,
Йөрәгемдә кайнар наз, ялкын һаман.
Дәрт калган,
Дәрман калмаган,
Үткән заман,
Үткән ул заман.
*1981*

## Юлың...

Юлың кан силләре[19],
Туфрагын ачы күз яшьләр чылаткан.
Күпме газап, җан кыюлар,
Күпме ятимнәр малын талап җыюлар.
Юлың канлы юл,
Тарихың хәсрәт,
Бәгырьләр әрнетелгән еллар.
*1982*

***

Бер гончәнең хушбуеннан исерек бүген,
Гомеремне яшьлеккә таба сөрдем бүген.
Аһ, бу җүнсез күңел, җүнсез күңел,
Юлдан сапды бүген, сапды бүген.
*1982*

## Ул – син

Гыйшкымны юнәлдердем бөек Тәңре дәргяһенә[20],
Тойгыларның яхшысы да, яманы да
Гел аннардан.
Зөһрәнең нурлары очкын булып,
Төбәлделәр синең күкрәк үзәренә.
Гашыйк булдым халкымның бер гүзәленә,
Ул – син.
*1986*

***

Гамәлеңнең әҗерен көтәсең бик тиз,
Кыяматтә генә булуы мөмкин аның.

[19] Силләре – ташкыннары.
[20] Тәңре дәргяһенә – Тәңре ишек төбенә.

Начарлык эшләсәң генә бит ул,
Дөньяга фаш була даның.

*1986*

***

И адәм...
Әүвәл мал җыясың.
Комсызланып,
Аннары кол буласың шул малга.
Картаясың,
Малыңа сакчы булып,
Барсын да калдырып,
Үзең үлеп.

*1987, декабрь*

***

Бетте дәрман,
Дәрт тә бетәр сыман.
Алга, аңда корылган булса план,
Бар да бушлык, бар да гөман[21].

*1989*

***

Алдагы юл булса кыска гына,
Узганы бормалы, тармаклы.
Хатирәләр белән маяклanган,
Барысы да гөлләнгән моң вә зардан

*1990, март*

***

Акылымның чуалган чагы,
Тагы нинди уйлар килә икән, тагы.
Төннәр үтә йокысыз,
Көнне көтәм, кояш нурларын.
Тормышның нурлавы.
Гомер узды төрле өмид белән,
Өмидләр өзелгән чагы.

*1990, июнь*

***

Гомеремнең салмак агымлы, унча рәхмәте белән[22],
Аерылган дәверенә килеп җиткән идек инде.
Айгөл белән гомеремне яңа мәгънәви кыйммәтләр белән,
Талгын хәлендә дәвам итә әле.
Айгөл дә яңарак бер сыйфатта булып,
Мәгънәдар[23] сурәттә күренә.
Минем гомеремнең хуҗасы ул инде.

*06.08.1990*

[21] Гөман – уй, фикер.
[22] Унча рәхмәте белән – аерым (үзенә аерым) кичерүе, мәрхәмәте белән.
[23] Мәгънәдар – мәгънәле.

* Бакый Урманче хатирәләре белән журналыбызның киләсе санында (№3, 2022) танышырга мөмкин.



*Баһаветдин Әнвәр улы Аджиев (1950) – күренекле кумык шагыйре, драматург һәм тәрҗемәче. Ул Дагстанның халык шагыйре Әнвәр Аджиевның улы. Гамзат Цадаса исемендәге институтның филология факультетын тәмамлаганнан соң, Махачкаладагы Кумык театрының әдәбият бүлеге мөдире булып эшли. Аның «Тал сыбызгы» дигән беренче шигырьләр җыентыгы 1978 елда басылып чыга. Шуннан соң бер-бер артлы «Тере ташлар», «Вакыт кыңгыравы», «Бәләкәй космонавт», «Таш көзге», «Нарын-Кала» һ.б. китаплары дөнья күрә. Ул 1980 елдан бирле СССР һәм Дагстан Язучылар берлекләре әгъзасы. Баһаветдин Аджиев – күп кенә драма әсәрләре авторы да. Шулай ук төрле халыклар язучыларының әсәрләрен кумык теленә аударган тәрҗемәче. Аның шигырьләре 2017 елда Рафис Корбан тәрҗемәсендә татар телендә «Дуслар җыры» дигән җыентыкта дөнья күрде.*

Баһаветдин
Аджиев

# ЙӨРӘК ТАНЫЛА ТИБЕШЕ БЕЛӘН...

ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

* * *

Бик кадерле минем өчен бу мәкаль,
Син дә тырыш аны отып калырга:
«Тот исеңдә, дошманыңның дошманы
Бер көн мөмкин синең дустың булырга!»

* * *

Юләр булма, дустым, һәрчак бел шуны:
Дошманы бар һәркемнең җир йөзендә.
Әгәр дустың әверелсә дошманга,
Монда гаеп түгел микән үзеңдә?

* * *

Кемдер тиздән туар, кемдер тиздән үләр.
Авыр көннәрдә дә кал син шагыйрь булып.
Һәркемнең үз чоры, үз намзәте җирдә,
Кыштан соң яз килер – син онытма шуны.

* * *

Хатын-кыз еш кына күбәләккә охшый,
Һәм көзгесе белән еш хыянәт кыла.
Менә уйла шуннан: өйләнергә микән,
Әллә яшәргәме буйдак булып кына?

* * *

Бернәрсә дә кинәт булмый,
Төрле хәлләр төшә башка.
Иң мөһиме, тырыш, туган,
Башыңны син югалтмаска!

* * *

Куркыныч түгел мөҗәһит тә, абрек та –
Гайбәтче бар, чын явыз бар кара йөзле.
Бер пуля бер кешенең тик гомрен өзә,
Йөз кешене егып сала гайбәт сүзе.

* * *

Икмәк ул бөтен нәрсәгә дә баш,
Начар булалмый икмәк берчак та.
Начар шул – кайсы чамадан тыш тук,
Алла барлыгын онытa хәтта.

* * *

Әмер биреп булмый һәрчак горур сүзгә.
Син ашыкма аны уйламый әйтергә.
Һәр әйткәнең хәдискә тиң дисең мәллә?
Кертергә дә мөмкин сине сүз кабергә.

* * *

Шигыреңне син тегәсең ак җеп белән.
Әкиятләргә ышанырга син ашыкма.
Буталып, син хыялларың җепләрендә
Шигыреңдә салма зыян  чынбарлыкка.

* * *

Ирнең бәхете – аның Ватаны,
Бу хакта һәркем әйтәчәк сиңа.
Ә кем Ватанын бер кат сатса да,
Ватаны җәза бирәчәк аңа.

* * *

Халык бәхете дип, гел сөйләнә,
Төкерек чәчә мактап тауларны.
Баксаң, үзенең хәзергә кадәр
Юк икән лә бит яклар Ватаны.

* * *

Аксакалның киңәшенә салмадым колак.
Сүзләренә аның бары карадым көлеп.
Бар уйларым, хыялларым шул вакыт миннән
Читкә качып гаеп булды кыргый ат кебек.

* * *

Әгәр хакимлек изсә халыкны,
Күпкә куркыныч дарга менүдән.

Йа Хода, кайчан котылыр халык
Илгә баш булган шундый чирүдән?!

* * *

Зирәк акыллы, намуслы затка
Хөрмәт, ихтирам булмаган җирдә,
Селәгәй агып торган этнең дә
Урыны була еш кына түрдә.

* * *

Саранга килсәң, заяга булыр,
Капчыгыңа ул бер телем салмас.
Тик сине күргәч, сүзе күп булыр,
Капчыгыңа да сыеп беталмас.

* * *

Шундый бер кеше белән мин таныш:
Кесәсе буп-буш, ә үзе кеше.
Ә ишәк калыр гел ишәк булып,
Алтыннан япкан булса да түше.

* * *

Бөтен нәрсәң дә бар кебек болай,
Акчаңны тавык чүпләп бетермәс.
Ләкин намуссыз булсаң, яныңа
Хәлең белергә беркем дә кермәс.

* * *

Йөрәк танылa тибеше белән,
Агач таныла җимеше белән.
Яңгыр шыбырдый, ерткыч ырылдый,
Кеше таныла тик эше белән.

* * *

Карга карганың күзен чукымас,
Бай хәерченең күзенә бакмас.
Хәерче байга төкерер дә, тик
Байның күзеннән тамчы яшь акмас.

* * *


Һәрвакытта да колдан кол тумас,
Бөкрегә дә дан килә беркөн.
Күңелең белән булсаң син мескен,
Колга әйләнеп китү бик мөмкин.

* * *

Койган кылыч – ул бары тик кылыч кына,
Кынында ул тик ятачак тыныч кына.
Беркемгә дә сугыш белән бармаячак,
Илне генә сугышлардан саклаячак.

*Кумык теленнән* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәләре.*

# МАҖАРА ТӘРҖЕМӘСЕ ЯКИ ТӘРҖЕМӘ МАҖАРАЛАРЫ




Марат Кәбировның үсмерләр өчен язылган «Убырлар уянган чак» исемле маҗаралы әсәре төрек теленә тәрҗемә ителде[1]. Бу эшне Төркиядә яшәүче милләттәшебез Алсу Камалиеваның шәкертләреннән берсе Алп Әрән Дәмиркая башкарды. Татар телен югары дәрәҗәдә үзләштергән Алп Әрәннең бу беренче генә тәрҗемәсе түгел инде: моңа кадәр аның тарафыннан Әмирхан Еникинең әсәрләре төрекчәгә «аударылып», Истанбул нәшриятында «Бер генә сәгатькә»[2], «Онытылмас минутлар»[3], «Система колы»[4] исемнәре белән өч китап булып басылды, шулай ук Ә.Еники иҗатына багышланган монографиясе[5] дә татар әдәбиятын сөючеләргә матур бер бүләк булып иреште. Анкарадагы Гази университетын бетергән, диплом эшен татар теле буенча яклаган, бүгенге көндә исә Бартын университетында укытучы яшь галим татар әдәбияты буенча кандидатлык диссертациясе яза, актив эзләнә, каләме җитез һәм шома.

М.Кәбиров әсәренең тәрҗемәсе басылып чыгу шатлыгын Алп Әрән бәй интернетта үзе бүлеште, миңа исә китапның электрон вариантын җибәрде. «Убырлар уянган чак» текстын Марат Кәбировның рәсми сайтыннан (www.maratkabirov.com) алып тәрҗемә иткән дип аңладым, чөнки бу хәл автор өчен дә бер сюрприз булганга охшый: «*Бу елның тагы бер сөенече. Казанышым дип булмый, чөнки бу китап чыксын өчен мин бер төк кыл да кыбырдатмадым. Алп Әрәнгә рәхмәт! Аның гаиләсенә, якыннарына шатлык-бәхет телим. Бу китап бездә ничектер күләгәдәрәк калды бугай. Төркиядә, бәлки, укучылар күбрәк булыр. Һәрхәлдә, мин шуңа өметләнәм*», дип язды М.Кәбиров узган елның 30 декабрендә фейсбуктагы сәхифәсендә. Төркиядәге нәшриятлар, гадәттә, китап тәрҗемәләрен бастырганда, автор хокукларын яклау максатында, язучыдан рәсми рөхсәт алалар, бу очракта андый рәсмилек сакланганмы, белмим, авторның шатлыгына караганда, әлеге мәсьәләдә нинди дә булса аңлашылмаучанлык юк кебек.

Татар әдәбиятының, аеруча бүгенге көндә язылган әдәби әсәрләрнең, төрекчәгә тәрҗемәләре, ни кызганыч, юк дәрәҗәсендә, шуңа күрә Алп Әрән кебек татар теленә гашыйк яшьләрнең Төркиядә барлыгын белү генә җитми, аларның иҗат осталыгын, камиллеген үстерү дә бик әһәмиятле. Шул максаттан, бу язмамда «Убырлар уянган чак» әсәренең татарчасы белән төрекчәсен чагыштырып, икесе арасындагы четерекле урыннарга һәм кайбер хаталарга кагылып китәргә булдым. Ник яшерим, төрекчә тәрҗемәсе чыкмаса, бәлки, повестьның[6] оригиналын укымый да калган булыр идем, төрек аркадаш аркасында М.Кәбиров әсәрен Яңа ел ялларында укып чыгарга мөмкинлек туды.

Марат Кәбировның бу әсәре бүгенге әдәбиятыбыз өчен яңа бер жанрда язылган:

---

[1] Marat Kebirov. Vampirlar Uyandığında. Çeviren: Alp Eren Demirkaya. Istanbul, Paradiğma Akademı. 2021. 256 s.
[2] Emirhan Yeniki. Bir Saatliğine. Çevirmen: Alp Eren Demirkaya. Istanbul, İdeal Kültür yay. 2021. 156 s.
[3] Emirhan Yeniki. Unutulmaz Dakikalar. Çevirmen: Alp Eren Demirkaya. Istanbul, İdeal Kültür yay. 2021. 177 s.
[4] Emirhan Yeniki. Sıstemın Kölesi. Çevirmen: Alp Eren Demirkaya. İstanbul, İdeal Kültür yay. 2021. 138 s.
[5] Alp Eren Demirkaya. Emirhan Yeniki'nin Hikayeciliği. İstanbul, Hiper yay. 2020. 276 s.
[6] М.Кәбиров үз сайтында әсәр турында болай дип яза: «Дөнья әдәбиятында убырлар хакында язылган романнарның чиге-чамасы юк. Хәтта иң күренекле дигәннәре генә дә ике йөзгә якын. Ләкин татар әдәбиятында моңа кадәр бер язучының да бу темага тотынганы юк иде әле. Татар әдәбиятының вампирлар турындагы беренче романы...» Күләме һәм сюжет эшләнеше буенча мин бу әсәрне роман дип түгел, повесть дип атарга булдым.

хәзерге заман балаларының мавыгып карый торган кино-мультфильмнарда яки компьютер уеннарында курку хисе уята торган кан эчүче вампирлар турында әле татарча әсәрләр юк иде дип беләм. Дөнья курку әдәбиятының (литература ужасов) классик алымнары кулланылып, татар җирлеге һәм гади татар авылы кешеләренең вампирлар һөҗүменә дучар булуы, күп кенә кеше һәм хайванның һәлак булуы сурәтләнә. Язучы татар укучысына дөньякүләм «вампир әдәбиятының» күренекле авторларын да санап үтә: авыл китапханәсенә кергән баш каһарман Илһам киштәдә Энн Райс, Ричард Матесон, Брайн Стейбелфорд һ.б.ның вампирлар турындагы романнарын күрә. Төп геройларга сүз әйтерлек түгел, гади, типик образлар бирелгән: Уфадан авылга ялга кайткан ундүрт яшьлек Илһам һәм әфган сугышында аяксыз калган, протезлар белән йөрүче, элегрәк салгалау гадәте дә булса да, вампирларга каршы аек акыл белән көрәшә белүче батыр Һидият. Убырларның авылга ияләшүен, көннән-көн көчәя баруын тасвирлап, язучы халыкның явызлык каршында бердәм булмавын, куркып калуын, шуның аркасында рухи һәм җисмәни кырылуын, аерым шәхесләрнең коточкыч шартларда да үз мәнфәгатен генә кайгыртуын, кайберәүләрнең убырлар килгәнче үк «вампирлашу» процессын ачып сала. Әдип, «*Үзенең канын эчә торган кануннарны халык үзе кабул итә...»* кебек сәяси көнүзәк темаларга да кагылып, укучысын уйланырга мәҗбүр итә.

Әсәрнең китап булып басылып чыгу-чыкмавы турында берни белмим, чөнки мин дә аны М.Кәбировның интернет сайтыннан алынган вариантта укыдым, тик текст белән танышкан чакта миндә мондый бер тәэсир калды: әгәр повесть китап булып басылып чыккан булса, нәшрият редакторы һәм корректоры тексттагы хәреф, басма, грамматик һәм стиль хаталарын төзәткән булыр иде, интернет вариантта исә шактый гына ялгышлар күзгә ташлана, андый урыннар очраганда, төрекчә тәрҗемәне махсус алып карадым, әле ярый, хаталар тәрҗемәгә әллә ни йогынты ясамаган, дидем. Әгәр чагыштыру урынлы булса, шундый сорау туа: Әмирхан Еникинең лирик өслүбле әсәрләрен эшләгәннән соң, тәрҗемәчегә Марат Кәбировның биредә кулланган теле шактый чуар һәм кимчелекле булып тоелмады микән? Ник дисәң, текст кирәкле-кирәксезгә рус сүзләре белән чуплөнгән, «ябеште» кебек әдәби нормадан тайпылган формалар, даими кабатланып, укучыга көчләп тагыла, тагын да аянычлысы: әсәрдә сүгенү сүзләре дә урын алган. Мәсәлән, «анаңны» гыйбарәсен геройлар повестьта 27 (!) тапкыр әйтә, әле алай гына да түгел, дүрт-биш урында ул «анаңны фәлән итим» рәвешендә «тулыландырыла». Әсәр үсмерләргә адресланган, дидек, әйе, бүгенге көндә зур егет булырга хыялланучы кайбер балалар мондый гыйбарәләрне еш куллануны мода дип саный, язучы да аларның сөйләмен типиклаштырырга омтыла дип уйлыйк, ләкин вампирларга каршы көрәшкәндә булса да, ике сүзнең берендә персонажлардан әшәке сүз әйттерү чама-чикләрне узып китә кебек. Төрки халыкларның сүгенү сүзләре, нигездә, бертөрле булганга, төрекчә тәрҗемәдә дә югарыдагы гыйбарәләрнең күбесе шул ук формада кала. Моннан тыш, «шайтан алгыры» гыйбарәсе – 59 (!), «шайтаныма» – 4 тапкыр очрый, төрек телендә бу форма кулланылмаганлыктан, Дәмиркая аны «ләгънәт төшсен» (lanet olsun) кебек гыйбарәләр белән алмаштыра. Никадәр генә мажара белән укучыны мавыктыру максат ителмәсен, әдәби әсәрнең тәрбия һәм әдәбе беренче урында булырга тиештер, минемчә. Югыйсә сүгенү чире яшь укучыга да, моңа кадәр андый сүзләрне авызына алмаган Илһамга йоккан кебек, йогачагы шиксез: «*Һәм үзем дә сизмәстән, нәкъ Һидиятчә итеп сүгенеп куйдым: – Анаңны*...» – ди бит әнә Илһам да.

Вампирлар һөҗүменнән тар-мар булган авылның дәһшәтле халәтен тасвирлау өчен язучы кара буяуларны, жанр таләбенә туры китереп, куе гына бирә («Беларусь» трактор арбасына төялгән җәсәдләр, койма рәшәткәләренә кигертелгән адәм башлары, кан күлендә яткан кеше әгъзалары, алардан килгән сасы ис һ.б.). Боларны күреп укшыган-коскан геройларның хәле ышандырырлык булса да, натуралистик сурәтләр арасында «клуб почмагында сиеп торучы ир-атлар», геройларның унитазга «печ итүләре» кебек зәвыксыз эпизодлар, бер дә мөһим булмыйча, урынсыз кебек тоела.

Сүгенү-ачулану сүзләреннән башка да, текстта тәрҗемәче өчен таныш булмаган бихисап сүз бар, боларның кайсысы шивә (диалект), кайсысы авторның үз «иҗаты» (*кыйрату, аңдып тору, мәрәкә, ныкыштым, өңрәеп торган ишек, ялтлау, базнат итми, трусигымның җимасы* һ.б.), кайсысы жаргон (*туфта, хана, шестёрка* һ.б.), кайсысы русчадан кереп «бозылган» сүзләр (*яшник, персидәтел, жалкы, бар хутына акыртып, адәм страмы* һ.б.). Рус теленнән алынмаларны (*фляга, вспышкалы фотоаппарат, штепсель, розетка, плафон, люстра, гримёрка, запас, штакетник, реликвия, кремация* һәм тагын әлләниләр!) төрек теленә аударыр өчен никадәр көч сарыф итәргә кирәклеген тәгаенләгәндер Дәмиркая... Егетнең русча сүзләрнең күпчелеген, нигездә, дөрес тәрҗемә иткәнен күреп шатландым, хәтта «белизна шешәсе» кебек, сүзлекләрдә табылмас матавыкларны да «дөрес чишә» алган, мөгаен, ул бу мәсьәләдә Татарстаннан килеп, Төркиядә яшәүче татарлардан ярдәм алгандыр, дигән фикер туа.

Инде хәзер игътибарыбызны төрекчә тәрҗемәдәге кайбер маҗараларга, Дәмиркаяның үз табыш һәм югалтуларына юнәлтик. Моны яшь тәрҗемәченең эшеннән гаеп эзләү өчен түгел, ә бәлки, аның филологик осталыгын арттыру һәм татарчасын камилләштерү максатында гына эшләвемне тагын бер кат искәртеп куям. Әсәрнең исеме төрекчәдә «Вампирлар уянганда» дип бирелгән, убыр образы төрек мифологиясендә очрамый, вампир сүзе исә бар дөнья балаларына таныш, автор үзе дә бит әсәр башында ук вампир сүзен кулланып, «*Шүрәле урамына убыр ияләшкән, диләр бит. Бампир дип әйтәләрме әле...»* дип, укучысын алдан хәзерләп куя. Шулай да тәрҗемәче китапның беренче битләрендә төрек укучысы өчен Шүрәле һәм убыр турында астөшермәдә берәр белешмә биргән булса, зыян итмәс иде. Югыйсә алга таба Алп Әрән бу төр астөшермәләр белән уңышлы гына эш итә.

Русчадан кергән әллә нинди төшенчәләрне, нигездә, дөрес итеп төрекчә бирә алган Алп Әрәннең ялгышлары, нигездә, татарча сүзләрдә очрый. Иң зур һәм оригиналга хилафлык китерүче хатасы «картый» сүзе белән бәйле. Башкортстанда туып-үскән Марат Кәбиров үз әсәрендә бар кеше дә аңлап җиткерә алмаган бу сүзнең этимологиясен баштан ук әйтеп үткән булса, яки аның урынына киңрәк таралган «карт инәй» сүзен кулланган булса, тәрҗеман, әлбәттә, бу урында абынмас иде. Ул картый сүзен «бабай» дип бирә һәм бөтен текст буенча тәмле коймаклар пешерүче, оныгын иркәләп сөюче карчык *дәдә* (бабай) булып бара: гәрчә Илһамның икетуганы булган Айрат әбисенә «нинәй» дип эндәшә, ул чакта тәрҗемәдә дә *нәнә* (әби) сүзе чагылып китә, ләкин ул картыйдан аерым башка бер шәхес кебек аңлашыла. Текстта бер урында картыйга исеме белән дә дәшәләр әле, ләкин Дәмиркая аны «күрмәмешкә салыша»: Наилә исемле кызның муенындагы эзнең убыр тешләвеннән булмавын ачыклаган картыйга, кызның әнисе Хәдичә: «*Рәхмәт инде, Фатима түткәй*», дип мөрәҗәгать итә. Төрекчә вариантта исә бу рәхмәт «абзыйга» адреслана. «*Иртән генә безгә коймак пешереп ашаткан назлы да ягымлы да карчык түгел иде бу»* җөмләсендә, әйтик, аның хатын-кыз булуы тәгаен белдерелсә дә, тәрҗемәдә үҗәт рәвештә «бабакаем» диелә: *Bize sabah kuytak pişirip karnımızı doyuran güzel dedeciğim değildi.*

Картый пешергән коймак та, нишләптер, тәрҗемәче тарафыннан ялгыш аңлатыла (татар халкын шул кадәр яраткан бу егетне бер генә татар кешесе дә коймак белән сыйламаган микәнни? дигән сорау туа), ул аны астөшермәдә «гөзләмә» (күзләмә) дип билгели, гөзләмә исемле камыр ашын төрекләр, кыстыбый камыры кебек, юка итеп җәелгән чи камырның эченә төрле эчлек (яшел үлән һәм эремчек, пюре, фарш һ.б.) куеп, кызган коры табада пешерәләр. Текст эчендә «куймак» (төрекләр бу сүзне ишеткәч, мәгънәле итеп елмаеп куялар) дип бирелгән «коймак»ны әгәр «пиши» (pişi), кашык белән салып пешерелгәнгә «кашык түкмәсе» (kaşık dökmesi) дип, яки «белен» аңламындагы krep сүзләренең берсе белән аңлаткан булса, дөреслеккә якынрак булыр иде. *Картый табадан коймак ала иде* җөмләсенең тәрҗемәсендә дә «бабай» бу ризыкны табадан түгел, кәстрүлдән алган итеп бирелә.

Тәрҗеман кайбер сүзләрнең, мәсәлән, *изү (түш), туган апа, калай түбә, балавыз, әрсез* һ.б., мәгънә яки үзенчәлекләрен белеп бетермәгән һәм башкача биргән. Төрек телендә дә очрый торган «бәндә» сүзе нигәдер тәрҗеман өчен четерекле тоелган һәм тулысынча ялгыш аңлашылган, бер урында аны «кеше ашаучы» (yamyam) дип язса, *Бу бәндәнең мазага тиюенә түзәр әмәл юк иде* җөмләсендә ул «бәдән» (гәүдә) булып киткән һәм Bu *bedenin kimseye kul olacağı yoktu* (Бу гәүдәнең беркемгә дә кол булачагы юк иде) дип «аударылган». Икенче урында автор *бәндә* сүзе янына *адәм* синонимын да куйгач та, тәрҗеман бәдән сүзенә «тугрылыклы» калган: *Менә шушы бәндә, беркем теләмәгәндә, беркем сорамаганда килеп чыккан шушы адәм, ничәнче кат инде минем юлыма аркылы төшә. İşte, şu beden! Bir kez olsun benden bir şey istemeyen, bana bir şey sormayan şu âdemoğlu!* (Менә шушы гәүдә! Бер генә тапкыр булса да, миннән берни теләмәгән, берни сорамаган шушы адәм баласы!) дип, авторның әйтергә теләгән фикерен аңлый һәм төрекчә җиткерә алмаган. Көтүе белән үтерелгән сарыклар турында сүз барганда исә, тәрҗеман, ни кызганыч, сарыкларны көтүче белән бергә үтерелгән итеп сурәтли. Бу төр гыйбарә һәм җөмләләр әдәби тәрҗемәнең эчтәлегенә әллә ни тәэсир итми, оригинал белән чагыштырып карамаганда, төрек укучысы аларга бик игътибар итмәс кебек. Ләкин кайбер нюанс һәм детальләр, баш каһарман Илһамның характерын ачу өчен кирәкле булганга, тәрҗемәдәге төгәллек бик тә әһәмиятле. Мәсәлән, язучы булган әтисе турында даими рәвештә хөрмәт белән искә алган үсмер егет, канын вампир-Нәфисә имгән вакытта да әтисенең сүзләрен хәтерләп, кешелеген югалтмый кала. Шуңа күрә балачагында улы Илһамны кайчакта «бәргәләп тә алган» әтисенең тәрҗемәдә «кыйный иде» дип тасвирлануы ялгыш. Язучы, *Болай гына, әтиләрчә генә* дип, бу урынны тагын да йомшартырга омтылса, тәрҗемәдә исә *«Һәр әти кебек» (Her babanın yaptığı gibi)* дип гомумиләштереп куела.

Ике текстта кулланылган мәкаль-әйтемнәргә аерым тукталу урынлы булыр. Алп Әрән бәй татарча әйтемнәрне төрекчә вариантлары белән бирергә омтылган, аларны таба алмаган очракта тасвир юлын сайлаган, кайчакта бу уңышлы гына чыккан, кайсыбер урында исә мәгънәгә хилафлык килгән. Мәсәлән: *Мулла песиләре кебек* гыйбарәсе «муллалар каршында хөрмәт белән башын иеп торган шәкертләр кебек» аңламындагы төрекчә әйтем (*mollaların karşısında el pençe divan duran şakirtler gibi)* юлы белән аңлатыла. Яки *Мин аның киенүенә карап: «Кошларга хана инде,» – дип уйлап куйдым* җөмләсен бик матур гына итеп: *Кыяфәтенә карагач, кошлар айва ашады инде, дип уйладым (Kıyafetine bakınca şimdi kuşlar ayvayı yedi diye düşündüm),* төрекләр ятатып куллана торган *айвайы йимәк* фразеологизмы авыр хәлгә төшүне аңлата. М.Кәбировның гади генә әйткән урыннарын, Дәмиркая кайчак бизәп, төрекчә әйтемнәр кулланып бирә һәм әсәрдәге экспрессияне тагын да арттыра. Мәсәлән:

*Ә мин нәкъ уртада басып калам… İki arada bir derede kaldım*

*Акырма әле шулкадәр! – «Kulağımın zarını patlattın be!»* һ.б. лар.

Сүзне йомгаклап, шуны әйтәсе килә: һәр эштәге кебек, әдәби тәрҗемәдә дә осталык тәҗрибә белән килә, Алп Әрән Дәмиркая, тәрҗемә өчен шактый катлаулы булган «Убырлар уянган чак» әсәренә алынып, үзе өчен бик күп яңа сүз һәм гыйбарә «ачкандыр», сүз байлыгын һәм осталыгын арттыргандыр, дип уйлыйм. Яңа китап басылып чыккач, төрекләрнең әйтә торган матур теләген монда татарча да әйтим: ике китапның да укучысы күп булсын, ә укучысы булган китап берничә тапкыр яңадан басылачак. Бу язмада күрсәтелгән кимчелекләр китапларның яңа басмаларында искә алыныр, әлбәттә. Татар әдәбиятында тәүге тапкыр вампир темасына язылган «Убырлар уянган чак» әсәренең авторы Марат Кәбировны да, аны төрек укучысына таныткан Алп Әрән Дәмиркаяны да уңышлары белән котлыйм.

**Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА,**
*Мәскәү*

# ФӘННИ СҮЗЕМ – САФ ТЫЛСЫМЫМ...

## НУРФИЯ ЙОСЫПОВАНЫҢ «XX ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ: ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ЯҢАЧАЛЫК» МОНОГРАФИЯСЕНӘ БӘЯ

Хәзерге татар поэзиясен узган гасыр шигърияте белән бәйләп, киң җәмәгатьчелеккә даими рәвештә нәзари-тәнкыйди фикер җиткерә баручы әдәбият галимнәре арасында филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты профессоры Нурфия Йосыпованың хезмәтләре аерым урында. 2002-2021 еллар арасында галимәнең татар шигъриятенә әтрафлы гыйльми анализ тәкъдим иткән 5 монографиясе, урта һәм югары мәктәп өчен 26 санда уку-укыту ярдәмлеге дөнья күрде. Н.Йосыпова – «Габдулла Тукай» энциклопедиясе (2016), сигез томлык «Татар әдәбияты тарихы» китаплары авторларының берсе. Соңгы елларда гына профессор әдәбият гыйльмиятенә шигъриятне нәзари һәм тәнкыйди яссылыкта бәяләгән өч монография бүләк итте.

«XX гасырның икенче яртысы татар шигърияте: традицияләр һәм яңачалык» (Казан, 2021) хезмәтендә әдәбият галиме XX йөз татар поэзиясенә нәзари күзәтү ясый, бер гасырлык шигърияткә структураль-семиотик анализ яссылыгында гыйльми бәя тәкъдим итә.

Фәнни монографиянең беренче «XX гасырның беренче яртысы татар поэзиясе: традицияләр һәм яңарыш нигезләре» дип исемләнгән бүлегендә галимә тарафыннан милли поэзиянең алты дистә еллык дәверенә күзәтү урын алган. Гасыр башы шигърияте хакында фикер йөрткәндә, университет профессоры Йосыф Акчура, Габдрахман Сәгъди, Газиз Гобәйдуллин, Җамал Вәлидиләрнең шул чорда төрле басмаларда дөнья күргән нәзари-тәнкыйди карашларын нигез итеп ала, кутәрә, нәтиҗә ясый. «XX йөз башы татар поэзиясендәге күп үзгәрешләр шәхес концепциясе алмашынуга бәйле» (7 б.) икәнлеген бәяләгәндә, Г.Тукай, М.Гафури, Н.Думавиларның мәгърифәтчелек рухы белән сугарылган шигъриятендә «татар халкының рухи юлбашчысы булып торырлык әдип» образы бирелеше игътибарга алына. Мәгърифәтчелек күтәргән идеяләрнең Г.Рәшиди, Я.Мамишев, Г.Гайнуллин-Чокрый, Х.Исхакый, К.Хаммадов поэмаларында урын алуы билгеләп үтелә. Н.Йосыпова карашынча, милли шигъриятнең бу дәверендә «жанр эзләнүләре аеруча лиро-эпик төрдә колач җәя» (27 б.). Романтик иҗат принципларының лироэпикада көчле яңгыраш алуын дәлилләү өчен, фольклор мотивларыннан, дини сюжетлар кулланылышы ягыннан Ф.Бурнаш, Б.Мирзанов, К.Юлдаш, Д.Гобәйди, Х.Исхакый поэмаларына мөрәҗәгать ителә. Бу урында галимәнең «XX гасыр башында мифологик сюжетларны яңарткан яки әсәр материалында яңа миф тудырган, матурлык концепциясенә таянып, милли яшәешне яңарту омтылышын алга куйган бер төркем модернистик» поэмаларга, аерым алганда, Б.Мирзановның «Җен туе», М.Гафуриның «Адәм вә Иблис», Һ.Такташның «Газраилләр», Г.Сөнгатинең «Хозер», Н.Думавиның «Шәрык даһие», шулай ук төрки-татар мифларына мөрәҗәгать итеп язылган И.Шаммаси, Г.Сөнгати, Г.Харис әсәрләренә анализлары игътибарга лаек. Анализлар нәтиҗәсе буларак, «модернистлар иҗатында поэманың традицион кануннардан баш тарткан антижанр формасы барлыкка килүе», «дини-дидактик эчтәлекле сюжет дөньяви фикерләрне җиткерүгә буйсындырылуы» (237 б.) хакында нәзари карашлар дәлилләнә.

1920 – 1950 еллар татар поэзиясе тарихында үзенчәлекле чор буларак бәяләнә. Галимә С.Сүнчәләй, Ф.Бурнаш, В.Җәлал, С.Кудаш, Т.Ченәкәй һ.б. иҗатларында яңгыраш алган фикерләргә таянып, «егерменче еллар татар шигъриятендә әле

XX гасыр башы татар поэзиясе традицияләрен дәвам итү яки поэзияне шул нигездә яңарту омтылышы көчле саклана» (32 б.) дигән нәтиҗә ясый. Әдәбият галиме Д.Заһидуллина карашларыннан этәрелеп, Н.Йосыпова бу чорда «форма эзләнүләре аша трансформация кичергән» (32 б.) Х.Туфан, Г.Кутуй, Һ.Такташ, К.Нәҗми һ.б. авторлар иҗатларына туктала, аерым алганда, Х.Туфанның «Татарстанда» поэмасына, «тартышчы» геройны тәкъдим иткән «Сынган кашлар» шигыренә һ.б. әсәрләренә, Г.Кутуйның «Көннәр йөгергәндә» дип исемләнгән футуристик, К.Нәҗминең «Өермәләр» җыентыкларына имажинистик эзләнүләр ноктасыннан тирән фәнни бәя бирелә. Галимәнең егерменче елларда хөкем сөргән гыйсьянчылык фәлсәфәсенә мөнәсәбәтле фикерләре игътибарга лаек. Г.Халитнең «гыйсьянчы герой XX йөз башы бунтарь шәхесеннән аерыла» дигән карашын, Н.Йосыпова «татар әдәбиятындагы гыйсьянчы геройның көрәш мәйданы үзгәрә» (42 б.) дип үстерә, бу яссылыкта Һ.Такташ, К.Нәҗми, М.Җәлил, Х.Туфан шигъри текстлары бәяләнә. Профессор 1920 елларның урталарыннан соң татар поэзиясендәге авангард эзләнүләрнең сүлпәнәюенә бәйле карашларын җиткергән урында Һ.Такташның «Иҗадиятем хакында» дип исемләнгән программ мәкаләсен шәрехли һәм «...Һ.Такташ татар поэзиясе өчен үзгә, интонацион шигырь – сөйләү шигырен мәйданга чыгара» (44 б.) дигән нәтиҗә ясый. Утызынчы еллар шигъриятенә бәя биргән вакытта да Һ.Такташның «Әдәбият нинди булырга тиеш» дип исемләнгән мәкаләсенә мөрәҗәгать итеп, «шушы чордан Такташ әдәбияттагы форма эзләнүләрен сыйнфый көрәштән читләшү буларак тәнкыйтьли башлый» (51 б.) дип, чор йөзенә төгәл, анык бәя теркәп куя. 1934 – 1941 еллар аралыгы белән тамгаланган утызынчы еллар татар поэзиясендә социалистик реализм агымына мөнәсәбәтле үзенчәлекләрне аерып куйган хәлдә, әдәбият галиме Ә.Фәйзинең «яңа идеологиянең зыялылар тормышында чагылышын үзәккә куйган» (56 б.) «Флейталар» поэмасын, С.Хәкимнең «Тукайга багышланган шигърияткә эчтәлек һәм форма яңалыгы алып килгән» (57 б.) мәгълүм поэмаларын, «Совет фольклорын җыйнарга чынлап керешергә» мәкаләсен язып, либреттолар тәкъдим иткән М.Җәлил әсәрләрен анализлап һәм ассызыклап үтә. Бөек Ватан сугышы чоры татар поэзиясен анализлап, Н.Йосыпова 1920 – 1930 елларда башланган яңарышның дәвам иттерелүе, сугыштан соңгы еллар татар поэзиясенең «XX гасырның алтмышынчы елларында булачак өченче «шартлауга» җирлек әзерләвен ассызыклый (86 б.).

Фәнни монографиянең икенче бүлегендә 1960-1980 еллар татар поэзиясе эчтәлек һәм форма өлкәсендә эзләнүләр ноктасыннан бәяләнә. Н.Йосыпова киң җәмәгатьчелеккә классик әдипләребез Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт иҗатларына саллы нәзари бәя тәкъдим итә. Әйтергә кирәк, соңгы биш-җиде елда әдәбият гыйльмиятендә милли поэзиянең әлеге дәверенә академик Дания Заһидуллина тарафыннан этрафлы анализ бирелде *(Заһидуллина Д.Ф. 1960-1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. – 383 б.)*. Нурфия Йосыпова әдәбият галимнәренең хезмәтләренә һәрдаим мөрәҗәгать итә, библиографиядә йөзгә якын фәнни хезмәткә сылтама бар. Монография авторы бу бүлектә остазлары, академиклар Тәлгат Галиуллин, Дания Заһидуллина хезмәтләреннән этәрелеп, яңа фәнни ачышлар, бу чор поэзиясен анализлауның үзенчәлекле юлын тәкъдим итә. Рус әдәбияты галимнәре Ю.Богомолов, И.Кукулин, Н.Лейдерман, А.Бочарев һ.б.ның әдәбиятның бу дәверенә мөнәсәбәтле фикер-карашларын өйрәнеп, галимә милли поэзиябезнең гаҗәеп тирән үзенчәлекләрен, бөеклеген шигъри текстларны җентекләп анализлау аша ача. Профессор әдәби дәвернең яңалыгы хакындагы гыйльми карашларны үстерә, аерым берләрен кайта-кайта ассызыклый. Әйтик, Г.Афзалның гражданлык лирикасында активлашкан иҗтимагый тәнкыйтьнең Ф.Яруллин, Ш.Анак, Р.Мингалим, К.Сибгатуллин шигъриятендә күтәрелүе, Х.Туфан, С.Баттал, Р.Фәйзуллин, Рәш.Әхмәтҗанов,

Роб.Әхмәтҗанов, М.Әгъләмовларда көчле яңгырашы шигъри текстларны анализлап дәлилләнә. Галимә карашынча, «авангард эзләнүләр милли шигърияттә үзенә бер дәрт белән иҗатка килеп кергән «Р.Фәйзуллиннар буынын» бер дулкынга җыя» (95 б.), «бу буын бердән, С.Рәмиев, Дәрдемәнд иҗаты традицияләрен үстерсә, икенче яктан, милли шигърияткә рус поэзиясенең, «шаулы эстрада» вәкилләре иҗатының йогынтысы көчәя» (96 б.). Күпсанлы шигъри текстларга филологик анализ бирү барышында Н.Йосыпова «сабыр лиризмга, төгәл ритмикага беренчеләрдән булып өстенлек бирә башлаган Г.Рәхим, соңрак кушылган «салмак лириклар» Р.Мингалим, Р.Гаташ, Зөлфәт, С.Хәким, Г.Зәйнашева, К.Булатова, К.Сибгатуллин һ.б. шигъриятләрендә тематик төрлелек, «фольклор стиле», «халык авыз иҗатыннан килгән образларны, мотивларны файдалану» (98 б.) хакында нәтиҗә ясый. Галимә романтик поэзия, фәлсәфи лирика, интеллектуаль шигъриятнең үсешен бер эзлеклелектә карый. С.Сөләйманова, Ш.Анак, Ә.Баянов һәм классикларыбыз Зөлфәт, Р.Фәйзуллин һ.б. иҗаты аша эчтәлек һәм форма өлкәсендәге эзләнүләрне аерып куя, дәлилли. Т.Галиуллин карашларын үстереп, Н.Йосыпова «Х.Туфан шигърияте 1960-1980 еллар әдәбиятында салмак лирика агымының төп үзенчәлекләрен билгеләүче иҗат» (126 б.) дип ассызыклап куя. Д.Заһидуллина фикерләрен дәвам итеп, галимә С.Хәким поэзиясендә «туган җирне изгеләштерү, мифлаштыру тенденциясен» (131 б.) күрсәтә, әдипнең тәнкыйди-публицистик мирасының кыйммәтен «әдәбият тарихында тирән эз калдырган шагыйрьләр мирасын барлау, әдәби процесска керткән өлешен тәгаенләп кую» (138 б.) дип тамгалап куя. Д.Заһидуллина, А.Даутов карашларын үстереп, Н.Йосыпова И.Юзеев шигъриятендә «кешенең Яшәешне һәм үз-үзен танып белүе, кеше гомеренең кыйммәте, кеше язмышы, яшәү мәгънәсе хакында фикерләр әйдәп баруы» (157 б.) турында нәтиҗә ясый. Р.Харисның интеллектуаль поэзиясен анализлап, шагыйрьнең татар шигъриятен яңа сыйфатлар белән баетуын дәлилли. Р.Фәйзуллинның «көнчыгыш әдәби үзенчәлекләрен иҗади үзләштереп, татар әдәби җирлегенә «яраклаштыруы», шагыйрьнең иҗади ачышлары «әдәби традицияләрнең үсешенә, фәлсәфә тирәнәюгә һәм әдәбиятара мәдәни диалогның көчәюенә дә көчле йогынты ясый» (192 б.) дигән нәтиҗәгә килә. Галимә М.Әгъләмов иҗатында яңа караш, яңа анализ юлы тәкъдим итеп, әдип шигъриятендә «милләт язмышы – шәхес язмышы – шагыйрь язмышы чылбыры»н (210 б.) аерып куя, әдипне «шигърияттә алдагы буыннарга иҗади тәҗрибәләр ясау мәйданын, чын мәгънәсендә шигъри мәктәбен калдыра» (216 б.) дип күтәрә, лаеклы төстә данлый. Зөлфәт шигъриятенә анализ белән танышканнан соң, галимәнең фикер-карашлары тирәнлеген Зөлфәтнең бер шигъри тезмәсен үзгәртеп, «Фәнни сүзем минем – саф тылсымым» дип бәялисе килә: «Үз кичерешләре аша халык язмышын җиткерә алган, милләтенең бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылган, кешелекнең имгәнгән яшәеш канунннарын савыктыру омтылышы белән янган шигърияте Зөлфәтнең үз мәсләгенә тугры калуын раслый» (243 б.).

Китапның өченче бүлеге «1980 – 2000 елларда татар поэзиясе: шигъриятне яңарту юлында эзләнүләр» дип исемләнә. Әдәбият галиме Нурфия Йосыпова милли поэзия мәйданына алтмышынчы елларда килеп кергән мәгърур буынның 1980 – 2000 еллар аралыгында да сайлаган кыйблага – шигъриятне «эчтәлек һәм форма ягыннан тирәнәйтүгә, яңарыш тенденцияләренә» (277 б.) тугры калуын, алар алып кергән яңарышның «ХХ йөз башында булачак әдәби-сәнгати, фәлсәфи эзләнүләргә нык-лы нигез салуын» дәлилли (278 б.).

Әдәбият гыйльмияте тарихында яңа сүз булып танылачак фәнни монографиянең дәвамы буларак, галимәнең гаҗәеп талантлы хәзерге буын шагыйрьләр, аерым алганда, Лилия Гыйбадуллина, Луиза Янсуар, Йолдыз Миңнуллина, Булат Ибраһимов һ.б. иҗатлары хакында фәнни-гыйльми сүзен ишетәсе килә.

**Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА,**
*филология фәннәре кандидаты*

## Дуска

Кемдер эзли миндә сердәш,
Ә кемнәрдер күрә көндәш.
Кирәк түгел лә, энекәш!
«Марсель» диеп, гади итеп,
Купшыланмый гына эндәш!

Мин фәкыйрьне санап тиңдәш,
Кайберәүләр сорый киңәш.
Берни яшермичә сөйләш –
Шул вакытта гына сүзем
Синең сүзгә булыр көйдәш!

Кемдер күрә миндә дошман,
Дустым булып йөри тыштан,
Явызлыгы баштан ашкан,
Эх, анаңны корт чаккыры –
Кирәк түгел миңа куштан!

Кылган эшең, һәр гамәлең,
Әйткәннәрең булса ихлас –
Кабат әйтмәм, тыңла, ышан:
Әрәм түгел синең өчен
Үземдәге соңгы ыштан!

## Корыч йозак

Озак чаптым, урау юллар аша,
Текә кыяларга менгәнче,
Ак болытлар арасында йөзеп,
Йолдызлардан таҗым үргәнче!

Җирдә яшәмәм дип, гел ашкынып,
Үз-үземә нык сүз биргәндә,
Мөлдерәмә тулган хис чайпалып,
Түгелде дә бәгырь күгеңә,
Оя корды йөрәк түреңә...

Үрсәләнде күңел кошың, күрәм,
«Эләктем» дип шигъри тозакка,
Йөрәгемне мин йөгәнли beләм:
Бикләп тотам корыч йозакка!
Тик шунысын анык әйтә алмыйм,
Түзәрсеңме үзең озакка?..

## Агач кашык

Әтәчләнмә, кабаланма,
Иртә бит чаң кагарга.
Паровоз алдыннан нигә
Кирәк сиңа чабарга?

Үз үзеңне күккә чөеп,
төк(е)рек чәчеп мактанма,
Чын татарга тыйнаклык хас –
халык бар бит мактарга!

«Өстем бөтен, тамак тук», дип
мәҗлес саен кикермә.
Авыз тулы кан булса да,
Кеше барда төкермә!

Ул гамәлең бер әйләнеп,
үз башыңа кунмасмы?
Халык түзем, тик шулай да
Сабыр-касә тулмасмы?

Күктә бары пәйгамбәрләр!
Очынма(ә)ле! Ашыкма!
Тормыш үзе күрсәтә ул,
Чүмечме син, кашыкмы?!

**Марсель ШӘРӘПОВ,**
*Арча районы Сарай-Чокырча авылы.*

# 922 ЕЛДА БАГДАД ХӘЛИФЕ ӘЛ-МӨКЪТАДИРДӘН КИЛГӘН ИЛЧЕЛЕК

Яңа җирләргә күченгән болгарлар, җирле кабиләләрне берләштереп, сәяси нигездә туплана башлыйлар. Әмма Х гасыр башында Идел-Чулман төбәгендә яшәүче болгарлар әле дә Хәзәр каһанлыгына бәйле булып, салым түлиләр. Әлтәбәр (буйсынган кенәз дигәнне аңлата) Алмыш ибн Шилкинең улы каһан сараенда яши, тәрбияләнә, олы кызы анда хатынлыкта була. Әлтәбәр, олы кызы үлгәннән соң, Хәзәр каһаны сәяси буйсыну билгесе итеп, хатынлыкка кече кызын сорагач, аны җирле кенәзгә кияүгә биреп, Габбасилар хәлифәте башкаласына ислам динен өйрәтергә һәм таратырга голәмә һәм кирмән төзү өчен акча җибәрүләрен үтенеп, хат юллый.

Хәлифәтнең рәсми кәгазьләре арасында Идел-Чулман буйларына илчелек җибәрү турындагы хәбәр сакланмаган. Чөнки 920-921 еллар хәлифәт өчен бик катлаулы вакыт булып, хөкүмәт эчке проблемаларны хәл итү белән мәшгуль. Икмәккә бәяләр югары булу сәбәпле, 920 һәм 921 елларда Багдад шәһәре халкы баш күтәрә. Яңа уңыш икмәген кайтарту өчен хәлиф башкаланы икмәк белән тәэмин итүгә җаваплы вәзирне шәһәрдән җибәрә. Ул Болгарга илчелек китеп, бер ай үткәч кенә әйләнеп кайта. Илчелек, Алмышка бүләккә дип, дәүләт казнасыннан традицион бүләкләр: парчадан тегелгән бәйрәм киемнәре, төрле кыйммәтле көнкүреш һәм бизәнү әйберләре алып китә. Ләкин юлга акчасыз чыга. Бу вакытта казнада йә акча булмый, йә юлның авыр һәм куркыныч икәнен күздә тотып, мондый зур сумманы биреп җибәрергә шикләнәләр. Ахыр чиктә Саусанәр-Расси җитәкчелегендәге илчелек Болгарга акчасыз килеп җитә. *(Большаков О. Исламский мир в VII – начале XIII в. // История татар с древнейших времен. Т.2. С.543).*

Багдад хәлифе әл-Мөкътадирдән 922 елның 22 маенда килгән илчелек һәм аның сәркатибе Әхмәт ибн Фадлан[1] турында күренекле совет ислам белгече Олег Большаковның фикере игътибарга лаек. Аныңча, бу вакыйга болгарларның үзләренең рухи сюзерены итеп, хәлифне势 тануларын һәм Идел төбәгенең мөселман дөньясы белән тыгыз элемтәләре булуны раслый *(Большаков О. Исламский мир в VII – начале XIII в. С. 522).*

Чыннан да, Ибн Фадлан килгәнче Идел-Чулман буенда көн күрүче болгар кабиләләренең ислам дине белән танышлыгы, кайберләренең Мөхәммәд пәйгамбәр дине тарафдары булуы түбәндәге чыганаклар һәм тарихи фактлар белән раслана.

1. Төбәктә 901-909 елларга караган «Җәгъфәр ибне Габдулла» дип язылган болгар акчасы һәм хәлифәл-Мөкътафи (902-908), самани әмире Исмәгыйль ибн-Әхмәд һәм Җәгъфәр ибне Габдулла исемнәре сугылган тәңкә табылу әле Багдадта илчелек килгәнче Алмыш әлтәбәрнең һәм аның якыннарының ислам динен тотканлыгын раслап тора *(Давлетшин Г.М. Волжская Булгария: духовная культура. Домонгольский период. X– XII вв. Казань, 1990. С. 78).*

[1] XIX гасырда тарихчыларга Габбасилар хәлифәтеннән болгарларга җибәрелгән илчелек сәркатибе ибн Фадлан «Рисаләсе» М.Х. Френ тарафыннан өйрәнелгән «Йакут сүзлеге» аша таныш була. Бу материалны Ш.Мәрҗани үзенең «Мөстафадәл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) исемле хезмәтендә файдалана һәм татар укучысын әлеге тарихи чыганак белән таныштыра.

Тәүге тапкыр дөньякүләм масштабта фәнни җәмәгатьчелеккә «рисалә»нең тагын да тулырак текстын ирештерү миссиясен Идел-Урал төбәгендә үскән икенче бер мәшһүр галим Зәки Вәлиди башкарып чыга. Тарихчы 1923 елда бу кулъязманың борынгырак һәм тулырак вариантын Иранда, Мәшһәд каласының «Имам Риза раузасы» китапханәсендә табып ала, чыганакны анализлый, мәкаләләр язып, фәнни әйләнешкә кертә, 1939 елда алман телендә китап нәшер итә. 1935 елда СССР Фәннәр академиясе гозерен үтәп, Иран хөкүмәте Мәшһәд кулъязмасының фотокүчермәсен Мәскәүгә бүләк итә. Шушы күчермә нигезендә А.П.Ковалевский текстны русчага тәрҗемә итеп, 1939 елда Ленинградта бастыра, 1956 елда дөнья күргән икенче басманы автор үзенең күләмле тарихи-этнографик мәкаләсе белән баетып чыгара.

Бу китапта, нигездә, 922 елда Идел буенда яшәгән болгарлар ислам динен кабул иткәннәр дигән фикер уздырыла һәм ул совет тарих фәнендә ныклап урнаша *(Гараева Н.Ибн Фадлан. С. 714-715).*

2. Фарсы милләтеннән булган гарәп географы Ибне Рөстә 903-925 елларда язган китабында болгарларның Алмыш исемле патшасының ислам динен тотуын, шулай ук күпчелек халыкның да мөселман булганын, торак урыннарында мәчетләр һәм мәктәпләр төзелгәнлекне, аларда имамнар һәм мәзиннәр барлыгын язып калдырган (*Гараева Н. Ибн Русте // История татар с древнейших времен. Т.II. Казань: Изд-во «РухИЛ», 2006. С. 702).*

3. Ибн Фадлан үзе болгар кабиләләре арасында очраткан мөселманнарны болай тасвирлый: бәрәнҗәрләр кабиләсе (Төньяк Кавказдан, Хәзәр каһанлыгыннан килгән кабилә) вәкилләре, саннары белән якынча 5 мең кеше чамасы ир-ат һәм хатын-кыз, агачтан салынган мәчетләре бар, шунда гыйбадәт кылалар. Намаз укый белмәгәнгә, Ибн Фадлан аларның бер төркеменә намаз сүзләрен өйрәтә, шулай ук Талут исемле болгар кешесен һәм аның гаилә әгъзаларын ислам диненә күчерә, ике Коръән сүрәсен ятлата.

4. Ибн Фадлан, шулай ук, аларның, җәен төнлә караңгы төшмәү сәбәпле, намазны биш тапкыр түгел, ә дүрт тапкыр гына укуларын хәбәр итә, ягъни төбәктә яшәгән яки башка җирләрдән килгән ислам галимнәре, фәтвә чыгарып, ислам ритуалын башкаруны Урта Идел төбәгендәге табигать үзенчәлекләрен исәпкә алып көйләгәннәр.

5. Мәзиннең намазга чакырып әйткән азанында, хәлиф әл-Мөкътадир сараендагы шәфигый мәзһәбеннән аермалы буларак, икамәне ике тапкыр, хәнәфи мәзһәбендәге, төгәлрәге, Урта Азиядәге кебек әйтү, дини һәм мәдәни йогынтының чыганагын – Урта Азия белән сәүдә бәйләнеше аша кергәнен раслап тора.

6. Багдадтан килгән илчелекнең Алмыш һәм кабилә башлыклары белән тантаналы һәм рәсми очрашулары атнакич хәлифнең ике байрагы җилфердәве астында әлтәбәргә бүләк итеп, иярләнгән ат, җилкәсенә савад салу һәм башына төрбән чорнаудан, илче тарафыннан хәлиф әл-Мөкътадирның, вәзир Хәмид ибн әл-Габбасның хатларын укудан гыйбарәт була. Хатлар укылгач, Ибн Фадлан әлтәбәргә һәм аның хатынына, җыелган халыкка күрсәтеп, ислемайлар, кием-салым, энҗеләр тапшыра. Тантаналы чара аш мәҗлесе белән тәмамлана. *(Гараева Н. Ибн Фадлан // История татар с древнейших времен. Т.II. Казань: Изд-во «РухИЛ», 2006. С. 730, 732, 736).*

7. 1135-1136 елларда Болгарда булып киткән гарәп сәяхәтчесе Әл-Гарнати «Болгар тарихы» исемле кулъязма укыганлыгын хәбәр итә. Анда Болгар исеме «бәлагъ», ягъни «гыйлемле кеше» сүзеннән килеп чыккан, соңрак гарәпләшеп, «болгар»га әйләнгән дип язылган була. Китапта бу төбәктә ислам дине тарала башлау тарихы да яктыртыла. Имеш, Бохарадан килгән бер мөселман сәүдәгәре куркыныч авыру белән чирләп киткән болгар падишаһын һәм аның хәләл җефетен дәвалап терелтә; хаким, сәламәтләнгәч, әйткән вәгъдәсен үтәп, яңа дин кабул итә, аның артыннан халкы да Мөхәммәд пәйгамбәр өммәтенә әйләнә; яңа дин кабул иткән төбәккә гаскәре белән Хәзәр каһаны килеп, болгарларны үзенең рөхсәтеннән башка ислам динен кабул итүдә гаепли һәм каты бәрелештә болгарлардан җиңелеп, кире кайтып китә. (*Путешествие АбуХамидаал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.). /Публикация О.Г.Большакова, А.Л.Монгайта. М., 1971. С. 781)*. Биредә нәкъ менә Урта Азиядән килгән сәүдәгәрнең миссионерлык эшчәнлеге турындагы фикер игътибарга лаек.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: Алмыш әлтәбәрнең үз исемен гарәпчә язып, акчалар сугуы, Габбасилар хәлифәте башкаласына илче җибәрүе, иң беренче чиратта, сәяси мөстәкыйльлеккә омтылуның кире кагып булмаслык дәлиле саналырга лаек. Бер үк вакытта акчаның X гасыр башында сугылуы төбәктә шәһәрләрнең күптән булганлыгын да раслый.

Ибн Фадлан язып калдырган күзәтүләр ярым күчмә тормыш алып барган болгарларның гореф-гадәтләрендә, хорафатларында һәм рухи тормышларында мәҗүси күзаллауларны бик ачык күрсәтә. Ягъни болгарлар ислам дине таралуның башлангыч халәтендә торганнар, дип әйтә алабыз.

X гасыр уртасында Болгар каласында булган әл-Истаһри Болгар һәм Сувар шәһәрләрендә һәммәсе 10 мең ир-ат яшәгәнлекне, шәһәр халкының мөселманнар

булуын, икесендә дә агач мәчетләр эшләүне теркәгән *(Большаков О. Ал-Истахри – Ибн Хаукаль // История татар с древнейших времен. Т.II. С. 751).*

Ислам кабул итүнең мөһим элементы дип, киемнең үзгәрүен күрсәтәләр. Ибн Рөстә һәм Гардизи үзләренең язмаларында болгар киемнәренең мөселманнарныкына охшаганын теркәп калдырганнар.

Бу сәяхәтчеләр, шулай ук, болгарларның каберлекләре дә мөселманча булганлыкны хәбәр итәләр *(Заходер Б.Н. Каспийскийсвод сведений о восточной Европе. Т. II. Булгары, мадьяры, народы Севера, печенеги, русы, славяне. М., 1967. С. 33).*

Археологлар фикеренчә дә, X гасыр ахыры – XI йөз башында Болгар җирләрендә мәетләр мөселманча җирләнә башлый, ягъни хакимият һәм руханилар күмү йоласын тулысы белән контрольгә алган дип әйтергә мөмкин *(Давлетшин Г.М. Волжская Булгария: духовная культура. Домонгольский период. X–XIIвв. Казань, 1990 С. 80).* Дөрес, табигать шартлары еш кына, бигрәк тә кыш нык салкын булган елларда, күмү йоласына үзгәрешләр керткән. Аерым елларда туң нык тирән булу сәбәпле, мәетне вафатыннан соң икенче көнне үк җиргә иңдерү мөмкин булмаган. Шул сәбәпле 1135-1136 елларда Болгарда яшәгән гарәп сәяхәтчесе әл-Гарнатиның кыш азагында үлгән улы мәете өч ай чамасы үткәч генә җиргә иңдерелгән *(Кобищанов Ю.М. Начало исламской цивилизации в Северной Евразии // Очерки истории распространения исламской цивилизации. В 2 т. Т.1. От рождения исламской цивилизации до монгольского завоевания. М., 2002. С. 46).*

## Идел буе Болгар дәүләте һәм аның казанышлары

922 елда Идел буе болгарларының Габбасилар хәлифәтеннән килгән илчелекне кабул итүе оешып килүче яшь дәүләтнең беренче халыкара акты, ягъни халыкара субъект булып танылуы иде. Без болгарларның Хәзәр дәүләтенә тагын күпме вакытлар салым түләп яшәгәннәрен әйтә алмыйбыз. Сәяси бәйлелекнең өзелүенә халыкара вакыйгалар, хәзәрләрнең сугышларда җиңелүе сәбәп була. Хәзәр дәүләте 965 елда Киев кенәзе Святослав гаскәре тарафыннан тар-мар ителгәч һәм хәлсезләнеп таркалгач, Идел буе болгарларына мөстәкыйльлек алу өчен җирлек туа. Дөрес, бу елларда әле төбәктә ике сәяси үзәк саклана: Болгар һәм Сувар. Якынча 976 елда Сувар җирләре Болгарга буйсындырыла, акча да Болгарда гына сугыла башлый.

985 елда дружинасы белән көймәләрдә елга буйлап түбән Иделгә юл тоткан Киев кенәзе Владимир Хәзәр каһаны гаскәрен тар-мар итә. Шушы вакыйгадан соң Идел буе Хәзәр дәүләте Харәземгә бәйлелеккә төшә һәм анда яшәүче күчмәннәр ислам динен кабул итә. Шул ук елны Киев кенәзе Болгар гаскәрен җиңә. Әсирләрне караганда, Добрыняның Владимирга, болгарларның барысының аякларында күн итекләр булуга ишарә ясап, болар безгә салым түләмәс, безгә чабата кигәннәрне табарга кирәк дип әйтүе теркәлеп калган. Бу сугыштан соң Киев кенәзе болгарлар белән, мөстәкыйль булуларын танып, тынычлык турында килешү төзи. *(Кобищанов Ю.М. Күрс. хезмәт. С. 51, 53).* Бу датаны Болгар әмирлегенең тулы хокуклы дәүләткә әйләнүен раслаучы факт дип бәяләргә мөмкин. Рус елъязмаларында аларның 986 елда кенәз Владимир чакыруы буенча ислам дине белән таныштыру өчен Киев каласына барулары хакында хәбәр сакланган (*ФахрутдиновР.Г. Күрс. хезмәт. С. 37-38, 82).*

XII гасырда Болгар дәүләте тагын да ныгып, үз составына Бортас җирләрен (бүгенге Пенза төбәге) кертә. Шул рәвешле, Көнчыгыш Европаның эре дәүләтенә әверелгән Болгар әмирлегенең төньяктагы чикләре Мишә һәм Казансу елгалары, көнбатышта – Сура елгасы ярлары, көньяк-көнчыгышта – Җаек елгасы, көнчыгышта Агыйдел елгасы белән билгеләнә. Көньякта Түбән Идел буйларына, ягъни элеккеге Хәзәр каһанлыгы җирләренә кадәр җитә *(Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш. Булгарская цивилизация на Волге. Казань, 2011. С. 21-22).* Мәхмүт Кашгарый 1074 елда язган

«Диване лөгатет-төрк» исемле хезмәтендә Каспий диңгезен Болгар диңгезе дип атый (*Фахрутдинов Р.Г.Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.С. 57).*

Башлап Болгар дәүләтенең географик яктан бик уңайлы урнашуын, шуңа күрә халыкара сәүдә системасының үзәгендә булуын әйтеп китү мәслихәт. Болгарга Харәземнән сузылган кәрван юлы һәм Идел су юлы – халыкара Бөек Ефәк юлының тармаклары булып тора. Кытайдан Урта Азиягә китерелгән тауарлар Харәзем аша Болгар дәүләтенә килеп ирешә. Әл-Масуди болгарларның, сәүдә итеп генә калмыйча, бу кәрван юлларын саклаулары һәм сәүдәгәр кәрваннарын озата барулары хакында язып калдырган (*Ковалевский А. П. Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921-922 гг. Статьи, переводы и комментарии. Харьков: Изд-во Харьковского гос.ун-та им. М.Горького, 1956. С. 29).*

Аңа янәшә диярлек сузылган сәүдә юлы моңарчы Кытайдан Сөгыдкә (Согдиана, хәзерге Үзбәкстан һәм Таҗикстан җирләре), Каспий диңгезенең көньяк яры буйлап Алгы Азиягә чыгучы юл белән, Кавказ һәм Дәрбәнд шәһәре аша, Хәзәр каһанлыгы башкаласы Итилгә килсә, хәзер Идел елгасы буенча Болгарга җиткән. Хәзәр каһанлыгы X гасыр ахырында таркалгач, Каспий елгасына кадәр Идел бассейны болгарлар күзәтүенә күчә.

Болгар шәһәре янында, Идел буенда җәйге чорда халыкара сәүдә үзәге булып, Ага Базарда чит илләрдән килгән сәүдәгәрләр көймәләрдән генә алыш-биреш иткәннәр һәм алып килгән тауарлары бәясенең уннан бер өлешен салым итеп, Болгар әмиренә түләп, казнаны баетканнар.

Болгарлар Түбән Иделдән су юлы белән килгән сәүдәгәрләрне төньяк өлкәләргә үткәрмәгәннәр, үзләре Киев Русе җирләре аша – югары Иделгә, шуннан – Ак диңгезгә, Ак диңгездән Балтыйк буена һәм Скандинавиягә кадәр барып тауарлар алмашканнар. Бүгенге фәндә Киев Русе, Балтыйк буе һәм Көнбатыш Европада болгар акчалары тупланган 60ка якын хәзинә билгеле. Шул исәптән, Швециянең Һотланд утравында шундый 16 хәзинә табылган. Болгардан кыйммәтле җәнлек тиреләре базарына алып баручы Кама юлы һәм Болгардан Киевкә кадәр сузылган кәрван юлы да Бөек ефәк юлының тармаклары саналган (*Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш. Күрс. хезмәт. С.66, 67).*

Сәяхәтче әл-Мөкаддәси X гасырның икенче яртысында Болгардан Харәземгә җибәрелгән тауарларны атый. Аннан күренгәнчә, чит төбәкләргә кондыз һәм сусар мехлары, куян, кәҗә, сарык, мөгезле эре терлек тиреләре, урман чикләвеге, ау этләре, киптерелгән һәм тозланган балык, бал, табылган мамонт сөякләре, шулай ук киездән, кеш яки сусар тиресеннән тегелгән бүрек-башлыклар, тимер ук очлары, сугыш киеме, мәшһүр, «болгари» исеме белән Көнчыгышта танылган иләнгән кәҗә тиреләре, мәрсин балыгының йөзү куыгыннан эшләнгән келәй һ.б. озатыла. Болгарлар, шулай ук, күрше илләргә чит төбәкләрдән килгән кылычлар, гәрәбә, кайбер кыйммәтле җәнлек (кеш, ас, кара төлке) тиреләре, төньяктан кайтарылган морж мөгезләре дә сатканнар, кәнизәкләр һәм коллар славяннар яшәгән җирләрдән китерелгән.

X гасыр башында Идел-Чулман буйларындагы болгарларда кышкы чорда сала-калада яшәү, җәйге чорда тирмәләрдә сахра буйлап күченеп йөрү кабул ителгән була. Аларның хуҗалык нигезен игенчелек тәшкил иткән. Әйтик, 1024 елгы ачлык вакытында күрше Суздаль кенәзлегеннән славяннар Болгарга килеп, көймәләргә төяп, ашлык алып китәләр: ягъни илдә чит төбәкләргә сатарлык икмәк җитештерелгән. Күрәсең, Хәзәр каһанлыгында яшәгәндәге иген игү тәҗрибәсе яңа урында тагын да киңрәк җәелгәндер. Язма чыганакларда теркәлгән һәм археологлар тапкан бөртекләрдән күренгәнчә, төбәктә күбрәк бодай, тары, борай, шулай ук арпа, солы, борчак, тары, ясмык, сабан арышы иккәннәр. Терлекчелекнең нигезен атлар, мөгезле эре терлек, сарыклар һәм кәҗәләр асрау тәшкил иткән. Кыйммәтле җәнлек, сарык һәм кәҗә тиреләрен эшкәртеп, югары сыйфатлы, чит илләргә сатарлык товар җитештергәннәр *(Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш. Күрс. хезмәт. С. 47).*

Археологлар Болгар әмирлеге җирләрендә 170 шәһәрлек барлыгын ачыкладылар. Проф. Ф.Ш.Хуҗин кырыкка якын шәһәр исемен атый. Башкалалары Болгар һәм

Биләрне дәүләт җитәкчеләре төзегән булса, Сувар, Өшел калалары, Муром һәм Юлау шәһәрлекләре кенәзлек үзәкләре буларак корылган. Алабуга, Казан кебек кирмәннәр дәүләтнең чик буе сак пунктлары итеп төзелгәннәр. Башкалаларның, шәһәр-кирмәннәрнең үсеп чыгуы сәүдә, һөнәрчелек йогынтысында яки хәрби максатларны күздә тоткан дип фаразлана *(Хузин Ф.Ш. Күрс. хезмәт. С. 74-79).*

XI гасыр башында славяннарның һөҗүмнәре ешайгач, башкала Идел буенда урнашкан Болгар шәһәреннән илнең эчке өлешендәге Биләргә күчерелә. Яңа башкала Киев Русендә «Бөек шәһәр» исеме белән таныла. Сәбәбе – Биләрнең ул заман өчен бик зур мәйдан: 620 га җир биләве. Шул исәптән, «тышкы шәһәр»нең мәйданы 490 га булып, ул 10 чакрым озынлыктагы өч кат агач дивар, «эчке шәһәр» (130 га), шулай ук, ике кат вал һәм чокырлар белән әйләндереп алынган була. Археологлар «эчке шәһәр»дә күп генә җәмәгать биналары булганын ачыкладылар: хан сарае, аның янындагы 2300 кв. метр мәйдан биләгән Җәмигъ мәчете, гыйбадәтханә янында кирпечтән салынган ике катлы баш рухани яшәгән йорт; мәчетнең икенче ягында – аксөякләр күмелгән мавзолей. Болар Биләр шәһәренең ислам мәдәнияте үзәге булуы хакында сөйли.

Шәһәр һөнәрчелегендә металл кою һәм эшкәртү мөстәкыйль тармак булып, дәүләтнең матди үсешен һәм икътисади көчен билгеләгән. Тимерне җирле казылмалардан тапсалар, никельне Көньяк Уралдан китергән рудадан аерып алганнар. Болгар тимерчеләре авыл хуҗалыгы, хуҗалык кораллары, кылычлар, ук очлары, хәрби балталар, сөңгеләр җитештергәннәр. Зәркәнчеләр алтыннан һәм көмештән хатын-кыз бизәнү әйберләре эшләү белән дан тотканнар. Аның аерылгысыз өлеше булып, кыйммәтле ташларны эшкәртү торган.

Шәһәрләрдә чүлмәкләр җитештерү, пыяладан савыт-саба эшләү алга киткән. Сөякләрдән кисеп, хуҗалык өчен кирәк-ярак хәстәрләү, кирпеч сугу, йортлар салу шәһәр хуҗалыгының аерылгысыз өлеше булган *(Хузин Ф.Ш. Күрс. хезмәт. С. 80-217, 218-236-254).*

## Болгарда ислам мәдәнияте

Гомумән алганда, Идел-Чулман төбәгендә ислам мәдәнияте үсешен ике яссылыкта карарга мөмкин. *Беренчесе* – Габбасилар хәлифәтендәге һәм башка мөселман илләрендәге мәдәни казанышлар белән танышу, андагы белемнәрне турыдан-туры файдалану һәм шул нигездә болгар ислам мәдәниятен үстерү. Турыдан-туры кабул ителгән казанышларга каен тузы һәм пергамент урынына Урта Азиядән китертелгән кәгазьне киң куллану һәм гарәп имласының рун язуын кысрыклап чыгаруын атарга мөмкин. Бигрәк тә чит илләрдән килгән сәүдәгәрләр гарәп язуының киң таралуына уңай йогынты ясаганнар. Казылма табылдыклар Бохара, Сәмәркандта киң таралган озынча тоткалы балчыктан эшләнгән казан капкачларының Болгар шәһәрләрендә күпләп табылуын, биредә Урта Азиядән килгән сәүдәгәрләр колонияләре булганын дәлилли, археолог Т.А.Хлебникова XII гасыр болгар керамикасы җитештерүдә һәм бизәүдә Урта Азия технологиясе киң кулланылганлыкны раслый: димәк, Болгар шәһәрләрендә Урта Азиядән килгән һөнәрчеләр дә күп булган. *(Кобищанов Ю.М. Күрс. хезмәт. С. 499).* Ислам дөньясында тупланган гамәли белемнәр, бигрәк тә математика, геометрия, физика, астрономия, химия өлкәләрендәге казанышлар шәһәрләр, кирмәннәр һәм җәмәгать биналары төзегәндә, киң кулланылган. Таштан шәһәрләр һәм йортлар баштарак, күрәсең, чит илләрдән килгән архитекторлар һәм осталар тарафыннан корылганнар.

*Икенче юнәлеш*, хаҗ кылудан тыш, белем алырга омтылган болгар егетләренең ислам дин һәм мәгариф үзәкләрендә белем туплап, үзләре күренекле галимнәргә әверелүдән гыйбарәт. Аралашу, фән һәм мәдәният теле булган гарәпне һәм әдәбият теленә әверелгән фарсыны камил белү аларның мөселман цивилизациясендә олы хөрмәткә лаеклы фикер ияләре булып танылуына юл ача.

Кызганычка каршы, Болгар чоры гыйльми-дини мирасыннан бүгенге көнгә

кадәр бик аз күләмдә мәгълүмат килеп җиткән. Мөселман дөньясында үзләрен аерымлау һәм туган илләрен билгеләү өчен Идел-Чулман төбәгендә туып-үскән һәм язмыш җилләре белән ерак илләргә китеп яшәгән интеллектуаллар «әл-Болгари» тәхәллүсе алганнар. Тарихчылар шуның буенча аларның Идел-Чулман төбәгендә туып-үскән галим-голамә икәнен ачыклыйлар. Проф. Г.М.Дәүләтшин күрсәтүенчә, энциклопедист галим Ибраһим Йосыф әл-Болгари Шәрык шәһәрләренең берсендә белем эсти. Болгар шәһәре казые (1006 елда исән була) Әбел Галя Хәмид бине Идрис әл-Болгари Бохара, Нишапур, Нәсеф галимнәреннән сабак алган була. Таҗеддинәл-Хәсәнибне Юныс әл-Болгари исемле табиб Гыйракның Мосул каласында белем ала һәм яши. XI йөзнең икенче яртысы – XII йөзнең беренче яртысында яшәгән башкала казые, «Болгар тарихы» исемле хезмәт язган Йакуб ибне Ногман күренекле Нишапур шәһәре дин галиме Мөхәммәд әл-Җүвәйнинең (1028–1086) шәкерте буларак билгеле Ш.Мәрҗани кулланган чыганакларда «имамнар шәехе»Хуҗа Әхмәд әл-Болгари телгә алына. Тәсаувыф гыйлеме тарафдары булган, Идел-Чулман буйларында үз тарикатен төзегән Хуҗа Әхмәднең «Тарикатьәл-Болгария», «Фәваидәл-Болгария», «Җәмигъ әл-Болгария» исемле хезмәтләре аеруча мәшһүр саналганнар. Солтан Мәхмүд бине Сәбәктәгинәл-Газнәви (967-1030) Әхмәд әл-Болгарины үзенең остазы, шәехе дип таныган. *(Дәүләтшин Г.М. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан, 1999. 260 б.).*

Безнең көннәргә килеп ирешкән хезмәтләрдән, Сөләйман бине Даудәс-Саксини-Суваринының күләмле «Зөһрәтәр-рийазвәнөзхәтәл-колубәл-мираз» («Авыру йөрәкләрне (калебләрне) сөендерүче бакча чәчәге») (XII гасыр) китабы Болгарда исламның, аның йола-гадәтләренең, ритуалларының, иманның, әхлакның ничек аңлатылуын күрсәтә, үз халкына мөселман булып яшәү нигезләрен шәрехли. Яки мәшһүр болгар табибы Таҗеддинәл-Хәсәнибне Юныс әл-Болгари 1220-1221 елларда әйтеп яздырган «Әт-тирйакәл-кәбир» (Зур тирйак) исемле хезмәт төрле авырулардан дәвалау яки профилактика өчен универсаль дарулар ясау технологиясе белән таныштыра. Бу ике трактат болгар галимнәренең һәм рухани, һәм төгәл-табигать фәннәреннән алга киткәнлеге, мөселман цивилизациясе белән бер дәрәҗәдә хезмәтләр язуы турында сөйли.

Болгар мәдәнияте ирешкән иң олы казанышлар арасында Кол Галинең 1233 елның 12 маенда (630 ел, рәҗәб аеның 30ында) язып тәмамлаган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы аерым бер урын тота. Бу ядкарь татар тарихының барлык дәверләрен буйлап, XX гасыр башына кадәр халкыбыз өчен милли әдәби, гыйльми-фәлсәфи, дини-мәдәни чыганак, рухи идеал булып кала. Аның язылу факты татар язма теленең, мәдәниятенең гаять зур үсешкә ирешү күрсәткече, дип әйтә алабыз.

Йомгаклап, шуны әйтергә кирәк: ислам динен кабул итү ярымкүчмә тормыш алып барган болгарларга сәүдә һәм мәдәни элемтәләр аша иң алдынгы һәм яңа технологияләр белән танышу һәм алгарышны тәэмин иткән кыйммәтле мөһим социаль мәгълүмат алу мөмкинлеге тудыра. Идел-Урал төбәгендә Болгар дәүләте (әмирлеге) оешу шулай ук ислам тәгълиматы йогынтысында бара. Шул ук вакытта дәүләт структуралары да төрле кабиләләрне бер дини идеология тирәсендә берләштерү һәм күндәмлек тәрбияләү максатында яңа динне тарату юнәлешендә эшлиләр. Бу өлкәдә мөһим рольне эре ислам шәһәрләрендәге фән үзәкләре һәм уку йортлары, халыкара икътисади элемтәләр һәм мөселман илләреннән килгән сәүдәгәрләр, голамәләр, һөнәрчеләр һ.б. һөнәр ияләре уйный. Ислам дине XI – XII гасыр болгар иҗтимагый аңында һәм тормышында сыйфат үзгәрешләренә нигез булып, зур бер тарихи-мәдәни алгарышка, яңарышка китерә.

1236 елда Болгар әмирлеге монгол-татарлар тарафыннан тар-мар ителгәч тә, дини-мәдәни мирас югалмый, Идел-Чулман буйлары Алтын Урда дәүләтендә дә ислам төбәге булып кала.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*

*Әхмәт Гаделнең тууына – 80 ел*

# МИЛЛӘТ ГАМЕ АНЫ ШАГЫЙРЬ ИТКӘН



Шагыйрь, язучы-публицист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әхмәт Гаделнең тууына 80 ел тулуны билгеләп үтү өчен без Татарстан радиосы фондында саклана торган бер язмага мөрәҗәгать итәрбез. 2012 елда, димәк, моннан төгәл ун ел элек, үзенең 70 яшьлек юбилеен үткәреп йөргән көннәрдә, Әхмәт Гадел безнең студиягә килеп, тапшыруда катнашкан иде. Әлеге язма Татарстан радиосы фондында кадерләп саклана. Шагыйрь шул ук елның 13 ноябрендә вафат булды, димәк, магнитофон тасмасына языльп калган иң соңгы чыгышы булуы ихтимал.


«Татар энциклопедия»сендә аның турында мондый мәгълүмат бирелгән: Әхмәт Һади улы Гаязов – Әхмәт Гадел – шагыйрь, кинодраматург. 1977 елда Мәскәүдә Максим Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлый. Гомер юлында газета хәбәрчесе, мәктәп укытучысы, Татарстанның телевидение һәм радиотапшырулар комитетында тәрҗемәче, Республика халык иҗаты йортында һәм Мәдәният министрлыгында – методист, СССР әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры була, Татарстан Кинематография дәүләт комитетында хезмәт куя, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары булып эшли. Әсәрләре 1960 нчы елларда басыла башлый. «Күгәрченнәр», «Чам», «Көмеш кылган җыры», «Яшьлегем былбыллары», «Дәрт» дип исемләнгән шигырь китаплары бар. Аның сценарийлары буенча һәм автордашлыгында 50дән артык документаль фильм һәм балалар өчен мультфильмнар төшерелгән. Ашхабад һәм Мәскәүдә үткәрелгән бөтенсоюз кинофестивальләре лауреаты.

Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган язмада исә шагыйрьнең язмыш юллары да, иҗаты да, күңел дөньясы да ачык чагылыш таба. Әхмәт Гадел – бик тә моңлы кеше иде. Аның көен дә, шигырен дә үзе иҗат иткән берничә җыры да бар. Шигырьләрен күп кенә композиторлар көйгә салды. Әңгәмә әнә шундый җырлар белән чиратлашып бара.

Моннан ун ел элек Әхмәт абыебызның тормыш юлдашы Зөлфия ханым аны радиога озаткан чакта, артыгын сөйләмәскә, кискен фикерләр әйтмәскә кушып җибәргән. Шул туры сүзлелегең аркасында кыенлыкны шактый күрдең, олыгаеп барган көннәрдә булса да тынычлап яшик, дип әйтергә теләве булгандыр инде. Әхмәт абый Зөлфия ханымга биргән вәгъдәсен үтәгәнме, үзендә кискен темаларга кагылмаслык көч тапканмы? Боларның барысы да язманы тыңлагач аңлашылыр. Тыңларбыз да шагыйрьнең якты рухын искә алырбыз.

*Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.*

# БЕЗ ЯРАТМЫЙ, ҖИРДӘ КЕМ ЯРАТСЫН?!



«Безнең шигърияттә иң үзенчәлекле, кабатланмас шагыйрьләрнең берсе, һичшиксез, Кадыйр Сибгатуллин. Ул телне гаҗәеп дәрәҗәдә сизгер тойган, тел белән фикернең-аңның диалектик бәйләнештә булуын үз иҗатында кат-кат раслый килгән шагыйрь иде. Тормышның кайчак гап-гади, артык гадәти булып тоелган вакыйга-күренешләреннән дә көтелмәгән сурәтләр таба алган, көтелмәгән гомумиләштерүләр һәм нәтиҗәләр ясый алган шагыйрь иде ул», дип язган иде аның турында шагыйрь Нияз Акмал.

Кадыйр Сибгатуллин үзе исән чакта да аның шигырьләре, шигырьләрендәге аерым гыйбарәләр халык телендә булды, китаплары бик күпләрнең куен кесәсендә йөрде. Инде менә туына 80 ел тулган шушы көндә һич икеләнмичә әйтә алабыз: Кадыйр Сибгатуллин безнең рухи дөньябызда әле дә зур урын алып тора. Шөкер, Кадыйр абыйның бәхетенә дип туган хатыны Флёра Хамматова, галим һәм язучы Факил Сафин, шагыйрь Вазыйх Фатыйхов кебек аның иҗатын халыкка ирештереп, әһәмиятен аңлатып яшәүче фидакарьләребез байтак. Бу эшкә Татарстан радиосы да ару гына өлеш кертеп килә. Филология фәннәре докторы Илдар Низамов «Тел күрке – сүз» тапшыруында «Кадыйр Сибгатуллинның шигъри каләме һәм аның тел белән эш итү осталыгы» дигән темага дәресләр циклы алып барды. Нәфис сүз осталары катнашында шагыйрьнең шигырьләреннән әдәби-музыкаль композицияләр төзелде. Күренекле актёр Илдар Хәйруллин башкаруында әдипнең «Дустым Мансур» дигән хикәясе әледән-әле эфирга бирелә. Соңгы елларда радио фондында аның шигырьләренә иҗат ителгән җырлар киштәсе дә шактый ук саллы була бара.

Укучылар игътибарына хәзер тәкъдим ителә торган аудиоязмага килсәк, без аны Кадыйр Сибгатуллинның үз тавышы белән башлап киттек (әле әдәбиятка тәүге адымнарын ясаган чакларында, 1960 нчы елларда, ул радио студиясендә берничә шигырен яздырган булган). Аннары Нияз Акмалның Кадыйр Сибгатуллин иҗатына кагылышлы чыгышыннан фрагментлар бирелә. Язма 2012 елда шагыйрьнең туына 70 ел тулуга багышланган тапшыру белән тәмамлана. Ул Чаллыда яшәп иҗат итүче шагыйрә Әлфия Ситдикова тарафыннан әзерләнгән. Тапшыруда Фәния Хамматова, Факил Сафин, Чаллы шәһәренең Муса Җәлил исемендәге Үзәк китапханәсенең баш китапханәчесе Роза Хәмидуллина белән әңгәмәләр урын алган.

*Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.*

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

Ictimaği-mədəni tormışıbızdan

# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ҮТКӘН ЕЛГА – ЙОМГАК, КИЛӘЧӘККӘ – БУРЫЧЛАР

«Казан ЭКСПО» Халыкара күргәзмә үзәгенең Илһам Шакиров исемендәге Концерт залында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы коллегиясенең киңәйтелгән утырышы булып узды. Анда министрлыкның 2021 елда эшчәнлегенә йомгак ясалды, 2022 елга бурычлар билгеләнде. Утырышта катнашучыларны Милләт эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе Игорь Баринов, РФ Президентының иҗтимагый проектлар буенча идарә башлыгы урынбасары Александр Журавский сәламләде. Чарада РФ мәдәният министры Ольга Любимова котлавы да ирештерелде. Игорь Баринов «Ключевое слово» Бөтенроссия иҗтимагый бәйгесенең «Иң яхшы фәнни проект» номинациясендә «Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты буенча материаллар» дип аталган хезмәтнең (проект җитәкчесе Марсель Ибраһимов) җиңү яулавын игълан итте, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары Олег Хисамовка Диплом тапшырды. Утырышта ТР мәдәният министры Ирада Әюпова доклад белән чыкты. Ул Туфан Миңнуллинның ТР Дәүләт Советы сессиясендә ясаган соңгы чыгышында ТР Милли китапханәсенә, Чаллы, Түбән Кама дәүләт театрларына яңа биналар кирәклеге турында әйтүен искә төшерде һәм бу бурычларның барысының да үтәлүен әйтте. Доклад буенча фикер алышуларда РФ Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының социаль әһәмиятле товарлар җитештерүне үстерү департаменты директоры урынбасары Лилия Нургатина (ВКС режимында), КФУның өлкән укытучысы Виталий Абрамов, «Акведук» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять директоры Асия Гобәйдуллина һ.б. чыгыш ясады. Утырышта ТР Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева катнашты. Ул үзенең чыгышында министрлык алдына яңа бурычлар куйды. Узган ел республикабызда «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы» буларак тарихка кереп калды. Кызганыч ки, коллегия утырышында елга йомгак ясаганда, барлык чыгышлар да фәкать рус телендә генә яңгырады. Чарада бер төркем мәдәният хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр бирү турында дипломнар, дәүләт бүләкләре тапшырылды. Коллегия утырышында ТР Президенты Аппараты Җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, ТР Муниципаль берәмлекләр советы ассоциациясе рәисе Экъзам Гобәйдуллин катнашты.

## ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышында 2022 елда ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар тәкъдим ителде. Идарәгә остаханәләрнең берләштерелгән утырышында каралган 6 кандидат кертелгән иде. Аларга берлекнең Чаллы бүлегеннән тагын икәү өстәлде. Барысы 8 язучы. Болар – Марат Әмирханов, Фәүзия Бәйрәмова, Рәшит Бәшәр, Флёра Гыйззәтуллина, Рәфкать Кәрами, Хәмит Латыйп, Ләбиб Лерон, Айдар Хәлим. Идарә әгъзаларының яшерен тавыш бирүе нәтиҗәсендә шагыйрә Флёра Гыйззәтуллина белән шагыйрь, прозаик, драматург Ләбиб Лерон Татарстан Язучылар берлеге идарәсеннән Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителде. Сабадан Илмира Гыймаева белән Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районыннан Рөстәм Арифуллин Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде. Газинур Морат «ТРның халык шагыйре» дигән шәрәфле исеменә тәкъдим ителде. Утырышны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ ТАРИХ

Татарстан Язучылар берлегендә «Татар әдәбиятында тарихның чагылышы» дигән темага «түгәрәк өстәл» утырышы узды. Ул Тарих институты һәм Татарстан Язучылар берлеге инициативасы белән оештырылды. Утырышта татар тарихчылары Дамир Исхаков, Илнур Миргалимов, Нурулла Гариф, тарихи темага язучылар Ркаил Зәйдулла, Рабит Батулла, Фәүзия Бәйрәмова, Вахит Имамов, Тәлгат Галиуллин, Фәрит Яхин һ.б. чыгыш ясады. Татар язучылары һәм тарихчылар киләчәктә активрак хезмәттәшлек итү турында сүз куешты. Чарада Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Рамил Төхфәтуллин, режиссёр, «Татфильм» киностудиясе җитәкчесе Илдар Ягъфәров катнашты.

## ЗӘКИ НУРИНЫҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Чүпрәледә күренекле шагыйрь, узган гасырның 70-80 нче елларында Татарстан Язучылар берлеге рәисе, «Казан утлары» журна-

лының баш мөхәррире булган Зәки Нуриның тууына 100 ел тулуны зурлап билгеләп үттеләр. Искә алу чараларында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, аның урынбасары Рифат Җамал, язучылар Ринат Мөхәммәдиев, Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Хәбир Ибраһимов, Рахман Шәфигуллин, Вакыйф Нуриев, Шәфыйк Иматдинов, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәүзия Солтан, Рәсимә Гарифуллина һ.б. катнашты. Кунакларны Чүпрәле районы башлыгы Марат Гаффаров сәламләде. Ул көнне Зәки Нуриның район үзәгендәге бюстына чәчәкләр салдылар. Аннары район Мәдәният йортында әдәби-музыкаль кичә булды. Анда Зәки Нури исемендәге премияләр тапшырылды. Бүләкләнүчеләр арасында өлкәннәр белән бергә мәктәптә укучы яшь иҗатчылар да бар иде.

## ШӘЙХИ МАННУР ИСТӘЛЕГЕНӘ

Мамадыш районында күренекле татар язучысы Шәйхи Маннур истәлегенә багышланган чаралар булып узды һәм әдип исемендәге премияләр тапшырылды. Быел әлеге премиягә «Мин дә китәрмен әле» (2019) җыентыгы өчен Рүзәл Мөхәммәтшин, күпьеллык әдәби эшчәнлеге һәм «Мои мечты», «Мне снится край любимый» (2020) китаплары өчен Владимир Калашников лаек булдылар.

## «ГОМЕР ЧАЛЫМНАРЫ»

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында «Гомер чалымнары» дип аталган әдәби очрашулар циклыннан беренче кичә уздырылды. Анда Татарстанның халык шагыйре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт, М.Җәлил исемендәге Республика премияләре лауреаты, ТР Дәүләт Советы депутаты Ркаил Зәйдулла үзенең каләмдәшләре, иҗатын яратучылар белән очрашты. Кичәдә ул үзенең соңгы вакытта язган шигырьләрен укыды, сорауларга җаваплар бирде.

## «ТАТМЕДИА» КЛУБЫ»

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте Балтач районы Норма авылы китапханәсе белән бергә Татарстанның халык язучысы Нәбирә Гыйматдинова белән очрашу уздырды. Бу – «ТАТМЕДИА» клубы» проекты кысаларында оештырылган тәүге чара. Очрашу Нәбирә ханымның әсәрләреннән өзекләр уку, әдибәнең сорауларга җаваплар бирүе, җыр-музыка белән үрелеп барды. Кичәнең икенче өлешендә тамашачылар «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте, аның эш-гамәлләре белән таныштылар.

## «БЕЗ – 41НЧЕ ЕЛ БАЛАЛАРЫ» ФИЛЬМЫ

Казандагы «Мир» кинотеатрында Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – 41нче ел балалары» әсәре буенча төшерелгән фильм (продюсеры Миләүшә Айтуганова, сценарий авторы Әлфирә Мәһдиева, режиссёры Әмир Галиәскаров) күрсәтелде. Соңыннан фильм авторлары һәм анда катнашучылар белән очрашу булды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге һәм актив иҗтимагый хезмәте өчен «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе **Вәлиев Разил Исмәгыйль улы** «Дуслык» ордены белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге һәм татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен, шагыйрь **Гатауллин Рәдиф Кәшфулла улы (Рәдиф Гаташ)** «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены медале белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге һәм татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен **Зәйдуллин Ркаил Рафаил улы (Ркаил Зәйдулла)** «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены медале белән бүләкләнде.

2022 елның 6 гыйнварында 74нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә, прозаик **Фәридә Атилла кызы Рәсүлева** вафат булды.

Мәрхүмәнең җәсәде Артём шәһәре зиратында җирләнде.

2022 елның 18 гыйнварында 62 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, прозаик, журналист, нашир **Заһид Борис улы Мәхмүдов (Заһид Мәхмүди)** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Кукмара районы, Манзарас авылы зиратында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Ф.ГИМАЛТДИНОВА «Буа», рассказы Р.ГАЛИУЛЛИНА; поэма Р.ХАРИСА, стихи Р.ШАРИПОВА, И.БИЕКТАУЛЫ, Л.ФАТХИ.*
*Литературный конкурс «Майдан – для батыров»: рассказ Х.ИСМАГИЛОВА «Первый Сабантуй».*
*«Встречая юбилей»: фотоархив.*
*«К 100-летию журнала «Казан утлары»: статья А.ХАМЗИНА.*
*«Казан утлары» – в моей судьбе»: статья Ф.ГАЛИМУЛЛИНА.*
*«Литературная критика»: статья Ф.ГАЛИМУЛЛИНА, посвящённая 65-летию Р.Карами; статья Р.РАХМАНИ, посвящённая 65-летию Р.Курбана; статья А.ШАМСУТОВОЙ, посвящённая 65-летию Г.Гильмана.*
*«Бриллианты эпохи»: статья З.МУХАМЕТШИНА; стихи Б.УРМАНЧЕ.*
*«Литература родственных народов»: стихи Б.АДЖИЕВА в переводе Р.КУРБАНА.*
*«Татарская литература – в переводе»: статья А.СИБГАТУЛЛИНОЙ.*
*«Обзор книги»: статья Г.ГАЙНУЛЛИНОЙ.*
*«Творчество читателей»: стихи М.ШАРАПОВА.*
*«1100 лет со дня принятия ислама Волжской Булгарией»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 80-летию А.Гаделя и 80-летию К.Сибгатуллина.*
*Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: набережная Казанки. Фото Р.ГАЛИ; журналист, писатель Фирдус Гималтдинов.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by F.GIMALTDINOV «Bua», stories by R.GALIULLIN; poem by R.HARIS, poems by R.SHARIPOV, I.BIEKTAULY, L.FATHI.*
*Literary contest «Maidan is for Batyrs»: story by H.ISMAGILEV «The First Sabantuy».*
*«Meeting the anniversary»: photo archive.*
*«To the 100th anniversary of the magazine «Kazan Utlary»: article by A.KHAMZIN.*
*«Kazan Utlary» is my destiny»: article by F.GALIMULLIN.*
*«Literary criticism»: article by F.GALIMULLIN dedicated to the 65th anniversary of R.Karami; article by R.RAHMANI dedicated to the 65th anniversary of R.Kurban; article by A.SHAMSUTOVA dedicated to the 65th anniversary of G.Gilman.*
*«Diamonds of the Epoch»: article by Z.MUKHAMETSHIN; poems by B.URMANCHE.*
*«Literature of kindred peoples»: poems by B.ADZHIEV translated by R.KURBAN.*
*«Tatar literature in translation»: article by A.SIBGATULLINA.*
*«Book review»: article by G.GAINULLINA.*
*«Creativity of readers»: poems by M.SHARAPOV.*
*«1100 years since the adoption of Islam by Volga Bulgaria»: article by I.ZAGIDULLIN.*
*«Priceless voices»: articles dedicated to the 80th anniversary of A.Gadel and the 80th anniversary of K.Sibgatullin.*
*The column is led by N.AKMAL.*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Kazanka Embankment. Photo by R.GALI; journalist, writer Firdus Gimaltdinov.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казансуның яр буе.
*Р.Гали фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* журналист, язучы Фирдүс Гыймалтдинов.